Казан утлары

4
АПРЕЛЬ-1975



Яңа йортлар күтәрелә.

Э. ЗАРИПОВ рәсеме.

Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

4
АПРЕЛЬ
1975

КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Бу санда

Ф. ТАБЕЕВ. Бишьеллыкның алгы сызыгында . . 3
Г. РӘХИМ. Тамыр. Шигырьләр 11
Э. КАСЫЙМОВ. «Зинһар, рәнҗемә!» Этюдлар . . 16
М. ГАЗИЗОВ. Авырлык үзәге. Шигырьләр . . . 26
Р. ХИСАМИЕВ. Уҗым булып калка. Шигырьләр . 31
С. ШӘРИПОВА. Акчарлактай ак самолет. Шигырьләр 32

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы 33
Г. ПАУШКИН. Чаллы сәхифәләре 36
Р. ВӘЛИЕВ. Таяну ноктасы 49

М. РАФИКОВКА 50 ЯШЬ

М. РАФИКОВ. Су буенда бер урам. Авыл язмалары 66

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 30 ЕЛ

Б. БООТУР. Пушкин таулары итәгендә 107
Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Фронт газеталары редакциясендә 117
С. ШАКИР. Утлы еллар дәфтәреннән 127
А. АЙНЕТДИНОВ. Юллар батырлыкка чакырды . 132
Ш. ЗӘЙНИ. Фронтта очрашулар. Истәлек . . . 138
Х. КАМАЛОВ. Безне намус утка кертте 143

Г. ТУКАЙНЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫНА

Шагыйрьнең бөеклеге 145
Х. ХӨСНУЛЛИН. Халкы җиккән атта. Шигырь . . 147
В. ИСХАКОВ. Тукай белән очрашу 148

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Г. ХАЛИТ. Иҗат методы һәм стиль мәсьәләләре . **151**
З. МӘҖИТОВ. Һәр шагыйрьнең үз тавышы . . . **162**

КИТАП КҮЗӘТҮ

КамАЗ китаплары **172**

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

А. БУЛАНОВ. Электр баганасы. Шигырьләр . . **183**
Ж. ДӘРЗАМАНОВ. Өйләнеп бер ел торгач. Шигырь **183**
Бервакыт шулай була **184**

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары **187**

Н. ЖИҺАНОВ, Р. ХАРИСОВ. КамАЗдашлар. Җыр . **192**

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләймановa, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 3/I-1975 ел. Басарга кул куелды 24/II-1975 ел. ПФ 05041. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91744 экз. Заказ Я-1. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1975 ел.

Фикрәт Табеев,

КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре, КПСС Үзәк Комитеты члены

БИШЬЕЛЛЫКНЫҢ АЛГЫ СЫЗЫГЫНДА

Кама автомобиль гиганты төзелеше КПСС Үзәк Комитетының, Совет хөкүмәтенең даими игътибар үзәгендә тора. Тугызынчы бишьеллыкның бу зур төзелеше барышы турында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре Леонид Ильич Брежнев үзе зур кайгыртучанлык күрсәтә. Төзелешнең һәр этабында төзүчеләр коллективын нигыту, алар алдында торган гаять зур бурычларны хәл итүдә Политбюро члены, КПСС Үзәк Комитеты секретаре А. П. Кириленко безгә һәр вакыт зур ярдәм күрсәтә. Төзелеш башланган чорларда Татарстанга, шулай ук Чаллыга һәм Түбән Камага Политбюро члены, СССР Министрлар Советы Председателе А. Н. Косыгин килеп китте.

КамАЗдагы эшләрне оештыру буенча СССР Министрлар Советы Председателе урынбасарлары И. Т. Новиков, В. Э. Дымшиц һәм В. Н. Новиков киптәшләр дә зур эш башкардылар һәм башкаралар.

Без шулай ук РСФСР хөкүмәтенең, КПСС Үзәк Комитеты машина төзү бүлегенең, ВЛКСМ Үзәк Комитетының, СССР Госснабының, СССР Госстроеның, СССР Энергетика министрлыгының, СССР Автомобиль промышленносте министрлыгының, СССР Монтаж һәм махсус төзелеш министрлыгының, СССР Транспорт төзелеше министрлыгының, СССР Нефть һәм газ төзелеше министрлыгының, СССР Элемтә министрлыгының һәм СССРның, РСФСРның башка министрлыкларының, ведомстволарының даими ярдәмендә эш алып барабыз. Кама автомобиль заводлары комплексын төзү буенча төзелеш подразделениеләренең һәм автозаводның партия оешмалары да, шәһәр һәм өлкә партия оешмалары активы да, ТАССР Министрлар Советы, Татарстан министрлыклары һәм ведомстволары да күп кырлы һәм киренке эш алып бара. КамАЗ төзелешен тизләтү буенча партиябез һәм хөкүмәтебез күп кенә мөһим документлар, карарлар кабул итте, аларның һәрбере җирле партия, совет, хуҗалык оешмаларында алдынгы эшчеләр, бригадирлар катнашы белән җентекләп тикшерелде, алдагы эш өчен конкрет бурычлар билгеләнде. Шулар нәтиҗәсендә производствога алдынгы технологик алымнар кертелде, хезмәт һәм көнкүреш шартлары яхшырды.

Бишьеллыкның өченче, хәлиткеч һәм дүртенче, билгеләүче елында завод корпусларының түбәләрен ябу, аларга җылылык үткәрү һ. б. мөһим эшләр башкарылу төзелешнең яңа этабын башларга мөмкинлек бирде — җиһазлар монтажлау һәм корпусларны моңа өзерләү эшләре башланды һәм алар зур темплар белән дәвам итә. Корпусларга җылылык үткәрү — төзелешнең төп этабында зур комплексны эшләр башкарып чыгу дигән сүз. Бу исә ТЭЦны төзеп бетерү, аның беренче агрегатларын, куәтле җылылык трассаларын һәм сууткәргечләрне, бик күп кондиционер-

ларны монтажлау, энергетика подстанцияләрен кору һәм электр үткәргечләр төзү, чистарту корылмалары төзү белән бәйле иде. Эш барышында алынган социалистик йөкләмәләр уңышлы үтәлде. Хөкүмәт заданиеләрен һәм йөкләмәләрне уңышлы үтәүләре өчен 526 төзелеш алдынгылары һәм аларга ярдәм сферасында эшләүче хезмәткәрләр СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде.

КамАЗда эшләр киң планда башкарыла һәм алар барысы да югары темп белән, зур колач белән эшләнә. КамАЗны чыннан да бөтен ил төзи.

КПСС Үзәк Комитетының 1973 ел декабрь Пленумы документлары, партиябез Үзәк Комитетының совет халкына мөрәҗәгате алда торган гаять зур бурычларны хәл итүдә мөһим политик вакыйга булды, 1974 ел планнарын тормышка ашыруда безнең эшебездә программа булып хезмәт итте.

КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы карарында СССР Автомобиль промышленносте министрлыгына, СССР Энергетика министрлыгына, СССР Монтаж һәм махсус төзелеш министрлыгына, СССР Нефть һәм газ төзелеше министрлыгына, 1974—1976 елларда комплекс объектларында төзү-монтаж эшләрен гамәлгә ашырып, 1976 елда комплексның беренче чиратын эшләтә башлау бурычы куела. Шул ук министрлыкларга Кама автомобиль заводлары комплексы төзелешендә төзү-монтаж эшләрен оештыруны яхшырту, төзелеш механизмнарын һәм транспортны эффектлы файдалану, еллык заданиеләрне арттырып үтәү максаты белән эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә аккордлы түләүне киң куллану тәкъдим ителә. Карарда күрсәтелгәнчә, 1975 елда КамАЗ һәм Чаллыда яңа шәһәр төзелеше буенча төзү-монтаж эшләре 215 миллион сумлык күләмдә башкарылырга, 420 мең квадрат метр торак мәйданы, 4 мәктәп, 10 балалар бакчасы, кинотеатр, культура сарае, спорт комплексы, музыка мәктәбе, бала табу йорты, больница, ашханәләр, гостиница, кибетләр һәм башка объектлар файдалануга тапшырылырга тиеш.

КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы РСФСР, Украина, Үзбәкстан, Әзербәйҗан Министрлар Советларына, союз күләмендәге күп министрлыкларга, хезмәт ияләренең Мәскәү өлкә һәм шәһәр башкарма комитетларына 1974—1975 елларда КамАЗ төзүчеләрен паркет, кирпеч, гранит, мәрмәр, агачтан, тимер-бетоннан ясалган әйберләр һ. б. төзү материаллары белән тәэмин итүне йөкли.

Бер Мәскәү шәһәре генә 1975 елда Чаллыда 100 мең квадрат метр торак мәйданы җитештерергә тиеш. Шулай ук карарда 1974—1975 еллар дәвамында КамАЗга 11 мең эшче, 3 мең производство-техник училище тәмамлаган белгечләр җибәрү күздә тотыла. КПСС Үзәк Комитеты ВЛКСМ Үзәк Комитетының комсомол чакыруы буенча өстәмә рәвештә тагын 4 мең ярым яшь төзүчеләрне КамАЗга җибәрү инициативасын яхшы дип тапты. Союз күләмендәге махсус министрлыклар 1976 елда Кама автомобиль комплексында авыр йөк ташу машиналары җитештерү буенча автомат системалар һәм аларны идарә итү аппаратларын сафка кертергә тиешләр. Шуңа бәйләнештәге күп кенә эшләр әйтелгән срокта — 1975 ел дәвамында, КамАЗның беренче чиратын сафка бастырганчы — эретеп ябыштыру, күтәрү-транспорт һәм стандарт булмаган җиһазлар белән тәэмин ителергә тиешләр. Алар барысы да автомат идарәгә корылган булачак.

КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы автогигант чыгарачак автомобильләргә ремонт ясау өчен, шулай ук аларга кирәк булачак запас частьлар эшләү өчен Чаллы районында 1976—1981 елларда үзәкләштерелгән махсус завод салырга рөхсәт бирде.

КПСС Үзәк Комитетының һәм СССР Министрлар Советының югарыда телгә алынган Карарлары — Кама автомобиль комплексын сафка бастыруның беренче чиратын тормышка ашыру буенча гаять мөһим директив документлар. Безнең алда торган бурычлар һәм мәсьәләләр, бу документлар яктылыгында, көн кебек ачык, ә аларны гамәлгә ашыру, нәтиҗәле итеп башкарып чыгу исә безгә, бездәге оешмалар һәм ведомстволарның киренке эшенә бәйле.

Кама автогигантын төзүгә киткән биш ел вакытны кабат күздән кичерәсе килә. Нәрсәләр эшләнде, партиябез һәм хөкүмәтебез наказына нинди эш нәтиҗәләре белән җавап бирдек? Татарстан җирендә моңа кадәр дөньяда булмаган шундый зур заводлар комплексы салу буенча шул чор эчендә ниләр башкардык?

Алар — чиксез киң горизонт. Аны күзаллау өчен җирдән торып та, 350 метрлы ТЭЦ моржасы биеклегеннән дә, хәтта югарырактан да карарга кирәк. Монда «подразделениеләр», «фронт» һ. б. кебек хәрби терминнар юкка гына гадәти булып әверелмәде. Монда чын-чынлап фронт, фронтның алгы сызыгы! Ләкин тыныч хезмәт фронты. Мондагы 2 мең бригада, йөзләрчә подразделениеләр арасында да, фронттагы кебек, командование билгеләгән рубеждан шактый алга ыргылучылар да, арттарак калучылар да бар. Шунысы күңелле: биредә дә һәр бригада, һәр подразделение алдынгылар белән тигезләшергә бөтен көчен куя.

КПССның Чаллы шәһәр комитеты, парткомнар, төзелеш объектларындагы һәм заводлардагы партия оешмалары, комсомол һәм профсоюз оешмалары, совет һәм хуҗалык оешмалары җитәкчеләре, барлык коммунистлар, бригадирлар, комсомол активистлары, барлык алдынгы төзүчеләр һәм эшчеләр, сәүдә-көнкүреш хезмәткәрләре — барысы, барысы да бер максатка: үз бурычларын намус белән, югары сыйфатлы итеп башкарырга омтылалар. КамАЗда һәр звено, һәр бригада, һәр подразделение — алгы сызыкта. КамАЗ төзелә башлаган көннән бирле безнең оештыру һәм политик эшчәнлегебезнең эчтәлеге төзүчеләр коллективының үсүен, берегүен, эшчәнлеген тәэмин итүгә, төзү объектларында эшләрнең киң колач белән баруына ирешүгә юнәлдерелде. Коллективларның, төзү-монтаж подразделениеләренең формалашуы һәм аякка басуы, гомумән, төзелеш белән идарә итү, җитәкче һәм инженер-техник кадрларны, партия, совет, профсоюз һәм комсомол кадрларын үз эшләрен оптималь башкарырлык урыннарга урнаштыру мәсьәләләрен гамәлгә ашыру беренче планда булды. Партия өлкә комитеты, республикабыз Министрлар Советы, партиянең Чаллы шәһәр комитеты һәм район башкарма комитеты сәүдә, җәмәгать тукланыу, эшчеләрне вахтага йөртү транспорты, торак һәм культура-көнкүреш объектларын төзү эшләрен даими игътибар үзәгендә тоталар. 1970 ел башында «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең кечкенә генә төзүчеләр отряды капиталь йортлар итеп 18 мең 700 квадрат метр торак мәйданы төзеде. 5 меңнән артык төзүчеләр якын-тирәдәге авылларда колхозчылар һәм совхоз эшчеләре өйләренә квартирага урнаштырылды. Күчмә өйләрдән һәм вагоннардан төзүчеләр өчен вакытлы поселоклар оештырылды. 1970 һәм 1971 елларда — төзелеш эшләре барышының кызу моментларында — республикабыз авылларыннан 3 меңгә якын балта осталары КамАЗның мөһим объектларында эшләде. Торак йортлары төзү эшенә Казан, Әлмәт, Түбән Кама төзүчеләре дә тартылды. 1971 елда мәскәүләләр һәм ленинградлылар Яңа шәһәрдә беренче йортларны салу эшен башлап җибәрделәр.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты инициативасы белән КамАЗга «Дуслык» төзү отрядлары килә башлады. Җәй көннәрендә автогигант төзелешендә һәр елны меңнәрчә студентлар төзү отрядлары эшли. Республика комсомол оешмасы системалы рәвештә Казан предприятиеләре эшчеләреннән төзү отрядлары җибәреп торды.

Инженерлык эшләре өлкәсендә КамАЗ бораулап коелган субайлардан нигезләр кору, түбә ябу эшләрен конвейер ысулы белән башкару буенча тәҗрибәле белгечләрне үзенә тартты. Аларның осталыгы җир эшләре күләмен шактый киметүгә, автозавод төзү темпларын тизләтүгә китерде.

Партия һәм хөкүмәтебез КамАЗ төзүчеләрен механизмнар, машиналар, автотранспорт белән бик юмарт тәэмин итте. СССР Энергетика министрлыгы төзелешне җыелма тимер-бетон конструкцияләр, инерт материаллар белән киң масштабта комплектацияләүне оештырды. СССР Монтаж һәм махсус төзү министрлыгы КамАЗны металлконструкцияләр белән тәэмин итте. Элемтә министрлыгы да күп эшләр башкарды. СССР Госснабы төзелешне металл, цемент, сантехника һәм башка әйберләр белән тәэмин итүне үз өстенә алды. Госснаб каршында Камснаб органы оештырылды һәм ул үзенең бурычын аклады, материаль-техник тәэминат иң прогрессив формалы эш алып бара.

1971 елның март ахырында КПССның XXIV съезды илебезнең халык хуҗалыгын үстерү буенча тугызынчы бишьеллык план Директиваларын раслады. Анда болай дип язылган: «Татарстан АССРда йөк автомобильләре җитештерү буенча заводлар комплексы һәм якын-тирә районнарда аның ярдәмчел предприятиеләрен булдырырга». Бу вакытта инде төзүчеләрнең һәм монтажчыларның 30 меңле отряды (аларның ун меңе Татарстан хезмәт ияләре вәкилләре) нәтиҗәле, зур эшләр башкара иде.

Коллектив үсү белән бергә төзүчеләрнең һәм монтажчыларның партия оешмалары да үсте, шәһәр партия оешмасы нығыды. 1970 ел дәвамында 72,3 миллион сумлык төзү-монтаж эшләре башкарылды, 100,7 мең квадрат метр торак мәйданы, социаль-культура һәм көнкүреш объектлары файдалануга тапшырылды. «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе коллективы автозаводның промышленность объектларын, ТЭЦ, төзү базалары, төзү индустриясе базасын салу эшләрен киң җәелдереп җибәрде. Төзү эшләре көннән-көн киңрәк колач ала барды. 1971 елның икенче яртысында инде һәр көн саен бер миллион сумлык төзү-монтаж эшләре башкарыла иде. Төзүчеләрнең күп милләтле семьясы үскәннән-үсте. Төзүчеләр бирегә илебезнең төрле республикаларыннан һәм өлкәләреннән килделәр. Аларны КамАЗга романтика гына чакырмады, ә КПССның XXIV съезды карарларын тормышка ашыруга үз өлешләрен кертү омтылышы алып килде. КамАЗның күп кырлы хезмәт белән тулы бер көне бер миллион сумлык төзү-монтаж эшләре генә түгел, ул — төзелешкә катнашучы, партия карарларын тормышка ашыручы һәркемнең тормышында тулы бер социаль, политик һәм тарихи сәхифә. Нәкъ менә шулар Сәләхов, Филимонов, Мәүликов, Деребизов, Сабирҗанов, Шатунов, Солтанова һәм башкалар җитәкчелегендәге бригадаларны фидакарь хезмәткә рухландырды. Алар һәр көн, һәр атна, һәр ай заданиесен һәр объектта арттырып һәм яхшы сыйфатлы итеп үтәү өчен социалистик ярыш оештырдылар. Бу башлангыч исә төзелешнең һәм аңа катнашучы барлык төзүчеләрнең сугышчан лозунгысына әверелде.

КамАЗдагы ярыш инициаторларына һәм барлык төзүчеләргә беренче бишьеллык батырлары Алексей Стаханов, Петр Кривонос, Мария Виноградова, Иван Гудов, Александр Бусыгин, шулай ук Магнитканың һәм Днепрогэсның алдынгы кешеләре, яхшы теләкләр язып, хат белән мөрәҗәгать иттеләр. Шулай итеп социалистик җәмгыять һәм коммунизмның материаль-техник базасын тудыручы төрле буын төзүчеләре арасында элемтә киңәйтелде.

Автозавод һәм шәһәр төзелешендә бригадалар төзелеш производствосының өйдәүче хезмәт һәм социаль ячейкасы булып әверелде.

Төзелештә бригадирның роле гаять зур. Чаллыга килгән кешеләр нәкъ менә бригадаларда беренче тапкыр производство рухын, ярыш дәртен тояллар. Хәзергә шартларда шактый белем һәм культура дәрәҗәсенә ирешкән яшьләр белән эшләү өчен белгеч булу гына җитми, киң кругозорлы тәрбияче булу да зарур. Партия оешмалары инициативасы белән КамАЗда махсус бригадирлар мәктәбе ачылды. Аңа иң яхшы производство алдынгылары алынды. Шунысы характерлы: бригадир булачак кешеләр, производство предметларыннан тыш, педагогика буенча да белем алалар. Партия өлкә комитеты, ТАССР Министрлар Советы, профсоюзларның өлкә советы һәм комсомол өлкә комитеты карары нигезендә һәр квартал саен Күчмә Кызыл Байраклар тапшырыла, ә алдынгы эшчеләр, КПССның Чаллы шәһәр комитеты, Чаллы шәһәр башкарма комитеты, профсоюзларның шәһәр советы карары буенча «КамАЗ төзү ударнигы» значогы белән бүләкләнә. Республика партия органнары, КПСС Үзәк Комитеты ярдәме белән, әдәбият, матбугат, радио, телевидение КамАЗ төзелешен пропагандалауда зур эш башкардылар. Элек бик азларга гына таныш булган КамАЗ сүзе югары темплар һәм киң масштаблар символы булып әверелде, илебез чикләрен үтеп чыкты, халыкара хезмәттәшлек һәм фәнни-техник прогресс символына әйләнде.

Күргәнебезчә, эшләнгән эшләр күп. Бу юлда уңыш шатлыклары да булды, кимчелекләр дә булмады түгел. Әмма ирешелгән уңышларны нығытырга һәм киңәйтергә кирәк.

КамАЗдагы промышленность объектларын һәм Чаллы шәһәрен төзү өчен биш ел эчендә бер ярым миллиард сумга якын акча тотылды, шул исәптән автозавод кору буенча бер миллиардтан артык сумлык төзү-монтаж эшләре башкарылды. Дәүләт планы 103 процентка үтәлде. Алтмыш мең кешеле «Камгэсэнергострой» берләшмәсе коллективы КамАЗ заводларын, Зәй ГРЭСын, Түбән Кама ГЭСын, авыл хуҗалыгы объектларын төзү буенча шушы ук вакыт эчендә 1,2 миллиардтан артык сумлык төзү-монтаж эшләрен гамәлгә ашырды. «Камгэсэнергострой» коллективы үзенең бишьеллык планын дүрт ел ярымда үтәде. Металлконструкцияләр монтажлау буенча гаять зур нәтиҗәләргә ирешелде.

1974 елның беренче яртысында ремонт-инструменталь заводының беренче чиратын сафка кертү — төзүчеләрнең зур казанышы. Бу завод төзелеш сыйфаты буенча эталон булып, ә техник һәм инженерлык җиһазлары буенча автомобиль төзү предприятиеләренең иң яхшысы саналырлык.

Иске Чаллы янындагы тигез басуда менә дигән хәзерге заман шәһәре калкып чыкты. Анда кыска гына вакыт эчендә миллион ярым квадрат метр торак мәйданы файдаланууга тапшырылды. Болардан тыш 18,5 мең урынлык мәктәпләр, 5 меңгә якын урынлык балалар бакчалары, сәламәтлек саклау объектлары, культура сарае, җәйге һәм стационар кинотеатрлар, ашханәләр һәм ресторанлар, көнкүреш комбинатлары, кибетләр салынды. Шәһәрне төзекләндерү буенча күп эшләр эшләнде, хәзер трамвайлар йөреп тора.

Автомобиль комплексын һәм яңа шәһәр төзү белән рәттән бөек төзелештә эшләүче барлык подразделениеләр авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерү буенча шәһәр тирәсе зонасында зур күләмдә эш башкаралар.

Соңгы вакытларда Түбән Кама гидроэлектростанциясен төзү эшләре дә көчәйде.

Шулай итеп, үзенең колачы, масштабы белән дә, Камада заводлар комплексын төзү тәҗрибәсе белән дә монда ирешелгән нәтиҗәләр бөтен дөньяга танылды, тарихи күренешкә әверелде. В. И. Ленин: «Безнең күз алдында зурдан-зур тизлек белән барган вакыйгалар шулай ук тарих алар»,— дигән иде. (3 том. 632 бит.) Комсомолның XVII съездында ясаган чыгышында КПСС Үзәк Комитетының Генераль секретаре Леонид Ильич Брежнев Байкал — Амур магистрален төзи башлау уңае белән болай диде:

«Без нык ышанабыз, комсомоллар, яшьләр бу бөек төзелешкә үзләреннән лаеклы өлеш кертерләр. Комсомольск, Магнитка һәм Турксиб, Днепрогэс һәм КамАЗ эстафетасын алар Себернең әлегә үзләштерелмәгән киңлекләре аша илтәчәкләр». КамАЗ төзүчеләре мондый бәя белән горурланырга, ышанычны акларга, хезмәт нәтиҗәләрен һәм үзләренең хезмәт данын үстерергә тиешләр.

Хәзерге вакытта барлык партия оешмалары, подразделение җитәкчеләре корпусларда алып барыла торган эшләрне уңышлы башкару, аларда мәйданнарны технологик җиһазлар монтажлауга тапшыру өчен төзүчеләрнең моторга көйләнгән армиясен эффектлы файдаланууга аеруча игътибар итәргә тиешләр. Моны тормышка уңышлы ашыру өчен төп юнәлешләрнең берсе: комплекслар — корпусларда җир һәм бетон эшләрен башкару өчен машиналар һәм автотранспорт системалары булдыру. Хәзергә утыздан артык шундый комплекс бар, ә аларны җитәрлек кадәр булдырырга, механизаторлар хезмәтен социалистик йөкләмәләрне үтәрлек итеп оештырырга кирәк. Республика партия оешмасы, министрлыклар һәм ведомстволар белән берлектә, КПСС Үзәк Комитеты күрсәтмәләрен тормышка ашыруда моны төп юнәлеш дип саный.

Алда торган бурычларны гамәлгә ашыру «Камгэсэнергострой», КамАЗ һәм СССР Монтаж һәм махсус төзү министрлыгының Чаллы Главкасы җитәкчеләреннән моңа кадәр күрелмәгән оперативлык, төгәллек һәм бер-берләре белән тыгыз бәйләнештә эшләүне таләп итә. Зур дәүләт эшендә зур дәүләт җитәкчесе һәм чын-чынлап партияле булу кирәк. Моны һич тә хәтердән чыгарырга ярамый. Мөһим мәсьәләләрне хәл итү өчен тиешле шартлар тудырылырга тиеш.

Төзелешкә катнашучы барлык кешеләр өчен — эшчеләр өчен дә, җитәкчеләр өчен дә — вакыт берәмлеге — бер тәүлек. Тәүлектәге сәгатьләрне күбәйтергә мөмкин түгел. Безнең бөтен эш сәнгатебезнең нәтиҗәсе шунда — тәүлектәге сәгатьләрне мөмкин кадәр эффектлырак итүдә. Менә шуңа күрә дә һәр эшченең, техника берәмлегенең, автотранспортның һәр эш минутын тирән инженерлык әзерлеге нигезендә рациональ файдалану — алда торган бурычларны гамәлгә ашыруның иң мөһим шарты ул. Әгәр дә моңа энтузиазмны, хезмәт һәм иҗади инициативаны, социалистик ярышны киңәйтү һәм тирәнәйтү факторларын кушсаң — бу КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы карарларын уңышлы тормышка ашыру эшенә тагын да зуррак практик өлеш булып керәчәк. Барлык партия оешмаларының, барлык

җитәкчеләрнең, безнең менә дигән эшчеләр сыйныфының — барлык подразделениеләрдәге хезмәт коллективларының сугышчан бурычы шуннан гыйбарәт.

Менә шуңардан чыгып, түбәндәгеләрне әйтәсе килә: Чаллы шәһәре партия оешмасы барлык ранглардагы җитәкчеләрнең партия, дәүләт каршындагы җаваплылыкларын, партиягә һәм хөкүмәткә биргән вәгъдәләренә җаваплылыкларын үтәүне тагы да ныграк таләп итәргә бурычлы. Хәзер автозаводчылар коллективы алдында автомобильләр чыгара башлау буенча алдан билгеләнгән проектларны тормышка ашыру бурычы тора. Бу эшне гамәлгә ашыру өчен җитәкчеләрдән дәүләт планнарын һәм социалистик йөкләмәләрне үтәүдә зур оперативлык һәм җаваплылык сорала. КамАЗ җитәкчеләре шул ук вакытта үз эшчәнлекләрен дә, производство эшләрен һәм кадрлар әзерләү эшләрен дә тагы да камилләштерү киряклеген дә онытмаска тиешләр. Шулай ук эшчеләрне төзелешкә җибәрүдә эзлекле производство системасын сакларга кирәк: үз заводларын салган кешеләр үз заводларында автомобиль төзесеннәр. Аларның хәзерге эш сыйфатлары өчен завод директорлары, партия оешмасы секретарьлары, төзелеш идарәсе начальниклары һәм алардагы партия оешмалары җавап бирсен. КамАЗ җитәкчеләре болардан дөрес нәтиҗәләр чыгарырлар дип ышанырга кала.

СССР Автомобиль министрлыгының, аның министры иптәш А. М. Тарасовның, чит илләрдә җиһазлар концентрацияләү һәм үз илебездә КамАЗ өчен заказлар төэмин итү буенча генераль дирекциянең эшләрен дә зур канәгатьләнү белән билгеләп үтәсе килә. Мәскәүдә, Парижда, Америка Кушма Штатларында сатып алу комиссияләре оештырылды, СССР Тышкы сәүдә эшләре министрлыгы белән берлектә, капиталистик илләрдәге һәм СЭВ членнары булган илләрдәге 830 дан артык махсус фирмаларда җиһазлар эшләү буенча техник заданиеләр эшкәртелде. 253 фирма белән җиһазлар җибәрү буенча контрактлар төзелде. Алардан тыш СССР Станок төзү промышленносте һәм СССР Авыр промышленностена караган барлык предприятиеләр диярлек КамАЗ өчен җиһазлар җитештерә. Бу җиһазлар барысы да иң яхшы продукция эшләргә яраклы.

Төзү һәм монтаж эшләренең бишьеллык нәтиҗәләрен анализласаң, шактый гына резервларның әле файдаланып бетмәве ачыклана. Кыенлыкларны, беренче чиратта, автотранспорт җитмәве белән аңлатырга була. Белгечләрнең исәпләве шуны күрсәтә: әгәр дә төзелештә оештыру эшләрен тагы да яхшыртсаң, әгәр дә социалистик ярыш утын тагы да көчәйтсәң, монтаж мәйданнарын тапшыру һәм объектларны хәрәкәткә китерү сорокларын кыскартсаң, беренче автомобильләрне чыгаруга 1976 елның беренче кварталында ирешергә мөмкин. Бу асылда тарихи чор — Ленин партиясенең XXV съезды ачылу алды көннәре. Совет кешеләре һәр вакыт коммунистлар форумына зур хезмәт җиңүләре белән килә. КамАЗ төзүчеләрнең йөз меңлек армиясе, шәһәр һәм өлкә партия оешмасы бу традициядән читтә калмас, өлбәттә. Димәк, беренче машиналар ясап чыгару көненә бары тик ел чамасы вакыт кала.

Төзелеш эшендә «пассив яшәү» — өлешчә алганда, мәскәүлеләр, ленинградлылар тәҗрибәсеннән, бригадс подряды алымын үзләштерүдән читкә тайпылу дигән сүз. Тәҗрибә күрсәткәнчә, бу алым зур экономик эффект бирү белән бергә, инициативаны үстерә, коллективизм тәрбияли, эшнең сыйфатын күтәрә. Чаллы шәһәрен төзүчеләрнең барысы да, шулай ук партиянең шәһәр комитеты, заказчиклар КПСС Үзәк Комитетының «Гражданлык торак объектларын ритмик рәвештә файдалануга тапшыруда КПССның Орел өлкә комитетының эше турында» карарыннан практик нәтиҗәләр ясарга тиешләр.

Төзелешне тигез ритмга салу һәм шул нигездә шәһәрдәге объектларны файдалануга тапшыру өчен бездә барлык мөмкинлекләр бар. Шәһәр төзү һәм объектларны файдалануга тапшыру буенча дәүләт планы һичшиксез даими үтәлеп барырга тиеш. Бу барлык коллективларның гражданлык бурычы.

Беренче трамвай юлының эшли башлавы шәһәр тормышына зур эчтәлек керттә. Әмма трамвай юлларын Яңа шәһәргә, кою заводына җиткерүне бик нык тизләтергә кирәк — төзүчеләргә эшкә бару һәм эштән кайтуда бернинди тоткарлык, кыенлык булмаска тиеш.

Халыкка хезмәт күрсәтү сферасы, азык промышленносте, элемтә һәм транспорт мәсьәләләре төзелеш барышында гигант индустрия һәм шәһәр кору эшенең аерылмас өлеше булып әверелде. КамАЗ төзелә башлаган көннән алып партия өлкә комитеты, республика Министрлар Советы, КПССның Чаллы шәһәре комитеты, шәһәр башкарма комитеты, КПСС Үзәк Комитеты һәм РСФСР Министрлар Советы ярдәмендә, шәһәр хуҗалыгының бу өлкәләрдәге эшчәнлеген яхшырту, аларга тиешле базалар булдыру буенча киренке эшне даими алып бара. Хәзер ит-сөт, икмәк пешерү предприятиеләре комплексы уңышлы эшли, сәүдә эше дә шактый җайга салынды, шәһәрдә һәм төзелеш мәйданнарында 20 меңгә якын урынлык ашханәләр бар. Көнкүреш тәэминаты челтәре дә киңәйтелгәннән-киңәйтелә. Телефон элемтәсен, шәһәр транспортын, һава транспортын үстерү буенча да шактый эшләр башкарылды. Автомобиль, елга, тимер юл транспорты хезмәткәрләре йөк ташу һәм пассажирлар йөртү буенча үз эшләрен намус белән үтиләр. Халыкка хезмәт күрсәтү сферасының төрле өлкәләрендә барлыгы 15 меңнән артык кеше эшли. Хезмәт ияләренә биредә өч меңләп автомобиль, 25 меңгә якын суыткыч, өч меңнән артык телевизор, 15 миллион сумлык мебель сатылды. Шәһәрдә яшәүче һәр кешегә елга 1,2 мең сумлык төрле товарлар сатыла. Бу — уртача республика күрсәткече яки гомумән РСФСР күрсәткече белән чагыштырып исәпләгәндә 1,5—2 мәртәбәгә артыграк.

Мәгариф, сәламәтлек саклау һәм культура хезмәткәрләре дә КамАЗ төзелешенә актив катнашалар. Чаллыда культура фронтының күп меңле менә дигән армиясе эшли. Балалар бакчаларындагы сабыйларны сәламәт, таза итеп тәрбияләү, меңләгән укучыларны белем, дөньяга коммунистик караш һәм югары әхлак нигезләре белән коралландыру, хезмәт ияләренә югары квалификацияле медицина ярдәме күрсәтү — болар барысы да мәгариф, сәламәтлек саклау, культура хезмәткәрләренең изге һәм җаваплы бурычы. Аларның бу күркәм эшен даими камилләштерергә кирәк, аларга партия оешмалары даими кайгыртучанлык күрсәтергә тиеш.

КамАЗ комплексын төзү буенча партия һәм хөкүмәтебез документларында, шәһәр халкын авыл хуҗалыгы продуктлары белән мул тәэмин итү максаты белән, шәһәр тирәсе авыл хуҗалыгы зоналары булдыру турында киң программа билгеләнә. Узган ел гына да «Камгэсэнергострой» берләшмәсе бу өлкәдә 30 миллионнан артык сумлык төзү-монтаж эшләре башкарды, күп кенә объектлар сафка кертелде. Шулардан 7200 баш мөгезле эре терлек өчен 21 абзар, 54 мең баш сыешлы дуңгыз асрау комплексы, Зәй авыл хуҗалыгы төзелеше комбинаты, теплица комбинаты һ. б. күп кенә объектларны әйтергә мөмкин.

«Камгэсэнергострой» коллективы тагын бер мөһим объект — Түбән Кама гидроэлектростанциясен төзү эшләрен алып бара. 1974 ел планы җиде айда ук арттырып үтәлде. Кама елгасына плотина кору 1977 елның октябрена төгәлләнергә, ике агрегат декабрь аенда ток бирергә тиеш. Бу — реаль срок.

КамАЗ төзелешенең барлык этапларында партиянең Татарстан өлкә комитеты, КПССның XXIV съезды, Үзәк Комитет карарларыннан, автомобиль комплексын төзүне тизләтү буенча партия һәм хөкүмәтебезнең конкрет документларыннан чыгып, үзенең эшчәнлеген төзүчеләр коллективларында партия-оештыру, партия-тәрбия эшләрен күтәрүгә, төзүчеләр, монтажчылар, завод эшчеләренең күп меңлек армиясен туплауга, хезмәт ияләренең иҗади һәм хезмәт активлыгын күтәрүгә юнәлдерде. Хәзер партиянең шәһәр комитеты 13 меңнән артык коммунистны берләштерә, төзелештә район комитеты хокукларында ике партком, 41 башлангыч, 236 цех партия оешмалары, 400 дән артык партия группалары эшли. Ун меңнән артык коммунист — турыдан-туры производствода. Партиянең зур көче бу, Кама автомобиль комплексын төзүчеләрнең күәтле авангарды. Төзүчеләр хезмәтендәге барлык уңышлар безнең партия эшебезнең конструкциясенә һәм эчтәлегенә бәйле.

Соңгы вакытларда төзелештә удар ике айлык вахталар оештырыла башлады. Бу кыйммәтле патриотик башлангыч хезмәт нәтиҗәләрен үстерүгә зур этәргеч бирде. Алынган социалистик йөкләмәләрен үтәүдә «Камгэсэнергострой»дан Кольцов, Наурбиев, ТАССРның атказанган төзүчесе Борһанов, Ященко, Фәйзиев, Отюбрина, Шаһазина, монтажчылар Главкасыннан Семенов, Петров, Закиров, «Главмосстрой»дан Турухина, «Камдорстрой»дан Сидорина бригадалары, РИЗ токарьлары Арсентьев һәм Красноперов удар алтмышкөнлек вахтасында зур хезмәт нәтиҗәлә-

ренә иреш теләр. Мәүликов бригадасы төзүчеләреннән Синичкин белән Анисимов ташчылар конкурсында бер сменада җиде норма үтәде. Барлык производство алдынгыларын һәм новаторларын санап үтү мөмкин түгел. Әмма шуны әйтәсе килә: алар үз эшләренең чын остасы, куәтле ашкыну, иҗади эзләнү белән яшиләр. Аларның һәрберсенең үз шәхси хезмәт лабораториясе бар. Аны өйрәнү, алар тәҗрибәсен һәр эшчегә җиткерү — бу партия, профсоюз, комсомол оешмаларының мөһим бурычы. Эшчеләрнең, бригадаларның, идарәләрнең хезмәт ярышын, материаль, мораль кызыксындыру ысулларын тагы да камилләштерергә кирәк. КамАЗ төзүчеләре белән төзелешне тәэмин итүче заводлар һәм предприятиеләр эшчеләре арасында тәҗрибә алмашу, хезмәт элемтәсе оештыру файдалы булыр иде. Күргәзмә агитациянең, ярыш нәтиҗәләрен даими белдереп торуның да тәэсир көче зур. Ышандыру сәнгатенең көчле коралы булган күргәзмә агитациянең образлылыгын һәм тәэсир итү көчен тагы да үстерергә кирәк.

Бөтен җәмәгатьчелекнең, зур һәм кечерәнгтагы һәр җитәкченең көндәлек беренче бурычы итеп кадрларны тәрбияләү һәм үстерү бурычы саналырга тиеш. Югарыда әйтелгәнчә, төзү-монтаж эшләре барышында бригадаларның ролен көчәйтү өчен без күп эшләр башкардык. Һәм бу үз нәтиҗәләрен дә ачык күрсәтте. Шулай да без объектларда конкрет бурычларны хәл итүдә мастерларның, прорабларның, участок начальникларының үзәк фигура булуларын онытырга тиеш түгелбез.

Кыскасы, хәзер Кама автомобиль заводы төзелеше яңа этапка — беренче автомобильләр чыгару производствосын әзерләү этабына басты. Төзелеш барышында тупланган тәҗрибә коммунистларның, барлык төзүчеләрнең һәм эшчеләрнең бу хәлиткеч этапта да партия һәм хөкүмәт куйган бурычларны уңышлы хәл итәчәкләренә ышаныч тудыра.

Гәрәй Рәхим

Тамыр

Кояшка ук сузмыйм нәфесемне.
Үз эшемне кылам сабыр гына.
Ахрысы, мин тормыш агачында
Чәчәк түгел, гади тамыр гына.

Ә чәчәкләр шаулый язлар саен,
Дөньясына хуш ис тараталар.
Алар өчен кызлар башын җуя,
Олы абзыйлар да яраталар.

Чәчәкләргә яуган мактауларны
Тыңлап торам шулай сабыр гына.
Алар өчен эчтән шатланам мин,
Үзем болай гади тамыр гына.

Әй, шатланам! Кара җирне ертып
Татлы матдә эзлим алар өчен.
Мин бит тамыр! Миңа бар дөньяга
Күрсәтергә кирәк чәчәк көчен.

●

Юк, шигырьдә йокы симертергә
Рөхсәт итми безгә бу замана.
Дөньясында күпме үзгәрешләр,
Һәр тумыш көн үзгә, ул өр-яңа.

Мәхәббәтне инде Мәҗнүн кебек
Эзләмибез таулар арасыннан.
Без эзлибез аны ыгы-зыгы,
Машиналар, шаулар арасыннан.

КамАЗларны төзеп ята кеше,
Үзе калган гүя нокта булып.
Шул ноктада бер уч йөрәк тибә
Дөньясына ныклы тотка булып.

Бер-бер шагыйрь «әлли-бәлли» җырлап
Йоклатырга тели шул йөрәкне.

Мәңгүн кебек яшәтергә тели
Җирне тотып торган шул терәкне.

Юк, шигырьдә йокы симертергә
Рөхсәт итми безгә бу замана.
Заманага лаек җырлар эзләп,
Йөрәкләрдән кайчак каннар тама.

Дуслар әйбәт

Дуслар әйбәт. Гөнаһына кермим,
Минем өчен үлеп тора алар.
Танышларым аша, телефоннан
Хәлләремне белеп тора алар.

Шаулап-гөрләп узган кичәләрдә
Миңа дигән урын гел саклана.
Минем нәни генә уңыштан да
Куаныша алар, әй, шатлана.

Дуслар әйбәт. Димәк, мин үзем дә
Бик үк начар кеше түгелмендер.
Тирә-якка бик үк чәчелмимдер,
Уңга-сулга бик үк түгелмимдер.

Әгәр дуслар миннән баш тартсалар,
Ни кылырга, әлбәт, мин белермен —
Кинәт кенә җилгә чәчелермен,
Язгы сулар кебек түгелермен.

Хыял

Хыялдан да иреклерәк
Ни бар җирдә, күңелем!
Нинди рәхәт ярып әйтү
Хыялның кол түгелен

Канун көчсез, хөкем көчсез
Бу хыялны тыярга!
Кай тиранның кодрәте бар
Аңа богау куярга?!
Хыял бит ул сыер түгел
Чыбык белән куарга!
Я бер төргәк акча түгел
Сейфларга сыярга!
Яки ул бер дуңгыз түгел
Шыр акыртып суярга!

Ул илаһи бөеклеккә
Илтә кеше күңелен.
Нинди рәхәт, ярып әйтү
Хыялның кол түгелен!

Димәк

Якын булса үз илең —
Илдә булсын үз гөлең.
Әгәр булса үз өең —
Үзеңчә күр үз көнең.
Җырлар булсаң үз көең —
Көйгә килсен үз телең.

Табалмасаң үз гөлең,
Коралмасаң үз өең,
Күрәлмәсәң үз көнең,
Табылмаса үз көең,
Аңламасаң үз телең, —
Аптырап йөрмә, гөлем,
Юк, димәк, синең илең.

Битараф бәндәгә

Бик кирәк чагында
Йөрәгем таш минем.
Дошманга бер суксам,
Һичшиксез үтерә.

Йөрәгем — тере су.
Дусларга өләшсәм,
Терелтеп җибәрә
Һәм мең кат үстерә.

Ә менә син, бәндә,
Ни дошман түгелсең,
Ни бер дус түгелсең.
Йөрәкне бирсәм — син үсмисең,
Ә суксам — үлмисең.

Тышта март

Тышта март.
Аңа ничә яшь?
Кем белсен, бик карт бит ул.
Мин туганчы ничә мең ел
Элек туган март бит ул.

Тышта март,
Их, күңелләрнең
Ташып туласы килә.
Куңелләрнең язлар кебек
Япь-яшь буласы килә.

Тышта март.
Миңа утыз яшь.
Чәчләр чаларып килә.

Ә мең яшьлек март дөньяга
Яшьлекләр алып килә.

Тышта март.
Күр, каеннарның
Тәннәрендә сут уйный.
Бөреләргә түзем кирәк —
Эчләрендә ут уйный.

...Каеннарның суты белән,
Бөреләр уты белән
Чал чәчле бер сабый булып
Мин җиргә кабат киләм.

Тышта март.
Сиңа ничә яшь?
Кем белсен, бик карт бит син.
Мин туганчы ничә туып,
Ничә үлгән март бит син.

Карт шагыйрьгә

Син җыр белән үзеңә дан китердең.
Һәм җыр өчен күрдең күпме җәза.
Син тәнеңә күпме чирләр алдың
Шигырьләреңә булсын өчен таза.

Эт һәм аның хуҗасы

Өстерде ул этен минем өскә,
Эт шашынып килде —
таламады.
Адәм-затның нәрсә икәнлеген
Эт аңлады, хуҗа аңламады.

Тагын өстерде ул...
Мин ялгызым
Алма бакчасына кергән идем.
Алмаларны түгел, гүзәл бер өн,
Бакча иркенлеген күргән идем.

Сукмакларда җырлап йөргән чакта
Өстерде ул...
Ә эт таламады.
Эт аңлады адәм баласының
Балалыгын...
Хуҗа аңламады.

Туй

Җил капкадан җилләр исә,
Җилгә куям битемне.
Җил капкадан керәсеңне
Күптән әйттем бит инде.

Җил капкадан керәсең син
Йоласын тотып кына.
Күпме көткән туебызның
Көйләрен отып кына.

Җил капкадан керәсең син,
Түремә үт, оялма,
Пакь җаныңны гомер буе
Җылытачак ояңа.

Бусагадан атлаганда
Изгелектә тот уең.
Бу бит синең гомереңдә
Тәүге һәм соңгы туең.

Соңгы туең. Җил капкадан
Чыгасы бар, онытма.
Без соңгы кат чыккан чакта
Елап калыр оныклар.

Җил капкада җилләр тынар,
Чыгулар туең булмас.
Чыкканчы яшиселәр бар —
Бусы да уен булмас.

Ә бүгенгә без бәхеттә!
Хыял көлә, уй көлә!
Җил капканы дер селкетеп
Җилләр исә — туй килә!

1974

Эдуард Касыймов

«ЗИНһАР, РӘНҖЕМӘ!..»

«Кама офыклары» циклыннан этюдлар

Дружина штабы хәйран зур йортның иң аскы катындагы бер бүлмәсенә урнашкан.

Кердек тә стена буендагы урындыкларга мыштым гына утырыштык. Без — төп-төгәл ун кеше, чиртсәң, каннары чәчрәп чыгарга торган ир-ат. Без пәһлеваннарга өстәп, тагы нечкә билле ике чибәр сылу да бар. Турысын әйткәндә, без аларны өйләренә, язның искитмәле бер кичендә шау-гөр килгән тулай торакларына кайтарып җибәрмәкче дә булган идек, әмма безнең нәзберек күбәләкләребез матур күзләрен тасрайтып кына карадылар: янәсе, патруль йөрүдән качарга без сездән кай ягыбыз белән ким?..

Беләкләргә кызыл чүпрәк бәйләнгән. Ипле генә утырабыз. Күзләр идәндә чүпләнә... Дружинабызның калган ике төркеме кайдадыр үз секторларында йөри. Әйдә, йөри бирсеннәр. «Иминлек һәм тәртип!» — безнең лозунг...

— Я, ничек, ал да гөлме?

Түр өстәл артына кереп кунаклаган Петлеванный, арпа кашларын югары чөеп, безне берәм-берәм сөзеп чыкты. Юк, ул бер дә әллә кем түгел. Үсеп килүче, өметле генә инженер. Безнең бүгенге башлыгыбыз. Яңа калада бу кичнең иминлеге өчен иң әүвәл ул җаваплы.

— Болай ярыйсы, әйбәт... тик ни...

— Нәрсә «ни»?

— «Дүрт тә ноль дүртенче» йортта берәү кияүгә чыккан. Туйлары алтынчы катта. Дөбер-шатыр...

— Аннан килеп, «ике ноль бердә» дә... Бәлкем берәрсенең туган көнедер? Бусында мәскәүлеләр. Тугызынчы катта. Андук менеп тормадык. Әмма тавышлары яшелле-күкле... Тик ул йорт безнең секторга керми кебек...

— Кермәсә соң!

— Үзебезнең шушы йортта да хәлләр: икенче подъездның кызыл почмагында танцы. Андагы бөркүгә ничек чыдый торганнардыр — әкәмәт...

— Үзләренә ярагач, теләсә ничек түзсеннәр!..

Петлеванный үтә эшлекле кыяфәт белән дежурлык журналын актарырга кереште. Ул, әлбәттә, игътибарга алырдай һәр нәрсәне кәгазьгә теркәп куярга әзер. Ләкин башлыгыбыз журналны бик тә җентекләп актарса да, анда туй яисә танцы хакында теркәп куелган бер сүз дә тапмады, ахры, иреннәрен турсайтты:

— М-м-да, бүгенге кич шома гына үтсен иде инде. Безгә авыз ачып утырырга ярамас!

Без әллә белмибезме! Бүген шимбә ич...

Озын муенлы бер егетебез, ул арада урыныннан кубып, стенадагы графикны «өйрәнергә» кереште.

— Иртәгә дежурга ПромУКС чыга икән, аннан соң РИЗ, кою заводы, КамАЗның баш механик службасы... Безнең бүлеккә төп-төгәл ун көн узгач, янә кызыл тасма тагасы икән... Сөенегез!

— Тагын ун көннән? Бик тиз түгелме?

— Куандырдың... рәхмәт!

Петлеванный ниндидер станокның схемасын өйрәнеп утырган жиреннән (һай, оста да соң — монда да кыстырып килгән) баш калкытты:

— Тизме-түгелме, тикшермик, яме! Әмма сезгә саф һавага чыгарга вакыт түгел микән инде? Бәладан башаяк...

Әлбәттә, бик вакыт. Ләкин кубарга ашыкмыйбыз. Каш астыннан гына Петлеванныйның аллы-гөлле галстугын җентеклибез.

— Бик дөрес: бәла ул агач башыннан йөрми...

Әнә шулай икеле-микеле хәлдә тагын бераз утыргач, кинәт бүлмәгә өлкән яшьтәге берәү атылып килеп керде. Чәчләре тузгыган, күзләре акайган. Үзе таушалып беткән пинжәген дә майка өстеннән генә киеп алган. Сулышына буылып, теш шыгырдатты:

— Сез монда рәхәтләнеп ләчтит сатасыз, ә тегендә хулиганнар өере, тфү, тын алырга бирми!..

— Тукта, юньләп аңлат... Хикмәт нидә?

— Хикмәт шул: музыка акырталар. Баш шартларга житте инде, валлаһи! «Дүрт тә унынчы» йортта. Җитмәсә, урамга да бер көтү ачык авыз җыелган. Мәхшәр прәме!..

— Кемнәр яши ул йортта?

— Механизаторлар. Минем ише шоферлар тагы... Кичә дә дөбершатыр кыландылар, бүген ищу катырак! Мин инде башны ике кат мендәр астына да тыгып карадым, юк, булмый гына йоклап... Ә бит миңа иртәнге дүрттә сменага. Йокламаган килеш рульгә утырып кара син!..

— Сез иң әүвәл тәрбиячегә әйтерләр.

— Әйтмәгән кая! Кулларын гына җәя: имеш, көченнән килми. Аптырагач, участковый милиционерга чапкан идем әле менә. «Минем компетенциядә түгел ул, монда халык дружинасы патша», — ди. Җибәрде сезнең янга... Сез, дускайлар, патша икәнсез, инде зинһар, ул мөртәтләрнең арт сабагын берәгәйле итеп укытыгыз әле.

Сыннарыбыз үзеннән-үзе турайды. Күзләрдә очкын кабынды...

— Ишеттегезме? — Петлеванныйның тавышы кырыс һәм кискен яңгырады. — Каңгырап утырган идегез, рәхим итәсез: менә дигән «эш» үзегезгә!

— Була ул!

Җәһәт кенә урыннардан куптык. Түшләр киерелгән...

Ишегалдында брезент фургонлы автомашина тора. Аның маңгаена эре хәрефләр белән «ДНД» дип язылган. Минутында кузгалырга әзер. Сәбәп кенә чыксын!

Борыннарны кытыклап, күкрәкләргә җәй башының саф һавасы кереп тулды. Кул кычытуына чыдар әмәл юк. «Патша» булсаң, бигрәк тә кычыта икән. «Эх, дим, ул хулиганнарны бер куырыйк әле янган утта!»

Мин эчтән генә шулай дип уйлыйм, ә төркем алдыннан атлаучы озын муенлы егетебез кулы белән һаваны кискәли:

— Минутында җиргә сеңдермәсәкме?!

Шофер абзый да эчендәге купкан ачуын түгә бирә:

— Кеше хәленә керә беләмени ул башкисәрләр? Төкерәләр! Ә мин, нәрсә, йокы туйдырырга тагын гаражга китимме? Юк, житәр, тулай торакта урын алганчы да ике атна буе кабинада әвәләндем инде...

Әлеге йортка якынлаштык. Чынлап та, дөнья шау-гөр килә монда! Динамик кайдадыр бик югарыда, әллә унынчы, әллә унберенче катта, балконга беркетелгән. Утлары юк, караңгы... Ә түбәндә түгәрәк мәйданчыкта халык... йөзләгән кеше! Юк, беркем дә биеми: аяк астында комдыр, чуер таштыр. Әйләнә-тирәдә исә дәһшәтле техника: гажәеп дәү үзбушаткычлар, автоскреперлар, озын муенлы кранлар. Һәм менә шушы дәһшәтле чолганыш эчендә түгәрәк мәйданда йөзәрләгән яшь җилкенчәк төркем-төркем укмашып та, аерым-аерым бүленеп тә музыка җаена ипле генә селкенә, тирбәлә бирә. Кайберәүләр хәтта авыз эченнән генә көйли дә... Менә хикмәти хода дигәндәй!

Ә югарыдан музыка куәтле ташкын булып агыла тора, коела тора...

— Күрдегезме инде?! Ә бит минем бүлмә шул динамик астында ук!.. Алар шулай озак кыланыр дисезме? Төн уртасы ашканчы! Ә бәлкем атна буе... җәй буе! Их, җыенысын бер капчыкка тутырып...

Без өнсез калдык. Озын муенлы егетебезнең дә куллары салынып төште, муены эчкә сеңде кебек...

Кинәт музыка кырт өзелде һәм югарыдан көр, гайрәтле бер тавыш яңгырады:

— Тәнәфес, егетләр! Бер көйрәтеп алыйк әле!

Караңгы балконда шырпы сыздылар. Аңа ияреп, монда да дистәләгән ут кабынды. Ләкин шул минутта ук җирдәгеләр арасында чыр-чу купты:

— Ниткән тәнәфес тагы!

— Әйләндерә бир!..

Янә чылтыр-чылтыр чишмә аккандай матур музыка сибелде, янә йөзәрләгән шәүлә талгын гына тирбәлә башлады...

Тик кайда соң монда тәртип бозу, кайда хулиганнар өере? Киресенчә түгелме?

Дистә-дистә яшь йөрәк бер сукмакта таптана! Танышалар, аңлашалар, кавышалар... Кайнар хисләрнең бөреләнгән чагы лабаса!

Көннәр, айлар үтәр... Дәһшәтле техника моннан китәр. Бер дә бер заман шушы мәйданчык яшеллеккә күмелеп матурланыр һәм анда бала-чага җыелыр. Ком һәм кояш нурлары белән уйнарга нәниләр — бүгенге мәхәббәт җимешләре чыгар... Моны без соңыннан күрербез...

Ә хәзер, бу минутта ни кылырга соң без «патшаларга»?

Тимердәй салкын һәм каты киңәше белән шофер абзый үзе кысылды:

— Менәргә дә динамикларын конфисковать итәргә! И бетте-китте, вәссәләм!

Җәй башы... Мәхәббәт чаткылары... Хисләр өермәсе... һәм боздай салкын таләп!

Без таптанып торудан бүтәнне белмибез.

Ниһаять, безнең арада сулышын кысып торган бер «нечкә билебезнең» күз агы елтырап алды:

— И абзыкай, бәлкем ничек тә түзәрсең, ә?!

Аңа икенче чибәребез кушылды:

— Һаман булса икән... Зинһар, рәнжемә инде, абый кеше! Монда бит әкияттәге кебек..

Кая ул рәнжемәгән! Теге абзыебыз үз сулышына буыла язды:

— Сез... сез үзегез әкият! Имеш, дружина, имеш, «патшалар»... Мин үзем тагы, тинтәк... тфу!..

Без күз ачып йомганчы, шофер агай караңгыга кереп тә югалды...

Нишләгәндер ул — йокы симертергә гаражына китеп барганмы, әллә башына кат-кат мендәрләр каплаганмы — белмәдек...

Без «патшалар» көчсез идек шул монда...

Дүшәнбе егете

Күк йөзеннән кара-кучкылт сәләмә болытлар агыла. Дымга инде болай да туенган җирне янә чылатып, салкын яңгыр сибәли.

Без тукталышта автобус көтәбез. Халык артканнан-арта бара, әмма безгә кирәкле маршрут автобуслары һаман күренми. Маңгайларына «служебный» яисә «бригадирский» дип язылган вахта автобуслары гына, без җәяүлеләрнең котын алып, пычрак чәчрәтә-чәчрәтә тыз-быз үтеп киткәлиләр.

Мондый хәлдә, билгеле, автопарк һәм шоферлар исеменә кагъ яудырмыйча түзеп буламыни?

— Маршруттагыларның әбәт чагыдыр. Ичмаса, чиратлашып кына тамак ялгый да белмиләр бит, туң җаннар.

— Алар шулай инде: алынкы-салынкы... Башлыклары ни карый тордыр?

Безнең янга өстенә соры болони куртка кигән чандыр гына бер егет килеп басты. Аның кояшта каралган какча йөзен карлыгач канатыдай нәзек һәм кыйгач мыек бизәгән. Егет баскан җирендә таптангалап алды да, гәүдәсен бөрештереп, миңа төбәлде:

— ЗЯБ поселогына икенче номерлы автобуста барасы бугай, шулаймы? Күптән көтәсезме?

— Әйе, «икенче»дә... Егерме минутлап көтәбез инде, тик әлегә ни икенче», ни «өченче» күренми, кадалгыры!..

Ул ачулы карашы белән һавадагы болытларны сөзеп алды:

— Ай-һай, сездәге һавалар! Күктәге аллагыз акылдан шашкан, ахрысы.

— Безнең Чаллыда шулайрак шул: тәмам шашты... Ә сез кайдан, иптәш?

— Көньяктан. Дүшәнбедән. Анда безнең эссегә чыдарлык түгел иде, кырык тирәләре иде, монда килсәм, хәлләр... Шундук куырып алды, башта томау гына иде, инде менә хәзер ангина...

— Э-э, чибәр егет, — дип баш селеккәләде янәшәдә басып торган зәңгәр яулыклы бер апа,— авыру килеш тырай тибеп йөриләрмени? Урынга ятасы иде сиңа.

— Мин болай да ике көн буе тулай тораКта дустымның түшәген изеп яттым инде. Монда аунарга дип килмәдем. Бүген менә кичке биштә медкомиссиягә керәсе.

— Качмас иде әле медкомиссияләрең.

— Һе, комиссиясез генә алырлар дисезме? Алмагайлары! Мин бит буяучы, иң биек йортларны буяучы... маляр-высотник ягъни...

— Кара син! — дип куйдым мин, ихтыярсыздан тел шартлатып.

Төркем буйлап та ниндидер дулкын йөгереп узды сыман: һәркайсы көньяк җилләре китереп ташлаган егеткә текәлде. Чем-кара нәзек мыеклы, мескенрәк кыяфәткә калган чандыр егет безнең күз алдында капыл үсеп киткәндәй булды.

— Маляр-высотник, алайсам... Ә нигә, үзегездә биек йортлар салмыйлармы әллә? Эш табылмадымы? — дип, сүзгә катышты зур күзлекле бер агай.

— Ник салмасыннар? Бар бераз бездә дә... Әмма бездә КамАЗ юк.

— Ә монда кая керергә ният? — дип сорадым мин.

— Чаллыда иң биек йортларны кемнәр сала? Главмосстрой! Мин кадрлар бүлегендә сөйләштем инде.

— Ах, оста да соң, ә! Әллә каян кил дә шундук мәскәүлеләр арасына кереп кысыл,— дип, теш ыржайтты чөгендердәй кызыл йөзле берәү, башындагы беретын кыңгыр салып.

Егетебез ак тешләрен елтыратып көлемсерәде генә:

— Күз күрер. Әле монда да эшләр муеннан, диләр бит. Берсеннән-берсе биек завод корпусларын да ялт иттереп бизәргә безнең ишеләр аз кирәк булыр дисезме?.. Тик менә бүген медкомиссияне ничек иттереп кәкре каенга терәтергә микән? Аптыраш!

— Ә нишләп «кәкре каенга?».. Соң син, туганкаем, врачларның үзләренә барасың ич,— дип чәрелдәде зәңгәр яулыклы апа. Әмма аның тавышы шундук йомшаграк, ягымлырак төсмер алды: — Томау төшүдән иң шифалысы теге ни... ингаляция булыр. Ягъни болай: бик әйбәтләп кайнар бәрәңге парын сулыйсың. Ә ангинадан дисәң, иң әүвәл сөт белән сода булышыр.

— Хе-хе... Таптыгыз: әллә ниткән ингаляция, җитмәсә, сода белән сөт тагы... Чүп сүз! — диде кызыл йөзле кеше. — Иң шәбе, иң берәгәйлесе, энекәш, бер стакан ак аракыга кара борыч сибеп, җылытып... Юар да алыр! Тик монда аракысын табуы гына... Хәер, коньяк та ярый...

— Ангинаданмы? Һай, ни ишетәм, — дип бот чапты яулыклы апа.

Тукталышта автопарк һәм шофер халкын битәрләү бөтенләй сүрелде. Кешеләр монда ни өчен җыелганнарын онытa төштеләр шикелле. Тегеннән дә, моннан да «иң шәп», «иң берәгәйле» киңәшләр яварга тотынды. Коньяктан килгән егетебез тәмам каушап калды, җилкә җыерудан бүтәнне белмәде.

— Мәтрүшкә кайнатып эчсәң иде менә! Яки, әйтик, кура җиләге белән дегеттәй куе чәй. Аннан соң, изрәп, манма тир эчендә ятарга...

— Юкә балы да булса идеме тагы?.. О-о! Тик каян табасың аны?

Бөжра кысылганнан-кысыла барды. «Чибәр мыек» инде хәзер, борын тартыштыргалап, күзләрен генә челт-челт иттерә иде. Мондый хәлдә, аңлашыладыр, минем дә бер читтә авыз ачып каласым килмәде, иң гади, иң ышанычлы киңәш бирмәкче булып, уртагарак кысылдым:

— Синең, дус кеше, — дидем, — комиссиягә барасың бармы? Бар. Димәк, сиңа иң әүвәл температураны төшерергә кирәк... Төкер бүтәненә, син мине тыңла, дускай! Менә монда күршедә генә аптека, шунда кер дә парацетамол яисә бүтән берәр төрле...

Ләкин мин иң кулай киңәшемне әйтеп бетерә алмадым: кинәт халык төркеме читкә сибелеште, ыгы-зыгы купты. «Икенче» номерлы автобус килгән икән. Ул арада инде егеткәем кысыла-кысыла автобус эченә кереп тә югалды..

Берәр ай чамасы вакыт үткәч, мин аны Яңа калада очраттым. Кибеттән чыгып килә иде. Кулындагы җәтмәгә әллә ниләр тутырган: кефирдыр, консерва банкалары, кәгазь төргәкләре, ә култык астына исә ике кирпеч икмәк кыстырган. Үзе сырмадан, башында колакчын бүрек. Әүвәлгечә үк чандыр, әүвәлгечә үк «сызылып киткән кара мыек». Тик хәзер йөзе алсуланып тора иде. Димәк, сау-сәламәт... Мин күптәнге белешләр сыман җылы гына күрештем дә:

— Соң кайларда, ниләр жимерттерәбез, туган? — дип сорадым.

— Әнәтерә: майлап маташабыз әкертенләп... — дип, ул бер читкә ымлады. Бездән әллә ни ерак та түгел, бик күп балконнары белән бизәлгән ундүрт катлы зур йорт калкынып тора иде. Аның бер як стенасы югарыгы өлешендә аксыл болыт төсенә буялган һәм шунда, кошлар очар биеклектә, буяучыларның бишеге дә асылынып калган иде.

— Менә үзебезнең кызларны сыйламакчы идем әле. Симертергә ният, һе-һе!..

— Бик яхшы ният!.. — дип баш каккаладым мин һәм, телем кычытуына чыдый алмыйча, янә сорап куйдым: — Теге чакны ничек соң... врачларны «кәкре каенга терәтә» алдыңмы?

— Ниткән врачларны? Нинди «кәкре каен»? — Күзләре шар булды моның. — Сез, иптәш, әллә ниме...

Әлбәттә, ул танымады мине. Артык бер минут тормыйча, җилкәләрен сикерткәләп читкә атлады. Ә мин шул чакны аның сырма аркасына ак хәрефләр белән: «Дүшәнбе. Әле өйләнмәгән!» дип язылган сүзләрне укыдым.

«Тагын бер исәрбаш... Димәк, чын-чынлап ияләшкән инде», — дип елмайдым мин.

Сөттәмени хикмәт?

Председатель, көндезге җил китереп ташлаган кайбер вак-төяк нәрсәләрне хәл итеп бетергәч, төп мәсьәләләрнең берсенә күчте:

— Димәк ки, иртәгә шефлар килә... шефлар! Бу юлы да күбесе хатын-кыз, ахры, җәмгысе өч йөзләп кеше ди. Биш-алты автобус белән. Димәк ки, бөтенләй яңгырга киткәнче, салам эскертләүне ипләп кенә...

— Өч йөзләп кеше! Ай-һай!..

— Ай-һайлыйсы юк, Ризван. Теге якшәмбе уттай егет башың белән үзең сынаттың. Җебемә! Сәнәк-тырмаларың җитәрлекме? Инде бу юлы да килгән халыкка карга санатып йөртсәң, чамала аны!

— Чамалыйсы юк. Җиткезербез!

— Ә син, Мөхи абый, — председатель кулындагы карандашны түшен киереп утырган агайга төбәде, — өйрәтүгә мохтаҗ түгелсең. Тик үзебезнең пекарнинының рәте киткән ди әле. Чаллыга бармыйча булдыра алмассың, ахры.

— Ай-һай, ипекәйне капчыгы-капчыгы белән кайсы кибет тоттырып җибәрер икән, ә?

— Кирәкмәгән җирдә авызың белән кош тотасың ич. Теленне җәлләмә, сандугачтай сайра: «Бер дә әллә кемгә түгел, үзегезнең халыкка, димәк ки, КамАЗны төзүче рабучи сыйныфка» диген. Аннан килеп, басуда казан асабызмы әллә? Бәрәңге җирләре янәшә генә бит. Тагы да сөт...

— Сөт дигәннән, үткәнендә хәйран да тамаша булган бит әле! — диде Мөхи агай, тез капкачын шапылдаткалап. — Өмәгә дип килгән хатын-кыз сөт белән битен-кулын юган. Чәчрәп китим! Имештер, алай итсәң, тән тиресен йомшарта. Әллә нихәтле сөтне күрәләтә җиргә сеңдергәннәр.

— Сөт беләнме? Битне-кулнымы?! — Әртил башлыгы бармак арасындагы карандашны өстәлгә атып ук бәрде, ак күлмәк изүенә ябышты. Ул да түгел, аның кырыендарак утырган баш бухгалтер сикереп торды, күзлеге чак төшеп китмәде:

— Мин дә ишеткән ием... Чын-чыннан безобрази! Без монда литрын литрга җиткезеп, чутка салып утырабыз, анда тән йомшарталар... Үзебезнең сыер савучылар ишетсәме? Адәм мәсхәрәсе!

Ишек төбендәге почмактан яңгыраган тавыш хәтта бухгалтер чәрелдәвен дә күмеп китте:

— Үзем күрдем: автобусларына шундый хушланып утырыштылар — прәме ихахай да михахай... Их, мин әйтәм...

Утка керосин сиптеләрмени — утырыштагылар дөрләп кабынды:

— Сөте сөт кенәмени, каймак бит ул безнең сөтләр! И шуны...

— Бушлай булгач, күктән яуган дип уйлаганнардыр.

— Үз акчаларына алган сөт белән шулай юыналар микән Чаллыда?

Баш бухгалтер, сөт турындагы сүзгә йомгак ясагандай, фикерен киңәш төсенә кертеп әйтте:

— Бу хәлләрдә шефларның өмәгә килгән һәр җан башына берәр чәки сөт тияр! Колхоз дигәч тә, ожмахтагы кәүсәр чишмәсе түгел лә ул.

— Дөрес!

Шул чак тәрәзә төбеннән берәү тамак кыргалады:

— Теге атнаны кемнәр килгәние? Җыен «керт тә ферт», жыен кантур халкы. Ә иртәгә кемнәр? Үзебезнең шефлар ич. Чын төзүчеләр, чын рабучи класс!.. Берәр чәки, имеш. Син нәрсә, сөтне аракы дип белдеңме әллә? Үзебезнең йөз каралмагае дим.

— Димәк ки... димәк ки...

Председатель тотлыгып калды. Иренен тешләштергәләде. Колак артын кашып алды. Аннары, тиле кеше кебек, тиктомалга башын селеккәләде. Ләкин тынлык озакка сузылмады, моңарчы дәшми-тынмый-чарак утырган чал мыеклы абзый, авыр гына кубарылып, председатель сүзен элеп алып китте:

— Димәк ки, болай: сөттәмени хикмәт? Әлбиттә, анысын жәлләмәбез. Йөз каралтырга ничу монда... Теге атнаны килгән халык көне буе бәрәңге тәгәрәтеп яттымы? Ятты. Үзебез гаепле: эшләтә белмәдек — болытта йөздердек. Тир түгеп, карыннары ачыкса идеме? Һе, сөт кенәме, әллә ниеңне йотарлар иде!

— Шулай, йотарлар ие! — дип жөпләде Мөхи абзый.

Әмма чал мыеклы агайның сүзе бетмәгән икән әле, ул, кәкрәеп катkан имән бармагын һавада болгатып алгач, аны үз күкрәгенә төбәде:

— Бусында үзем хужа булып йөрим килгән халыкка — вәссәләм! Ә Ризванмы? Жебегәнлек күрсәткән икән, әнә минем урынга урманга барып, кискән агачның исәбен жыеп кайтсын. Моннан ары кыз-кыркын янында йөрмәс мыек шәбәртеп кенә. КамАЗныкылар атчайный алар!

— Күрче, бу акбашыбызга тикле канын кыздырган бит! — дип гүләде ишек төбе. — Соң үзеңне карчыгың кунарга кертмәсә, нишләрсең, абзыкай?

— Минем өр-яңа ак мунчам бар.

— Дөрес, ак мунчасы бар,— дип баш какты председатель. Аның да калын кашлары тәмам язылып, иреннәре жәелергә тора иде. — Ризван турында тап авызымнан суырып әйттең, Сәет абый: урманга китәр. Димәк ки, мәсьәләгә нокта куябыз! Ә син, Сәет абый, бер дә хафаланма: булышмага үзем чыгармын. КамАЗның яшь-жилкенчәге тирәсендә бергә-бергә дигәндәй...

— Вәйт, ичмаса! Соң сине дә Мәймүнәң кертмәсә? — дип муенын сузды Мөхи.

— Менә бит, «ак мунча» ди... Шәт, мине дә сыйдырырсың әле, Сәет абый, ә?

— Кистереп әйтә алмам, энем прсидәтел. Үзем, дим, басудан иярtеп кайтмагаем. Безнең сөтләрдә йомшарган берәр чибәрен, дим...

Бүлмәдә снаряд ярылдымыни!..

Баш бухгалтерның дуамалланып ишекне теге яктан хәтәр шапылдатуы гына сыгылып төшкән халыкны беркадәр айнытып жибәрде.

Председатель авыз тирәсен жыя төште һәм, әйләнә кайтып, «мәсьәләгә нокта куярга» ашыкты:

— Димәк ки, туганкайлар, сөттә түгел хикмәт... Килгән халыкка карга санаттырмыйк — менә кайда хикмәт!..

Менә ул ике катлы таш бина. Һай, көләч тә соң үзе — ишекләре шар ачык, тәрәзәләре яп-якты!

Янәшәдә исә бүрәнәләрдән салынганы, искесе... Ул инде тәмам какшаган, хәлдән тайган, әмма ник яшерергә, ул бер үк вакытта горур да, шат та лабаса: иң олы, иң мөкатдәс хезмәттә — авылны нурландыруда ул инде бар булганын биргән. Мең рәхмәтләр сиңа, иске мәктәп!

Якында үтә эшлекле кыяфәт белән абзыйлар һәм апалар йөренә. Яңа мәктәп бинасын тапшыру-кабул итү мәшәкатенә чумганнар алар...

Биклән авылында олы тантана, Бикләндә зур бәйрәм бүген!

Олысы-кечесе, эресе-вагы — бөтен халык купкан — барысы шат-көләч!

Ә күк йөзе кырыс һәм ачулы. Аны авыр соры болытлар каплап алган. Менә тагын яңгыр коя башлар кебек. Инде тәмам туйдырган, эч пошыргыч салкын яңгыр...

Дәүләт комиссиясендәгеләрнең дә чырае кырыс һәм җитди. Бинаны айкап йөри бирәләр. Бүлмә артыннан бүлмә артта кала. Һәркайда пөхтәлек һәм яктылык. Борыннарны буяу исе яра. Кайберәүләр ипле генә атлаган шәпкә артларына борылып-борылып карый: ялт иткән идәннәрдә эзләре калмаганмы, янәсе....

Әйе, тагын өч көннән балалар мәктәпкә килер!

Комиссиядәге кешеләрнең йөзләре торган саен ачыла, мөлаемлана бара... Хәтта бер-берсенә каш сикертешүләрдән дә тартынып тормыйлар. Димәк ки, ярыйсы, әйбәт, шәп!

Әлбәттә, аерым житешсезлекләр дә килеп чыккалый. Мондый чакта төзүчеләрнең вәгъдә сүзләре яңгырап киткәли:

— Була ул... Эшләрбез... Теркәп куйдык!

Кай арада мәктәп дирекциясе, хәтта аерым укытучы да үз теләгән яисә үз тәкъдимен әйтүдән куркып тормый. Мәсәлән, физика кабинетында өстәмә розеткалар куйганда, бик тә уңай булыр иде, ди берәү. Мондый гына нәрсә төзүчеләр өчен нәрсә ул? Чүп ул!

— Ихтыярыгыз... Сез теләгәнчә итәрбез, алайса, — диләр.

Төзүчеләр бүген аерата күңдәм, юмарт һәм сөйкемле! Гажәп иркен спортзалны үткәч, булачак ашханә аша кухняга керделәр. Монда өр-яңа жиһазлар куелган. Һәркайсы ап-ак, һәркайсының никельләре ялт-йолт итеп тора — күзләр камаша. Авыл мәктәбендә мондыйларны күрү ничектер сәер дә шикелле... Мөгаен, күңелнең күнегәсе һәм ияләнәсе бардыр?

Генподрядчикларның башлыгы, әйләнә-тирәгә сынаулы карашын йөртеп чыккач, мәктәп директорына таба борылды:

— Безнекеләр монда тагын ике-өч көн булачак әле. Сезнең аш-су осталарыгызны шушы әйберләр белән эш итәргә өйрәткәндә, начар булмас иде. Өйрәнердәй кешеләрегез бармы?

Мәктәп директоры — өлкән яшьләрендәге укытучы апа — шундук ашыгып баш каккалады:

— Кешеләрме? Бар инде, бар! Бүген дисәгез — бүген, иртәгә икән — иртәгә ябышырлар...

Ул арада ишегалдында халык ишәйгәннән-ишәя барды. Күпләр, әлбәттә, мондагы төзелешне бер генә күзәтеп китмәгәндер. Ләкин шушындый да хикмәтле көнне янә килмичә, авыз ачып калырга ярыймыни?

Әйләнә-тирәсе рәшәткәләп алынган киң бакчада — шәһәрнекеләр чын-чынлап көнләшердәй бик зур аланда — жирне чүп-чардан тазартып, жыйнак кына бульдозер — «Беларусь» ыгы-зыгы килә. Берише адәмнәр, себеркеләрен жил-жил уйнаткалап, асфальт юлда тузан туз-

дыра, икенчеләре, яшьрәк кызлар, үз нурларын да кушып, мәктәп тәрәзәләрен ялт иттерә. Һәркайда күңелле шау-шу...

Иске мәктәп каршындагы алмагачлы бакчада исә икенчерәк күренеш. Монда олы тантанага әзерлек күрелгән: иң түргә, зур алмагач ышыгына табарак кызыл постаулы өстәл куелган, бер кырыйдарак матур гына стенд — монысында мәктәпнең үткән юлы гәүдәләнгән, әмь-яшел чирәмдә мәйданга рәт-рәт иттереп урындык һәм эскәмияләр тезелгән. Тик бакча хәзергә буп-буш әле...

Дәүләт комиссиясе, ниһаять, мәктәпнең иске бинасы эченә кереп югалды. Тиешле кәгазьләргә кул куясылары бар... Шактый озак тордылар. Четерекле хәлләр туып, бәхәс булып алган, күрәсең. Кайберәүләр ярыйсы ук кызарынып чыкты. Аерата мәктәп директоры — хөрмәтле укытучы апа кызарган иде. Артык дулкынланган, күрәсең. Комиссиядәге агай-энегә нәрсә? Чаллының үзендә дә, аның тирәсендәге авылларда да туып кына торган өр-яңа объектларда йөри-йөри тәмам шомарып беткән, хәтта, әйтергә яраса, «эт каешына» әйләнгән инде алар. Ә безнең директор апабыз? Аның үз җилкәсенә шушындый зур жаваплылыкны беренче тапкыр алуыдыр әле.

— Ярар, алайсам, башларбыз... Хәерле сәгатьләрдә!

Һәм менә инде бәйрәмнең иң кызыклысы, тантананың, кем әйтмешли, «үр түбәсе»...

Алгы рәтләргә авылның өлкән кешеләре утырышты. Күпшылар, һавалылар! Яшел чирәмле алан читенә дугайланып һәм тыгызланып яшьләр басты. Авыл халкы төзүчеләр белән кушылып бетте.

Сүзне иң әүвәл карт укытучыга бирделәр. Күп кенә гыйбрәтле һәм күркәм хәлләрне исенә төшерде. Озаклап һәм тәмләп сөйләде абзый. Аны завуч алыштырды.

Тын калып, кешеләр тыңлый, алмагачлар тыңлый!

Төзү трестының партоешма секретаре Дамир Зарипов аланны тәмам ялкынга урады. Сүзләреннән дәрт тә, төпле инану да бөркелеп торды:

— Биклән язмышында бу инде беренче карлыгач түгел һәм соңгысы да булмас, ләкин ул сезнең барыр юлларыгызны һәр чак яктыртып торыр... Озакламас, шушындый ук зур куанычлар бөек төзелеш тирәсендәге бар авылларга да дулкын-дулкын булып таралыр. Әйе, олы бәйрәмнәр күп көтелә әле, дуслар! — диде ул.

Мәйданга тигез сафларда дөнья гөрләтеп укучылар килеп керде. Барабаннар кагып, баян уйнатып... һәркайсының күкрәгендә кызыл галстук, сафлар алдында — ал байрак!

Иң ямьлесе шуннан башланып китте дә инде...

Ә югарыда соры болытлар куерганнан-куера бара сыман иде. Президиумда утырганнар әледән-әле күккә күз салгалый: тагын ява башлар микәнни, тантананы өзәр микәнни?

Укучылар уйлап та карамый: күктәмени хикмәт! Һавада шигырь артыннан шигырь яңгырый, ташкындай булып дәртле җыр агыла...

Яшьләр хакында әйткән дә юк, карт-корының да җыерчыкларына тикле балкый...

Менә инде беренче класска барырга әзерләнгән сабыйлар да керде. Тез аслары йомшарган, ахры: сафлары таркау, йөзләрендә курку, каушау галәмәте. Әмма шушы почык борыннар да тиз арада хәлгә килеп, җайга баса белде. Янә шигырьгә җыр кушылды, аннары шуңа бию ялганды... Бакчаларында ныклап әзерләнгәннәр, күрәсең, бәйрәмгә!

Председательлек итүче агай — район мәгариф бүлеге мөдире Әхсән иптәш Сәхапов — олы гәүдәсен калкытып, бер генә күтәрелмәде: янәсе, дускайлар, тамаша матурын матур да... озынгарак китмәдеме? Ләкин абзыкаең, аптыраганнан такыр баш түбәсен сыйпаштыргалап, кире үз урынына сеңүдән бүтән чара тапмый иде. Әйе, митинг әле тәмамланмаган. Ул бары тик зур концерт белән бүленгән генә: «бәй-

рәменә күрә чәчкәсе» дигәндәй. Әле алга таба «Жилстрой» башлыгы Зубченко белән колхоз председателе Ямалиевның, бер-берсен котлап, кочаклашасы булыр. Аннары СМУ вәкиле алтынсу йөгертелгән дәү ачкычны мәктәп директорына тапшырыр, ә монысы — безнең хөрмәтле апабыз — жавапка юньле-башлы сүз дә әйтә алмас, чөнки ул бүген чамасыз дулкынланудан хисләр йомгагына әверелгән...

Президиумда кайберәүләр инде урындык шыгырдата. «Башсантехмонтаж» кешесе «Жилстрой» инженерының кабыргасына төртеп, колагына пышылдый:

— Яна бит минем планерка!

— Ә безнең идарәдә киңәшмә. «Баш» үзе катнашмакчы иде... Балалар президиумдагыларның хәлен аңлыймыни? Алар «планерка, киңәшмә» дигәнне бар дип тә белми. Бетмәс шатлык дулкынында үзләре телә-гәнчә кинәнә бирәләр. Бу сәгатьтә жир дигән планетабызның бәләкәй генә шушы мәйданчыгында бары да аларга буйсына, бары да алар ихтыярында шикелле!

Президиумда кыбырсып утырган әлеге кешеләрнең берсе инде менә бүтәнчәрәк шыңгырдый:

— Ярар, ник чәнчелеп китми планеркасы!.. Болай булгач, банкетка да калам әле!

Банкет дигәне ашханәдә әзерләнгән. Колхоз идарәсенең төзүчеләргә сюрпризы. Ләкин күпләр сизеп алган инде моны. Уты барның төтене чыкмыймыни!

Ә монда, яшел чирәмдә, ике почык борын баян шашуына ияреп бөтерелепме-бөтерелә! Чүгәлиләр, сикерәләр, кул чәбәклиләр... Менә аларга ярдәмгә ике кызчык — ике күбәләк — атылып чыга. Биюләре бетмәстер, хәлдән таеп егылырлардыр кебек...

Бию тынуга, пионерлар сафыннан кайнар авазлар күтәрелде:

— Бездән төзүчеләргә мең-мең рәхмәт!

— КамАЗга да рәхмәтләр яусын! Ул безнең авылга шул хәтле тиз килә белде!

Ул да түгел, тагын да куәтлерәк бердәм тавыш, һаваны гөрселдәтеп, күкләргә ашты:

— Урак белән Чүкеч арасында дуслык ныгый бара, көчәя бара! Мәңге яшәсен Олы дуслык!

Алмагач ябалдашларыннан, яфракларны шыбырдатып, жил исеп үтте. Карт-коры бер төсле рәхәтлеккә чумган хәлдә баш каккалады, яшьләр йөзендә горур елмаю нурланды...

Ә күк?.. Күк инде чигенгән: соры болытлар тарала һәм чалара төшеп, менә-менә кояш балкып чыгар төсле иде...

Жәй азагының үтә караңгы чырайлы, үтә юеш август атнасында иң көләч, иң нурлы көннәрнең берсе булды бу Чаллы якларында...

Мәхмүт Газизов

Авырлык үзәге

Төзергә тотыныйк дигәндә,
эш янә бүленде бер тынга,
эзлисе, табасы бар икән
авырлык үзәген...
бетонда.

Карыйбыз, барлыйбыз төрлечә,
исәпкә хисаплар кушыла,
авырлык төшәсе үзәкләр
бит алар кайдадыр шушында.
Шушында төшәсе иң элек
замана йөгенең басымы,
какшарлык, чатнарлык түгелме,
тазамы нигезе. аслыгы?
Үзебез башлаган эшләрне
үзебез очларга тиешле,
әйтсеннәр соңыннан:
— Күр әле,
Һәр төше җыр төсле килешле!
...Табылды!
Терәкләр билгеле,
хәерле сәгатьтә, тизрәк, я! —
Беренче өрлекләр салынды
зур йөкләр төшәсе үзәккә.

Өрлекләр — өметләр,
аларга —
ышаныч, күпме күз карашы.
Ни кырсын таяныр ноктасыз,
ни корсын Җир-ана баласы?!

Сизми дә калганбыз, төн үткән,
яктырып килә ич, кара син! —
Без салган нигезләр өстендә
өлгерә тагын бер
яңа көн!

Лабиринт

Саласы, иплисе
никадәр торбаны!
Торбалар — шәһәрнең
җылы кан юллары.
Канаулар сузыла
бормалы-бормалы,
әбәткә туктады —
ял итә бригада.

— Егетләр, — ди берәү, —
менә бит тамаша:
безнең бу — җир асты —
лабиринт ләбаса!

Белмим, кем ни уйлый —
дәшүче булмады,
кемнең дә юллары
бормалы-бормалы.
Гомер дә — лабиринт,
теләсәң ничек ит —
кер дә бер очыннан,
адашмый чыгып кит...
Эзлисең, йөрисең
тукталып-тукталып,
кайчакта бөтенләй
каласың буталып.

— Башлыйбыз! —
кузгалды
һәркем үз эшенә,
керделәр кешеләр
лабиринт эченә...

Торбалар. Бормалар —
бер очтан бер очка,
сузыла лабиринт,
кушыла тормышка.

Шәһәрнең туган көне

Килде бәйрәм —
шәһәр туган көн!
Кызык икән халык йоласы —
көмеш тәңкә салдык, нигезгә
иң беренче ташны куйганчы.
Дала җирдә кала корганда,
бәйрәмнәр күп минем урамда:

адрес өчен каккан казыклар
биек йортлар булып үскәндә,
кешеләр тар вагон-өйләрдән
иркен бүлмәләргә күчкәндә
бәйрәм миңа,
квартир ачкычы
әйтерсең лә минем кесәмдә!..
Чулман-суда балык чиртсә дә,
кызлар эшкә җырлап үтсә дә,
«кызыл шимбә» көнне утырткан
яшь куаклар үсеп китсә дә,
бәйрәм килә минем урамга,
иркенәеп китә җырлар да.

Шат елмаеп, илне күрергә
кояш чыга һәрбер иртәдә,
кояш кебек якты чырайлы
дусларым бар гомер итәргә.
Бәйрәмнәр күп минем урамда,
ләкин дөнья бәйрәм, туй түгел,
җир хәтере ачы булганда
кырыкмаса-кырык уй минем...

Җирнең күкрәгендә һәр кала —
имчәк бала — имә, суыра,
нәрсә күрер, ниләр күрсәтер
үсеп зур булганның соңында?

...Бәйрәм бүген —
шәһәр туган көн!
Исән-имин халык йоласы —
изге теләк салдык нигезгә
изге булсын диеп бинасы,
изге булсын диеп дөньясы.

Баш уйлый таш турында...

Тимер-бетон багана
асылынды һавада...
— Баш өстеңә таш килә,
әй, дус кеше, чамала!

Күрми әле, ишетми,
китсә ыргак ычкынып,
качып котылу түгел,
өлгермәс тә кычкырып.
Улый мәйдан, гөж килә:
— Таш килә бит, таш килә!
(Нинди ир мин, нәрсә бу? —
тамак төпкә яшь килә...)

Күрде кеше: караса —
кояш тотыла лабаса!
Таш инде — баш турында,
Баш уйлый таш турында...

(Ак шәһәр шәп булачак,
йортлары төз — шәм кебек,
бу җирдән бит бер көнгә
китүең дә жәл кебек.
Баш өстендә таш тора,
әйтерсең таш кычкыра:
— Таш гасырдан бирле сез
безгә тынгы бирмисез!..)

Минуты ел тоелды,
таш узды, яшь йотылды,
бер — ноль! — безнең файдага
бетте язмыш уены.

Әнә ул — җирдә ята —
әлеге таш багана,
акылын җыя кеше
утыра да аңарга.

Уйлый булыр, мөгаен,
башыннан таш үткәнне,
ташларга патша булып
яшисе бар икәнне.

— Вира! —
күккә менәргә
бүтән ташлар чираты,
килә кран, элмәге —
сорау-билге сурәте...

●

Миңа уен-көлке дә, —
мәшәкать кыз кешегә:
яз килдеме, кызларның
сипкел чыга битенә...

Сипкел, сипкел сибелде,
ак шәһәр дә сипкелле:
сары-яшел балконнар
йортта сипкел шикелле.

Чынлап менә, икмәктер,
быелгы яз нишләптер
сипкеллерәк, гөллерәк,
сөйкемлерәк, хикмәттер!

Сере кайда соң дисәм,
бөтен хикмәт шул икән:
чәчәк тоткан, сипкелле,
янәшәмдә ул — иркәм!

Болынга бетон җәйгәндә

Үткән язлар, киткән казлар,
кайтыгыз дип, кайтыгыз,
кем җырлады, кайсыгыз?

Кем җырлады әрәмәдә
шәһәргә юл җәйгәндә —
яшел болын, хәтфә чирәм
бетонга әйләнгәндә?..

Җырчы кызның тавышында
ниндидер сагыш иде,
гүя моннан киткән казлар
үзләре тавыш бирде.

Шуннан ары нәрсә кирәк
чуалган зиһен өчен,
үсә дип тә, бетә дип тә
уйладым бөтенесен.

Үткән язлар кайтмаса да,
алда — өр-яңалары,
казлар гына нишләр менә...
тузыла оялары.

Күк мең катлы, каз канатлы,
җирдә җай да күп күбен,
язны казлар китермәсә,
кителер инде күңел.

Болынга бетон җәйгәндә
кем җырлады, кайсыгыз? —
казлар килсәләр, минем дә
көткәнемне әйтегез.

Таганда

Бәхет юра, матурым,
аймыл булма, егылма,
кызык та бит таганда,
уймак диләр уенда.

Таганыбыз шул менә:
эш-һөнәре бер генә —
күк белән җир арасын
бер төшә дә бер менә.

Уен шундый: чөелдең,
очарсың күк кояшка,
ул да булмый — иелдең,
катлы-катлы җир аста...

Айката да чайката,
таганда баш әйләнә,
җепләр — күңел җепләре —
чияләнә-бәйләнә.

Егылмадык моңарчы,
атынабыз һаман да,
без генәме, замана
үзе дә бит таганда!..

Бер таганга элəктек,
ялгыштырмы, чындырмы,
безнең болай булулар
бəеттерме, җырдырмы...

Тормыш — таган шул менə:
эш-һөнəре бер генə —
кайгы-шатлык арасын
бер төшə дə бер менə.

●

Вакытны күп төрле
эшкə җигеп була.
Җиргə бодай чəчеп
икмəк итеп була:
— ачка тилмергəннəр
күмəч ашасыннар!
Китап, каламə, дəфтəр,
мəктəп итеп була:
— язу белмəгəннəр
укый башласыннар!
Җылы өйлəр, авыл,
шəһəр итеп була:
— йорты булмаганнар
рəхəт яшəсеннəр!

əллə никадəрле
игелек көтеп була,
һəй, вакытны аны
тормыш итеп була!

Вакыт ике башлы,
кемгə кирəк кайсы:
бер башында — яман,
икенчесе — яхшы,
дилбегəсе монда
үзебезнең кулда!

Ə вакытны төрле
нəрсə итеп була...

Чаллы чатында

Булса булыр бу чаклы
«күч» сарылган юл чаты,
юл чатында, эш хастында
җирнең күпме ир заты!

Хəрəкəттə бəрəкəт,
һəр хəрəкəт — бер хикмəт:
чаба панеловозлар,
төзелешкə йөк илтə,
бара кызу тизлектə,
бар да кызу тизлектə.

Кабаланып бар көйгə,
егет белəн кыз килə,
өйлəнгəндə көн кыска,
ашыгалар загска —
эш сəгате беткənче
өлгерергə ничек тə!
Яшь кыз — кызу тизлектə,
язмыш — кызу тизлектə...

Тормыш, ахры, чатларда
үз тизлеген арттыра,
автобуска ул ənə
йөгертə бер картны да.

Кем йөгерə, кем чаба,
бөтенесе ашыга,
кая илтеп чыгарыр
заман аты — машина?

Хəрəкəт — катлы-катлы,
тизлек кызу, юл каты,
абынсаң да, бəрелсəң дə,
безгə булыр ояты.

Торам юллар чатында,
Яңа Чаллы каршында,
Чаллы чаты — чор чаты,
җырланмаган җыр чаты.

Рафис Хисамиев,
«Спецстрой» тресты эшчесе

Уҗым булып калка...

Күз күреме җитмәс киң кырларда
Яшелләнеп килә уҗымнар,
Игенченең язгы сөенечен
Ишетәм мин тургай җырыннан.
Мин дә кушылам аның моңнарына,
Куанычым — язгы ташудай.
...Игенченең җиргә мәхәббәте
Уҗым булып калка басуда.

●

Сиздермәскә тырышсам да,
Сөюем сизәсеңдер.
Чыныксын әле сөюнең
Утында диясеңдер.

Бер утка, бер суга атып
Бәгырьне теләсеңдер.
Корыч та — артык чыныкса,
Тиз сына, беләсеңдер...

Сәлимә Шәрипова,
кондитер фабрикасы эшчесе

●

Акчарлактай ак самолет,
Утыр әйдә, аппагым!
Синең әле канатланып
Дөнья гизәр чакларың.

Акчарлактай ак самолет
Очарга ярсып тора.
Ак күңелле дусларымны
Китереп-ташып тора.

Акчарлактай ак самолет
Офыкка кереп бара.
Ак яулыктай ап-ак йортлар
Ак бәхет теләп кала.

Тын чишмә

Тын авылдагы тын чишмә,
Елга түгел, күл түгел.
Данын дөньяга шаулаткан
Диңгезләргә тиң түгел.

Вак ташларга чүгеп кенә
Суларын эчим әле.
Шуның сихри көче белән
Диңгезләр кичим әле.

Челтер-челтер челтерәвен
Йөрәккәемә салыйм.
Дусларымның күңеленә
Тын чышмә булып агыйм.

КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Илебез матбугаты КамАЗ турында

АПРЕЛЬ, 1974 ЕЛ

Төзелеш яңа этапка — корпус эчләрендә интенсив эшләр, технологик җиһазларны монтажлауга әзерлек эшләре чорына аяк басты. Быел идәннәр генә дә миллион квадрат метр мәйданда җәелергә тиеш.

Төзелештә социалистик ярышның яңа формалары туа. Цехларда станокларга иң яхшы төзүчеләрнең һәм монтажчыларның исемнәре язылган җиз калайлар беркетү планлаштырылды. Гигант заводны төзүчеләрнең батырлыгы бу станокларда эшләүчеләргә һәр вакыт рух биреп торачак!

Ә мондый хокукка лаек булу җиңел түгел. Чын-чынлап ударникларча эшләргә кирәк. Мәсәлән, бертуган Майоровлар кебек.

Алар дүртәү: Валентин, Николай, Василий һәм Алексей. Алар — куәтле экскаваторның экипажы. Бер гаилә кешеләреннән торган бу экипажның эше бөтен илебезгә билгеле. Алар машиналарына шундый игътибарлы — ватылулар, техник җитешсезлекләр аркасында эшсез торулар бөтенләй булмый. «Бер минут та эшсез тормаска!» — Майоровларның девизы шундый. Алар һәр көнне бер ярым норма үтиләр.

КамАЗ — зур заводлар комплексы гына түгел, совет шәһәр кору тәҗрибәсенең иң яхшы үрнәкләрен үзенә туплаган яңа социалистик шәһәр дә.

Кама буенда күп катлы биналар өзлексез күтәрелеп тора. Шәһәр көннән-көн яхшыра. Соңгы вакытларда «Энергетик» культура сарае, яңа кинотеатр, 1200 урынлы тамаша павильоны төзүчеләргә ишекләрен киң ачты, КамАЗ культура сарае, балалар бакчалары, мәктәпләр, больницалар һ. б. объектлар төзелә. Әлбәттә, иң күп төзелгәне торак йортлар.

Хәзер автомобильчылар шәһәрендә 130 мең кеше яши, ә ел ахырында алар шактый артачак. Чөнки көн саен никадәр өй туйлары үткәрелә анда!

Шәһәр кору чын-чынлап бөтен халык эше булып әверелде. Бирегә илебезнең барлык почмакларыннан ташчылар һәм монтажчылар, бетончылар һәм малярлар килә. Бигрәк тә мәскәүләләр үз эшләре белән дан казаналар.

Б. Ковальский, А. Московцев, Л. Лобачева җитәкчелегендәге бригадалар чын-чынлап башкала төзүчеләре эшләгәнчә эшлиләр, алар зур осталык, хезмәтне төгәл оештыру, төзелештә индустриаль ысулларны киң куллану үрнәкләре күрсәтәләр.

«Волга» журналы.

8 апрельдә Чаллыга Америка Кушма Штатларының сәүдә министры Ф. Дент, АКШның СССРдагы илчесе У. Стессел, финанс министры урынбасары Д. Беннет, АКШ Дәүләт секретаре ярдәмчесе урынбасары Д. Армитейдис, төрле фирмаларның вәкилләре, журналистлар килде.

АКШтан килгән кунаклар төзелештә булдылар, кою заводы һәм КамАЗның башка объектларын, шәһәрнең төньяк-көнчыгыш өлеше панорамасын карадылар, ремонт-инструменталь завод цехлары белән таныштылар.

КамАЗның генераль директоры Л. Б. Васильев тарафыннан үткәрелгән мәҗлестә Ф. Дент үзенә һәм юлдашларына төзелештәге зур темплар һәм аның киң колачы белән башкарылуы зур тәэсир калдыруын әйтте.

Шул ук көнне Ф. Дент, У. Стессел, Д. Беннет, Д. Армитейдис һәм аларның юлдашлары Мәскәүгә очтылар.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

...Төньяк, Себер, Ерак Көнчыгышта табигый байлыкларны һәм чирәм җирләрне үзләштергәндә яшьләрнең фидакарь хезмәт батырлыгын Совет халкы тирән рәхмәт хисләре белән билгеләп үтте. Ә менә күптән түгел партиянең яңа гаять зур төзелешкә — Байкал — Амур тимер юлы төзелешенә актив катнашырга чакыруын комсомол кайнар рәвештә кабул итте.

Без нык ышанабыз, комсомоллар, яшьләр бу бөек төзелешкә үзләреннән лаеклы өлеш кертерләр. Комсомольск, Магнитка һәм Турксиб, Днепрогэс һәм КамАЗ эстафетасын алар Себернең әлегә үзләштерелмәгән киңлекләре аша илтәчәкләр.

Л. И. Брежневның ВЛКСМның XVII съездындагы реченнән.

КамАЗның киногруппасы «КамАЗ» автопоездларының Забайкалье юлларында сынау үтүен карап кайтты. КамАЗның Үзәк кинофотолабораториясе редакторы Г. Седова сынау эшләренең барышы турында сөйләде.

Забайкалье сынауларының төп геройлары — комсомолецлар — сынаучы шофер Николай Сидоров белән контролер Борис Диковский — үз эшләренә керешәләр. Мәскәүдәге Лихачев исемендәге заводның иң яхшы шоферы-сынаучысы Сидоров житез һәм җиңел эшли. Ул армиягә кадәр үк һәм армиядә дә машиналар йөрткән. Ә армиядән соң сынаучы булып Лихачев заводына эшкә кергән.

«КамАЗ» машиналарын инде ул дүртенче ел сыный — җитди эш, кызыклы һәм романтик эш. «Кырым юлларында тормозларны сынау бик кыен булды»,— дип искә ала Николай.

Диковский 1971 елда Казан авиация институтын тәмамлый һәм авиация двигательләре буенча инженер-механик дипломы алып чыга. Аннары КамАЗга китә — үзе генә түгел, аның белән тагын утыз комсомолец китә. Борисны баш конструктор бүлегенә инженер-сынаучы итеп эшкә урнаштыралар.

Борис яңа машиналарның беренче серияләрен үк сынауда катнаша. Хәзер инде дүртенче сериясен сыныйлар... 1973 елда «КамАЗ» машинасының дүртенче сериясе дәүләт сынавын үтә. Борис аңа да катнаша.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Вильнюстагы «Коммунарос» станок төзү заводы коллективы КамАЗ өчен универсаль фрезер һәм башка станокларның зур партиясен җибәрде. Заказ срогыннан ике айга элек үтәлде.

Фрезер станоклары конструкциясенә предприятие новаторлары күп кенә камилләштерү үзгәрешләре керттеләр. Бу үзгәрешләр станокларның вибрациясен бетерергә, детальләр эшкәртүне зур төгәллек белән башкарырга мөмкинлек бирә...

ТАСС, Вильнюс.

22 апрельдә Чаллыга Польша берләшкән эшчеләр партиясенең Үзәк ревизия комиссиясе председателе А. Лашевич җитәкчелегендә партия делегациясе килде.

КПССның Чаллы шәһәр комитетында очрашуда партия шәһәр комитетының беренче секретаре Р. Беляев Польша кунакларына Кама автомобиль комплексы төзелешенең барышы турында сөйләде.

Польша кунаклары зур кызыксыну белән КамАЗ һәм шәһәр төзелеше мәйданнары белән таныштылар, автогигантның беренче карлыгачы — РИЗда булдылар.

«Советская Татария», Казан.

ВЛКСМ Үзәк Комитетының пропаганда-художество группасы Чаллыда булып китте. Группа составында Советлар Союзы Герое генерал-майор Г. Б. Петерс, СССР җыелма хоккей командасының элекке атаклы уенчысы В. Якушев, «Октябрьский» клубы каршындагы «Московские ребята» вокаль-инструменталь ансамбле членнары бар иде.

Алар төзелеш мәйданнарында, бригадаларда, тулай торакларда, автомеханика техникумында, ремонт-инструменталь заводында, «Энергетик» культура сараенда төзүчеләр һәм эшчеләр белән очраштылар.

* * *

«Энергетик» культура сараенда «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенең тулай торакларындагы үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсы тәмамланды. Конкурска биш үзешчән коллектив катнашты. Тамашачылар Галия

Шәймөхәммәтова башкаруында башкорт биюен, Галина Тимченко белән Владимир Смирновларның мәзәк такмакларын, Юрий Кощеевның сәнгатьчә укуын аеруча ошаттылар.

Үзешчән артистларның иҗади конкурсларын үткәрү Чаллыда матур традициягә әверелде.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Интернациональ дуслык клубындагы очрашу вакытында Германия Федератив Республикасы сәүдә фирмасы вәкиле ремонт-инструменталь заводының комсомол-яшьләр сменасы начальнигы Володя Потаповка шундый сорау бирде:

— РИЗда Голландиядән килгән фрезер станок-автомат ничек эшли?

Володя болай дип җавап бирде:

— Яхшы гына климатлашты.

— Моңа күпме вакыт кирәк булды? — дип, кызыксынуын дәвам итте чит илдән килгән белгеч.— Бездәге эшчеләр бу станокны бары тик ярты ел эчендә үзләштерәләр. Бу срокта сез үзләштерә алдыгызмы?

— Әлбәттә,— дип елмайды Потапов.— Кызганыч, бүген монда Юра Авдеенко юк. Ул ярты ел эчендә мондый ничә станокны эшләтә башларга мөмкин булуын төгәл әйтер иде. Чөнки Юра бу станокны бары тик егерме көн эчендә үзләштерде.

— Кызганыч,— диештеләр егетләр, кайтып барышлый.— Володя җавабыннан соң бу әфәнденең ничек бот чабуын Юра үзе күрмәде. Ул әфәнде, мәгаен, бу станокны эшләтү өчен еллар буе азапланалар булыр болар, дип уйлагандыр...

«Комсомолец Татарии», Казан.

«Энергетик» культура сараеның өченче катындагы холлда төзелештәге тормышны сурәтләгән рәсемнәр күргәзмәсе ачылды. Аларның авторлары — СССР художниклары союзы членнары — Чаллыга еш киләләр. Дәүләт премияләре лауреаты, сәнгать профессоры К. М. Максимов җитәкчелегендә бер төркем рәссамнар хәзер дә биредә. Чаллы кешеләре күргәзмәне кызыксынып карый.

* * *

В. И. Ленин исемендәге комсомолның 50 еллыгына багышланган «Комсомол җыры» дигән бөтенсоюз фестиваль-конкурска КамАЗ төзүчеләре арасыннан күп кенә сәләтле үзешчән коллективлар катнашты. «Минмонтажспецстрой» берләшмәсеннән «Яшь тавышлар» ансамбле, «Автозаводстрой» берләшмәсеннән «Нәфислек» ансамбльләре һ. б. коллективлар уңышлы чыгыш ясадылар.

* * *

Рәсем, скульптура, графика сәнгате әсәрләре — йөз дә ике хезмәт — боларның барысын да Чаллы музеена РСФСР Культура министрлыгы бүләк итте. Аларның күбесе хезмәт кешеләренә багышланган. Мәсәлән, М. Негинаның «Төзүче кыз» скульптурасы, С. Перфильевның «Эшче», В. Панкратовның «ВАЗ эретеп ябыштыру остасы А. Морев портреты», Л. Носовның «Эшче ялы», Н. Костинаның «Уралмаш»ның хезмәт яшьләре» һ. б. әсәрләр шундыйлардан. Чаллы хезмәт ияләре сәнгать осталарының әсәрләрен зур кызыксыну белән карыйлар.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Күптән түгел Бигеш аэропорты беренче «ТУ-134» рейс самолетын кабул итте. Бу авиалайнер 1 сәгать 35 минут эчендә Мәскәүдән 75 пассажир китереп җиткерә. «АН-24» самолетында 43 пассажир өчен шушы ук араны үтәргә 2 сәгать 40 минут вакыт кирәк.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Геннадий Паушкин

ЧАЛЛЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

КамАЗга килә кешеләр

I

Ни генә җитми инде аларга? Кояшны, саф һаваны, җиләк-җимешне калдырып, каядыр Татарстанга ашкыналар...

— Иң мөһиме шунда: аларны бит беркем дә чакырып тормый. Шулай бит?

— Әйе, шулай, — дип җавап бирде Шемякин һәм күзләрен вагон тәрәзәсенә төбәде.

Юлның башы бик уңышлы булмады. Каменная Балка белән Благодарный арасында юл бик пычрак иде. Автобус әллә ничә тапкыр батып ятты. Тягачлар белән сөйрәп чыгарырга туры килде. Ничек кирәк алай Пятигорскига кадәр барып җиттеләр. Шунысы әйбәт булды: поездны озак көтәргә туры килмәде, буш урыннар бар иде. Тик Виктор белән икесе ике купега туры килде.

«Купеда хатын-кызлар булудан да начары юк инде,— дип уйлады Шемякин.— Кассада нигә инде шуны искә алмыйлар — бер купеда ирләр булсын, икенчесендә — хатын-кызлар. Кадак өстендә утыргандай утырасың... Виктор Смоляниновның да хәле шундый ук. Кайчаннан бирле инде коридорда вакыт уздыра. Ә купеда бер хатын иртәнге ашын ашый, киемнәрен алыштыра, бизәнә.

Ул тәрәзә янына утырып ялгышты. Купедаш хатын-кызлар әллә нәрсәләр сорашып хәзер аның теңкәсенә тияләр.

— Семьяң бардыр, мөгаен?

— Бар, — дип җавап бирде Николай. Чыгып китәргә уйлаган иде дә янында утырган чал чәчле парик кигән ханымны борчырга уңайсызланды.

— Семьяларын калдырып, кая тели шунда китәләр. Ышан син хәзерге ирләргә... Акча эшләргәдер инде.

— Уздырып җибәрегез әле,— диде Шемякин.— Тартып керәсе иде...

Артыннан сөйләнеп калдылар:

— Тагын бер төзелеш башланган, ди. КамАЗ.

— Кайда соң ул?

— Кама елгасы буенда, ди. Урман эчендә. Барсаң барыр, кайтсаң кайтыр юлы юк, ди.

— Яшьләргә ярый инде. Ә моның бит семьясы бар. Иптәш кешесе дә аның малайшалай түгел.

Поезд тизлеген арттыра бирде. Кардан арынып бетмәгән ала-кола басулар артка йөгерде.

— Нигә алар сиңа бәйләнәләр? — дип сорады Виктор, күзен тәрәзәдән алмыйча гына.

— Курорттан кайтып киләләр. Кояшлы көньяктан кырыс төньякка күчеп барганга жәлләгән булалар...

Мәскәүдә алар тукталып тормадылар — танышлар юк, һава хәле дә шәп түгел: буран, кар ява. Туп-туры үз поездларына утырдылар. Ярты тәүлектән артык баргач, Можга дигән кечкенә генә бер станциядә төшеп калдылар. Әмма Алабугага йөри торган автобус киткән иде инде. Шундагы гостиницада төн үткәрергә туры килде...

Март ае булса да, яз килеп житмәгән әле монда. Юлны кар күмгән. Автобус көчхәл белән генә Алабугага барып житте.

Юлда Саша исемле бер Чаллы егете белән таныштылар. Военкомат янындагы бер йортта әнисе белән генә тора икән. Үз йортларында. Кая барырга, эшкә урнашу өчен кемгә мөрәҗәгать итәргә кирәген әйрәтте.

Яшь камазлы.

В. ИГНАТЬЕВ рәсеме.

Кама елгасын боз өстеннән жәяүләп кичтеләр. Борынгы шәһәр. Бер-ике катлы иске йортлар. Урамнар тар. Сашалар өенә керделәр. Саша юлдашларын әнисе белән таныштырды. Әнисе, эшкә урнашканчы, әйберләрен үзләрендә калдырып торырга риза булды.

— Әллә нәрсә калдырыр әйбер дә юк инде,— диде Шемякин.— Менә бер чемодан.

— Ярый әле, — диде аңа каршы Саша, — юлга тун киеп чыккансың. Монда көньяктагы кебек түгел.

Тамак ялгап алганнан соң, КамГЭС поселогына киттеләр. «Дүрт тә ике» йортын эзләп таптылар. Кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать итмәкче булдылар. Кая анда: урамда демонстрация диярсең — сигез йөзләп кеше чират тора.

Нинаять, чират аларга да житте. Бөдрә чәчле бер егет аларның һөнәрләрен сорады.

— Безгә шоферләр кирәкми, — диде ул. — Ташчылар, бетончылар, балта осталары кирәк...

Кадрлар бүлегендә дә эшләр уңмады. Урамга чыктылар. Куну мәсьәләсен хәл итәргә кирәк иде.

— Сез бала-чага түгел бит, — диде бер егет. Куртказының аркасына аның зур хәрефләр белән «Братск» дип язылган иде.— Илнең барлык почмакларыннан кеше агыла. Һәркемгә квартир өлгертерлекме. Кызыл почмакларда да балалары белән торалар. Ә сезне чакырып китерделәрме соң?

— Юк?

— Алай булса, юкны бушка әйләндереп йөрисе дә юк...

— Әйдә, алайса, Саша квартирасына киттек,— диде Смолянинов.— Калыргамы, китәргәме икәнен шунда хәл итәрбез.

— Әйе, — диде Николай, аптырап. — Поездда килгәндә теге хатын әйткән дөрес икән. Безне монда беркем дә көтеп тормаган.

— Эшләр ничек соң? — дип каршы алды аларны Саша.— Тәртиптәме?

— Юк,— диде Шемякин.— Кайтып китәрбез, ахры.

— Шул кадәр ерактан килепме? Ашыкмагыз. Йөрегез, кешеләр белән сөйләшегез.

Саша (татарча исеме Мәдәррис) үзе төзелештә эшли, әнисе янында түгел, хатыны белән «Автозаводец» поселогында вагонда тора икән.

— Иртәгә иртән үк район элемтә үзәгенә барыгыз,— дип киңәш бирде Саша.— Аннан завод төзелешенә вахта машиналары йөри.

Иртәгесен «РИЗ»га бара торган машинага утырдылар. Нәрсә соң ул «РИЗ». Ремонт-инструменталь заводы. Биредә андый атамаларның барысын да баш хәрефләр белән генә әйтәләр. «БСИ», «МТС», «ДСК».

— МТСлар да бармыни әле? — дип гаҗәпләнде Смолянинов.

— Бездә бар,— диде Саша, көлеп.— База материально-технического снабжения. БСИ — база строительной индустрии.

— Кара син аны! Монда барысына да төшенү өчен күнегергә кирәк икән.

— Әле күптән түгел район конференциясендә авылдан килгән бер вәкил сөйләде. КРС та КРС ди.

— Нәрсә соң ул «КРС».

— Шуны да белмисеңме? Крупный рогатый скот — мөгезле эре терлек.

— Димәк, кыскартып сөйләү бер бездә генә түгел.

— Ә «РУС»ка ничек барасы.

— Военкомат янына чыгасы да икенче автобуска утырасы. Ун минутта барып җитәсең.

Военкомат янында брезент куртка кигән егетләр-кызлар автобусларга чират тора. Ике-өч автобусны уздырып җибәрергә туры килде. Хәер, аларга кая ашыгырга — төзелештә көтеп алмадылар бит аларны.

Бары да КамГЭС поселогына бара. Киң проспект, биш катлы йортлар...

Район элемтә үзәге бинасы янында автобустан чыктылар. Әлмәт тракты буйлап йөк төягән «БелАЗ»лар, «Краз»лар туктаусыз агыла. Барысы да каядыр ашыга.

Шемякин белән Смолянинов поселок буйлап җәяүләп кенә атладылар.

Сидоровка авылына кадәр бардылар. Завод корпуслары төзелешенә җиттеләр. Менә кайда икән ул КамАЗ.

Орловка авылы тирәсендә иксез-чиксез мәйданда җир казу эшләре бара. Кешеләр күренми. Кая карама — бульдозерлар, скреперлар, экскаваторлар.

Бер бакча аркылы үтеп, җир казучылар янына килеп чыктылар.

— Монда нинди дә булса объект төзелә булса кирәк,— диде Смолянинов.

— Эшләр уң булсын! — дип сәламләде Николай.

— Бергә булсын! Кая юл тоттыгыз, егетләр.

— КамАЗга!

— КамАЗга икән, кою заводына барыгыз, ә монда без ТЭЦ өчен котлован казыйбыз.

Прораб бүлмәсен эзләп таптылар, прораб Анатолий Исакович Гриншпун — үзе үк участок начальнигы һәм мастер — эшчеләр кирәген, әмма хәзергә торак урыны булмавын әйтте.

— Үзегез кайда да булса урнашып торыгыз инде,— диде.— Озакламый вагоннар килеп җитәр дип көтәбез.

Аларны Дипов бригадасына җибәрделәр. Башта үк искәрттеләр: ул тәҗрибәле һәм кырыс кеше, фронтовик.

Александр Андреевич Дипов җитди итеп аларны тыңлады, аннан чыраен сытты:

— Миңа шоферлар кирәкми кирәген. Аларда әллә ни өмет юк.

— Качып китмәбез,— дип елмайды Шемякин.

— Кайчан да булса балта тоткаңыз бармы?

— Леспромхозда эшләгән идем. Төрлесе булды.

Бу ике дусны Дипов бригадасына икенче разрядлы бетончы-балта остасы итеп эшкә алдылар.

Александр Андреевич Дипов үз сүзендә нык тора торган булып чыкты. Әлбәттә, хәтта ун сәгать рәттән машина рулен боргалау көрәк белән бетон бушатуга караганда бик күпкә җиңелрәк иде.

Бетон килде, ә кранчы авырган. Ә Дипов бетонны кабул итте. Бетон машиналарын кире җибәреп булмый бит инде. Бригаданың барлык членнары көрәккә тотынды.

Өч сәгатьләп эшләгәч, Николай шабыр тиргә батты. Беләкләр, җилкәләр авырта, күз алларында кара бөжралар уйный. Ә аның янында гына яшь кенә, чандыр гына бер егет эшли. Ару-талуның галәмәте дә күренми.

Егет аңа үз тәҗрибәсен өйрәтергә кереште.

— Кабаланма. Уңайлы урын сайлап урнаш. Баштарак миңа да җиңел булмады. Син кайдан? Ставропольдән. Мин армиядән туп-туры КамАЗга кайттым. Чик буенда хезмәт иттем. Таныш булыйк: исемем — Федор, фамилия — Брыляков...

Атна буе бик авырга туры килде. Аяклар эштән кайтканда чуен кебек авыр. Ә бүтән егетләрнең исләрендә дә юк — җырлап, уйнап-көлеп кайталар.

Бригада егетләре аларның хәленә керде: тулай торакта үз яннарына урын җайладылар: «Күңелең киң булса, кысан урынга да сыясың!»

Ике атналап эшләгәч, рәсми рәвештә трестка эшкә алдылар, прописка керергә рөхсәт бирделәр...

Нинаять, алар торасы вагоннар да килеп җитте. Су керттеләр, җылылык керттеләр, канализация трубалары урнаштырдылар. Бу вагоннар ерактан караганда тупикка урнаштырылган поездны хәтерләтәләр. Һәр вагон ике семьяга исәпләнеп ясалган. Энтузиастлар поселогында көпчәкләреннән алынган, түбәләренә телевизор антенналары менеп кунган мондый вагоннар дача йортларына охшап утыралар.

Смолянинов та, Шемякин да семьяларын бирегә чакырдылар. Ике семья бер вагонга урнашты.

Саша — Шемякинның кечкенә улы — вагоннарны күргәч, кычкырып җибәрде:

— Ура!.. Автобуста яшибез икән. Шуның белән су буена да төшәрбез!..

Җитмеш беренче елның икенче яртысы иде бу вакыт. Әле автозаводның нигезен генә салалар иде...

II

«АН-24» самолетына утырып Казаннан Бигеш аэропортына ярты гына сәгать оча сы. Аннан такыр, туры магистраль Чаллыга китә. Миңа Чаллы тирәсендәге далалар яхшы таныш: анда кышын сәякләргә үтәрлек салкын җил тынып тормый. Шуңа күрә өскә кат-кат киендем. Әмма шунысы бар: кырык градуска җиткән салкында монтажчылар эшлиме икән? Бигрәк тә югарыда эшләүчеләр. Балта осталары, бетончылар, кран машинистлары да эшкә чыктымы икән?..

Төзелеш мәйданы гаять зур — аны бер көндә генә әйләнеп чыгып булмый. Объектка барасың, кирәкле кешеңне эзләп табасың — әллә никадәр вакыт уза. Ә аның эше күп. Әйтәсе дә юк инде — әллә никадәр мәшәкать. Биредә фронттагы кебек: алгы сызыкка килдеңме, солдат язмышын уртаклаш.

Без Чаллыга автобуста мәскәүләләр белән килдек. Алар — «Современник» театрында эшләүче электриклар. КамГЭС поселогында, шәһәр башкарма комитеты янында төштек.

— Инде хәзер кая?

— Гостиницага заказ биргән идегезме?

— Әйе, Мәскәүдән сөйләшкән идек.

— Алай булса, өйдәгез. Минем белән.

Проспектның ахырына кадәр барырга кирәк. Ә егетләрнең өсләрендә көзге пальто, аякларында ботинка. Йөгереп диярлек бардык.

— Ә мондагы культура сарае ничек?

— Менә дигән, — дип җавап бирәм.

— Ә сәхнәсе?

— Сәхнәсе дә. Бәхетле Чаллы кешеләре. Культура сарае эшли башлаганга ике ай да юк. Кемнәр генә булмады инде анда: Гуляев та, Зыкина да, Огневой да, чех ансамбле «Клара Вита» да. Менә хәзер «Современник» килә.

...Тәрәзәдән таныш пейзаж күренә. Каршыдагы калкулыкка кар түшәлгән. Калкулык түбәсендә — ике иске агач йорт. Аннан ары биш катлы йортлар тезелеп киткән. Уң якта — балалар бакчасы шәһәрчеге.

Кичен «Металлургстрой» идарәсе парткомы секретаре Виктор Иванович Ермашовка шалтыраттым. Виктор Иванович иртәгә җиде сәгать утыз минутта кою заводы төзелеш мәйданына килергә чакырды. Шемякин бригадасы да элек шунда эшли иде.

— Ул һаман шундамыни? — дип сорадым.

— Килгәч күрерсең.

Шемякин фамилиясе — сезгә билгеле инде — миңа күптән таныш. Аның турында күп укыганым, күп ишеткәнем бар.

«Коммунистик хезмәт ударнигы».

«КамАЗ төзелеш ударнигы».

«1973 елда социалистик ярышта җиңеп чыкты...»

III

Газик такыр бетон юл буйлап элдертә генә. Мин тәрәзәдән тирә-юньне күзәтәм. Әле тегендә, әле монда узган юлы килүемдә булмаган яңалыклар күзгә чалынып кала. Монда җәяү йөрсәң адашуың бик тә тиз — ориентирлар инде үзгәргән.

Виктор Иванович дәшми. Ниһаять, ул алдагы төзелеш мәйданына ымлый — кою заводы. Ике корпусның инде түбәләре ябылган, төсле металлар кою цехы монтажланып ята. Дүртенче корпусның нигезен салалар...

Завод корпусларына җитәрәк машина сулга борылды, зур котлован янына килеп туктады.

Без котлован кырыена килдек. Котлован төбенә вак таш һәм ком түшәлгән, уң яктан бетон коеп киләләр. Шул тирәдә өсләренә җылы сырма кигән берничә кыз йөри.

— Шемякин бригадасы биредә эшли инде,— диде Виктор Иванович.— Яннарына төшикме?

— Әлбәттә,— дидем мин. Котлованның аргы ягында бер кечкенә вагон күрдем. Суык бик куыра башласа, шунда кереп җылынып чыгарга була.

Без текә ярдан тигез мәйданга төштек, аяк астында бозлы вак таш шыгырдый.

— Менә Шемякин шушы үзе була инде,— дип, Виктор Иванович ак йөзле бер егет белән таныштырды. Өстенә сырма кигән урта буйлы бу егет башкалардан берни белән аерылмый — хәтта ни аркасына, ни җиңенә «КамАЗ» эмблемасы да тагылмаган.

Таныштык. Әгәр дә үзем генә килгән булсам, бу егетне бригадир дип һич тә башыма китермәгән булыр идем. Гади бетончы дип уйлар идем. Ә бит аның бригадасы атаклы, СССР ның 50 еллыгы исемен йөртә.

Чаллыда булган кеше белә: КамАЗ төзүчеләр курткасында гына да илебезнең бөтен географиясе диярлек ярылып ята. Аркаларында, бер җилкәсеннән икенче җилкәсенә кадәр, һәр төзүченең кайдан килгәнлеге язылган. Ә Шемякин, әйткәнемчә, әле «КамАЗ төзүчесе» дигән мактаулы исемгә лаек булып җитмәгән өйрәнчек эшчене хәтерләтә.

— Әле монда килдек кенә,— диде Шемякин.— Моңа кадәр РИЗда төп подстанцияне урнаштырган идек. Хәзер биредәге блокны урнаштырабыз.

— Бу блоктан башка,— дип өстәде Виктор Иванович,— кою заводы эшли алмаячак.

Без зур чокырның төбендә торабыз, ә чокыр ярларыннан су саркып чыга. Насослар эшли, кая карама анда, елан кебек булып, шланглар сузылган...

— Ә бу су каян килә?— дип сорадым мин.— Шундый салкын, ә су һаман саркып тора.

— Кайдандыр, якын тирәдән Каманың иске ерганагы уза, Чаллы елгасы да якында гына. Менә шулардан су монда килә... Завод корпуслары да җиргә басым ясый, суны кысып чыгара. Ә су, коега җыелган кебек, котлованга җыела.

Сүзне Ермашов алды.

— Без озак баш ваттык,— диде ул.— Бу объектны кемгә тапшырырга дип. Монда бит төгәл исәпләү, фикер йөртү генә җитми. Тәвәккәллек, егетлек тә, коллективның бердәмлеге дә кирәк. Шемякинның комплекслы бригадасына туктадык. Эшне гамәлгә ашырыр дип ышанабыз.

— Ә салкын комачауламыймы?— дип сорыйм мин Николай Шемякиннан, калын бияләй кигән кулларын бер-берсенә шапылдатучы кызларга ымлап.

— Тагын да салкынрак булсын иде әле,— дип елмая Шемякин.— Менә икенче генә көн әле нормаль һава саклана.

Ташчылар бригадиры Г. ГЕВОРГЯН. В. ИГНАТЬЕВ рәсеме.

— Кырык градус нормальмы? — дип гаҗәпләнәм мин.

— Их, тагын бер ун көн һава шулай торса иде! Никадәр эш башкарыр идек.

— Ә ничек бетонлыйсың?

— Кызлар үз эшләрен яхшы белә. Әнә Җәмлиха Юсупова белән Нина Костикова. Менә дигән белгечләр.

Чокыр төбендә өстәгегә караганда да салкынрак шикелле. Анда җил өрсә дә, машиналар гөрелтесен ишетәсең, хәрәкәт, электросваркалар утын күрәсең. Ә монда боз мәгарәсендәге кебек. Әледән-әле бөтен тәнең белән калтыранып куясың.

— Без монда килгәнче,— ди Шемякин,— бу тирәдә үле тынлыгы иде.

«Әйе, дип уйланам мин, СМУ-1 механизаторлары эшләрен тәмамлаганнар, чигенгәннәр, судан куркып алгы сызыкны калдырып киткәннәр. Ә Шемякин бригадасы прорывка ташланган. Әйе, Виктор Иванович әйткәнчә, биредә аерым кыюлык һәм фидакарьлек кенә җитми, бердәмлек кирәк, һәр вакыт бер-береңнең җилкәсен тоеп эшләү кирәк».

— Әйдә, вагонга менәбез,— диде Виктор Иванович.— Анда сөйләшергә уңайрак.

Агач баскыч ачык грунт өстенә салынган, өскә үк җитү өчен өч ярус менәргә кирәк.

Шемякин бульдозеристлар белән сөйләшеп аста калды.

— Шемякин җитмеш икенче елның февралендә бригаданы кабул итеп алды,— дип сөйләп китте Ермашов. — Башта звеньевой иде. Бу эш тә җиңелдән түгел. Аннары бригада тәкъдим иттеләр. Чөнки егетнең «котелок» шәп эшли, тырышлыгы да зур...

Шемякин бригадасы — комплекслы бригада. Ни дигән сүз соң ул «комплексы бригада»? Элек шулай иде: берәүләр әзерлек эшләрен башкара, аннан икенчеләре бетон коя, аннары өченчеләре монтажлый. Бер-берләрен алыштырганчы вакыт уза, эшнең сыйфатына да әллә ни игътибар бирмиләр. Балта осталарының бетонда, тимер эшләрендә гаме юк. Үзләренекен генә беләләр. Шемякин бригадасы объектны заказчикка тапшырганчы барлык эшләрне үз өстенә алды.

— Злобин методы буенчамы?

— Шулай булып чыкты. Әмма Шемякин бригадасы бу эшне башлаганда Злобинның исеме дә, методы да билгеле түгел иде. Шемякин бригадасы субай нигезләр коруда эшләп «нуль» отметкасыннан алып нигезне монтажчыларга тапшырганчы барлык эшләрне башкарды. Аннары Шемякинның удар комсомол отряды РИЗда эшләде: җылылык үткәрү өчен кабель тоннельләре корды. Объектны тапшыргач, менә монда килделәр...

— Прорывкамы?

Шулай дисәң дә була. Кою заводын ходка җибәрү өчен шушы блокны өлгертергә кирәк. Аны графиктан алдарак өлгертү зарур. Үзең күрәсең: бригада нинди шартларда эшли. Һәр көн, һәр сәгать су белән көрәш алып барырга кирәк. Ә җылы көннәр башлангач, нәрсә булыр? Кою заводы төзелешендә бу объект иң катлаулысы, иң киеренкесе...

Вагонда җылы, тимер мич агарганчы кызган. Без, бүрекләрне салып, өстәл янына утырдык. Мин онытылганчы Виктор Иванович сүзләрен язарга дип блокнотымны чыгардым. Әмма Шемякин килеп керде. Ермашов аны минем каршыга утыртты.

— Ул үзе тулырак сөйләр, — диде.

...Шемякин Хабаровск краенда туган, сигезьеллыкны бетергән. Һөнәр мәктәбе, энергомаш заводы. Токарь... Тын океан флоты. Флоттан ата-анасы янына, Хабаровск

краена кайта. Әтисе леспромхозда механик булып эшли, әнисе почтада. Шоферлар курсында укып, урман ташый. Өйләнә. Хатыны — урта медицина белгече — больницага эшкә урнаша. Уллары туа. Әмма аңарда үпкә авыруы башлана — салкын тия. Яшь ярым вакытта. Климат алмаштырырга туры килә. Кырымгамы, Кавказгамы китәргә? Кавказ янында гына булган Ставрополь крае да күңелгә хуш килми. Бәлки иң яхшысы Россиянең урта полосасыдыр. Һәм шул уй белән ул бирегә килә.

— Ничек булды соң?

— Ышансагыз — ышанығыз, ышанмасагыз — ышанмагыз, килеште климат. Сашага да, Татьяна белән миңа да. Шунысы кызык: мин дә, Таня да эштә, ә малай — көне буе урамда. Манма су булып, пычракка батып кич кенә кайта. Үзе тап-таза.

Әйе, мин гади эшче булып эшли башладым. Өч айдан өченче разряд бирделәр. Балта остасы, бетончы һөнәре буенча. Сменага җитмешәр кубометр бетон җәя идек. Исәпләп карасаң, бу өч-дүрт норма...

Иң мөһиме: егетләр әйбәт туры килде. Акча дип кумыйлар, булсын дип тырышалар. Өчәр смена рәттән эшли идек, зарланучы булмады...

Кемнәр дисезме? Минем белән бергә килгән — Смолянинов Виктор. Ул хәзер звеньевой. Кавказдан килгән Анатолий Кузнецов. Аның улы Вячеслав. Федор Брыляков — армиядә чик сакчысы булган. Һәркемгә ярдәмчән, бик булган егет. Марсель Галәвиев, Виктор Степанов, Әдһәм Баһаветдинов, Анатолий Бахтин — гомумән, барлык егетләр-кызлар белән дә бик тиз дуслашып киттек.

Шуны да әйтергә кирәк: Бахтин армиягә бездән киткән иде. Хезмәтен тутырып үзебезгә үк әйләнеп кайтты. Ун көн инде бездә эшли.

— Николай флотчыларны аеруча ярата, — дип сүзгә кушылды Виктор Иванович.

— Дөрес сүзгә җавап юк, диләр. Флоттан кайтканнарны беренче чиратта эшкә алам. Үз тәҗрибәмнән беләм — алар йөзгә кызыллык китермиләр.

— Югары йөкләмәләр алгансыз. Аларны башкарып чыгу нинди нәтиҗәләргә китерәчәк?

— Бригада йөкләмәләрен саннар белән әйтеп чыгарга булыр иде. Әмма эш саннарда түгел, процентларда гына да түгел. Менә бу блокны корып бетерү ике елга исәпләнелгән. Ә безнең ике елга сузарга хакыбыз юк. Заводның төп объектларыннан берсе. Ел ярымда башкарып чыгарга тиешбез.

Шунысы гаҗәп: барлык алдынгы бригадирлар бер-беренә охшаш. Характерлары уртак. Филимонов һәм Мәүликов, Сәләхов һәм Шемякин — берсе дә аларның кычкырынмый, мактанмый, башкалардан бернәрсә белән дә аерылмый. Шуңа күрәдер инде алар җитәкчелегендәге коллективлар яхшы көйләнгән механизм кебек. 1970 елда ук партия шәһәр комитетының беренче секретаре Рәис Беляев әйткән сүзләр хәтергә төшә: «Күп кычкырган җитәкче түгел, өйрәтә белгән җитәкче», — дигән иде ул.

Ул көннәрдә Чаллыга комсомол путевкалары белән меңнәрчә егетләр һәм кызлар килә иде. Алар арасында тәҗрибәле белгечләр дә, яңа гына һөнәр мәктәбен тәмамлаганнар да, әлегә кулына бернинди корал тотмаган «юеш борын»нар да бар иде. Барысын да кабул итәргә кирәк. Иң мөһиме: бердәм коллективларга, грандиоз төзелешнең барлык катлаулы мәсьәләләрен хәл итәрдәй подразделениеләргә (бу хәрби термин КамАЗ төзелешенең беренче көннәреннән үк кулланыла башлады) тупларга кирәк иде. Ә бу коллективлар, подразделениеләр белән җитәкчелек итү өчен производство технологиясен белү генә җитми, башлык кешедә тәрбияче сәләтә дә булырга тиеш. Приказдан, начальниктан курку түгел, үзеңнең иҗтимагый бурычыңны аңлау, кыенлыклар аша максатка омтылыш, принципиальлек, югары идеялелек таләп ителә иде.

«Без либераллар түгел, без җитәкчеләр алдына кискен таләпләр куябыз, әмма кадрлар белән эшләүне ышануга корабыз, коммунистларның һәм һәр төзүченең үзүзенә җаваплы карашына корабыз. Ә башкалардан таләп итәргә тиешле кешеләрдә моңа мораль хокук булырга тиеш», — дигән иде ул вакытта беренче секретарь.

«Мораль хокук». Бу тәгъбирне күп әйтмиләр иде ул чакта. Язганда да бик саклык белән язалар иде. Ә КамАЗ төзелешендә аны кычкырып әйттеләр, әйттеләр генә түгел, җитәкчеләрдән бу хокукны таләп иттеләр. Әйе, эшчеләр коллективы белән бары тик кристаллдай саф, намуслы, ышаныч казанган, остаз була белгән кешеләр генә җитәкчелек итәргә хокуклы. Һәм шундый сыйфатларга ия булган гади эшчеләр брига-

дирлар, участок начальниклары булып үсте. Фронтта да шулай иде бит: иске карашлы хәрби җитәкчеләрне сугыш барышында яшь, талантлы командирлар алыштырды, һәм алар генералга, хәтта маршалларга тикле үстеләр. Һәр чор үз геройларын тудыра.

Һәм биредә — КамАЗда — меңнәрчә, меңнәрчә кешеләр катнашындагы хезмәт фронтында производствоның заманны һәм үзенең сугышчан бурычларын яхшы аңлаучы яңа командирлары үсеп чыкты. Әмма аларның сугышчан сыйфатлары башка инде: купшы сүзләр кычкырмыйлар, башлык икәнлекләрен аерып, калку итеп күрсәтергә тырышмыйлар; алар кешеләр күңеленә юл таба белүче, үзләренең шәхси үрнәкләре белән башкаларны уртак максатка әйдәүче командирлар.

Николай Шемякин да шундый командир. Ул киң җилкәле дә, баһадир гәүдәле дә түгел, урта буйлы, гади чырайлы. Яше дә КамАЗ төзүчеләрнең уртак яше белән тигез. Кеше буларак та тыйнак. Әмма аны һәркем хөрмәт итә...

— Яңа шәһәрдән квартира бирделәр. Йорт номеры — дүрт-унике. Йөз кырык беренче квартира. Буш вакытыгыз булса, килеп әйләнегез. Кунак булып китәрсез...— дип бетерде ул сүзен.

М. ХӘМИТОВ тәрҗемәсе.

ГЕННАДИЙ ПАУШКИН ЧАЛЛЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

Балта остасы һәм шагыйрь

Якшәмбе көн иртән мин торган гостиницага КамАЗның төзү-монтаж идарәсе балта остасы Кувайцев белән инженер Лыжин баян күтәреп килеп керделәр.

Аларның килүен мин үткән юлы да көткән идем, ләкин ул чагында без очраша алмадык: Лыжин ашыгыч командировкага китеп барды, ә Евгений Кувайцевны кинәт кенә объектка чакырып алдылар. Мин кунаклар килүгә бик шат идем: ниһаять, аларның КамАЗ турында чыгарган җырларын ишетәчәкмен.

Егетләр чишенделәр. Салкыннан соң, бераз сулу алгач, Лыжин футлярдан баянын чыгарды, урындыкка җайлап утыргач, бармаклары белән төймәләр өстеннән йөгертеп үзды да Кувайцевка ымлады. Шунда ук алар ике тавыштан җыр башлап җибәрделәр:

Нам досталась судьба завидная,
Мы идем по отцовским стопам.
Вам вчера покорилась Магнитная,
А КамАЗ покоряется нам...

Мин, җырның бер өлешен тыңлау белән үк, сүзләрнең көйгә аһәңле ярашуын тоеп алдым. Яшерен-батырын түгел, югыйсә, кайбер профессиональ авторларыбызда да көй белән сүзләрнең ярашмаган очраклары булгалый бит. Ә бу җырда алар икесе бер бөтен һәм иң әһәмиятлесе тагын шул иде — җыр дулкынландыра, хәтердә кала.

КамАЗ турында нинди генә җырлар язылмады инде! Тик аларның берсе дә Чаллыда яшәп китә алмады. Ә бу җырны яшь төзүчеләр яраттылар: көе дә, сүзләре дә аларның күңелләренә хуш килде.

Егетләр әйбәт җырладылар, бернинди дә артистлык галәмәтләре күрсәтү белән мавыкмыйча, җәен урманда, яисә кырда ял итәргә туктаган җирдә, учак янында җырлап утыргандай гади тоттылар үзләрен — җырны башкарганда да зәвык сизелде аларда.

Мин авторларны тәбрик иттем, плитәгә чәй куеп җибәрдем. Ә Лыжин «кызып китеп» тагын уйный башлады һәм алар Лыжин тарафыннан Виктор Боков сүзләренә язылган «Җиләк җыйганда» дигән җырны башкардылар. Бусы да колакка ятышлы булды, Кувайцев моны да үзенең сүзләренә язылган җырны башкаргандай ук бирелеп җырлады.

Дулкынланудан Кувайцевның йөзе сулып, агарынып киткәндәй күренде, бары тик тез өстенә куйган куллары гына беләзеккә кадәр каралып күренә иде. Мин аны

мәктәп елларыннан ук белəм шикелле тоелды: йомшак күңелле, мәрхәмәтле җан, тыныч акыл белəн эш итүче, күркəм йөзле егет...

Мин һəр вакыт «гади кешеләрнең» биографиясе белəн кызыксынам. Көндəлек тормышта аларны шулай атап йөртсəләр дə, кешеләр арасында «гадиләр» бөтенлəй юк. Кешеләр бик төрле, аларның һəркайсының үз тормышы, искиткеч язмышы бар.

Мин Кувайцевның шигырьләр язуын, җирле һəм республика газеталарының аларны бик теләп бастыруларын беләм. Аның шигырьләре бик гадиләр, аларда бернинди дə формальлек юк: алар ачыктан-ачык сөйләшүгə корыла.

Балта остасы-эшче шигырь яза. Ул үзе күргəн, үзе кичергəннəр турында яза, Чаллы яшьләре аның шигырьләрен «үз» итеп кабул итə. Һəркем: «Мин дə шулай яза алыр идем, тик өлгерə генə алмыйм. Əйдə, Кувайцев безнең барыбыз өчен дə язсын»,— дип уйлыйдыр кебек. Аның шигырьләре самимилек, табигыйлек, үзенə генə хас алымнары белəн аерылып тора: əйтерсең лə ул рифманы, үлчəмне уйлап чыгарган да шигырь юллары белəн сөйли башлаган...

«Орфей» əдəби берләшмəсендə аны грамматик ялгышлары өчен, сүзләргə басымны дөрес куймавы өчен ачуланалар, ə аның үз туксаны-туксан: «Минем шигырьләремне укучылар яраталар, əйбəт кабул итəләр!..» — ди.

Ə шулай дə Кувайцев үзендə əдəбият белеменең җитəрлек булмавын тоя, «үзешчəн шагыйрь» генə булып калмас өчен укырга кирəклеген, хəзер Чаллы җирендə барган бөтен нəрсəгə кызыксыну көчле булганлыктан гына үзенең шулай күтəрелеп китүен аңлый.

КамАЗның балта остасы. Кайдан ул? Бирегə кайсы яклардан килеп чыккан? Аны бирегə нəрсə тарткан?

Язучы нинди генə булмасын, барыбер биографиясе бар инде аның. Фадеев əйткəнчə, «биография» төшенчəсендə халык һəм заман белəн бəйле кешенең язмышын аңлаган хəлдə, безгə үз биографиябездəн тыш язар əйбер дə юк.

Ə КамАЗга килеп җиткəнче, Кувайцев нəрсəләр күргəн? Килүенə бер атна дигəндə район газетасында шигырь белəн чыгыш ясаган бу егетнең бирегə килгəндə үк ни дəрəҗəдəдер «багажы» булган бит инде.

Без сөйләшеп киттек — һəм мин Кувайцевларның Аксаков əсəрләрендə тасвирланган урында яшəгəн булуларын белдем. Евгений табигать кочагында, проза остасы, атаклы «Аучы язмалары»ның авторы тарафыннан сурəтлəнгəн имəн һəм каен урманнары шавын тыңлап үскəн. Малай чагыннан ук ул көзләрен миләш «тамчыларын», ə язларын — бөреләр «серләшүен», кар янəшəсендə үк умырзая чəчəге янып утыруын күргəн...

Евгенийның əтисе хезмəте буенча күп вакыт урманда йөри, агачларны карап, саклап гомере үтə. Ə көзге озын кичləрдə, янына улын утырта да, Сталинград янындагы сугышлар турында, Евгенийның əнисе белəн бергəлəп, Иделдəн алып зəңгəр Дунайга кадəр үтелгəн утлы юллар, генерал Шумиловның легендар армиясе, Дунай буе халыкларын фашистлар коллыгыннан коткарганда үзləре кичкəн Карпат таулары турында мавыгып сөйли башлый.

Евгенийның əтисе белəн əнисе хезмəт иткəн хəрби часть Румыния территориясендə урнашкан була һəм сугыштан соң беренче тыныч елда өлкəн лейтенант Павел Кувайцев гаиләсендə малай туа. Часть буенча дежур офицер полкта беренче бала туу хəбəрен шунда ук бөтенесенə җиткерə — һəм Җиңү көненнəн соң беренче тапкыр полкта алар хөрмəтенə бəйрəм тантанасы үткəрелə. Сугышның бөтен авырлыгын татыган кешеләргə бу көн онытылмаслык тəэсир итə, бəбине кулдан-кулга йөртəләр, ə часть командиры аңа карый да: «Төп кебек!.. Танкист булыр бу!..» ди.

Демобилизацияләнгəннəн соң запастагы өлкəн лейтенант Павел Кувайцев үзе туып-үскəн җиргə — Башкортстанның Воскресенск районына кайта һəм хəрби форманы тыныч хезмəт профессиясе булган урман караучы формасына алмаштыра.

Женя Дуван авылында сигезьеллык мəктəптə укый һəм, аны тəмамлагач, Уфага елга техникумына укырга китə. Ерак илləргə сəяхəт итү омтылышы аны шул юлга чакыра: «Əти белəн əни үз гомерləрендə күпне күргəннəр, ə мин һаман бер урында утырыймммы?.. Дөнья күрəсем килə!..»

Елга техникумында уку еллары сизелми дə үтеп китə — менə инде ул Агыйделдə һəм Камада, Иделдə һəм Мəскəү елгасында йөрүче йөк һəм пассажир судносында

әшли башлый. Евгений эшләгән ул пароходның исеме дә шигъриятле — «Җамбул» була...

Техникумда укыганда Евгений елга флотында рулевой һөнәренә өйрәнсә дә, беренче навигациядә матрос булып эшләргә тиеш була. Ә икенче навигациядә матрос Кувайцев танкерларда практика үтә: «Уфа-Дербешки»да рулевой булып рейдка китә.

Алтмыш бишенче елда Евгений Кувайцев армия сафларына алына, танк гаскәрләрендә хезмәт итә: әтисенең полкташ дусларының әйткәне шулай рас килә...

Яшь солдатлар Киевтан үзләренең хезмәт итү урыннарына су юлы белән барырга тиеш булалар. Армиягә кадәр Кувайцевның кем булып эшләвен белеп алгач, аңа штурвалга басарга рөхсәт итәләр. Елга флоты рулевое, булачак танкист, пароходны Днепрдан үзе алып бара, хезмәттәш дусларын кирәкле җиргә бернинди хәвеф-хәтәрсез илтеп җиткерә...

Комсомол-яшьләр бригадасы җитәкчесе Н. СТАРКОВА. В. ИГНАТЬЕВ рәсеме.

Бер айдан соң танк та, кайчандыр елга пароходы буйсынган шикелле үк, аның кулларына ияләшә, тыңлаучан булып китә һәм өйгә, әтиәнисенә язган хатларында ул хезмәтнең «нормаль» баруын, кайчандыр Шумилов армиясе үткән җирләрдә булуын хәбәр итә...

Шул вакытта Евгенийның хәтерендә нык калырлык вакыйга була, ул аңа инде ераста калган сугыш давылы белән йөзгә-йөз очрашкандай тәэсир итә. Танкистлар, яңа полигон өчен урын хәзерләп, карт, кәкрәеп беткән наратларны кискәндә, кинәт пычкылар ямьсез тавыш чыгарып сызгырыша башлый, һәм берничә пычкы теше сынып та чыга. Агачның киселгән җирен карасалар, снаряд кыйпылчыкларын күрәләр...

— Минем өчен бик истәлекле кебек тоелды алар, — дип искә ала Кувайцев, — аларның берсен мин өйгә алып кайттым һәм әнигә күрсәттем. Һәм чыннан да шулай булып чыкты.

— Син аны кайсы районда таптың? — дип сорады ул.

Мин аңа полигонның төгәл урынын әйтеп бирдем.

— Менә,— диде әни.— Без әтиең белән немец артиллериясе уты астында калган җирләрдә булгансың да инде син, улым.

Армиядән соң, урта мәктәпнең унбер классын тәмамлап, Евгений Уфада заводка эшкә керә. Ул иң әйбәт цехка туры килә, комсомол «Прожектор»ының штаб начальнигы итеп сайлана. Шигырьләр яза башлый, аның язганнары заводның күп тиражлы газетасында басыла. Евгений яшьләр газетасы «Ленинчы» редакциясендәге әдәби берләшмәгә йөрергә дә вакыт таба.

Кама буендагы комсомол удар төзелеше турында ишеткәч, Евгений пароходта Кама буйлап үткән вакытларын, таныш урыннарны хәтеренә төшерергә тырыша... Пирамидаларга охшаган мәһабәт биек ярлар, борынгы Болгар хәрабәләре, Алабуга шәһәренең истәлекле урыннары, ерактан су астында тынып калган мамонтны хәтерләткән зур элеваторлы Чаллы шәһәре...

Әйе, ул аларның барысын да күрде, әлеге ярлар яныннан күп тапкырлар үтте, пристаньнарына тукталды. Шишкин урманнарына карап сокланды...

Борынгы мәһабәт ярлар аны үзләренә тартты, ләкин аны бер уй борчыды: «Төзелештә кем булып эшләрмен мин?»

Шул чак әйтерсең лә кемдер колагына пышылдады: «Столяр, балта остасы булырсың!»

«Чыннан да, — дип уйлап куйды Евгений, — елга техникумында столярлык эшенә яхшы өйрәткәннәр иде бит...»

Кувайцевка ул чагында икенче разряд биргәннәр иде. Кышын, пароходларны ремонтлаган вакытта, ул бу эшкә хәйран өйрәнеп китте.

— Димәк, болай булгач һөнәрем бар!

Җитмеш беренче елның 26 маенда кулына кечкенә генә чемодан тоткан Евгений Кувайцев, үзе шикелле бер төркем егетләр белән бергә, Чаллы пристанена төшеп калды.

Балта осталары кирәк иде һәм КамАЗның төзү-монтаж идарәсендә аны өченче разряд буенча эшкә алдылар, ЗЯБтагы (ЗЯБ — күзәнәкле бетоннар заводы) тулай тораккa урнаштырдылар. Балта остасы, штукатур булып эшләүче егетләр белән икенче катта яшәделәр, бишенче катта эшләделәр. Ут юк иде (үткәрергә өлгермәгәннәр иде әле), су да юк иде, тик шулай да өстендә түбә (дөресрәге, түшәм) булуы һәм яңгыр үтмәве дә бик яхшы иде...

— Язган әйберең белән япа-ялгызың гына калу никадәр авыр икәнен азмы-күпме язу белән шөгыльләнгән һәркем белә, «үзең өчен генә язу» дигән сүзләр әкият ул: яздыңмы — язганыңны укучы да кирәк! — ди Евгений.— Көлсеннәр, ачулансыннар, тик тыңласыннар гына. Тавык та йомырка салу белән кытакларга тотына. Ә монда шигырь, йөрәк җылысын кушып, ялкынланып язылган шигырь. Аны берүзең нишләтмәк кирәк?

Яшьләр тулай торагының кечкенә бер бүлмәсендә, «сигезенче комплекста», аның шикелле үк «шашканнар» җыелуын, бәхәсләшүен, шаулашуын, шигырьләр укуын, плакатлар язуын сөйләделәр миңа... «Факел» матбугат үзәге дә шундый ук: биредә һәвәскәр артистлар да, музыкантлар да бар, үзешчәннәрнең программалары да биредә төзелә...

Җәйге кичләрнең берсендә Кувайцев әлеге «Факел»ны эзләп таба, кем әйтмешли, «ут күреп» керә, үзе шикелле эш урыныннан ук бирегә ашыккан бик күп егетләрне күрә.

«Ленинчы» газетасындагы әдәби берләшмәдә бөтенләй башкача иде, — дип уйлап куя Кувайцев, бүлмәдәгеләрнең кайсысы янына да барырга белмичә...

Ләкин аны шунда ук күреп алалар: «Берәр нәрсә китердеңме?.. Утыр, нигә басып торасың?..»

— Кайдан син? — дип сорый аннан сакаллы һәм күпереп торган чәчле бер егет.

— КамАЗның төзү-монтаж идарәсеннән балта остасы Кувайцев мин, — дип таныштыра үзен Евгений.

— Ә мин — Валерий Суров — монтажчы,— ди әдәби берләшмә җитәкчесе.— Таныш булыйк!

— Шигырьләр язасыңмы? — ди егетләрдән берсе.

— Әйе, язам, — ди Евгений.

— Бездә монда барысы да шагыйрьләр, — Суров каршы як стена буенда утырышкан егетләргә ымлап куя. — Барысы да — таланглар!

— Тәнкыйтьчеләребез дә җитәрлек, шөкер!

— Китердеңме — укы, — ди Суров. — Ә сез, егетләр, акрынрак!..

— Без — комсомоллар — каты токым, — дип башлый Евгений һәм пафос белән укып китә...

— Маяковскийга иярә! — дип шаулашалар егетләр. — Ә син үзеңчә яз...

— Алайса, «Кыяр» турында, — ди Кувайцев.

— Кыяр турында? Әйбәт булыр!.. Әйдә җибәр кыярны!..

— Иртәгә яшьләр тулай торагында Хатюшин, Лимонова, Яшкина белән бергә син дә чыгыш ясарсың... Безнең тагын кемнәр бара?..

Кичә искиткеч шәп була! Бергәләп гөрләшеп алар урамга чыкканда, сигезенче комплекс йортларының тәрәзәләре генә ялтырап күренә, уңда — төн караңгылыгында, йолдызлардай булып, кран башняларында утлар җемелди, электр белән эретеп ябыштырган җирдә көлтә-көлтә булып очкыннар сибелә... Алар трамвай юлыннан баралар, шау-гөр килеп бәхәсләшәләр (тулай торак бүлмәсендә «талашып» туймаганнар, күрәсең), Кувайцевның «Кыяр» шигыренең соңгы юллары бәхәсне шулай кыздырып җибәрүгә сәбәп була.

Ләкин колакта әле һаман моңа кадәр бөтенләй ишетелмәгән яңа шигырь юллары яңгырап тора. РИЗда эшләүче япь-яшь кызлар язган шигырьләр арасында Инна Лимонованың «Әтәч»е бигрәк мәзәк тоела. Ул шагыйрьне таң әтәче белән чагыштыра. Монда нәрсәдер бар, дип уйлый Кувайцев, башкалардан аерылып ялгызы гына калгач.

Егетләр инде йоклыйлар, ә ул, корылган аккумулятор кебек, «лампаларга электр энергиясен бирүне дәвам итә» — башында яңадан-яңа шигырь юллары, сурәтләүләр, чагыштырулар кайный.

«Иртәнгә кадәр тагын йоклый алмаячакмын, — дип уйлый Евгений. — Тиздән яктырачак, көн авыр булачак, ләкин... онытмас борын язарга кирәк»...

Дәфтәр битенә шигырь юллары язганда «иртәгә тәртипкә китерермен әле», дип уйлый. Ләкин юл артыннан юл туа тора:

Нам досталась судьба завидная:
Мы идем по отцовским стопам.
Им вчера покорилась Магнитная,
А КамАЗ покоряется нам...

Аннан соң үзешчән композитор — «Запорожметаллургмонтаж» идарәсенең өлкән инженеры Юрий Лыжин бу сүзләргә көй чыгара — һәм Кувайцев-Лыжиннарның җыры Чаллыда популяр булып китә. Ләкин Кувайцев башта болар турында башына да китерми, билгеле.

Балта остасының эше җиңел булмавын һәркем белә. Кайбер атналарда (чиратлап) якшәмбе көннәрендә дә эшләргә туры килә, ә шимбә турында әйткән дә юк инде — КамАЗда ул эш көне булып санала. Шигырь турында уйларга вакыт та калмый кебек. Ләкин, ни әйтерсең, шигырь юллары бөтенләй уйламаганда башка килә тораалар һәм Кувайцев алардан берничек тә арына алмый.

Көннәрнең берендә аның күңеленә шундый фикер килә — вакытлыча гына булса да ялгызлыкта калу өчен, Чаллы инеше буенда өй салырга уйлый ул. Төзелеш материаллары яздырып ала да якшәмбе көннәрнең берсендә эшкә дә керешә. Әдәби берләшмә егетләре дә аңа булышка киләләр, кулларына балта алалар да — аксәякләр түгел ләс! — егерме көн дигәндә менә дигән итеп йортны эшләп тә куялар.

— Уфадан хатынымны алып килдем, — ди Кувайцев. — Бар мөлкәтебезне бер ящикка тутырдык та, «Җамбул» пароходына утырып — теге вакыттагы пароход үзе инде! — юлга чыктык. «Җамбул»да әле матрос Кувайцевны хәтерлиләр икән. Юлыбыз күңелле булды. Егетләр Чаллы пристаненда төшеп калырга булыштылар, КамАЗда бәхетле тормыш теләделәр...

Кувайцевның йорты Чаллы инешенең уң яктагы биек ярына урнашкан иде. КамАЗны һәм Яңа шәһәрне төзү эшләре шул кадәр тиз барды, егетләр әйткәндәй, «монда бер көн эчендә атналык эш башкарылды». Төзүчеләрнең алдынгы бригадалары йортларны егерме биш көн эчендә салырга өйрәнделәр, КамГЭС поселогы күзгә күренеп үсте, Чаллының агач йортларын биек стеналар артында калдырды, «Том агай алачыгы» — Чаллының яшь әдәбиятчылары Кувайцевның өен шулай атадылар — утырган җир генә утрау сыман бүленеп калды.

Евгений Кувайцев үзе күргәннәр, үзе кичергәннәр турында рухланып яза. Вакыйгалар давылыннан үзенең куышына качып калмый, төзелеш аны бөтен барлыгы белән үзенә тарта: ул «удар» темптагы лозунг рухындагы шигырьләр дә иҗат итә. Аның андый шигырьләренең кайбер юлларын җирле художниклар унар метрлы полотноларга язып элделәр. Ул шигырьләрдә хәзерге буын яшьләренең тавышын ишеткәндәй буласың.

Вакыт үтә торды, вакыйгалар барышы турында фикер йөртергә, төзелеш белән бергә үсәргә, тормышта үзеңнең урыныңны билгеләргә кирәк иде һәм «Орфей» егетләре укуга бирелеп киттеләр. Хәзерге заман таләпләре югарылыгында шигырь язу Кама ярында моңа кадәр тиңдәше булмаган заводлар комплексын төзү шикелле үк авыр икәнлеге ачык аңлашылды. Валерий Хатюшин Горький исемендәге әдәбият институтына гариза бирде, иҗат конкурсында җиңеп чыгып, Мәскәүгә укырга китте. Инна Лимонова Казан университетының журналистика бүлегендә читтән торып укый башлады.

— Сиңа да чират җитте, Кувайцев,— диделәр орфейлылар.— Синең шигырьләреңне тыңлау өчен әйбәт, колакка ятышлы, ләкин нык игътибар белән укыганда алардагы ялгышларны бик ансат табарга була...

— Мин хәзер күп укыйм,— диде миңа Кувайцев.— Кирәкле әдәбиятны табам да төннәрен укып утырам, әдәбият институтына хәзерләнәм. Белмим, ничек булып чыгар...

Әйе, вакыт үтә. Ә КамАЗда һәр көнне атналык эш башкарыла. Буш урында завод корпуслары калкып чыкты, РИЗ эшли башлады, башка заводларда да җиһазларны монтажлау эшләре башланачак. Эшчеләр сафына урта һәм югары белемле кешеләр, әйбәт белгечләр һәм эрудитлар киләчәк. Бездә кешеләр тиз күтәрелә. Акыллы һәм фикер йөртү сәләтенә ия булган укучы шагыйрьнең яшьлегенә дә, тема актуальлегенә дә ташлама ясамаячак. Шунлыктан укучы белән бергә үсәргә, «меңнәрчә тонна сөйләм рудасыннан бердәнбер кирәкле сүзне эзләп табарга» өйрәнергә кирәк.

Танылган тәнкыйтьче Макаровның: «Поэзия илһам ясалма булмаган очракта гына барлыкка килә ала», — дигән сүзләрен тезис итеп алсаң, Кувайцевның бик күп шигырьләре шул таләпкә җавап бирә. Ләкин шул ук вакытта поэтик хезмәтнең югары культурасы турында да онытмаска, нәрсә бирсәң шуны чәйнәми йота барган кайбер укучылар зәвыгы дәрәҗәсен канәгатьләндерү белән генә мавыкмаска кирәк.

— «Орфей» егетләре хаклы, — дидем мин Евгенийга. — «Безнең эш һәр хезмәткә кардәш» саналса да, язу ансат түгел, ә бәлки йортлар салуга һәм металл коюга караганда күп тапкырлар катлаулырак. Син үзеңнең хезмәтеңдә иң нечкә һәм иң җаваплы материал — сүзләр белән эш итәсең. Хәтерлисеңме, Паустовский үзенең «Алтын роза» повестенда ничек язган?

«Һәр минут, искәрмәстән әйтелгән һәр сүз һәм күз карашы, тирән уйландырган яки шаяртуны күздә тоткан һәр фикер, кеше йөрәгенең һәр тибеше, тирәктән очып төшкән мамык яки төн караңгылыгында атылган йолдыз — болар барысы да алтын тузаны бөртекләре.

Без, язучылар, ул миллионлаган бөртекләрне ун еллар буена берәмтекләп эзләп табабыз, үзебез дә сизмәстән, аларны җыя барабыз, барысын бергә кушудан хасил булган әлеге нык матдәдән «алтын роза»бызны ясыйбыз — повесть, роман яки поэма иҗат итәбез».

— «Алтын роза» повесте Паустовский сайланма әсәрләренең икенче томына кертелгән, син аны кичекмәстән укып чык, — дидем мин Кувайцевка. — Повесть Париждагы чүп түгүче Жан Шамет белән булган хәлне сөйләүдән башлана. Ул ювелир мастерскойларындагы тузанны иләп бераз гына булса да алтын кисәге җыярга һәм шуннан Сюзаннасы өчен кечкенә роза ясарга хыялланган. Ә бәлки, әнисе сөйләгәнчә, башка бик күп гади кешеләрне дә шул роза бәхетле итә алыр дип уйлагандыр...

— Әйе, — диде Кувайцев. — Озакка сузыла торган вак эш, моны бары тик мәхәббәт хакына гына эшләргә мөмкин.

— Әйе, мәхәббәт хакына, бары тик мәхәббәт хакына гына. Мәхәббәттән башка әлеге вак бөртекләрне берәмтекләп җыеп торуның мәгънәсе дә юк...

Кувайцев шигырьләр яза. Әгәр ул заман һәм үзе турында язарга уйласа, безгә җитмешенче елларның яшь кешесе турында кызыклы чын хикәя бүләк итә алыр иде.

Аңа кагылышлы тагын бер кызыклы детальне әйтеп китү кирәктер: район советы башкарма комитеты карары белән «алачыгы» сүтеп алынгач, аңа ишек-тәрәзә блокларын үзе куйган, идәннәрен үзе җәйгән йорттан квартира биргәннәр...

Т. ТАҺИРОВА тәрҗемәсе.

Равил Вәлиев

ТАЯНУ НОКТАСЫ

Баһадирлар гаиләсенең олы улы

Чорыбыз баһадиры — КамАЗның берсеннән-берсе куәтле алты улы булачак. Ремонт-инструмент заводы — РИЗ — шуларның иң өлкәне, беренче булып сафка кертелгәне.

Беренче коймак төерле була дигәндәй, РИЗ үзенең кече «туганнар»ына караганда кыенрак шартларда дөньяга килде. Чөнки аның җир астында калган «беренче кат»ы, гадәттәгечә, иске алым белән салынды. РИЗ төзелә башлаганда нигезләрне бораулап коела торган субайларга утырту ысулының Чаллы җирендә исе-хушы да күренми иде әле. Шуның аркасында күпме котлован казып, аннан күпме балчык чыгарырга, нигез салынгач, шул ук балчыкны кире ташып, дыңгычлап төяргә-тыгызларга туры килде.

Чаллы җирендә кулланылган икенче зур яңалык — түбә блокларын җирдә эреләндереп җыю алымы да КамАЗның беренче карлыгачына тимәде: 1971 елның октябренда двигательләр заводының алтмыш тонналы беренче эксперименталь блогы урнаштырылганда, РИЗда соңгы металл конструкцияләр куелып ята иде инде. Бер сүз белән әйткәндә, РИЗ ваклап, «бал кашыклап» монтажланды.

Шулай инде, беренчеләргә гел кыен була!..

Түбәсе ябылган, стеналары балык тәңкәсе кебек вак-вак ялтыравык плитәләрдән «тегелгән» ап-ак тун кигән төп корпусның эченә кергәч тә, РИЗ төзүчеләренә яңадан-яңа кыенлыкларны җиңеп чыгарга, гигант төзелеш, тормыш үзе алга куйган әһәмиятле проблемаларны хәл итәргә туры килде.

Бетон идәнгә торецлы шашкалар — дым үткәрмәүче махсус сыекча сеңдерелгән агач шакмаклар түшәү мәсьәләсен генә алыйк. Промышленность биналары идәннәрен җәюдәге бу прогрессив алымның мондый зур күләмдә илебездә беренче мәртәбә генә кулланылуы иде әле. Тәҗрибә җитеп бетмәү эш барышында үзен бик нык сиздерде. Өстәвенә материаллар белән тәэмин итүдә әледән-әле өзеклекләр булып торды. Чөнки идәнгә җәю өчен кирәкле һәм дефицит корыч плитәләр һәм башка күп металл җиһазлар РИЗга илебезнең ерак шәһәрләреннән, хәтта чит илләрдән кайтарылды.

Бу беренче зур баһадир сафка керү белән, камазчыларның сулышы иркенәеп китте. Алюминийдан коелган тәрәзә рамнары, автозавод эшчеләре өчен кирәк булачак ун меңләгән кием шкафлары, транспортерлар, шудырма ишекләр, завод корпусларының түбә тәрәзәләре, аларны ачып-ябу өчен автомат җайланмалар РИЗның

үзендә җитештерелә башлады. Димәк, калган биш заводка кирәкле эшләнмәләрне китерү өчен тотылырга тиешле күпме юл чыгымы һәм, иң әһәмиятлесе, вакыт янга калдырылды.

Озын сүзнең кыскасы, үзе тәртә арасына кереп җигелер-җигелмәс борын, биш кече туганына аякка басарга булышып, РИЗ киләчәктә КамАЗны барлык кирәкле инструментлар, махсус һәм стандарт булмаган җиһазлар белән тәэмин итеп торырга тиеш иде. Менә ни өчен 1972 елның азагыннан башлап камазлыларның телендә иң еш кабатланган сүз — «РИЗ» сүзе булды. Менә ни өчен РИЗ Чаллыда барган бөек эшләрнең төп юнәлешенә әйләнде.

Киләчәктә төзү-монтаж эшләрен тагын да киңрәк җәелдереп җибәрү өчен, камазлыларга ул, үзенә күрә, Кама ярында яулап алынырга тиешле беренче плацдарм ролен үтәде һәм үти.

КамАЗның калган заводлары — биш кече баһадир — үзләренең «РИЗ» исемле олы «абый»лары җилкәсенә таянып күтәрелделәр...

Такташ якташы

РИЗ төзелешендәге «төп хуҗа»ның — 6 нчы төзү-монтаж идарәсе начальнигы Мансур Татлыевның үзенә бик тә килешеп торган кара мыегы бар.

Оперативка тәмамланып, кешеләр таралышырга дип урыннардан торгач игътибар иттем: күршемдә утырган Хәсән ага Урмановның да нәкъ шундый кара мыегы бар икән бит!

Хәсән агага иярә чыктым. Оперативка вакытында колагыма чалынып калган «луноход» дигән сүз күңелгә һич тынгылык бирми, тизрәк серенә төшенәсе килә генә бит!

Хәсән ага эшли торган диспетчерлык пункты РИЗ янәшәсендәге бер вагончыкка урнашкан икән. Шунда барышлый сөйләшеп киттек. Сүзне ул башлады.

— Син кайсы якныкы әле, энем?

— Арча ягы... Ә сез?

— Тамбовтан мин... Ишеткәнең бармы шундый шигырьне? — дип, Хәсән ага ягымлы йомшак тавыш белән таныш шагыйрьнең юлларын укып китте:

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге оныта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...

— «Бер җирдә юк андый ак каеннар, бер җирдә юк андый урманнар...» — дип дәвам иттем мин шигырьне. Шул Тамбов урманнарындагы нарат кебек озын, таза гәүдәле, гөлдерәп чыккан йомшак тавышлы, зур-зур адымнар белән минем алдан салмак кына атлап барган шигырь яратучы бу агай кинәт кенә күңелемә бик якын булып китте.— Димәк, сез Такташның якташы икәнсез, алайса?

— Шулайрак... Ә хатын Башкортстаннан минем.

— Кайсы районнан?

— Чишмәдән... Ә нәрсә, берәр туганың бар мәллә ул якларда?

— Юк...— дигән булдым. Ә үземнең искә кылт итеп кичә Мансур Якупович белән булган сөйләшү килеп төште... Тукта, тукта! Биредә берәр төрле бәйләнеш юкмы икән?

— Мансур Якупович та хатыным Чишмә районыннан дигән иде...

Барган җиреннән туктап, Хәсән ага кинәт миңа борылып карады. Аның йөзе, гаебе ачылган кешенекедәй, кызарып китте:

— Ә...й-йе шул... Авылдашлар алар... Ташкенттагы гидротехника институтын тәмамлап, Урта Азиянең бик күп ГЭСларын корышкач, Мансурны Чаллыга идарә начальнигы итеп җибәрделәр. Аннары ул Тамбов заводларының берсендә тәэминатчы-инженер булып эшләп яткан җиремнән безне дә куптарды. Безне дип... Сәкинә белән балалар килмәде әле. Минем квартир чираты җитүен көтәләр...

СССР Верховный Советы депутаты РӘИС СӘЛӘХОВ.

Р. ИМАШЕВ рәсеме.

Диспетчерлык пункты янына килеп туктадык. Сөйләшү шунда өзелде. Ләкин бу турыда сүз бетте дип санарга ашыкма әле, Хәсән ага! Журналист халкыннан алай тиз генә котыла алмассың әле син!

Хәзер минем бер әйберне ачыклыйсы калды: Хәсән ага КамАЗга килгәнче мыек йөрткәнме, юкмы? Йөртмәсә... Әгәр йөртмәсәме? Димәк, ул үзенең «якташ» начальнигына һәрьяклап охшарга тырыша. Аны тирән хөрмәт итә.

Әнә бит бирегә килешли дә ничек сайрап барды. «Татлыев менә дигән җитәкче. Андыйларны елап эзләсәң дә табып булмый: үзе кешелекле, үзе сабыр, үзе принципиаль», ди...

Саубуллашыр алдыннан, туңсам туңармын, уңсам уңармын дидем дә, бар кыюлыгымны җыеп:

— Хәсән ага, ачуланмый гына әйт әле, зинһар! Чаллыга килгәнче мыек үстерә идеңме, юкмы? — дидем.

— Үстерде, ди, көт!.. Карчык югында дип маташуым инде азрак,— дип шаярткан булды ул, мыек очларын сыпыргалап.

Ай-һай, карчык юклыкта микән хикмәт? Белмим, белмим...

Хәсән агадан теге «луноход» дигән серле машинаның кайдалыгын белештем дә, саубуллашып, корпус эченә кереп киттем.

«Луноход»

Яныннан ничәмә-ничә кат үтеп йөреп, моңарчы игътибар иткәнем юк иде. Баксаң, ул «луноход» дигәннәре нәп-нәни трактор булып чыкты.

«Кай төше «луноход» булсын инде моның?» дип, башта бик нык сәерсенеп куйдым. Ләкин серле машинаны идарә иткән егетләрнең берсенә сүз каткач, шигем юкка чыкты. Әйе, карама түшенә, кара эшенә, ди шул...

Сабиржан Кәримуллин — әле яңа гына мыек төртә башлаган яшүсмер егет. Урал ягыныкы. Кунадай киң җилкәле гәүдәсенең һәр мускулыннан, һәр хәрәкәтеннән яшьлек дәрте бөркелеп тора. Әти-әниләре кайчандыр ябык елларда Сарман районының Казаклар авылыннан күченеп киткән булганнар икән. КамАЗ төзелү хәбәрен ишетү белән, ояларын сагынган кошлар кебек, кабат, туган якларына әйләнеп кайтканнар. Әтисе Мөнәвир абзый да РИЗ төзелешендә слесарь булып эшли.

Сабиржан армиядән күптән түгел генә кайткан. Ул анда танк йөртүче булып хезмәт иткән. Шинель-погоннарын салса да, футбол тубы кебек буынтыклы-буынтыклы кара шлемофоны һаман башында үзенең. Танкист хезмәтен бик яраткан, күрәсең.

«Луноход», билгеле, танк түгел. Ләкин кечкенә булса да, эче төш кенә аның. Эшләмәгән эше, кермәгән ишеге, чыкмаган тишеге юк! Нәни бульдозер да ул, кечтеки тягач та...

«Татэнергомонтаж»ның кече механизация идарәсе карамагындагы «Т-54В» маркалы мондый тракторлар Кишиневта ясала икән. Бакчаларда, виноград плантацияләрендә эшләү өчен билгеләнгән бу трактор «балалары», кирәкләре чыккач, ашыгыч төстә РИЗ төзелешенә кайтарылганнар. Һәм, кайтып җитү белән, эшкә дә җигелгәннәр.

РИЗның шушы бер төп корпусы эчендә генә дә ике меңнән артык станок урнаштырылачак. Аларның күбесе бер-берсенә охшамаган. Арада келәт хәтлеләре дә, сандык чаклылары да бар. Төрлесенә төрле зурлыкта, төрле тирәнлектә казылган нигезләр кирәк. Менә шунлыктан төп корпусның эче, төрле төстәге чүпрәк кисәкләреннән тегелгән палас кебек, вак-вак кишәрлекләргә бүлгәләнеп беткән. «Тар тишеккә — тана башы» кебек килеп чыкмасын дисәң, күп санлы корыч колонналар арасындагы «түтәлчек»ләргә иләмсез дәү бульдозерларны кертеп җибәрә алмыйсың. Ә ут борчасы кебек терчә «луноход»ларның бу тыгынлыкка исләре дә китми. Кәҗә бәтиләре кебек терт тә терт килеп, казылган балчыкны нәни, ләкин көчле корыч мәгезләре белән сөзә-сөзә, минутында кирәк урынына алып китеп куялар.

«Луноход»ның икенчесен дә шундый ук кечкенә, таза гәүдәле Факил Ганиев йөртә булып чыкты. Башкортстанның Үзләк станциясе егете. Шулай ук армиядән кайткан. Шулай ук танк йөрткән. Шулай ук башында — буынтыклы-буынтыклы кара шлемофон.

Язмышлары белән дә, үзләре йөрткән «луноход»лары белән дә бер-берләренә охшашкан бу егетләр!

Танклар хәрби һөҗүм вакытында корыч күкрәкләре белән пехотачыларга юл ярып, алдан барыр өчен кирәк. Погоннарын салган, ләкин кадерле шлемнарыннан һаман да аерыласы килмәгән шинельсез танкистлар — Сабиржан белән Факил — бүген дә тыныч хезмәт фронтының алгы сызыгында. РИЗ очраштырган, танкистлык хезмәте табыштырган аларны!..

Әйе, «луноход» танк түгел-түгелен... Тик кем белә бит: ашъяулык кадәрле генә җирдә чүкердәшеп эшләп яткан игезәк язмышлы бу егетләр үзләрен вакыт-вакыт РИЗ туфрагында түгел, ә серле ай күкрәгендә сукмаклар салып йөргән чын луноходта итеп хис итмиләр микән әле?..

Луноход!

Айда түгел, РИЗ туфрагында тирән эз калдырып, «луноход»лар йөри! Никадәр ярату, нихәтле җылылык салынган бу сүзгә! Әйе, халык әйтсә, хак әйтә шул, белеп әйтә.

Түбәдә мотороллерлар

РИЗ түбәсенә менгәч, үзеңне башта гаять зур стадионга килеп кергәндәй хис итәсең. Түбә өстеннән бер катлы йорт биеклегенә күтәрелеп, әкәмәт зур зонтиклардай тезелеп киткән аэрацион фонарьлар — гүя трибуналар. Шушы трибуналар каршыннан, бертуктаусыз тырылдый-тырылдый, мотороллерлар үтеп тора. Артларына тагылган прицеп әрҗәсенә түбәләмә итеп чуерташ, утын түмәрләредәй түгәрәк битум кисәкләре, төтене чыгып торган мастика төяп, алар түбәнең икенче башына чабалар. Артларыннан җил генә исеп кала! Күз ачып йомарга да өлгермисең, йөкләрен бушатып, тагын түбәнең бу башына килеп җителәр...

Түбә транспортын булдыру мәсьәләсе белән иң беренче булып Тольятти төзүчеләре кызыксына башлый. Очсыз-кырыйсыз түбә мәйданы. Тик менә түбә ябучылар искечә эшлиләр. Төзү материалларын һаман тачкалар белән ташый бирәләр. Техника да бар, югыйсә! Тик менә аны ничек кулланырга? Бәлки түбәгә мотороллерларны күтәрергәдер? Шулай эшлиләр дә.

КамАЗның гигант корпуслары түбәләрендә бу мотороллерлар гадәти һәм алыштыргысыз транспортка әйләнде.

Хәзер «Спецпромстрой» трестының мотороллерлар участогында 120 гә якын «кырмыска» бар. Һәр көнне иртә белән гаражда техник контроль үтеп, путевка алганнан соң, алар КамАЗ корпусларына киләләр. Махсус күтәрү җайланмасы аларны түбәгә менгерә.

Күтәрү кранының мотороллер әрҗәсенә йөк төяп торуыннан файдаланып, шул «кырмыскалар»ны йөртүче кызларның берсенә сүз каттым. Ул — молдаван кызы Оля Топал булып чыкты. Шакмаклы шәльяулыгы астыннан чыгып торган маңгай

чәчен шаян җил тарый. Алсу иреннәрендә — елмаю. Күренеп тора: механизатор кыз үз язмышыннан бик канәгать.

Комсомол путевкасы белән Чаллыга җибәрелгәч, үзе кебек үк егерме тугыз кыз белән, Оля Топал ДОСААФ комитеты оештырган махсус курсларда мотороллерчы һөнәренә өйрәнеп чыккан. Хәзер кызларның утызы да КамАЗда эшли.

— Сезне җил дә куып җитә алмый торгандыр, Оля! Сәгатенә 25—30 километр тизлек белән йөрисез икән. Куркыныч түгелме соң? Ни әйтсәң дә, урам түгел, түбә бит...

Йөк төялеп бетеп, корыч «кырмыска»сы чабыш атыдай кузгалып китәргә ашкынып торган Оля Топал кычкырып көлде дә:

— Һи-и-и, абыкаем! Җилдән генә уздыртып торган юк инде анысы, — диде.— Дөрес, безне «түбәдә сәгатенә 5 километр тизлек белән генә йөрергә рөхсәт ителә» дип өйрәттеләр. Ләкин моңарчы биредә ГАИ постларын очратканыбыз юк әле. РИЗга җылы бирү өчен, түбәне тизрәк ябып бетерергә кирәк. Шуңа кызурак йөрергә тырышабыз... Ә аннары... мин сезнең соңгы сүзләрегез белән килешә алмыйм, абыкаем! Түбә түгел, ә нәкъ менә ындыр табагыдай тап-такыр урам! Урамның да ниндие әле: киңе, озыны!..



Геодезистка.

Р. ИМАШЕВ рәсеме.

Әйе, КамАЗ түбәсендә дә үзен Кишинев урамнарындагыча иркен хис итүче бу кыю молдаван кызы белән килешмичә мөмкин түгел. Кем белә, самолет төшеп утырырлык КамАЗ түбәләре өчен ул инструкциядә каралган тизлекләр инде бәлки искергәндер дә. Аларның бәлки яңаларын язарга кирәктер...

«Кырмыска»сының сул колагын борып, Оля газны өсти төште дә пырылдатып китеп тә барды. Әрҗәсен тутырып чуерташ төягән мотороллер артыннан, Оляның зәңгәр шәльяулыгы кебек, зәңгәр төтен генә бөркелә иде.

Кәрнизләрдә язу бар

Ютазы егете, мастер Фрат Закиров белән түбә буйлап барабыз. Аларның участогы төп корпуста идән җәю, түбә тәрәзәләре — аэрацион фонарьларга пыяла кую белән шөгыльләнә. Сәгать теле кебек гел хәрәкәттә булган тынгысыз җанлы Фратны шуңа күрә әле төп корпуснын эчендә, әле түбәсендә очратасың. Урта буйлы, юантык гәүдәсе белән ул туп кебек тәгәрәп кенә йөри. Футбол кырыдай иркен бу түбәнең һәр карыш җире аңа яхшы таныш. Һәр кимчелек, һәр башкарылып бетмәгән эш анын күзенә ташлана. Мин сөкланып барган урыннарда ул еш кына, бусын фәлән, тегесен төгән иткәндә тагын да яхшырак буласы икән бит, дип уфтанып куя...

Шулай түбә буйлап барганда, күзләрем кинәт кәрниздәге язуларга төште. Житомир, Тамбов, Ирбит, Самара, Тбилиси, Киев, Фрунзе, Кушка, Воркута, Сәмәрканд... Сыек сумалага манчылган пумала белән кәрнизгә дистәләгән шәһәрләрнең исемнәре язылган!

— Кайсының кулы кычыта инде тагын? — дип йөзен чытып куйды Фрат Закиров, бу язуларны укыгач.— Бүген-иртәле түбәне кабул итәргә заказчылар киләчәк бит...

— Юкка борчыласың, мастер иптәш! Боларны язучыларга беркем бернә әйтә алмас. Болар бит — яшьлек автографлары! — дидем мин, аны тынычландырырга теләп.

Кәрнизләрдә язулар! Телогрейкалы иңнәрдә язулар!..

Үз исем-фамилияңне партага язарга ярамый, стенага ярамый, башка бик күп урыннарга ярамый дип, мәктәп бусагасын атлап кергәч үк колакларыбызга тукып үстергән сәекле укытучыларыбыз! Сез бу автографларның ияләрен бәлки гафу итәрсез? Бу язулар — гадәти булмаган язулар! Алар, иректән, рейхстаг колонналарына солдат әтиләребез штык белән чукып язган җиңү автографларын искә төшерәләр. Еллар алар арасында күзгә күренми торган һәм мәңге өзелмәслек җепләр суза.

Еллар үтәр. КамАЗ төзелеп бетәр.

Көнне-төнне аермый эшләп, Чаллы күкрәгендә бүген гасыр маягын — ил гигантын калкыткан яшь төзүчеләр, үсеп җитеп, үзләре әти-әниләргә әверелгән булыр. Инде шактый тузган, ләкин яшьлекнең иң кадерле ядкаре буларак сакланучы ул язулы телогрейкалар бер көнне сандык төбеннән чыгарылыр. Һәм алар, бүгенге камазчылар, яңа төзелешләргә китү өчен ерак юлга җыенган уллары һәм кызларына эчке бер горурлык белән:

— Менә бу телогрейкаларны киеп, без илгә КамАЗ төзедек! — диярләр!..

Кырыктан артык телдә илнең кырыктан артык шәһәр исемнәре язылган бу телогрейкалар музей залларында эленеп торыр! Һәм бирегә килүчеләр, ул кадерле экспонатларга карап, эчке бер горурлык белән:

— Менә бу телогрейкаларны киеп, безнең әти-әниләр илгә КамАЗ төзегәннәр! — диярләр.

Мин моңа ышанам! Минем моңа ышанасым килә!

Чөнки һәр буынның үз Магниткасы, үз Амурдагы Комсомольские булырга тиеш. Ә безнең Магнитка — КамАЗ ул!

Җыр

Менә бер заман корпус эче аккош йөзгән күлдәй тынып калды. Төш вакыты җитеп, төзүчеләр кайсы кая таралып беттеләр. Кеше-кара югында төп корпусның уң канатындагы бүлмәләрен иркенләбрәк карап төшим әле дип, бормалы баскычлардан өскә менеп киттем.

Зал буйлап барганда, янәшәдәге бүлмәдән тонык кына яңгыраган җыр ишетеп, кинәт туктап калдым. Йөрәк төбеннән кайнап чыккан, үзәк өзгеч җыр!

Бер илләәрдән чыгып киитккәч,
Кайтып буулмый тиз генә шул...

Үзем тыңлыйм, үзем җырлаучы агайның язмышы турында уйланам. Мин аны үтәдән-үтә күрәм төсле...

Менә җыр тынып калды. Ишеге дә куелмаган зур бүлмә эченә үттем. Борынга алебастр, цемент измәсенең таныш әчкелтем-дымсу исе килеп бәрелде.

Чандыр гәүдәле, биленә зәңгәр алъяпкыч бәйләгән шактый олы яшьләрдәге бер агай түр стенага кардай ак плитәләр тезә иде.

— Куәтең артсын, абзый кеше!

Ул плитә алырга дип иелгән җиреннән миңа сагыш тулы күзләре белән бер күтәрелеп карады да:

— Рәхмәт, энекәш, яхшы сүзеңә! — дип, эшен дәвам итте.

— Нишләп төшке ашка да туктамыйча эшлисе иттегез әле? Бик моңлы итеп җырлыйсыз да икән... Тик аңлашылмый: КамАЗда ошамыймы әллә сезгә? «Туган илгә кайтып булмый тиз генә» дип җырлаганга әйтүем инде...

Җыр сүзе чыгу белән ул эшеннән туктап калды. Ак плитәне кулына тоткан килеш, миңа якын ук килде дә:

— Җыруның ертыгы юк, энекәш! — диде.— Таныш булыйк: Әбекәрам Кәбиров булырмын мин. Хуп. Туган ил дисең инде син? Туган ил ул, энекәш, Ташкенында да, Чаллысында да берәү генә! Әмма ләкин ата-бабалар гомер иткән җирдә һәммә



КамАЗда яңа көн.

Э. ЗАРИПОВ рәсеме.

халыкны кузгаткан завод салына башлагач, түзеп торып булмады... Син, энекәш, армиядә хезмәт иттеңме соң?.. Хуп!.. Әбекәрам абзаң да хәзер службасын тәмамлап, өйгә кайтыр алдыннан сәгатен тәүлек итеп тоя башлаган солдат хәлендә... Өч бүлмәле квартирга ордер бирделәр, энекәш! Төнәген генә. Яңа шәһәрдән! Хуп!.. Инде карчык белән бала-чагаларны апкиләсе ие дә... Нәчәлнигемнән дә рөхсәт бар. Тик мондый кызу урак өстендә ничек кайтып китмәк кирәк? Күбенә түзгәнне, әзгә калгач түзми булмас. Хуп!.. Менә тапшырыйк әүвәле башта корпусны хуҗаларына. Вәт шуннан тыныч лап кайтып килермен дип торам...

Әбекәрам абзый мине ишек турысына алып килде.

— Нинди махинаны күтәрдек бит! Бер елда! Шушы куллар белән! — диде ул, ак плитәләргә төренгән якты, биек залга күрсәтеп.— Мамык эскертемени! Аппак!.. Вәт шуңа җырлата, энекәш!

Ул арада ашап-эчеп, бераз ял итеп алган башка плитәчеләр дә килеп җитте. РИЗда көнен дә, төнен дә тынып тормаган гадәти эш башланды.

Мамык төсле ап-ак плитәләр түшәлгән стеналар бертуктаусыз зурая, алар зурайган саен, корпус эчендә яктылык арта бара. Килер бер көн: бу зал-бүлмәләрдә яктылык һич бетеп тормас! Бу яктылык эштән соң бирегә ял итәргә кергән камазлыларның йөзенә күчкән булыр!.. Чөнки «игелекле эшнең иртә-киче юк» дип, көндезге ял вакытында РИЗ стеналарына җырлый-җырлый плитәләр тезгән, гаиләсе белән очрашу шатлыгын үзе үк һаман кичектерә килгән Әбекәрам абзый һәм аның хезмәттәшләренең метлах плитәләре төсле ак күңел сафлыклары, хыял-омтылышлары да сеңеп кала бит бу стеналарга!

Сигарет һәм анкер

Степан Иванович Уразаев белән сөйләшеп утырганда, бик ашыгып, штабка бер егет килеп керде. Әрекмән яфрагыдай киң погонлы «роба»дан. Иңбашына кәкребөкре тимерләр — анкерлар аскан. Сул кулының бармаклары арасында — ут алынмаган сигарет. Хуҗасы гүя бөтенләй онытып, ул шулай ике бармак арасына кысылып калган.

— «Бомба» ташладылар! — диде егет, керә-керешкә.— Срочно су суырткыч насослар кирәк!

Штаб начальнигының киң маңгайлы йөзе кызыл кирпечтәй кызарып чыкты. Ул, үзе дә абайламастан, җәһәт кенә урыныннан торды.

— Туктале, юньләп сөйлә! Кая ташладылар? Нинди бомба? Кем син? Кайдан?..

— Зөфәрит Бикташев булам мин... СМУ семьнең баш механика бүлегеннән. Слесарь... Вәт шулай... Өч ай буе көне-төне РИЗның канализация станциясен төзедек. Соңгы трубаларны сузып, резервуарларны күмәсе генә калганые. Инде эш бетә дип торганда — менә сиңа мә! Бүген иртүк эшкә килсәк... күзләребез шар булды. Бер резервуарыбызның эче тулы су!.. Пычаксыз суйдылар, Степан Иванович, пычаксыз...

— Су-у-у?! — дип бүлдерде аны Уразаев һәм, үз-үзенә дәшкәндәй, гаҗәпләнеп өстәп куйды.— Каян килергә мөмкин соң ул су?..

Кинәт аның муен тамырлары бүртеп чыкты. Ул, ике кулы белән пеләш баш түбәсен учлап, теше сызлаган кешедәй бераз авыр сулап торды да телефон трубкасын алды.

— Теплотрассадан агызганнар диме шунда. Теге... трубаларны сынаганнан калган суны...

Ләкин штаб начальнигы күптән барысын да аңлап алган иде инде. Ул, сүзсез генә башын ымлап, слесарь егеткә рәхмәт әйткәндәй итте дә, ашыга-ашыга, үзенә кирәкле номерны җыя башлады.

Зөфәрит, биредә үзенең кирәге бетте дип булса кирәк, саубуллашты да кабаланып чыгып китте. Мин дә аңа иярдем. Штаб начальнигы телефоннан сөйләшеп калды:

— Спецстрой! Спецстрой!.. А-ло! СМУ сиксән икеме?.. Менә нәрсә, Гурьянов! Тиз генә берничә насос җибәрегез! Ишкәнсез икән ишәк чумарын сез монда!..

Торнанықы кебек озын ботлары белән җил-җил атлап, Зөфәрит алдан бара. Анкерлы болтлар һаман җилкәдә. Сигарет һаман кабызылмаган... Тукта, тукта! Нишләп штаб хәтле штабка кадәр өстерәп килгән әле ул артык йөк итеп бу авыр анкерларны?

— Шырпың юк, ахры. Мә, Зөфәрит, кабызып җибәр, булмаса...

— Ә-ә-ә, шырпымы?.. Бар ие барын... Болай... истән чыккан,— диде ул һәм сигарет капкан авызын минем кушуч эченә төртте.

— Ә анкерлар?

Зөфәрит, иңбашындагы анкерларны әле генә күргән кешедәй, озын чәче ишелеп төшкән җилкәләрен сикертеп куйды.

— Штабка барышлый мастерскойда калдырып китәрмен дип алганыем мин аларны...

— Болары да истән чыкканмы?

Җавап бирү урынына Зөфәрит кулын гына селтәп куйды һәм, бу турыда сүзне беткәнгә санап, үзенекен сөйләргә тотынды:

— Ярый әле, көннәр җылы тора. Биш градус салкын булдымы, су кысылып, резервуарның шартлавы мөмкин. Значит, безнең өч ай буе чиләнүләр җилгә очты дигән сүз! Резервуардан суны суыртып чыгару өчен кимендә бер көн вакыт кирәк. Әле монысы да көчле насослар булганда гына. Безнең «пульт-пульт»лар белән анда берни дә кырып булмый... Инде килеп «Гидромонтаж» безнең аркада бер көн буе эшсез торсынмы?.. Да-а-а, хәлләр ал да гөл, калганын үзең бел! Йөр инде менә хәзер кеше ураста, без эштә дип...

Җил-җил атлап, олы юлдан барабыз. Аның уенда — су тулып бер резервуары шартлар дәрәҗәгә җиткән канализация — насос станциясе. Ул инде уңъяк иңбашын басып барган авыр анкерлар турында янә онытты булса кирәк (мастерской турысын узып барабыз). Һәм бәлки бу турыда башка беркайчан да исенә төшермәс...

Еллар үтәр. КамАЗ төзелеше бер заман ерак тарих булып калыр. РИЗның иң кайнар, иң авыр көннәре дигәндә, бармак араларына кысылган, әмма ут алынмаган сигареты, иңбашында тирбәлеп барган анкерлары белән ул — Зөфәрит Бикташев исемә төшәр!..

«Бир бишне!»

Штабка кайтып килгәндә, сиртмәле угының буеннан-буена «КамАЗ төзүчеләре 2 миллионынчы куб метр бетон өчен ТПП[1]га рәхмәт белдерә» дип язылган автокран күренде. Уразаевтан бу турыда җентекләбрәк сорашырга кирәк әле дип, аңа сугылдым. Ул тирләп чыккан киң маңгаен кулъяулыгы белән сөртеп тора иде.

Сүз башланып китәргә дә өлгермәде, штабка производство предприятиеләре трестының партком секретаре Петр Кряхин килеп керде. Кош тотканмыни! Йөзе балкыган, бит алмалары алсуланып тора...

Тулы гәүдәле, түгәрәк битле, һәр вакыт ачык чырайлы бу егетне мин күптәннән беләм. Чаллыга бер тирәдәрәк — җитмешенче елның җәендә килгән идек. Петя башта Бөтенсоюз удар төзелеш штабы начальнигы урынбасары булып эшләде. Хәзер менә — зур трестның партком секретаре!

— Я, Степан Иванович, кайсы җиргә салынды инде ул безнең истәлекле бетон? Шуны күрәсе иде,— диде ул, кул биреп исәнләшкәч.

— Киттек, алайса, сиксән җиденче оська!

Сиксән җиденче ось дигәннәре штаб каршында гына булып чыкты. Кое кебек текә итеп казылган тирән чокыр. Чокыр эчендә биле берничә урыннан агач «камыт» белән буылган бура-калып. Калып өстенә толь капланган.

— Менә шушында салынды инде ул,— диде Степан Иванович, изоляция толенең бер читен күтәрә төшеп.— Ипи камырымыни: чемер-чемер итеп тора!

— Бу нигезгә нинди станок куелачак соң?

— Бик дәве... Төгәлрәк итеп әйтсәкме? Өч тонналы строгальный станок!

— Алай икән... Әгәр бу нигез янындагы колоннага мемориаль такта куйсак, ә? Әйтик, «1972 елның фәлән көнендә бу станок нигезенә ТПП әзерләгән 2 миллионынчы куб метр бетон салынды. Аны автотранспорт идарәсе шоферы Александр Ворошилов алып килде. «Автозаводстрой»дан Виктор Стрельченко бригадасы калып эченә агызды»,— дип язып?.. РИЗ эшли башлагач, ул бу цех токарьларына күп нәрсә сөйли алыр иде бит!

— Карап-карап торам да, синең дә бармак үзеңә таба кәкрәя башлаган икән бит, Петр Ильич! Үз предприятиеңне тарихка кертеп калдырасың килә инде, ә?

— Ни әйтсәң дә, түгәрәк дата бит, Степан Иванович! Мондый темплар белән барганда, өч миллионынчысына инде РИЗ күптән төзелеп беткән булыр.

— Шаяртып әйтәм, Петр Ильич! Шаяртып кына-а-а... Ә, гомумән алганда, бик яхшы идея бу!

— Килештек, алайса?

— Ике куллап!

— Бир бишне!..

Иске яңа установка

Ремонт-инструмент заводы белән танышып йөргән көннәрнең берсендә бөтен игътибарны үзенә тарткан «Яшен»гә юлыктым:

«Бүген УФБ-1 установкасы КамАЗда беренче мәртәбә сынау үтә. Аның бетон фрезерлау сәләте — сәгатенә 60 квадрат метр.

РИЗның матбугат үзәге».

Моңарчы башка «Яшен»нәрдән укып, бер эшченең сменага күп дигәндә 6 квадрат метр бетон идән шомарта алуын, каткан бетон өслеген тигезләү төзүчеләрнең теңкәсенә иң нык тигән мәсьәлә икәнен белә идем инде. Ә менә бу яңа установка берүзе җитмеш кешене алыштыра ала икән ләбаса! Болай булгач, нибары берничә атна эчендә РИЗның бөтен идәнен «ялап» чыга инде ул!

[1] ТПП — производство предприятиеләре тресты. Аңа, башлыча, Чаллыдагы измә-бетон, тимер-бетон конструкцияләр, агач, чуерташ җитештерү заводлары керә.

Серле установка турында күбрәк белер өчен, РИЗ төзелешендәге комсомол штабына кереп киттем. «Автозаводстрой» парткомы җитәкли торган штабның яшьләр филиалы шушы була инде. «Яшен»нәрнең оясы...

Будка эчендә буйдан-буйга сузылып киткән озын өстәл тора. Өстәл өстендә кая карама табак-табак кәгазь, пыяла банкага салынган төрле төстәге буяулар, карандаш-пумалалар ята. Ләкин линейканы биредә көндез чыра яндырып эзләсәң дә табармын димә. Биредә хәрефләрнең юанлык-озынлыкларын үлчәп азапланмыйлар. Инкубатор чебешләре кебек, сәгать саен туып торган «Яшен»нәрдәге хәрефләрне ничек үлчәп бетермәк кирәк? Иң әһәмиятлесе, эчтәлеге әйбәт булсын!

Өстәл әйләнәсендә дүрт-биш кеше. Кемдер, телефонга «асылынып», мәгълүматлар җыя. Кемдер аларны тиешле калыпка сала. Кемдер әзер текстны кәкре-бәкре хәрефләр белән «Яшен» битләренә төшерә. Кемдер, тиешле оешмалардан телефон аша җавап таләп итеп, чыккан «Яшен»нәрнең нәтиҗәлелеге өчен көрәшә.

«Юл уңае»ннан комсомол штабы начальнигы Володя Колтунов белән таныштым. Ул күтәрү краны кебек озын буйлы, ябык гәүдәле, иягенә берәм-сәрәм генә сакал бөртекләре төртә башлаган яп-яшь егет булып чыкты. Володя — булачак РИЗның технигы. Завод өлгергәнче комсомол комитетында эшләп торырга билгеләгәннәр икән үзен. Акрын гына, быдыр-быдыр гына сөйли. Ләкин үткәзеп сөйли.

Яңа установканы эзләп киттем. Көпчәкле трактор охшаган булыр, дигән идем Володя аны. Бу установка КамАЗга килгәнче Киев, Ленинградта, тагын әллә кайларда сынау үткән инде. Хәзер чират — Чаллыга! Тәҗрибә өчен чыгарылган мондый установкалар бөтен СССРда берничә генә икән әле.

Килсәм, ни күрим: искереп, буяулары кубып, кыршылып беткән бер трактор!

— Сез яңа установканың кайда сыналганын белмисезме?

Зәңгәр комбинезонлы бер агай, «әллә бүген генә дөньяга килдеңме?» дигәндәй, миңа астан гына бер карап куйды да көлеп җибәрде:



КамАЗда беренче станок.

В. ИГНАТЬЕВ рәсеме.

— Ха-ха... Менә шушы була инде ул яңа установка!

— Кай җире яңа булсын — чыкмаган «җаны» гына бар ич моның!

— Ә-ә-ә, брат, шаярма син аның белән! — диде агай.— Заманында космодромны төзешкән установка ул!

— Мастер шаяртмый. Мәскәү хәтле Мәскәүдән, махсус КрАЗ белән барып, бишектәге бала кебек иркәләп кенә апкайттык үзен,— дип, сүзгә кушылды сакалмыек үстергән ир уртасы егет.

Ул әлеге установканың хуҗасы Рәшит Закиров булып чыкты. Яңа установканы Рәшиткә ышанып тапшырулары тикмәгә түгел икән. Ул, Чаллыга килгәнче, Тәтеш районының Бидәнге авылында, аннары Казагыстан далаларында озак еллар тракторчы булып эшләгән. Кечкенәдән үк машина «җене» кагылып, техникага бик мәһир егет булып үскән. Үзе йөрткән һәр машинаны биш бармагы кебек белә.

Фрезерлау установкасы белән ничек эш итәргә өйрәткән инструкцияне укучы бердәнбер кеше дә әлегә ул. Калган механизаторлар өлгермәгән. РИЗ өчен шул кадәр кирәкле яңа машинаны тизрәк ходка җибәрәсе бар бит. Шуңа күрә һәркемнең күзе Рәшиттә. Нәрсә әйтер икән дип, авызына карап кына торалар. Ләкин ул үзен бик гади тота. Установка белән кызыксынган кешеләргә:

— Һи-и-и, бер катлаулылыгы да юк. Моторы да ЗИЛ-157 автомобиленеке бит аның! — дип кенә җибәрә.

«Татэнергомеханизация»нең Чаллыдагы кече механизация идарәсе мастеры Владимир Федорович Шенцель — бая миңа саргылт кашлары астыннан карап көлгән агай — Рәшит турында болай диде:

— Минем үземә дә, кем әйтмешли, караңгы урман әле бу установка. Аны белүче КамАЗда Рәшит кенә. Төрле җиргә күчеп йөри-йөри, инструкциянең кайбер битләре югалып та беткән иде. Ләкин Рәшит аптырап калмады. Машинаның йөрәгенә үз зиһене белән барып җитә алды.

Яңа установканы куллану КамАЗ идәннәренә шашкалар җәю эшен бик тизләтәчәк икән. Эш шунда: мондый шашка-шакмаклар җәелгән завод идәне шома, матур килеп чыксын өчен, алар астында калачак бетон катламы көзге кебек типтигез булырга тиеш. Шулай булмаса, вак шакмакларның кайсы батып, кайсы калкып торачак... «Ялгышу» нормасы — нибары 2—4 миллиметр! Туптан атып чыпчык күзенә ядрә тидерү белән бер бит бу! Чөнки, гадәттә, бетончылар җәйгән бетон өстенең тигезсезлеге, бик тырышып эшләгәндә дә, 15—20, кайчакларда хәтта 40 миллиметргә хәтле җитә. Шунлыктан каткан бетонны тигезләү-струклау башлана.

Моңарчы бу эшне мозаик идәннәрне шомарта торган «нәзберек» механизмнар белән генә башкарып килгәннәр. Чөнки башка коралы юк! Нигә юк? Чөнки тормыш моңарчы таләп итмәгән. Нигә таләп итмәгән? Чөнки, Волга автомобиль заводыннан тыш, моңарчы илебездә бер генә завод-фабриканың да идәннәрен мондый «гектарлаган» мәйданда тигезләү-шомарту булмаган. Нигә булмаган? Чөнки завод идәннәренә шашкалар түшәү безнең илдә соңгы елларда гына кулланыла башлый. Ә гади бетон идәнне алай «нечкәртеп» маташуның кирәге булмаган.

Әйе, КамАЗның болындай иркен, киң идәннәре төрле мозаик бизәкләр төшерелгән кечкенә участок түгел. Менә ни өчен РИЗ идәннәрендә шомарту механизмнарының «теш»ләре бик тиз үтмәсләнеп чыга. Болай эш бик озакка да сузыла. Механизм сәгатенә нибары бер квадрат метр идән шомарта ала. Эшче куллар күп кирәк. Ничаклы электр энергиясе тотыла. Җитмәсә, уч төбе хәтле җирдә бөтерчек кебек әйләнеп торган дистәгә якын шомарту механизмнары күз ачкысыз тузан чыгара.

Ә менә хәзер сынау үтә торган бу яңа установка алмаз бөртекләре тезелгән фрезлы күчәре белән бетон өслекне кирәкле тирәнлектә «ялап» кына алачак. Һәм идән әзер: агач шакмакларыңны түши башла! Тиз дә, чиста да. Тузанның әсәре юк. Бетон «кимерүче» алмазлар янып чыкмасын өчен, шомартыла торган мәйданга махсус шлангтан автоматик рәвештә су сиптерелә.

Дөрес, әлегә фрезлар тигез әйләнми икән. Бер як тирәнрәк ала. Кичәдән бирле шуны төзәтеп азапланалар. Установканың баш конструкторын чакыртып, Мәскәүгә телеграмма да җибәргәннәр. Бүген-иртәгә килеп җитүе көтелә.

Ә яңа установканың артык иске булуына сәбәп шул: җимерелгәнче-тузганчы эшләргә тиеш ул. Аннары, табылган кимчелекләрен бетереп, аны күпләп җитештерүгә тәкъдим итәчәкләр икән.

Җиде туларга биш минут

Театр кием элгечләреннән башлана, диләр.

Төзүченең эш көне иртәнге автобустан башланып китә. Мин эшчеләр белән шыгрым тулы «вахтовка»ларда утырып барырга яратам.

Күңелләрнең керләнергә өлгермәгән саф, чиста чагы!

Берәүләр кичтән укып бетерә алмаган китапларына тәкәлгән; икенчеләр нинди-дидер отметкалар, кондиционерлар, перемычкалар турында сөйләшә; өченчеләр, автобус тәрәзәсенә карап, тирән уйга талган. Я булмаса, кайсыныңдыр теленнән мәзәк сүз очып төшә дә, автобусны туктатырлык итеп, иптәшләре берьюлы көлешеп куялар.

Төзүченең ничек эшләве күпмедер дәрәҗәдә аның иртәнге автобустан нинди кәеф белән төшүенә дә бәйле, минемчә.

Тик бер нәрсә эчне пошыра.

Автобус кузгалып китеп бераз вакыт үтүгә, кырык минутлап юлга чыдый алмаган кайбер түземсезләр тәмәке пыскыта башлый. Еш кына хәтта шоферлар үзләре дә моның ярамавы турында авыз ачып бер сүз әйтмиләр. Чөнки белеп торалар, әйтсәң — күптән җавап әзер:

— Автобусның хуҗасы кем — без! Кем аны арендага алды — безнең идарә! Шулай булгач?.. Телеңә салынып торма, шеф, элдерт давай!

Беркөнне автобус кабинасының арткы ягына язып куелган сүзләр исне китәрде: ат башы хәтле хәрефләр белән «Не бросай окурки и не сори!» диелгән. Җитмәсә әле, өстеннән пыяла белән каплап, рамга уратып куйганнар.

Ишетмәсәң ишет, тау асты Кишет! Димәк, бу автобуста тартып барырга рөхсәт ителә?.. Тик төпчегеңне генә идәнгә ташлама, чүпләмә, янәсе!

Каның корымаслык түгел. Шофер егетнең тәмәкечеләр каршында кулын күтәрүен раслап сугылган пичәт бит инде бу лозунг!

Бүген дә шулай булды.

Машина кузгалып озак та үтмәде, тәмәкечеләр үз эшләренә керештеләр. Бераздан автобус эчендәге төтенгә тотынып барырлык булды. Арада хатын-кызлар да бар, югыйсә. Тик алар да, авызларына су капкандай, дәшми баралар. Күнегелгән.

Ләкин бу ни хәл?.. Әйбәт кенә барган җиреннән юл читенәрәк чыга төште дә автобус кинәт туктап калды. Алгы һәм арткы ишекләр төбенә чаклы ачылды. Микрофоннан шоферның кырыс тавышы ишетелде:

— Кемнәр тарта, рәхим итсеннәр! Көтеп торабыз...

Әйтерсең автобус эчендә аяз көнне яшен ялтырады. Тавыш китте, шау-шу китте:

— Кара, кара! Чебен дулап тәрәзәне ватмакчы...

— Ут белән шаярма, шеф, алдыңа кара да атыңны куала!

— Җитәр пыскытырга!

Хатын-кызлар да шоферны дәррәү яклый башлагач, тәмәкечеләр бу юлы чигенергә мәҗбүр булдылар. Бирелмәсләр иде — эш башланырга нибары егерме минут!

Кабызылган папиросларсүндерелде. Автобус үз юлын дәвам итте. Карале, бергәләшеп тотынгач, тәмәкечеләрне дә авызлыкларга була икән бит, әй!

«Молодежное» поселогын үткәч, хәрәкәтнең иң җанлы урынында туктап калган бер «МАЗ» очрады. Минзәләдән кайтып килеше икән. Ягулыгы беткән. Автобусны туктатты да безнең «шеф» аның шоферына ярты чиләк солярка агызып бирде.

Ә җиде туларга нибары унбиш минут!

Хәерчегә җил каршы дигәндәй, ремонт-инструмент заводына җитәрәк, җылылык трассасының галәмәт озын көтүче чыбыркысы кебек көмеш трубалары олы

юлны аркылы атлап чыккан турыда, автобус моторы кинәт тынып калды. Шофер кабинадан сикереп төште, хәлне тиз генә ачыклап керде. Двигатель клапаны астына су кергән икән. Булыр, булыр... Яз бит тышта, бил тиңентен су бит көпчәк эзләрендә!..

Хәзер инде тәмәкечеләр тәмам ярсулы һөҗүмгә күчте:

— Үз борын астын җыештыра белми, башкаларга булышкан була тагы...

— Трамвайда дип белдең мәллә безне? Адым саен туктап барырга...

— Соңга гына калдырып кара! Җавабын үзең бирерсең...

Ә җиде туларга нибары ун минут!

Шофер егеткә бу каргыш яңгыры әллә бар, әллә юк — автобусның арт капкачын ачкан да моторында тыныч кына казынуын белә. Юлбарыс тиресе күк юллы-юллы калын кепкасын куе каш өстенә үк бастырып кигән. Кызыл свитерының җиңнәре терсәгенә чаклы сызганулы.

Гәүдәгә кечкенә булса да, шофер егет уңган, күрәсең. Бер тәмәке тартып алырлык вакыт та үтмәгәндер, автобус тагын олы юл буйлап чаба иде инде.

«Хәзер, шәт, бәйләнә алмас» дипме, кайберәүләр янә кесәләреннән папирос чыгара башлады. Үзсүзле шоферны җиңгәнлекләрен күрсәтәләр, янәсе! Тик, автобус туктарга чамалап, тизлеген акрынайтуга, папирос каплары янә кесәгә тыгылды.

Ә җиде туларга биш минут!

Автобус РИЗга вакытында килеп җитте:

— Тютелька в тютельку! Бер тартып алырлык вакыт та калдырмады, имансыз! Номерыңны язып алдык. АТХаңа хәбәр итәчәкбез! — дип, тәмәкечеләр теш кайрап төшеп киттеләр автобустан.

Ә ирен кырыенда аксыл җөй эзе калган берәү, шоферның җилкәсеннән кагып:

— Теләсәң, эшкә минем бригадага килә аласың.— диде.

Мин, чыгышлый, «кире беткән» шоферга сүз каттым:

— Ватылганнан соң, икенче мәртәбә туктарга чамалавыңның кирәге булды микән, шеф? Ни әйтсәң дә, эш башланырга биш минут кына калган иде бит...

— Биш минут? — дип кайтарып сорады шофер егет һәм җәһәт кенә җиргә сикереп төште дә аяк астында аунап яткан арматура чыбыгын кулына алды. Тагын бер мизгелдән исә бармак юанлыгындагы арматура чыбыгы дага кебек бөгелгән иде.

— Менә... Моны бөгү өчен бер секунд та җитте. Аны яңадан турайтырга була, билгеле. Тик ул элеккечә нык булмаячак инде. Ә син биш минут дисең!..

Әйе, бер бөгелсә, тимер булып тимер дә ныклыгын югалта шул.

Бер сынма, бер сыгылма икән бу тормышта!

Күпер

Мәләкәс елгасы аша салынган чуен күперне чыгуга, безнең автобусны бер әби туктатты. Кара плюш пальтосы өстеннән шакмаклы калын шәл бөркәнгән тәбәнәк буйлы бу әби дәү төенчеккә охшап калган иде. Ерак юлга җыенган, күрәсең...

— Сиңа кая, әбекәй? Бу бит — вахтовка, РИЗга бара,— диде шофер егет, яртылаш ачылган автобус ишегеннән тубал бүрекле башын сузып.

— Һай, рәхмәтләр яугыры! Туры килеп торуың зерә дә әйбәт булды әле, балам! — дип, әби автобуска кыймыл-кыймыл керә үк башлады.

Алгы рәттә утырган брезент курткалы монтажчы егет, итәгенә ут капкандай сикереп торып, аңа үз урынын бирде:

— Рәхим ит, әби!

— И-и-и, рәхмәтләр яусын инде, балам! Аяк-кулларың сызлаусыз булсын берүк,— дип, әби йомшак урынга килеп утырды.

Тик автобус һаман кузгалып китми иде әле:

— Син бу машинага ялгыш утырдың бугай, әбекәй! Үзеңне заводка илтеп ташласам, адашып кайталмый йөрерсең бит...

— Онытым янына гына илтеп куйсаңчы, балам! Ул үзе дә: «Сиңа заводны күрсәтеп кайтам әле бер, әби!» — дип, бик гайрәт орып йөридерие. Вакыты тыгыз бугай шул, җитешә алмыйдыр инде, багалмам...

— КамАЗ бик дәү бит ул. Онытың кайсы заводны төзи соң, әбекәй?

— РИЗны, балам. РИЗны...

— Һи-и, әби, алай булгач, юллар бергә икән безнең,— дип гөрләштеләр егетләр.— Әйдә, шеф, кузгал, тот рульне туры!

Сөйләшеп бара торгач, бик олы язмышлы кеше булып чыкты безнең Асылбикә әбиебез. Ул әле утызынчы еллар башында ук карты белән Амурдагы Комсомольск шәһәрен салышкан. Карты,— кайчандыр безнең кебек үк беләгендә көч, йөрәгендә дәрт ташып торган Чаллы егете,— моннан берничә ел элек дөнья куйган икән.

— И-и-и, насыйп булмады шул Тимерханга бу тамашаларны күрергә, насыйп булмады-ы-ы! — дип, Асылбикә әби көрсенеп куйды.— Менә сез хәзер эшкә ак пәрдәле афтауызларга гына утырып йөрисез. Без иңбашына кәйлә-көрәк саладырыек та җәяү генә теркелдәр иек... И-и-и, заманалар, биллəһи.

— Син бит аяклы тарих икәнсең, әби! Бүген бригадада политинформация көне иде. Әйдәле, безнең белән төшеп калыйк! — дип кыстый башладылар монтажчы егетләр әбине.

— Куегыз, куй, балакайларым! Хәтерләрем дә начарайган. Миннән әгитәтерфәлән тагы...

Бераздан автобус эче, ничектер, тынып калды.

Сизеп торам: бу минутларда безнең һәрберебез КамАЗ төзүче оныгы янына барырга чыккан әби, аның кызыклы үткәне турында уйлый иде.

Ә менә Асылбикә әби үзе машиналар агылып торган юлдан ниләр кичереп барды икән?

Ул арада кемдер акрын гына җыр башлап җибәрде:

Хәтердә ул тыныч, айлы кичләр,
Хәтердә бормалы су юлы-ы.
Онтылмый беренче саф мә-хәб-бәт,
Онтылмый Агыйдел сылуы-ы.

Аңа башкалар кушылды.

Үзеңне автобус эчендә түгел, ә Кама дулкыннары өстендә тирбәлеп барган көймәдә кебек ничек хис итмәссең! Монтажчылар җилкәсенә эленгән чылбырларның әледән-әле селкенеп куюы саратский гармун чыңын хәтерләтә иде.

Җыр, ярты юлда моторы сүнгән автобус кебек, кинәт тукталып калды:

Сез искә алыгыз яшьли сөйгән...

Моның сәбәпләрен эзләп, без бер-беребезгә караштык. Ә тагын бермәлдән барыбызның да күзләр юлдаш әбигә текәлгән иде.

Ул эсселәп киткән, күрәсең. Калын шәлен салып алдына куйган. Чулманның ак сыртлы дулкыннарыдай чал чәчләре чәчәкле кәшимир яулыгы астыннан бүселеп чыккан да җыерчыклы маңгаена чәчелгән. Ә уңган яулык төсле агарган ике як битеннән, юеш эз калдырып, ике көмеш тамчы тәгәрәп төшеп килә иде...

Кич эштән кайтышлый, маңгаена «РИЗ-КамГЭС» дип язылган шул ук шыгрым тулы автобуста бу әби яңадан очрады. Ул иң алдагы урынга утырган да автобус кабинасының боз катмый калган алгы як пыяласыннан тирә-якны бик бирелеп күзәтеп кайта иде.

Әбинең йөзе яшәреп киткән төсле күренә. Аның янәшәсендә, басып, озын буйлы тагын бер егет кайта. Ул, каршы як тәрәзә пыяласына таба кулын суза-суза, әбигә вакыт-вакыт нидер сөйләп ала иде.

Күпергә җитәрәк, шоферга күптин-күп рәхмәтләр әйтеп, Асылбикә әби белән озын егет автобустан төшеп калдылар. Мин дә төштем. Әби белән егет агач йортлы тыкрыкка кереп китте.

Кем булды икән Асылбикә әбине җитәкләгән бу егет? Әбинең оныгымы, әллә булмаса, аны озата баручы бөтенләй ят монтажчымы?.. Хәер, моның ул хәтле ни әһәмияте бар соң?!

Кичке Чаллы утларына сокланып, бер алдыма, бер артыма борылып карый-карый, озын күпер буйлап атлыйм.

Бер якта — болытларга ашкан унике катлы ташпулатлар, икенче якта — җиргә сеңгән агач йортлар. Бер якта — без яшәгән яңа Чаллы, икенче якта — Асылбикә әбиләр гомер иткән Иске Чаллы.

Ике ярны тоташтырып торучы күпер!

Һай, шәп, һай, мәңгелек итеп салганнар да соң бу күперне! Бер башыннан икенче очы күренми. Стройдагы солдатлар кебек тезелешеп киткән бетон колонналар өстенә сузылып яткан да, Иске Чаллыны яңасына, Яңа Чаллыны искесенә озатып тора.

Күпер өстендә хәрәкәт туктап тормый.

Без — яшьләр үтәбез, әти-бабайлар үтә...

Давыл һәм җыр

Түбә блокларын җирдә әреләндереп җыю конвейерында эшләүче монтажчылар кичке әбәткә туктады.

Шуны гына көткәндәй, кинәт Чаллы күген каяндыр төньяктан томырылып чыккан кургаштай авыр болытлар каплап алды. Җил-давыллы көзге яңгыр коя башлады.

Без, давыл алдыннан канат астына сыенган каз бәбкәләре кебек, зәңгәр будкаларга кереп тулдык. Берәүләр домино, шахмат-шашка уйнарга, икенчеләр тамак ялгап, газета-журнал караштырып алырга кереште.

Будка эчендә якты, җылы иде. Бераздан җил-давыл бөтенләй онытылды. Тик форточкаларның шалт-шолт ачылып-ябылып торуы гына тышта «пәри туе»ның әле һаман дәвам итүен сөйли иде.

Менә әбәт вакыты үтеп китте. Ләкин берәүнең дә салкын җил оясына башлап чыгып китәргә батырчылыгы җитми иде. Кемдер, будка ишеген ачып, башын гына чыгарып карады да:

— Рәхәтләнеп уйнагыз! Барыбер бу җилдә монтажлап булмаячак! — дип, яңадан үз урынына килеп утырды.

Шул чак, будка ишеген төбенә хәтле ачып, күрше бригада монтажчысы Фәез Әмиров килеп керде.

— Женя, ви-ра! Краныңны давыл аудара күрмәсен! — диде ул.— Валя әнә кабинасында: кран сиртмәсен гел җилгә каршы борып утыра...

— Уен-муен эш түгел... Вира, крановой, ви-ра! — диештеләр уендашлары, кул ишарәләре белән Женяга урыныннан торырга киңәш итеп.

Кранчы ашыкмый гына урыныннан күтәрелде һәм теләр-теләмәс кенә төнге караңгылыкка чыгып югалды. Мин дә будкадан тышка ашыктым.

Фәезнең сүзләре колактан китми. Үзем монтажчылар каскасы төсле чем-кара төнгә каршы атлыйм, үзем, онытылмасыннар дигәндәй, шул бая гына ишеткән сүзләрне кабатлыйм:

— Валя кранда берүзе... Ирләр булып ирләрне җылы будкаларга качырган шушы мәхшәр уртасында яңа-ялгызы!.. Краны аумасын өчен, аның озын сиртмәле угын ул гел җилгә каршы борып утыра!.. Берүзе!.. Җилгә каршы!..

Валяның үзен күргәнче үк, моның шулай булуына тирән ышанган хәлдә, әбәткә чаклы монтажланып өлгерә алмаган блокның корыч терәкләре арасына кереп бастым.

Шашкын җил тимер юл вагоннарын хәтерләтүче аерым блоклардан төзелгән конвейерны, рельслар буенча тәгәрәтеп алып китмәкче булып, селкетеп-селкетеп куя. Ләкин аны тотып торучы куәтле чыгырларның гитара кыллары кебек тартылган корыч арканнары өзелми. Тормоз башмаклары ныгы! Алар, майланмаган капка кебек, вакыт-вакыт шыгырдап кына куялар.

Кран кабинасы түбәсенә тияр-тимәс аккан кургаш болытлар астында, актарылган-бөтерелгән көчле давыл уртасында, биек агач башларыдай тирбәлеп торучы кранның сиртмәле угын, флюгер кебек, минутына кырыкмаса-кырык якка борып

РИЗ эшчесе А. МОРОЗОВ.

В. ИГНАТЬЕВ рәсеме.

утыручы гүзәл Валя! Әйе, әйе, ялгышмадым! Туптай йомры гәүдәң, түгәрәк йөзең, күпереп торган калын иреннәрең, почык борының сине чибәрләрнең-чибәре итеп күрсәтмәсә дә, җаның чибәр икән синең, күңелең гүзәл икән, Ленинград кызы!

Кем белән, нәрсә белән чагыштырырга синең батырлыгыңны?!. Кара карчыга кебек томырылып, фашист самолетлары җиңелмәс Ленинград өстенә кадалганда, яндыргыч бомбаларны сүндерергә әзер булып, ачык кырдай шыр ялангач йорт түбәсендә утыручы блокада кызынамы?!. Әллә берәзлексез миналар чинаган, снарядлар-пулялар сызгырышкан сугыш кырында яралыга беренче ярдәм күрсәтергә теләп шуышучы шәфкать туташынамы?!.

Тукта, чү!.. Ни бу?.. Үзәккә үткеч нинди моң бу?

Кемдер, үзе чирткән гитарага кушылып, ярсып-ярсып җырлый иде. Миңа таныш түгел телдә яңгыраган бу җыр бер башлана да бер бетеп тора. Гүя кемдер радиоалгычта үзенә кирәкле җыр тапшыручы дулкынны тота алмыйча азаплана иде.

Гаҗәпләнеп тирә-ягыма карыйм: кем җырлап йөрер бу күзгә төртсәң күренмәслек кара төндә, гитара чиртеп?.. Валя краны кабинасыннан ишетелә түгелме соң бу җыр? Шулай ич... Күрәсең, Валя транзисторын борып җибәргән.

Ул арада җыр акрынайды, диктор сүзләре ишетелде:

— Аның кулындагы гитара хунтачыларга һәртөрле автомат-пулеметлардан куркынычрак, ул җырлаган җырларның һәр сүзе пулялардан җитезрәк булып тоелган. Шуңа күрә хунта фашистлары, гитара кылларына чиртә алмасын өчен, башта аның бармакларын сындырганнар. Аннары, җырлау бәхетеннән мәхрүм итү өчен, телен кисеп алганнар. Ә аннары мылтык түтәсе белән бәреп башын ярганнар. Ләкин коммунист Виктор Хараның җырлары бүген дә исән!.. Җырларны үтерергә мөмкин түгел!..

Авыр туфрагы җиңел булсын: хунта фашистлары газаплап үтергән Чили халык шагыйре Виктор Хара җырлый икән бит!

Их, замана, замана! Егерменче гасыр! Атом гасыры! Бер улларың, ялгыз гитарасына чиртеп, революцион җырлар җырлый-җырлый, баштанаяк коралланган хунтачылар өстенә бара, икенче улларың, шул җырларны тыңлый-тыңлый, ярсып искән давылда сынмый-сыгылмый, мәшһүр КамАЗны төзи!..

Менә ярсу җилләр тагын таныш моңнарны алып килде. Батыр үлеме белән үлемсезлек яулаган Виктор Хара җырлый иде. Миңа ят телдә яңгыраса да, бала чактан гаҗәп таныш җыр! Үзебез җырлап үскән җыр!

Этих дней не смолкнет слава,
Не померкнет никогда:
Партизанские отряды
Занимали города!..

Нигә Виктор Хара нәкъ менә бу җырны сайлаган! Нигә?.. Дошман алдында тезләнергә теләмәгән батыр йөрәкле Чили уллары һәм кызлары да хәзер тауларда партизаннар сугышы алып баралар бит! Димәк, Виктор Хара бу авыр көннәрнең киләсен гүя алдан сизенгән! Әйтерсең ул шулай гитара кылларына түгел, йөрәкләргә чиртеп-чиртеп ала һәм безне уяу булырга, ә үзенең ватандашларын исә хунтачыларның кара режимына буйсынмаска, аларга каршы рәхимсез партизаннар көрәше алып барырга чакыра иде...

МӘҖИТ РАФИКОВКА 50 ЯШЬ

Каләмдәшебез Мәҗит Рафиковка 50 яшь тулды.

Әле кайчан гына ул әдәби кичәләрдә илһамланып шигырь сөйләүче, комсомол җыелышларында ялкынланып речь тотучы җитез хәрәкәтле, какча яңаклы бер студент иде. Кай арададыр шактый гомер юлы үтелгән, илле дигән бер баскычка да җителгән.

Мәҗит Рафиков әле Казан дәүләт университетының студенты булганчы ук зур тормыш сынаулары узды, унсигез яшьлек комсомол егет, рядовой солдат булып, Бөек Ватан сугышына катнашты, Украинаны фашист илбасарларыннан азат итеште, сугыштан яралы солдат булып кайтты.

Яшьлек шигырьләрендәге дәрт, ялкын, тормышның, кешеләрнең матур якларына соклана белү Мәҗит Рафиковның чәчмә әсәрләренә дә күчте. «Илһам авазы», «Ишгилде» исемле лирик бер тойгы белән язылган повестьлары, «Биш пуля», «Рәхмич» һәм башка хикәяләре аны укучыларга шигъри күңелле прозаик итеп танытты. М. Рафиковны татар һәм рус укучылары гына түгел, Советлар Союзыннан читтә дә беләләр. «Шарлама», «Сиңа ничә яшь?» һәм тагы кайбер хикәяләре «Совьет ленд» — («Советлар иле») журналында Һиндстанның 12 милли телендә, инглиз һәм непал телләрендә дөнья күрде.

Соңгы елда ул туган авылына, аның кешеләренә багышланган «Су буенда бер урам» исемле әсәрен тәмамлады.

Югарыда әйтелгән әсәрләре Мәҗит Рафиков иҗатының бер өлеше генә. Ул рус һәм татар телләрен яхшы белүче тәрҗемәче буларак та зур эш башкара. Г. Тукайның чәчмә әсәрләрен, Ш. Камалның «Матур туганда» романын, Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион» исемле китапларын, Х. Сарьянның «Әткәм һөнәре» дигән повестен, И. Гази, Ә. Еники, М. Әмир, Г. Минский, Л. Ихсанова, Ф. Хөсни һәм башка татар язучыларының хикәяләрен рус теленә тәрҗемә итте.

Мәҗит Рафиков

СУ БУЕНДА БЕР УРАМ

Авыл язмалары

Агроном Фатих Вәлитов!
Без синең белән бергә дөнья танып үстек. Син Бөек Ватан сугышының Көнчыгыш фронтында булдың, мин — Көнбатышта. Хәзер син авылда, мин шәһәрдә, син игенче, мин каләм тибрәтәм, ә күңел белән барыбер гел бергә без.
Сиңа багышлана бу язмалар.

Автор.

Туган өен белмәгән —
Туган авылын белерме?
Туган авылын белмәгән —
Туган илен белерме?..

Мәкаль

Башкортстанның көньяк тарафында Җидеболак Күгәрчене дигән авыл бар. Аскы урам аның иң кыска урамнарыннан берсе. Капкалары йөгерек сулы Җидеболакка карап ачыла. Урамның югарыгы башында — авылның мәктәбе, түбәнге очында — бакчасы. Бездә колхоз оешу белән яралган җиләк-җимеш, яшелчә бакчалары. Ике арада элек җиде-сигез генә өй иде, хәзер йортлары ишәйде.

Бу кыска урам — минем туган урамым. Урамдашлар, күршеләр, туганнар — авылның мәктәбеннән алып бакчасына кадәр — миңа язмышлары белән якын, үз, аңлаешлы. Алар мине күптәннән бирле уйландыра: «Кемнәр соң без? Нинди язмышлы кешеләр?..»

Хәзер сөйләячәгем повесть та, роман да түгел. Гади язмалар гына. Шушы мәктәпле, бакчалы урамның төрле характерлары, тере язмышлары турында күргәнемчә, белгәнемчә, аңлавымча язуым.

Әгәр кайбер геройларым бу кечкенә урамнан ил мәйданына чыга икән, моның бер дә гаҗәбе юк: аларны ил эшләре, ил язмышы белән бәйләгән кайнар «җепләр» миңа аеруча кадерле.

1

Маһирәттәйнең үзенә аерым бер сүз багышламый булмый. Заман кешесе ул. Аңа карап безнең авылның кабатланмас бер чорын күрәсең.

Күп балалы, зур хуҗалыклы бу йортта тормыш дигән катлаулы нәрсәне мин белә-белгәннән бирле Маһирәттәй үзе шаулатып-кайнатып алып барды.

Ире Миңгали абзый — ул үз кәсебе белән көннәр, атналар буе авылдан-авылга, базардан-базарга йөреп ятучы атлы сәүдәгәр — табышларын төягән килеш үз өенә кадерле кунак булып кына кайтып төшә торды, бер-ике көн эчендә табышының сортын сортка, чуртын чуртка аерып төйи дә янә Кара турысын җигеп, үзе шомартып, ялтыратып бетергән юлларына чыгып китә торды. Шул ике-өч көн эчендә дә, ана белән балалар арасына керешеп, әллә ни авырсынмады. Тик кайвакытларны, базарда ат-арба янында калдырып торырга дип, Әбрар абыйны да яшел сандыгы янына утыртып алып чыгып киткәли иде.

Өйдә балаларын ул-бу йомышка тынлату, эшкә кушудан гыйбарәт булган тәрбия яклары исә тоташы белән Маһирәттәй өстендә кала бирде. Кыскасы, өй кайгысы, мал-туар, бакча-түтәл, бала-чага кайгысы барысы да ана кеше өстендә булды.

Миңгали абыйның үз балаларына тәрбияви тәэсире булса, бердәнбер шул үзенең эш үрнәге генә булгандыр. Үзләренең арбалы-чаналы ишегалларында, бу дөнья шулай атлар-атламас кына йөри торган Кара туры җаенча гына барачак дигәндәй, ашыкмый-кабаланмый, борчылмый-каударланмыйча гына арбасын майлап, атын кадерләп ашатып-эчертеп йөрде ул, камыт-ыңгырчакларын атына таман гына китереп тотты, табышларын аерып-аерып төягәндә тыгызлап, тигезләп салды, тауларда-чалуларда аумас-ишелмәс иттереп бастырып бәйләде, атын җиккәндә ыңгырчагы ат аркасын чиләтмәс, камыты муенын сукмастай, кичүле-чокырлы җирләрдә тугарылып китмәстәй итеп җикте. Әтиләренә йөк төяшеп, ат җигешеп йөргән бала-чагага шушы эш үрнәкләреннән дә көчлерәк тагын нинди тәрбияви тәэсир булсын, ди!..

Хәер, урам яктан кинәт «ызнакум»нары-белешләре тавыш бирсә, әтиләренең аю хәрәкәте белән атлый-йөгерә чыгып, җил капкаларын төбе шытырдаганчы киң ачып җибәрүе, якты йөзле, татлы сүзле булуы, табыннарында бәлешләре дә тәмле булуы — болары тагы бала-чагага ничек инде тәрбия тәэсире ясамасын, ди!..

Шулай да йорт тоту, гаилә үстерү мәшәкатьләре барыбер йорт анасы өстеннән төшмәде.

Киң ак битле, юан беләкле, баһадир гәүдәле Маһирәттәй холкы ягыннан да ифрат та кырыс, ифрат та гайрәтле апакай иде. Дивизия, хәтта армияләр йөртердәй гайрәт иясе диярсең.

Урам малайлары без дә аның йогынтысыннан читтә кала алмадык: ул безгә дә «яу» булды, без дә аның белән үзебезчә тарткалашып үстек. Ул «фронт сызыгы»ның теге ягында, без бу ягында идек...

2

Без Аскы урам малайларының күңелендә хәтер кошы уянып, исәкыл кергән чаклар колхозлы яңа чорның беренче елларына туры килде. Авыл тормышына, яшен-картын шаккаттырып, беренче күрмештә гаҗәп тә куәтле тоелган тракторлар, машиналар килеп кергән чаклар...

Һәм безнең Күгәрчендә беренче күренгән машиналарга каршы «мө-

селманлык сагында» иң яман гайрәт чәчеп торучы «батыр» кем булды дисез?

Нәкъ үзебезнең шушы Маһирәттәй!

Минем истә: машина күренсә, нәрсәдер укынып, ялт-йолт каранып төкеренә-төкеренә узып китә торган үз урамыбыз карчыгы Хәбиб тә бар иде, капка төпләрендә ни гаҗәпләнергә, ни шомланырга белмичә катып калган түгәрәк сакаллы картлар да... Әмма ул тракторларга, машиналарга каршы үзе бер яу булып күтәрелеп чыгучы тик бер Маһирәттәй генә булды.

Хәтәр ханым иде ул. Үрге очның Язари карт кызы. Ул картны безнең авылда «Зари мулла» дип тә йөрткәннәр. Күрәсең, указлы ук мулла булмаса да, тәкъвалыгы, кызу канлы фанатиклыгы белән дан тоткан. Менә шуның кызы Маһирә безнең түбән очтагы атлы сәүдәгәр Кара Бакый йортына ак килен булып төшкән дә инде. Ак битле ул үзе, зәңгәр күзле. Төскә-биткә ак булса да, казан чуеныдай Кара Бакыйлар токымына бик тә торырлык килен булып чыккан. Кара Бакый нигезендә тормышны биетеп алып баручы башкомандующий булып киткәч, инде тагын ни әйтәсең!

Биредә мин Маһирәттәйләрнең йорт урыны турында берничә сүз әйтеп узарга тиеш булам. Авылның гына түгел, бар районның, хәтта илнең диярлек кайнар бер ноктасы ул алар торган урын. Нәкъ олы юл өсте. Капкалары олы юл күперенә каршы гына ачыла.

Өстәвенә тагын нәкъ колхоз оешкан елларны безнең этиләр үзебезнең урамга бер кое казытасы булганнар иде. Ул вакытларны безнең авылга кайдандыр кыргызлар килеп чыкты. Шуларның берсе — имән төбедәй тазасы, йөргәндә зур башын югары тотып, калын күкрәген киереп, тезләрен яхшы аттай күтәреп-күтәреп атлый торганы — Чирекгали исемле иде. Менә шул Чирекгали безнең Аскы урамга кое казып бирде. Кызыл балчык өеме уртасындагы тирән чокырга этиләр үзен такта чиләккә утыртып чыгыр арканы белән төшереп җибәрә торганнар иде... Тирән булды коесы. Сиртмәсе биек, суы тәмле, салкын, тешләреңә тиярлек.

Шул Чирекгали коесы хәзер дә авылны тәмле суы белән рәхәтләндерә әле. Өске урамнан да, аргыяк Башмак урамыннан, хәтта Олы урамнан да көянтә-чиләкле кызлар өзелми. Менә шушы коеның да урынын, кайндыр белеп, нәкъ Маһирәттәйләрнең капка артыннан гына сайлап тапканнар бит! Күпернең каршысында гына ул кое, олы юлның борылышында гына... Маһирәттәйләр капкасыннан чыгып, өч-дүрт кенә адым уңга атлыйсы...

Мрак, Мәнәвез, Уфа якларыннан килүче машиналар да, аларга каршы Мәкъсүт, Исәнгол, Сарыкташ, Оренбург якларыннан килүчеләре дә уза безнең авыл аркылы.

Күпер башында тезелеп куе ябалдашлы мәһабәт тал-тирәкләре дә, күпер борылышында гына шундый әйбәт сулы коесы да була торып, ничек инде шофер халкы, тузан йота-йота килешли, шушында бер туктап мыек чылатып, тын алып китмәсен, ди?..

Ә күпер астыннан йөгерек Җидеболак чуер ташлар өстеннән тәгәрәп агып ята. Мондагы каз-үрдәк дигәнең! Күпернең астында да, чуерташ җәелеп киткән өске ягында да, ләмләнеп киткән түбәнге агымында да бакырдашып тулган. Ярты авылның каз-үрдәге шушында каңгылдаша.

Күпер каршында торучы йорт анасы Маһирәттәй үзе дә күп бәбкәле бер ана каз шикелле иде. Дөрес, казларның да төрлесе була. Тузынып, канатлар кагып, кычкырыша-каңгылдаша талашкан чакларында, кайвакытны ата казың да, муенын борып ысылдый-ысылдый, үз «көтүен» алып бер якка чигенә башлый... Маһирәттәй исә ана казларның да шундые булды — ата казларга бирешәсе түгел! Яңгыравыклы

олы тавышы да аның — нәкъ гайрәтле бер ана каз тавышы, — үзеңнең түбән очта бер кычкырып җибәрсә, Язари карт торган Үрге очларны яңгырата...

Әмма да дин-мөселманлык дигәндә Маһирәттәй үзенең сәүдәгәр иреннән чагыштыргысыз куәтлерәк иде. Миңгали абзый ул — көнендә дә, төшендә дә гел тире-яры, чүбек-чүпрәк, йомырка-фәләнне кайгыртып өйрәнгән башы белән, ашын бисмилласыз гына ашап, түшәккә бисмилласыз гына ауса да, бик рәхәт йөреп, бик рәхәт йоклый белә торган кеше — аңа ни, дөньяда иске-москы бетмәсә, йөрер юлында кинәт җир ярылып, аты-арбасы гына убылмаса, калганын бик ул хәтле кайгырып мәшәкатьләнмәс бер зат. Ә Маһирәттәй... Ю-у-у-к! Ул бу «ахыр заман галәмәте», «шайтан арбасы» трактор, машина кебекләргә тыныч кына чыдап карап торасы кеше түгел иде!

3

Бер дә аңлый белми иде шул Маһирәттәй безнең ише бала-чага күңелен. Үз балаларының («кыргын явы»ның) да күңел нечкәлекләренә керешеп тора торганнардан түгел иде шул...

Истә, бик истә ул беренче трактор, беренче машиналар. Безнең ише, су буеннан бака «колыннары» тотып, аларга «абзар» корып уйный торган авыл малайларын нинди кайнар кызыксыну белән кызыктырып, акыл ирешмәс хыяллар белән канатландырып җибәрде алар!..

Без беренче күргән трактор үзе моржа сөремедәй кап-кара, киң түшле, искитмәле зур, коточкыч көчле булып та, үзе ят, хәтта куркыныч та, үзе тагын мавыктыргыч кызык та тоелды.

Март аеның дуамал яман кар бураннары тынып, көннең ачылып, күкнең язгыча зәңгәрләнеп киткән бер чагы иде. Ап-ак кар сырыннларын бурап-бурап сылап салган — абзар түбәсенә кардан гына йөгереп мен дә кит!

Ник шушындый көнне сайлаган ул трактор? Куәтен ачыграк күрсәтер өченме әллә?..

Район үзәге Мрак ягыннан, Түбәнге оч Бәләкәй күпердән килә иде ул. Без ишегалдында кар сырынтысын астан казып, «өй ясап» йөргән җирдән, кинәт пыр тузып чабыша-чабыша, аргыяк Башмак урамына чыгып каршыладык аны. Беренче аптыраганым шул булды: чиксез калын яткан карга ничек батмый килә диген син аны! Чана юлыннан да түгел бит, тапталмаган җирдән килә. Борынын әле түбән төртеп, бер сырынтыдан төшеп китә, әле күккә чөеп, икенче сырынты өстенә менә. Артыннан төшеп, эзеннән йөгерү рәхәт тоелды: бер дә карга батмыйсың. Яссы-яссы сырлы чылбыр эзләре карны тигез генә тыгызлап, басынкырап узган — такыр җирдән йөгерәсеңмени!

Гөрелтесе тагын! Шул хәтле авыр «тимер тавын» дерелдәтеп алып килә. Йөрешен бер әкренәйтеп, бер шәпләп киткәндә, я борылганда хәтта калтырап-калтырап пытырдый башлый. Тимер-томыр чыкырдавы шундый каты — әниләрнең пычак белән көйгән таба кыруы гына түгел инде... Үзен күргәнче, әнә шул гөрелтесенә ис китеп йөгердек тә без аның каршысына. Үзенең торбасы да бар. Шома һәм кара торба. «Выт-выт!» китереп, күккә зәңгәр төтен алкалары чөеп бара.

Бер уң ягына, бер сулына чыгып йөгерешәбез, батыраеп хәтта алдына, каршына ук чыгып карыйбыз бу «тыррахтырр» дигән тимер пәһлеванны. Үзе бик куркыныч та тоелып куя. Кинәт борылып өстеңә килә башласа, син хет кычкыр, хет кычкырма, ул барыбер сине ишетмәс, шытырдатып таптап китәр кебек... Өстендә утырган кара киемле, ак чырайлы кешегә күз төшкәч кенә тынычланып куясың...

Кире артыннан төшсәң, басып менә торган баскычына күзләр кызат «Их, сикереп менеп, басып китәргә!..»

Тракторның көчле гөрелтесен ярып-ярып, нечкә тавышлар ишетелеп китә:

— Кара, кара! Тәгәрмәчләре ничек!

— Карга тимичә дә тәгәрәп кенә бара бит, ә!

Без әле аның киң ялтыр чылбыры көпчәкләре астына түшәлеп кенә бара дип тел белән әйтә дә белмибез, әле «әллә нәрсәләренең әллә нишләүләренә» гаҗәпләнә генә беләбез. Ә шулай да бу безнең өчен ат кына, колын гына түгел инде! Бу ниндидер коточкыч куәт иясе. Яман да кызыклы нәрсәкәй, әлегә безнең «буйлар җитмәс» хыялга карый торган нәрсә...

— Кибәнеңне эләктереп алса, кибәнеңне дә өстерәп апкитәр бу!

— Һи! Кибән, ди. Эләктерсәң, әнә безнең Уен тавын да... Әйеме?..

Гөрелдәп барган шушы трактордан башка акны-караны күрмичә, үзебезнең Уен тавы яныннан төшеп, әлеге өянкеле күпергә якынлап кына килә идек, менә бер вакытны, дөнья яңгыратып, яман да гайрәтле бер тавыш колакларны ярмасынмы!

Мин аның беренче сүзләрен абайламый да калдым бугай... Карасам, җил капка артында Маһирәттәй дулыймы бу, әллә давыл уйныймы! Каян безне күреп алган диген! «Хәким!» — дигән сүзен аерып ишеттем...

— Ах, ходай оргыры бала! Син дә тагылдыңмы?! Ахыр заман фетнәсе булыргамы?! Кайт хәерле сәгатьтә, башыңны бәреп ярганчы!..

Күрәм, Хәкимнең бите агарды, төсе качты. Фатих белән мин дә туктап калдык. Тракторыбыз туп-туры күпергә карап китә барды, без — яшен тизлеге белән яр астына сикереп, өянкеләр артына поса-поса, карлы боз буйлап элдерт! Рәхмәтулла абзыйлар ягына чыктык та тизрәк тыкрык башына кереп постык.

Поссаң да, мондый минутта тик кенә торып буламыни ул! Хәким тыкрык башында яшеренеп калды, Фатих белән без, кире бозга төшеп, өянке төбенә күчтек.

Трактор, кәефле генә гөрелдәп, күпер аркылы чыгып бара, Фатихның әтисе — киң сакаллы, көрәк куллы Газиз абзый — үзләренең капка төпләреннән, бер дә акыл жуймастан, тыныч кына, сабыр гына карап тора...

Ә Маһирәттәең ике беләген сызганган, итәген кыстырган, камырлы кулында күп балалы гаиләнең озын да, юан да уклавы, сары кашларын җимергән, күзләрендә, бөтен чыраенда — әллә кемнәреңне өзгәләп ташлардай дуамал ачу! Җил капкаларыннан атылып килеп чыкты да, уңлы-суллы ялт-йолт бер каранып:

— Һай, аңгыра бәрәннәр! Нәстә карап торасыгыз, сакал сәлперәйтеп! Куыгыз чукмарлап ахыр заман галәмәтен! Куыгыз шайтан арбасын! Көлен күккә очырыгы-ы-ыз!..

Газиз абый, бәласеннән баш-аяк дигән шикелле, тыныч кына борылып ишегалларына кереп китте. Ә безнең Маһирәттәй — кайда да үз хөкемен өстен тота торган апакай — кайнап торган бу олы юлны да үзенең мич арасы кебегрәк күргәндер, ахрысы, менә бер заманны «зөлфекар»е белән яман селтәнеп, тракторны җәһәннәмгә очырырдай кыяфәт белән һөҗүмгә ташланды бит!.. Менә уклау башы, һаваны ярып-ярып, радиаторга төшә, «дан-доң»лар ишетелә башлады...

Бер вакытны тракторчы абзый иелә төшеп әллә нәрсә эшләгән иде, тимер таудай трактор, юл читеннән борыла төшеп, калтырана-калтырана пытырдап, әкрен генә Маһирәттәйнең өстенә килә башламасынмы! Маһирәттәй бик кыю карап торды да, бу тимер тауның акылыгын аңлап алгандай, ялт борылып: «а-ай алла»сын тәкърарлый-

тәкърарлый өенә чапты. Капка төбендә абынып егылгач, бер катасын кулына тотып, кереп юк булды.

Бу хәерсез сәгатьтә кайтып әнисенең күзенә күренергә Хәкимнең дә башына тай типмәгән бит. Киттек без барыбыз бергә трактор артыннан. Олы урам малайлары да кушылды. Үрге очның Сыртка чыга торган урамыннан Мәкъсүт юлына ук озатып җибәрдек.

Бездән унбиш кенә чакрымдагы борынгы башкорт авылы Мәкъсүттә МТС ачыласы безнең әле истә-акылда да юк иде...

Бу көнне, безнең ише малай-шалайга дисәң, бөтен дөньяда авыл ярып узган шушы трактордан кызыграк бер нәрсә дә, шуны йөртүчедән батыррак, шәбрәк кеше дә юк иде.

Бу трактор безнең акыл да, хыял да әле иңли алмас яңалык булып килде. Без аның куәтен-сәләтен печән кибәненә, хәтта үзебезнең Уен тавына нисбәтләштереп чамалаганда, авылның бар тормышын каядыр алга, яхшы якка таба сөйрәп алып китәсен дә күңелнең ниндидер бер сиземе белән сиземли идек бугай.

Шулай итеп без, атлы-арбалы, чөшлеле-чабаталы авыл үзе һичкайчан, һичничек ясый алмас тракторны да күрдек. Авыл аксакалларының барысының бергә зиһеннәре җитмәс бер әкәмәт нәрсәкәй! Әмма авылның нәкъ үзенә кирәк нәрсә.

Иң олы хикмәте шунда — кеше ясаган бит аны! Безнең «Мыр-мыр» Сәлахи абзыйлар, «Манифыс» Насыйбулла абзыйлар, әтиләр ни күреп, ни ишетеп тә белмәгән әллә кайсы ерак каладагы, безнең әтиләр бер дә күрешеп танышмаган, белмәгән кешеләр ясаган аны.

Авыл белмәгән җирләрдә дә авылны кайгыртучы кешеләр булыр икән!

Хәким ул көнне кичен бик ачыгып кайтып кергәч, Маһирәттәй аны, «ахыр заман фетнәсе булмасын»га юрап, бәргәләп алган бугай. Без, үзебезнең иптәш малайның горурлыгын кимсетмәс өчен, анысын сорашып тормадык...

4

Бу чылбырлы тракторның үзенчә юл ярып узуы шуңа булгандыр: карлар эреп, юллар өзелгәнче тагын бер шундый трактор гөрелдәп үтте, ташудан соң, сулар тартылып, арба юлы төшкәч, җитез генә көпчәкле тракторлар да, алыптай зур әрҗәле йөк машиналары да уза башлады.

Бәләкәй күпер ягыннан берәр гүелдәү ишетелдеме, аргы як өйләр артында юл тузаны күрендеме,— без инде, өянкеле күпер аркылы, Уен тавы кабыргасыннан, колхоз тимерлеге яныннан үргә, Башмак урамына кем узардан йөгерешәбез. Машинамы ул, трактормы — ике кулны болгап, җилләнә-җилләнә, һай-һаулап каршына чыгабыз да, артыннан ук борылып, тузан болытына чумып, рәхәтләнеп йөгерә-йөгерә кире төшәбез. Тузаны, бензин исләре безгә кызык та, рәхәт тә...

Машина дигәнең, күперне чыккач, юл борылышындагы сиртмәле кое янында тукталмый узамы соң! Майланган кара куллы абзый безнең урам коесыннан агач чиләген тутырып су ала, үзе дә эчә, машинасына да эчерә. Менә шул арада без ялан тәпи, ялтыр борыннар, иркенәеп китеп, аның машинасын якыннан ук бер карап чыксак ни була да, канатына басып, кабина эчендәге елтыр нәрсәләренә бер күз салсак ни була ди? Бигрәк тә кабинадан чыккан шоферның нишләгәннәрен күзәтеп, күңелдән отып кына торсак? Батыраеп, үзенә: «Драстуй, ызнакум!» — дисәк?! Бу сүзне без бит беләбез! Хәкимнең әтисе Миңгали абзыйдан отып алганбыз: руслардан берәрсе килеп туктаса, ул аны шулай дип чыгып каршылый, кунакның атын җитәкләп, көр тавышы белән: «Әйдә, әйдә, пырхади!» — дип тә өстәп җибәрә... Ә инде шунда шофер

абзыкаең бер елмаеп, күз дә кыссамы, шаярткандай берәр сүз дә ычкындырсамы?.. Безгә аңа бу җәйге эссе көнне әнидән чүмечкә генә әйрән тугылатып алып чыгып сыйлау да «пужалысты» гына! Инде машинасына да утыртса, әллә кайларга да чыгып китәр идек әле. Вәт булыр иде үзебезнең дә бер ызнакум абзый!

Ә шундый бәхетле бер минутта, бусагадан бер кычкыруы белән дөньяны икегә ярып, сафура буранналары куптарып, Маһирәттәй килеп чыкты исә — бөтенесе бетте диген! Шатлык та, якты көннең кызыгы да бетте, ызнакум да юк...

— Ah, алланың каһәре генә суккыры! Каян килә бу шайтан арбалары?! Бу ахыр заман фетнәсе нишләп йөри монда тагын! Тапканнар юаныр нәстә! Ух, мордар киткереләре!..

Без шунда ук, кычыткан чыпчыклары кебек, кайсыбыз кая пыр тузышып, юк булабыз...

Андый чакта Маһирәттәй безгә чын дошман иде, әлбәттә. Хәким дустыбызның әнисе булса да, барыбер явыздан-явыз дошман...

Без тыкрыктан, Өске урамнан әйләнеп каршысына чыгарга ашыгабыз да бит, кая ул өлгерү! Машина шул... урамда тузаны гына эленеп калган була...

5

Көтмәгәндә — менә шатлык! — безнең «1 август» колхозына да машина килде. Йөк машинасы. Шоферын бүгенгедәй хәтерлим, дядя Федя исемле иде. Фамилиясе Соловьев. Озын буйлы, таза гәүдәле бер абзый. Безнең өйгә керсә, түбәсе матчага тиярлек. Озынча битле, зәңгәр күзле, сирәк саргылт чәче читләрен пеләш ялый башлаган маңгаена төшеп тора. Тыныч, сабыр табигатьле, салмак хәрәкәтле, ачык чырайлы, хуш күңелле һәйбәт бер абзый иде ул. Каян белгәннәр диген безгә нәкъ шундый кирәген!

Бөтен җәйне кояшта янып, җиңсез майкадан, ялан баш йөреп чыкты дядя Федя. Җилкәләре киң, беләкләре бүрәнәдәй.

Хәзер инде без иртәдән үк колхоз правлениесе янында чуалабыз. Анда Маһирәттәй дә юк, машина да төннәрен правление ишегалдында тора. Кара айгыр абзарының капкасы артында гына.

Чынын гына әйткәндә, без бу «полуторка»ның көпчәк сырларын капшап, фара пыялаларын ялап алырдай булып, кызыксынып караулардан тиз уздык, бала җанлы дядя Федяның кул астына тиз үк керә башладык. Тукталыш саен аңа әле яньчелгән кара чиләге белән йөгертеп су алып киләсең, әле кузовтан тимер көрәген алып сузасың, әле ындырда, яңа уңыш игенен төяшкәндә, киң яшькелт-соры брезентны ялан аяклар белән такта әрҗәнең почмакларына үк җиткереп, тишекярыкларын каплап түшәшәсең, ашлык төягәннән соң брезент читләрен кайтарып, әйбәтләп өстен каплашасың — безгә мондый эшләр «нипачум» гына ул!

Бер көнне без шул машина белән кузгалып киткәндә, правлениедан колхоз председателе Кабак башы Мотыйгулла абзый килеп чыккан иде. Дядя Федя аңа, безнең якка елмаюлы бер ым ясап: «Эти тоже мои стажеры!» — диде... Үзенең чын стажеры исә Өске урамның Дәмин карт улы Мөхәммәтвәли абый — **Дәмин Вәлие иде аның.**

Дядя Федя үзенең ялтыр башлы, ялтыр саплы кәкре тимер ачкычын, радиаторның «ияк астына» тыга да, бер генә зырылдатып әйләндереп җибәрүе була — машина дер-дер калтырый да башлый. Ул кабинага кереп рульгә тотынганчы, без әрҗәсенә, песи балалары кебек, тырмашып менеп бетәбез...

Дядя Федя безне ничек тә зурлардан аера. Кабина тәрәзәсеннән юрамалый бер кырыслык белән:

— Держись, орлы! — дип кычкыра да кузгатып алып китә иде.

Соңыннан белдем: ул безне бөркетләр дип йөрткән икән...

Машина кузгалып киткәч, аның иң кызыгы — кабинасына тотынып алга карап бару! Менә бер вакытны тузанлы юлдан, кытаклашып, пыр тузышып, каралы-сорылы тавыклар ике якка оча. Ул арада әллә кемнәр капкасыннан, зур кара бер йонлач йомгак булып, калын тавышлы, яман да усал бер Карабай атылып чыга, тешләрен ыржайтып, ыргылабәрелә, машинаны өзгәләп ташлардай булып кылана — инде ничә тапкыр шулай абалап та, бу машина дигән нәрсәнең бер дә алай зыянлы түгеллеген, хәтта бик тә файдалылыгын, армый-талмый эшли белүен һаман аңламый...

Ә каршыңа... ә каршыңа йөгерә-шуа тузанлы юл килә, тәрәзәле-гөлле өйләре, капкалары, читәннәре, урам уртасындагы кибете белән, үтеп-сүтеп йөрүче, карап торучы кешеләре белән урам йөзеп килә. Барысы да үзебезнең авыл. Йорт-куралары, бәрәңге бакчалары, кешеләре — барысы да...

Авылдан чыгып киткәч, су буе таллыклары, өянкеләр, арыш, бодай, солы, көнбагыш басулары, калку җирләр, уйсу буйлар — барысы да ике ягында, зур-зур ике патефон тәлинкәсе шикелле, ике якка әйләнеп-әйләнеп узалар. Якын тирәләр тиз әйләнә, ерак калкулыклар, урманлы зәңгәр таулар, сиздермичә үк диярлек, әкрен генә йөзәләр.

Без, тешләрне ялтыратып, бер-беребезгә карашып алабыз: «Тот, Маһирәттәй, безнең койрыкны!..»

Безгә рәхәт! Без бу кояшлы болыннарның, басуларның, урманлы тауларның җылы һавасында җилләнә-җилләнә, һәр якка кызыгып, йотылып карый-карый, бу дөньяны шундый кояшлы килеш, үз өебез кебек якын күреп, күңелгә кабул итеп алабыз.

Гажәптер, ул малай чакларның көне бик озын кебек тоела торган иде. Бәләкәйрәк бер авылның бөтен бер елы хәтле! Һәрбер көне — үзе бер мәңгелек...

6

Бәйрәмнәрне бик күп ташып йөрде ул дядя Федяның «полуторка»сы. Күмәк хезмәт, күмәк ял бәйрәме. Әле ул аллы-гөлле киенгән печәнче апа-тутиләрне, абый-абзыйларны, тальяннарын уйнатып, яңа җырлар җырлатып, Тукмак чишмәсе болынлыгына, я Олы тауның аргы буена алып китә, әле шаулап-гөрләп торган ындырдан, үлчәүдән ашлык төятеп, бушатучыларын утыртып, Назаркинога юл ала, әле колхоз бакчасыннан әрҗәсенә кыяр тутырып, Чапык, Троицк, я Мрак базарларына юнәлә. Өсте-өстенә куеп, ящик-ящик карлыган төяп җибәрсәләр, Баймакка да, күрше өлкә үзәге Оренбургның атаклы «Толчок» базарына да, хәтта Магнитогорскига да барып, зур базарлар шаулатып йөреп кайта... Инде язгы чәчүләр беткән бер арада агай-тутәйләрне Эйек буена ташый. Авылда бер гармун калдырмыйча, сәхрәгә! (Күңел ачып, ял итәргә су буена, табигать кочагына чыгуны бездә сәхрәгә төшү диләр.) Я күп авыллар аркылы, чәчәкле болыннар, тугайлар буйлата, колхоз халкын Мрак ягына, район сабан туена алып чыгып китә...

Зурлар кайда, без шунда инде! Аяк араларына кысылып булса да барабыз...

Безнең ише каткан тезләрне, бу машинаның машиналыгы гына түгел, бәлки аның ешрак менә шулай кешенең күмәгрәк җиренә, эшнең кайнаррак, шаян сүзнең, уен-муенның күңеллерәк җирләренә йөрүе дә кызыктыра иде. Эти-әниләр эшләгән кыр станына туры килсәң, төшкелектә дядя Федя белән эшем кешеләре безгә дә итле аш сосып бирәләр.

Печәнчеләр янына барып чыгасың икән, анда комсомол укытучы-

лардан я куе толымлы, зур-зур зәңгәр күзле җырчы апа Мәбрүрә, я буе озынлыгыннан уңайсызлангандай, иелә төшеп йөрүчән Фәйзер абый эш арасында әле кычкырып яңа гәзит укыйлар, әле «Чимбирлинның сатыйм анасын!..» дип, шигырь сөйләп, әле җыр башлап, яшьләрне бер җилкендереп алалар.

Көлтә ташучы, эскерт салучылар янына килсәң, анда әлеге озын Фәйзер абыйның әтисе Хәбибрахман абзыкай — «ярман» сугышында бер бармагын өздереп кайткан чал башлы, каткан түбәтәй, ерык авыз, шаян сүзен һичкайчан өендә онытып калдырмас хуш күңелле, әйбәт карт — эскерт башында торган җиреннән, ак күлмәгенең сызганылган бер җиңен кире кайтарып төшергән, кулы белән колагын учлаган да, җиң эченә борыны белән кереп өрә-өрә: «Күгәрчи! Әлү! Әлү! Күгәрчи-и! Вада нады! Вада-а! Тут нашы рабуты гәрәчә... Бригадир пил, пил да әйрән канчал!..» — дип кылана-кылана, бар кешене аяктан егып көлдерә. Имештер, авылга яңарак кергән телефон инде басуга, эскерт башына да килеп менгән!..

Ындырда дисәң, анда инде ялкауга гына эш табылмый! Берәүләр яңа ашлыкны җилгәртә, икенчеләр себерә, өченчеләр өя... Анда үлчиләр, монда төйиләр дә Назаркино ашлык тапшыру пунктына озатып торалар... Монда дисәң, үзебезнең йомыры гәүдә, түгәрәк сакал, хәйләкәр шаян Ибәтулла абзый, мыек астыннан гына көлә-көлә остара: «...Юк, шалишь! Әйтегез ул Кызыл таш егетләренә, мондый уңган кызларны читкә жибәрә, ди, панимаеш! Чыгармыйбыз авылдан! Егетләр үзебездә житәрлек... Ялкаурак берәрсе булса, әйдә, юлы такыр! Жәл түгел!» — дип кыек атып, туры тидереп йөри...

Сәхрәдә, сабан туйларында бигрәк тә күңелле инде! Безнең ул елларда гы икенче бригада бригадиры, тау башы Көртлек Сабиржан бабайның олы улы Фәезхан абзый шундый да моңлы җырчы икәнен мин нәкъ Эйек буенда сәхрәдә генә белеп алдым. Аяз матур бер көнне халык яр башында, таллык арасындагы чәчәкле болында, казаннар асып, самаварлар кайнатып, табын корып утырганда, комсомоллар җыелышып-биешеп, өлкәннәрнең дә күңелен җилкендереп жибәргән иде. Фәезхан абый «Кара ла гына урман»ны шундый өздереп салды — хәтта нечкә яшь талларың, ал чәчәкле болын канәферләрең дә тынып тыңлап торгандай булды.

Ул сәхрәләрдә алдынгы колхозчыларның исемнәрен кычкырып әйтеп, рәхмәтләр яудырып, ил-күз алдында бүләкләр дә тапшырыла, бөтенесе бергә ашап-эчеп сыйлана да... Ә район сабан туенда исә безнең ат җанлы Шәрифулла жизни, колхоз Кара айгырының каеш дилбегәсен өзәрдәй булып тарта-тарта, төрле районнарда дан тоткан юргалар белән узыша...

Маһирәттәй шулай капкасы артында күренгән машиналарны «каршылый» калды, безнең исә иң күңелле сәгатьләр дядя Федя машинасында шулай уза башлады.

Ул «мәңгелеккә тиң» көннәрнең берсендә без шулай җәйге кояшны имин генә баеттырып, өйгә, үзебезнең әниләр янына, кайтып киләбез. Өс-башны тузан баскан, күңелләр канәгать, карын ачкан. Үзебез һаман дядя Федя белән иртәгесе көн турында сөйләшәбез... Маһирәттәйнең Хәкиме дә шул безнең «шәйкә»дә инде...

Менә бер вакытны, кичке һаваны ярып, әлеге ана каз тавышы яңгырамасынмы! Маһирәттәй капкадан чыгып баскан, ачулы карашы белән яндырып карый.

— Әй, бигылай! Тагын шул шайтан арбасында йөрдеңме?! Кая синең бозавың, адәм актыгы? Шулаймы синең бәрәңге утавың? Шулаймы түтәлләргә су сибүең?! Кая качасың тагын? Аш суынып бетә бит инде, гөнаһ шомлыгы! Кайт әйдә хәзер үк аш эчәргә! — Үзенең кулында, һаваны чаж-чож кисеп, яшел тал чыбыгы уйнап тора.

Хәкимебез, кызу табага баскан песи кебек, угаланып таптанып торды да, читтән, күпер башыннан ук урап, Фатих белән миңа иярeп, безгә кунарга китте...

Бардырмы дөньяда хәзер ул олы җанлы әзмәвер ир дядя Федя? Ватан сугышы юлларында минага-бомбага эләкмичә, өенә исән-сау кайта алдымы икән?

Соловьев иде аның фамилиясе. Очрашырга-күрешергә язса, татлы да бер әңгәмә корып утыра белер идек!..

7

Маһирәттәй балалары эшнең авырыннан да, карасыннан да курыкмас әрсез һәм чыдам булып үстеләр. Киреләнү, чәпчү, шыңшу дигәнең аларга йокмады, әниләренә каршы сүз әйтү гадәтләре булмады. Иртән торгач, урын-җир әйберләрен кояшка, бакча киртәсенә чыгарып элү, идән себерү кебек вак-төяктән башлап, түтәл казу, ул түтәлләрнең туфрагын әледән-әле йомшарту, бакча утау, бәрәңге төпләрен өю, иртәкичләрен су сибү, абзар чистарту, ишегалларын себерү кебек йорт эшләрен алар бәләкәйдән үк башкара белделәр.

Маһирәттәйнең телендә «выступай пырбалис!» дигән бик көчле бер рус сүзе бар иде. Балаларын ашатып-эчергәч, кайсысын кайсы эшкә, нинди йомышка олактырганда, үзенең яңгыравыклы тавышы белән: «Я, выступай пырбалис!»ны бер әйттеме, шуннан соң да таптанып торуның хәерлегә түгел икәнен сигез баласының сигезе дә бик яхшы белеләр иде...

Уенда да, эштә дә алар әүвәл авыр кузгалучан, әкрен кызучаннар, әмма дә бер җайга кереп алгач, инде ару-талуны да, туктауны да белми торган ныклы, куәтле булдылар. Кара Бакый токымы! Буш хыялга бирелмәс, күктәге йолдызга үрелмәс, әмма җирдә нык тора торганнар. Әкрен үрлиләр, әмма бер ирешкәннән кире чигенмәсләр. Егам дигән имәнен екмый, салам дигән өен салмый калмаслар. Алынган эшләрен җиренә җиткереп эшли белерләр. Ачык күңелле, йорт җанлы, дус җанлылар. Шаян сүзнең дә йомшагын, артык нык чәнчеми-чеметми торганын, күңелгә хушрак килә торганын сайлаучан—менә шундыйлар алар.

Миңгали абый үзе, аты кайсы авылда туктаса, шунда яшел сандыгыннан «мәкәрҗә» таратып, елмаеп йөри бирде.

Тора-бара Маһирәттәй дә бер кузгалган машиналар агымына тынычрак карый башлады.

Олы кызлары Хәят апаны күп сөйләп торасы да юк: без мәктәпкә йөри башлаганда, аны башкорт авылы Мәкъсүткә кияүгә бирделәр.

Механизацияле эшкә гаиләләреннән беренче булып зур уллары Әбрар абый тиенде.

Мин беренче тапкыр малайлар белән ат җигеп көлтә ташыган көннәрне Әбрар абый, Манифыс Насыйбулла абзыйлар белән берәттән, минем биек үрәчәле рыйдыванга да көлтә төяп йөрде. Арыш көлтәсе авыр булса да, Әбрар абый ике япьле сәнәген жиңел уйната, көлтәләрнең башаклы башын үрәчәнең эчке ягына, камыл төбен тышка каратып биреп, минем эшне жайлы итә. Житлеккән ир диярсең! Сөргән җирләр тырматуда без, малайлар, үгез житәкләп йөргәндә дә безнең «ыстаршуй» Әбрар абый иде... Исәпләп карасаң, үзе уналты-унжиде яшьләрендә булган.

Шул ук елларны ул тракторга да ияләшеп китте. Бер көнне минем абый: «Я, бүген кич нишлибез? Клубкамы?..» — дип сүз кушкач, Әбрар абзый: «Юк, мин бүген төнге эсминәгә чыгам бит, пылугарда мин...»— диде. Анарчы мин, трактор белән җир сөргәндә, аңа махсус сабанчысы да кирәк була икәнен белеп тә бетерми идем...

Минем яшьтәге Гөлшатлары, авылның үтә дә тыйнаклыкта үсә торган бүтән кызларыча, әллә ни күзгә чалынмый иде.

Хәким янына дип, Фатих белән килеп керсәң, Маһирәттәй безне шунда ук кире борып чыгарып та җибәргәли иде:

— Хәким өйдә юк ул! Гөлшат тәтәсе белән иртүк чыгып китте. Чирбай юлы өстендә бәрәңге күмәләр...

Без уен-муен эзләп йөрибез, ә алар, әнә, үзләренең бәрәңге төпләрен дә өеп бетергәннәр, колхоз бәрәңгесенә чыкканнар! Безнең әниләр әлеге «выступай пырбалис!» дигән җилле сүзне әллә белмәгәннәр инде?!.

Аннары Хәкимнең әнеләре Ягъфәр белән Рәшит, минем энекәш Марат белән Айратлар машина артыннан йөгерешә башлады...

Сарыкай Гөлчирәләре, аның артыннан Гөлмәрьямнәре дә инде бишектән төшеп килә иде. Гөрләп кенә яшиселәре, үрчи бирәселәре иде дә бит, бар илне тетрәтеп Ватан сугышы кабынып китмәсә...

Дәүләт бу күп балалы гаиләгә юкка гына ел саен зур акчалар биреп тормаган! Оланнары барысы да таза-сәламәт үстеләр. Төрле тәти китап, буяу каләмнәре, уенчык-мазардан да өзелмиләр иде. Беренче алган сырлы-бизәкле тальяннарын куенына кыстырып, Әбрар абый каршы тауның иң биек түбәсенә менеп, ялгыша-ялгыша уйнарга өйрәнгәндә, мин аңа «Атлар килә атлап-атлап, алма чәчәген таптан...»ны кабат-кабат җырлап, көй биреп утырган язгы кичләр дә булгалады...

8

Ирләр китте сугышка. Атлар китте. Машиналар...

Сугыш безне дә төрлебезне төрле якка ташлады.

«Пылугар» Әбрар абый белән кырык беренче елны бер күрешкән идек. Мин Оренбург фельдшерлар мәктәбенең беренче курсыннан кайткач. Бер айлык каникулда бер генә күрдем мин аны. Анда да очраклы гына. Ул трактордa, мин печәндә йөргәч ни...

Аскы урамда, Әбрар абыйларның читән коймалары турысында, бер ике-өч минут кына аны-моны сөйләшеп тордык. Үсеп, сөлекләнеп, тазарып киткән яшь егет иде инде ул. Кояшта янып, тагын да карала төшкән озынча шома битле, шат чырайлы. Калынча төз борыны астына ефәктәй тигез-кара мыек тибеп чыккан, коңгырт-кара күзләре дәртле карый, зур кытыршы куллары майланып каралган, күлмәк изүен ычкындырып җибәргән, кара тутлы муены шома, таза...

Шунда Әбрар абыйның бер-ике сүзе мине тәэсирләндереп, хәтта шомландырып куйды: «Сугыш килгән якларда, малай, кич караңгы төшкәннән алып, көн яктырганчыга хәтле бер дә ут алырга ярамый икән. Калаларда да, авылларда да... Әллә кайда бер җирдә шпион тоткаННар, ди. Идел күперен шартлатырга йөргән, ди...»

Шулай күршеләрчә гади генә сөйләшеп тордык та, иртәгә тагын күрешербез әле дигән сыман, һәркайсыбыз үз юлыннан китте...

Егерме ике ел узгач кабат күрештек без Әбрар абый белән. Ул Ленинградтан, мин Казаннан — икебез бер вакыттарак отпускага кайтып төшкәнбез булып чыкты.

Безнең Аскы урам үз балаларын шулай әллә нидә бер булса да очраштыра, күрештерә тора ул. Ярый ла, безгә күрешергә язган! Ә шулай, иртәгә тагын күрешербез әле дигән кебек, күршеләрчә гади генә сөйләшеп торган җирдән, киләсе язмышларын үзләре дә белмичә, мәңгегә аерылышып киткән иптәшләр, дуслар безнең буын яшьләреннән азмыни!...

Болай карап торуга Әбрар абый һаман шул, үзгәрмәгән төсле иде. Тик хәзер фотоаппарат тоткан куллары ул хәтле үк каты, кытыршы түгел, ә җәйге кояшлы көнне анасы йортында киеп йөргән буй-буй көн-

рән ефәк пижамадан, үкчәсез жиңел ләпләктән, ул миңа бераз гына буй чүккәндәй дә тоелды. Хәрәкәте дә бераз йомшаграк, ничектер саграк төсле тоелды. Чигә чәчләренә көмеш җепселләр үрелгән, йөзенең элеккеге кара туты уңа төшкән, бит тиресе дә бераз юкарган, сөякләренә сылана төшкән кебек, күз тирәләренә берничә җыерчык кунган, елмайса-көлсә — битен-чыраен ничектер нурландырып җибәрәләр сыман — нәкъ Миңгали абзый елмаюы...

Фронтта Әбрар абый шофер булып йөргән. Сугыш беткәннән бирле — Ленинградта. Такси йөрткән, хәзер дә машинада. Хатынының исемен Маруся диде, бердәнбер уллары Валерик икән. Миңа үзенең адресын язып биргәндә, Финский вокзалдан нинди-нинди трамвай-троллейбуслар белән барып, ничек ишекләренә борылып керәсен сызып-сырлап күрсәткәч, үз исемен «Халитову Борису» дип язып куйды...

Бу күрешүдә аеруча гажәпләндергәне шул булды — Әбрар абый баянда татарча-русча-башкортча көйләрне әйбәт сыздыра, үзе дә бик моңлы җырлый икән!

Менә ничек гомер буе әкренләп ачыла икән сәләтләр!..

Юк! Сугышка кадәрге имин-аман елларны тау башында яңа тальянын юкка гына шыгырдатып утырмаган ул!..

Бу кеше дигәнеңне гомерең буе өйрән, гомерең буе аңла икән — ул барыбер син белгәннән баерак булачак...

Маһирәттәй жил-жил йөреп табын җыйган арада, Әбрар абый минем алга Ленинградта үзе төшергән карточкаларын китереп салды. Арада кайберләрен өнсез-телсез калып карап утырдым.

Менә таза, калын гәүдәле Маһирәттәең дә Ленинградка барып чыккан. Балалары арасында утыра. Күлмәге каплау изүле, бала итәкле. Кәшемир яулыгын, авыл әбиләречә, ияк астына китереп бәйләгән килеш, галстуклап киенгән Әбрар абый белән шәһәрчә килешле, шома киенгән килене, ялбыр кара чәчле оныгы Валериклар арасына кереп кунаклаган, авызын кыса төшеп, чыраен катырып, объективка туп-туры карап утыра... Тән-бәдән җәһәтеннән көдрә чәчле сарыкай килене дә Маһирәттәйдән бер дә ким түгел.

Ә оныгы, Валеригы,— нәкъ Әбрар абыйның үсмер малай чагы. Кара тутлы озынча шома бите, күзләре-кашлары — бу кадәр Кара Бакый булыр икән!

Әтисенең авылда нинди уеннар уйнап, нинди эшләр эшләп үскәнен күз алдына китерәме бу бала? Безнең Күгәрченне беләме? Яратамы ул?

Менә Маһирәттәең, такси белән туктап, Дворцовый площадьта, Бөек Петр патшаның атлы һәйкәле янына килеп баскан... Әбрар абый аны, күрәсең, чүгәли төшеп, астан өскә карап төшергән: безнең авыл түтиенең башы бөек падишаһ башы турысынарак килгән. Бу якынлыктан каушаган, куркынган дисеңме Маһирәттәйне? Юк! Нәкъ үзебезнең Маһирәттәй килеш җитди, кырыс карап тора...

Ә менә монысында ул Пескаревское каберлегенә килеп чыккан. Чал башын игән. Ике каш арасын җыерчыкландырып, күзләрен әз генә йома төшкән. Аның да хәләле Миңгали абзый Бөек Ватан сугышында ятып калган бит! Миңгали абзый да ил азатлыгы өчен башын куйган... Сөякләре бу зиратта булмаса да, ил бер ләбаса!

9

Маһирәттәйнең Хәкиме авылдан китмәде, алай да күңелендә машиналарга бер уянган мәхәббәтенә тугры калды.

Хәким ул, инде әйткәнемчә, миннән бер-ике яшькә яшьрәк, сугышка эләкмәде, укуын гына читкә куеп торып, җиң сызганып колхозда эш-

ләде, фронтка ипи ашатты. Хәрби хезмәтеннән кайткач, үзебезнең авылда пар тегермәнендә эшләп алды. Машинист булып.

Өйләнеп башка чыккач, үз нигезен ата-анасы йортыннан якын гына корып жибәргән ул. Әлеге өянкеле күперне генә чыккач, аргы якка, Башмак урамына менеп китә торган юлның астында гына. Нәкъ үзебезнең элеккеге колхоз тимерлеге урынында.

Келәт хәтле генә бер бура алачык иде ул элеккеге тимерлек. Кин такта капкалы, караңгы эчле. Сөрем тулы. Тышта, тирә-ягында сынган-ватылган атлы ургычлар, печән жыйгычлар ремонт көтеп торганда, без аларның утыргычларына менеп сикеренергә, атынырга, зурларча ат куган булып уйнарга ярата идек. Читтәрәк бер жирдә ат дагалый торган станы да бар иде ул тимерлекнең. Шул станның кин каешларында да атына белә идек... Олылар кушканда, без ул тимерлектә, аяк очына басып үрелә-үрелә, утлы күмергә күрек тә өрдерә торган идек әле.

Нәкъ шушы иске тимерлек урынында инде хәзер Хәкимнең йорт-ихатасы. Алты почмаклы өй, абзар-кура, бакча-түтәлләр. Балалары жидәү. Нәкъ шул без уйнап йөргән жирдә уйнап, шул туфракта казынып үсәләр. Кара Бакый балалары...

Хәзер авылда ул элеккеге тимерлекне күпләр белми дә инде. Эзе дә юк. Хәзер тимерлек дигәнең авыл артында, Сыртта. Автопарк дворында. Ремонт мастерскоеның бер цехы гына ул хәзер. Үзе үк зур бер сарай хәтле. Эченә керсәң — якты тәрәзәләре, баш өстендә — лампочкалары. Сандал, верстаклары, тишү-кыру станоклары. Станок саен — стенада электр кнопкасы. Учагында ташкүмер, күреген дә кнопкага басып кына өрдерәсең.

Бу тимерлекнең беренче кул остасы — шул Маһирәттәйнең икенче улы Хәким үзе була. Элекке тимерлек урынына шулай йорт салып утырган да үзе яңа тимерлекнең баш остасы булып киткән, анда хәзер теләсә нинди тимер кисәген балавыздай эретәләр дә сыгылдырып-бөгелдереп «Әпипә»гә биетәләр.

Гүя ки тормыш үзе без малай чакларда ук Маһирәттәй улы Хәкимнең киләчәген шулай «программага салып» куйган!..

Алып батырдай таза гәүдәле ир хәзер Хәким. Буйга теге шофер дядя Федядан бераз гына кайтышрак булыр, әмма беләк, жилкә жәһәтләреннән аңардан тазарак. Игәүдәй кытыршыдыр көрәк куллары, дуслыкка, яхшылыкка юмарттыр күңеле, ачыктыр чырае. Мәжлесләрдә карлыккан калын тавышы белән сузып жырлап жибәрүләре ни тора...

Эше шул булгач, кулына-битенә корымы-сөреме дә ягыла, билгеле. Әмма Маһирәттәй барыбер аны «ахыр заман фетнәсе» дип орышырга уйламый да...

10

Хәлләр менә шулай: Маһирәттәй белән безнең арадагы «яу» күптән беткән. Безнең як жинде, Маһирәттәй жиңелде. Хәзер уклау белән трактор кыйнаганнарын сөйләсәң, көлә генә. Бер дә гаепсез, гөнаһсыз бер кеше кебек көлә. Әйтерсең ул жиңелмәгән дә! Кайвакытны машинада узып барган балаларына, оныкларына капка төбеннән генә кул болгый:

— Кереп чыксагыз ни була! Чәй эчеп китәриегез...

Без Аскы урам малайларының барыбызның да әниләр инде дөнья куйган. Бер Хәкимнәрнең әнисе Маһирәттәй генә исән. Барыбызга бер ана кебек ул. Безнең әниләргә күрше дә, гәптәш-сердәш тә иде бит.

Мин авылга кайтып, урамнан беренче тапкыр узганда ук капка төпләрендә күренә ул, кычкырып әйтеп кала:

— Керми китмә безгә дә! Бергә уйнап үстегез бит... Локман Хәким-не мең яшәгән, диләр. Бер дә мең яшәмәгән ул, дус-иш белән бер күрешеп, бер сөйләшеп утыруны бер гомергә санаган, шуңа күрә мең яшәгән, дип әйтәләр аны...

Рәшит йорты — Маһирәттәйнең төп йорты. Шушы нигезгә ул Язари карт өеннән Кара Бакый сәүдәгәргә килен булып төшкән. Шушында ул, җил капкасын ачып, Миңгали абзыйны кәсеп юлына озаткан, кайтканда исә — йөгереп чыгып каршы алган, сугышка да шуннан озатып калган. Шушы капкадан кызларын төрлесен төрле якка кияүгә, улларын тормышның төрле юлларына чыгарган. Янында Рәшите. Картларның: «Хас Кара Бакый!» дигәннәре.

Маһирәттәй биредә — олы гомер кичергән зур тәжрибә иясе, хөрмәтле түр анасы. Хәер, ул үзен алай зурга куймый. Улы-килене белән бергә, ул да эш эшли, аның киңәше ишетелә. Юкка-барга керешмәс ул, вакланмас, килешмәгән сүз чыгармас. Барлык бәбкәләрен — олыларын да, кечеләрен дә — куш канаты астында җылытучы карт ана каз кебек. Оныклары аның итәгенә ябышып тәпи басалар, кулына тотынып атлап китәләр...

Элекләрен Маһирәттәйләр өенә керсәң, түрдә — ярты взвод тәгәрәшеп йокларлык бер сәке дә ишек төбендә — кәнфит кәгазьләре ябыштырылган бер пыяла шкаф күрә идең... Бүген анда — болдыр баскычларына кадәр буялган сары идән, никель караватлар, диваннар, көзгеле, полировкалы кием шкафлары, озайтмалы аш өстәлләре... Телевизорлары — яңа маркалы «Рекорд», радиоалгычлары — «Гамма-В-С», проигрыватель дигәне дә үзендә. Сырлы этажеркаларында китап та китап: «Сиваш», «Агыйдел», «Ак чәчәкләр», «Муму»... Өстәлдә яңа килгән «Огонек», «Азат хатын» журналлары, «Кызыл таң», «Хезмәткә дан» газеталары...

Әмма бу өйдә күзгә бигрәк тә ташланып, бәрелеп торганы — гөл! Гөл дә гөл! Безнең аналар, апалар һәм сеңелләр тәрәзә төбен тутырып үстерә торган ал, кызыл, алсу-кызыл, чия-кызыл чәчәкле гөлләр — тамчылы гөл, рәйхан, бәрхет гөлләре... Элекләрен бу гөлләр Маһирәттәйнең түр тәрәзә төпләрендә генә, кечерәк иске чуен, я чүлмәк савытларда үсә иде. Хәзер кая ул тәрәзә төпләре генә! — тәрәзә янындагы комод, өстәл, тумбочка өсләре дә тулы. Савытлары да зуррак, гөлләре дә эрерәк.

— Күп-үп шул гөлләрем, күп! — ди Маһирәттәй. — Кунак чакырасы булдымы, берәм-берәм апчыгып, чолан тутырып тезәм. Әтү кеше утырырга урын җитми. Кунак таралгач, кире ташып куям. Урыннарына...

Балаларының кыз балалары да — Гөлҗиһан да Гөлсара, Гөлбану да Гөлҗәүһәр... Кайсысының кияве «үзбәктән, шуфир, өч балалары бар инде. Ташкент ягында торалар, Кәмчәткәдә... Әйе, әйе, Кәмчәткәдә инде, Ташкент ягында...». Берсе әрмән егетенә чыккан: «Төзүчеләрдән. Менә бездә дә таш магазин салып киттеләр бит... Ә кыз ашханәдә, аш биреп торучы. Танышканнар... Бардылар кияүнең иленә. Кавказ таулары ап-ак карлы, шундый мату-ур, ди! Беренче бәбиен дә шунда тапты. Тапкач кырык көн бер эш тә эшләтмәгәннәр, вәт! Бәбиен, ак бала дип яратып, үзләрендә калдырганнар...» Ә берсе Стәрлетамакта пединститутта укый икән: «Практикыга эти-әниләре авылына кайта, Мәкъсүткә...»

Инде оныклары кырыктан арта Маһирәттәйнең, оныкларының балалары егермегә җитә.

— Балакайлары-ым! Барысы да балакайларым!..

Мәскәүдәге яшь төзүче оныгы да аның балакае, Уфадагы оныгы белән килене дә, аларның кечкенәләре дә, Ленинградтагылары да,

«Кәмчәткә»дәгеләре дә... Барысы да аның канаты астындалар. Дөньяга килгәннәре дә, киләселәре дә...

Ил анасы булган безнең Маһирәттәй. Кайларга барса да, күкрәгенә кысып сөяр балалары бар, кая керсә — түр аныкы.

Ана кеше чыраен балаларын сөйләгәндә күр икән!.. Яулыгы астыннан чал чәче бүселеп чыккан. Итләч битләре, киң борыны белән авызын, маршал Жуков иягедәй киң вә чыгынкы ияген уртада калдырып, ике якка салыныбрак тора. Үз гомерендә курку белми, сер бирми яшәгән кеше чырае бу. Үз иманы белән гомер сөреп, картлыкка аяк баскан... Әмма «балакайлары»н сөйләгәндә шушы кырыс чырай бу кадәр яктырып, дымсу зәңгәр күзләр бу кадәр яшәреп лә китәр икән! Ана бәхете бу кадәр дә олы булыр икән!

Ә бит бу чырайда, бу карашта тулы бер чорны үзенә сыйдыра алган бер күңел чагыла. Каршылыклар, авырлыклар тулы бөек бер чорны чагылдыра бу күңел.

Сүз дә юк, Язари картның Маһирәсе Кара Бакый йортына төкле аягы белән килеп кергән! Рәхәт булса, торырмын, кыен булса, аерылырмын да китәрмен, дип түгел.

Маһирәттәй кыйссасы

Үзенең Ленинградка баруын сөйләде миңа Маһирәттәй.

Берүзе чыгып киткән ул ил буйлап.

— Пуез сызгыртып кына очыртып аппара! Оренбурдан утырып киттем. Балалар аппарып утыртып җибәрде... Мәскәүдә — кеше! Килеп торып күп. Кая карама — пыяла да язу, тәрәзә дә чират... Кычкырдым: «Балам, дидем, билетка кайда пичәт сугып бирәләр соң?»... Ышанмассың, кассадагы кыз: «Дабай, бабушка», — диде дә, шыгрым кеше арасыннан кул сузып, пичәт басты да бирде...

Ленинградта туктагач, тәрәзәдән карасам, Мәрүсә килен халыкны ярып килә! Балалар тилиграм суккан. Шакмаклы йомшак машинага утыртып апкайтты. Йөртүе рәхәт.

Икенче көнне ачкычны миңа бирделәр дә эшкә киттеләр. Вәлирик укуга йөри әле. Өй эчләре ялтырап тора, бер эшләре юк. Күңелсез.

Бикләдем дә бакчага чыктым. Буяулы эскәмияләре, түгәрәк башлы тирәкләре, аллы-гөлле чәчкәләре... Карап туймассың!

Менә хатыннар килә. Күлмәкләре, яулыклары безнеңчә, сөйләшүләре дә безнеңчәгә охшаган. Юл кешеләре. Чимаданнары бар. Куанып киттем: «И-и, мин әйтәм, сез кайсы якларныкы соң?» — дим. Бәхәчкаладан икән...

Бер бәләкәй лафкыда борыч күрдем. Борчаклы кора борыч. Өч кызыл ун сумлыкны чыгардым да өч кило алдым. Авылга, күчтәнәчкә. Хәзер ит күп...

Килен ошатмады. Үз кулымда бушлай да тулып ята, ди. Бульниста эшли ул. Авыруларга аш пешерергә көрпәләрен, маен-шикәрен биреп торучы...

Кунакка аппардылар бер туганнарына. Ялтыр тартма апменеп китте. Кынупкасына баскач. Ышкафларын, диваннарын да шуның белән апменгәннәр... Ай-һай ла, биектер өйләре! Тугызынчы катта торалар. Тәрәзәсеннән караганыем, кала өстенә колап төшәм дип торам. Чайкалып киттем... Шуннан тәрәзәгә карамыйча гына ашап-эчеп утырдым. И ташкаласы зур! И матур!.. Ленин бабай торган өйне дә барып күрдем. Теге революция көннәрендә торган өен... «Әврура»га аппардылар. Пырахутына ук...»

*
* *

Беренче машиналар килгәндә Маһирәттәй нәрсә кичергән дип уйлыйк икән? Үзенә күрә бер күңел фажигасе түгелме? Үз иманыннан ваз кичәсе умырткасыз җилбәзәкләр рәтендә түгелме ул? Итәгеннән төшкән һәрбер малае, ана иманын таптап, машина артыннан чабып китә торсын әле!..

Үзе дә сизмәстән, буласы шоферлар, механизаторлар үстергән ана ул. Хәзер үзе, машинада ил гизеп, туйдан-туйга, бәби туеннан бәби туена йөреп ята...

Кешелекле заман аны үз машинасыннан төшереп калдырмады. Балалары белән бергә утыртып алып килә.

Заман кешене кеше итми дип әйтеп кара инде!

Музгарка

I

Безнең аламачы, тирече күршебез камыт аяк Миңгали абзый — минем беренче тапкыр каләмгә үрелүемә дә сәбәпче булган кеше ул.

Тире-ярының ул һәртөрлесен җыя иде. Ат тиресе, сыер, сарык, кәҗә тиреләре турында сүз дә юк. Үрге Саздан бер малай Миңгали абзый килешкә хәтта «тун»нары әйбәтрәк күренгән песиләрне дә тунап, тиреләрен киергечкә кидереп, киптереп әзерләп куя иде. Ә Каран малайлары язларын Чапык юлы буенда, җирдәге тирән-тирән тишекләргә чиләк-чиләк су коеп, үткен тешләрен ыржайтып, ысылдап килеп чыккан әрләп, йомраннарны аулыйлар... Барысы да шул, кесәдән акча чыгармыйча гына, Миңгали абзыйның кырык тартмалы сандыгыннан үз кирәк-ярагын эләктереп калу өчен инде...

Сунарчылардан төлке, аю, бүре тиреләре килеп керсә, Миңгали абзыкайның түбәсе күккә тия! Дөньяда шайтан тиресе була торган булса, ил буйлап шайтан тиресе дә җыеп йөрер иде ул, валлаһи!

Җан атып яраткан бер этем бар иде минем.

Үрге Сазда өченчене бетергәч, мәктәп мине пионер лагерена җибәрде. Лагеребыз чиста, яшькелт агым сулы Эйек буенда иде. Район үзәгебез Мрак авылы — куе тирәклек, өянкелеккә күмелеп утырган матур зур авыл — суның болын ягында, безнең ак палаткалар исә каршы яктагы урманлы тау итәгендә... Ярыша-ярыша озынлыкка, биеклеккә сикерешеп, чияле буйларга поход ясап, чоңгыллы тирән җирләрендә дә чуер ташлы төбе күренеп яткан Эйектә, текә ярдан баш ташлап, чума-чума су кереп, кояшта янып, каралып йөргән алтын көннәр бар иде.

Пионер лагереның шундый күп төрле рәхәтләрен күреп, кайтыр көннәр җиткәндә, минем эти Мракта укытучыларның белем күтәрү курсында укый иде. Алар Үрге Саз башкорты Хәмит Бикколов. Дәүләткалдан башкорт укытучысы Гаипъян агай Госманов, Кызыл Ярдан чуваш Степанов дигән дуслары белән Ворошилов урамында бер фатирда торалар. Шунда сугылдым. Кайтам, дигәч, эти миңа бер сум кәгазь акча бирде дә бер йомыш кушты: «Кайту юлында, Сәеткол башкортын узгач, Бикеш дигән озын урамлы бер авыл бармы? (Беләм инде: башкортлы-руслы катнаш авыл.) Менә шул авылның урта төшендәрәк, уң кулда тимер ишекле ак таш лафкы булыр, ә сулда, лафкы каршындарак — бер ак өй. Урам якларында карт тирәкләре дә бар. Алты почмаклы, урамга буй тора. Менә шул өйдәге русларның кәнтәе балалаган. Кәнтәйләре сунар эте. Төлкегә-куянга бик шәп нәрсә. Хуҗа картка шушы бер сумынны бир дә зуррак көчеген үзең сайлап алып кайт...»

Кайту юлына эти мине чуваш укытучысы — буйга тәбәнәк, калын җилкәле, зур башлы Степанов абыйга утыртып җибәрде. (Ул өенә кайтып ризык алып киләсе икән.)

Юлда Каран күперен чыккач та, минем бу юлдаш абзыкай җирән юргасын уңга борды да, куаклык буйлата юырттырып, Кызыл Яр ягына түбәнли китте, мин, борынына ис тә кермәгән туп корсак, без койрык көчекне кепкага салып, күкрәккә кыстым да, кичкә каршы атлый-йөгерә, тузанлы олы юлдан ялгызым кайтып киттем. Хәер, каян килеп ялгызым булсын, ди? Минем бит кочакта куяннар, төлкеләр алачак, бүреләр буачак этем бар! Минем көчек зурайсын гына әле ул!.. Менә хәзер генә, өйгә кайтып җиткәнче генә өскә бүре-фәлән килеп чыкмый торсын...

Көчек үзе түгәрәк кенә, йомшак кына. Әти алып биргән яңа соры кепка аркылы учка да, түшкә дә рәхәт җылысы сизелеп тора. Үзе тагын авыр гына, гел бер көе тотып кайтканга, кулны талдыра... Сунарларга чыгасы эт булгач ни, кепканы башка киеп, ике кулны селтәп, үзен янымнан йөгертеп кенә алып кайтасы килә...

Көчекне төшереп юлга бастырдым да үзем алга киттем. «Mah! Mah!» дип, кул селкеп чакырам да, чөңгереп тә, сызгырып та карыйм — юк! — минем этем кыска-кыска гына дүрт аягына баскан, без койрыгын сузган, ялтыр кара борынын җиргә төрткән — ике яңагы саргылт-соры үзенең, ике кашы кап-кара, ике колагы, сырт буе, койрык ягы кара-соры, түше, корсак тирәләре, тәпиләре коңгырт-сары, үзе карасу-күк күзләре белән әллә берәр нәрсә күрә, әллә инде бер ни дә күрми — адымын да атлый белми бит, мәхлүк, аңгыра шикелле тик тора...

Хет шунда башын калкыткандай, борынын сузып, боргалангандай, эзләнгәндәй итенсә ни була инде!.. Ул эт түгел, син аңа хуҗа түгел... Карын ачкан, кайта-кайта арыганмын да инде. Шушы Ягъфәр каенлыгы дигән иңкү җирдә, шушы көнбагыш басуы белән арыш басуы арасында, баганалы юл өстендә калдырып кына китсәм, ачыгып, интегеп үләрме икән инде ул?.. Аның да әнкәсеннән аерылганга әллә нихәтле вакыт үтте бит. Үзе тагын түшне дә җылытып өлгергән...

Кояш баю ягына тәгәри. Кичке һава салкыная төште. Ачылып киткән күк гөмбәзе салкынча-аксыл. Төньяктан, Кырлы куак сырты ягыннан, искән җил дә ничектер рәхимсез сыман тоелды.

Кире барып, көчекне кепкага салып түшкә кысам да тагын тәпилим. Балта кулы чокырында тагын төшердем көчеккәйне. Дус кирәк миңа, юлдаш кирәк. Сызгырам, чөңгерәм, сөйләшәсе килә үзе белән... Тора бит, тик тора!.. Кинәт миңа таба бер-ике адым атлап, нечкә генә, йомшак кына итеп чинап куймасынмы! Борынын сузган була...

Әллә минем тавышны таный да башлады инде! Атылып барып кочаклап алдым да үргә йөгердем...

Чаталы багана турысына чыккач, авыл бөтенләй якында ук күренде. Әнә безнең колхоз бакчасы тирәли җилфердәп утырган топольләр, әнә бик тә олы, бик тә куе ябалдашлы биек Өч тирәк. Әнә бүтән өйләр арасында безнең салам түбәле өй кыегы... Урамнарда тузан. Көтүдән төшкән кәҗә-сарык тавышы бүтән бар тавышларны күмеп-басып ишетелә...

Икенче көнне минем Музгарканы күрергә иптәш малайлар — Фатих, Хәким, Заһидуллалар җыелды. Башыннан, сыртыннан сыйпыйбыз, бәби үчтекиләгән кебек, күтәреп тә йөртәбез, күккә дә чөябез, бәбкә үләненә чалкан салып әвәлибез — нишләтергә генә белмибез! — табылды безгә эш юктан эш.

Музгарка дип исем бирүем шуннан: Үрге Сазда укытучыбыз Тарас Ивановичның малайларга укып торырга биргән юка китаплары арасында рәсемле шундый бер китап та бар иде — әллә кайда урманда ялгыз яшәгән яхшы күңелле бер сунарчы карт белән аның бик акыллы, бик сизгер эте турында. Малай чакта шулай бит инде ул: китабын укып

чыгасың, исемен онытасың, авторына игътибарың да юк, ә менә сунарчы картын, бигрәк тә ул картның этен мин хәзер дә онытмыйм, кичә генә укып чыкканмын кебек, бөтенесе истә... Былтыр гына, кызымның китапларын караганда күреп алдым: Мамин-Сибиряк хикәясе булган икән ул — «Зимовье на Студеной» дигән хикәя. Ул карт үзенең этенә Музгарка түгел, Музгарко дип дәшкән икән. Мин ул нечкәлеккә игътибар да итмәгәнмен, ә үземнең көчекне барыбер шул хикәядәге этнең исеме белән атаганмын. Яратканга күрә...

Менә инде минем дә Музгаркам булды! Без аның кызыл теле белән ялап-ялап, койрык очын селкетә-селкетә китек тәлинкәдән сөт эчкәнен ис китеп карап торабыз. Әле колагыннан, әле койрыгыннан тарткалап, әле борынына селтәнеп үчеклибез, әле кочакка алып сыйпап иркәлибез, аннары бәбкә үләненә җибәреп тагын үчекли башлыйбыз: әйдә ырылдасын, тешләсен, тик эт булсын да безгә дус булсын!

Әни безнең яннан узышлый әйтә:

— Катыгын да космаган икән әле. Һи-и, әллә күз пәрдәсе дә ачылмаган инде?.. Менә катыгын коскач, бик тиз зурая башлар әле, — ди.

Иртән торуга Музгарка янына атылып чыга торган булдым. Көн дә малайлар килде, көн дә Музгарка белән мәш килдек. Табыннан калган сөяк-кимерчәкне аңа ташу дисеңме, аның белән бергә үләндә аунау, иске бишмәт җиңнәрен ерттыра-ерттыра аны үчекләү дисеңме, аның яман ырылдап, әле беребез, әле икенчебезне кууы, иске бишмәт итәкләрен шатырдатып өзгәләүләре, теше-тырнагы белән өстеңә ыргылулары, үзебезнең Кызыл Яр астында су кергәндә суга ташласаң, борынын күтәреп йөзеп китүләре, соңрак, көтү каршыларга чыкканда, бозауларны өркетеп йөрүе — барысы да безгә шул бер Музгарка китергән шатлык иде.

МӘЖИТ РАФИКОВ ◆ СУ БУЕНДА БЕР УРАМ ◆

2

Август бетеп, кабат Үрге Сазга киткәндә, мин әти-әнине дә, абыйны, эне-сеңелләрне дә, туган өйнең рәхәтләрен дә ул хәтле уйламадым, Музгарканы гына бер дә калдырасы килмәде...

Атна узып, ял көненә каршы үзебезнең авылга кайткан саен, сырттан, Рамазаннар тыкрыгыннан авылга төшкән уңайга бер генә тапкыр сызгырып җибәрәм... Безнең өй күренми әле, ул ераста, әллә кайда! Ә Музгарка?.. Музгарка минем сызгыруымны колагына шунда ук элеп тә ала, — мин әле Сәлахетдин абзыйларның бакча башына да җитмәгәнмен, ә ул инде, атылып-атылып, каршыма чабып килеп тә чыга! Бәреп егардай булып өскә сикерә, куанычыннан ыргый-ыргый, чиный-чиный, авыз-борыннарны, бит-күзләрне ялап ала, кайтып җиткәнче сикеренә-сикеренә миңа сарыла, сыйпана, читкә ырганлап китеп тора да тагын атылып килеп өскә ташлана...

Мин кайткан саен, ул зуррак, мин кайткан саен, ул көчлерәк, елгыррак, матуррак. Карашы шундый ачык, якын, үз: «Менә куаныч! Менә кайттың! Я, нихәл?» диргә теле генә юк. Ике күзендә шатлык очкыннары уйный. Үзе зурайганнан-зурая, тазарганнан-тазара, түше киңәйгәннән-киңәя, тиресе астында мускуллары тыгызланып уйнап тора, йоннары елкылдый, җилкәсендә хәтта дулкынланып, бөтеркәләнеп киткән...

Ялга кайткан саен, мин аны, янына бастырып, сырт биеклеген бер үлчәп алам: «Әһә, минем тездән биек булган бит инде! — дип, эчтән генә куанам. — Тиздән бот төбемнән дә була инде!..»

Октябрьның соңгы атналары булдымы икән, кар әле ятмаган, бер явып эрегән генә иде. Мин шулай бер ялга кайтып, якшәмбе көнне төшкелектә әни җыйган табында ник кына сыйлангач, кире Үрге Саз

юлына җыендым. Музгарка мине озата чыкты. Ул инде хәзер озынча зур борынлы, озын сыйраклы, үтә җиңел сөякле, елгыр, җитез бер эт булып килә иде. Көчек чакларында ук мин аңа ипиен-сөяген, кулны югары тотып, биеккә сикертеп каптыра торган идем, хәзер инде киртә башына менеп, ипиеңне үргә күтәреп тотсаң да, сикереп эләктереп ала..

Музгарка миңа ияргәч, Сәеткол башкортында җиденчедә укып йөргән абыем Мәсгут тә, күрше иптәш малай Фатих, Заһидуллалар да авылдан чыгып, кырларны күреп әйләнәсе булдылар, урамдагы берничә Актырнак, Алабай да безгә тагылды.

Рамазаннар тыкрыгыннан Сыртка чыксак, Өске урам малайлары, сунарчы Сабиржан абзый улы Кара Мөбәрәкҗан да, Гариф, Габдуллалар да өч-дүрт эт ияртеп, көзге эскертле-кибәнле кырларда куян ауларга чыгып баралар. Этләре арасында Сабиржан абзыйның бозау хәтле яман да көчле, йонлач Карабайлары да бар иде — үзенең аяусыз кодрәтен белгән сыман, бик вәкарьле генә кыяфәттә алдан атлый ул. Менә без барыбыз бер яу булып, Сырт буйларын иңләп, Олы тауга таба киттек.

Иркен кырга чыккач, Музгарка кинәт сылуланып, сөлекләнеп китте сыман, дәртеннән тыела алмыйча, бер ары чабып китә, бер кире килә.. Габдулла атлы зур малайның аңа сокланып карап алгалаулары минем күздән ычкынмады.

Менә Маташ урамы турыларын да уздык. Мин йөри торган Үрге Саз юлы уң кулда калды: ул Олы тауның уң як итәгеннән, тау үзәне чокырлары аркылы бер төшеп, бер менеп сузыла. Без исә камылы тырпаеп калган басу кыры читеннән, анда-монда кибәннәре таралып утырган чабымлык буйдан барабыз.

Тирә-яклар бушап, төссезләнеп калган. Һава салкынча, җиләс. Күктә, биектәге юка ак болытлар катлавы тик кенә тора сыман, ә алардан астагы күксел-соры болыт кисәкләре, каядыр ашыккандай, агыла да агыла. Шулар арасыннан кайчакны күкнең тирән, йомшак зәңгәрлеге ачылып-ачылып китә. Ераста, кайдадыр Тукмак сырты аръякларында, калын болытлар арасыннан түбәнгә якты кояш нурлары саркып, сибелеп төшеп тора. Кояш дигәнең анда да бу көзге җирне, бу шәрә кырларны күреп торырга урын сайлап тапкан...

Менә бервакытны сулда, басу читендәге тирән буразнадан соргылт сыртлы бер куян, озын колакларын торгызып, уңга-сулга каранып алды да, арт санын җиңел генә сикертеп, посып яткан җиреннән купты.

— Һайт! Куян!..

— Өссәй-й! Өссәй-й-й!..

Кычкырыша-шаулаша, дәррәү алга ыргылдык. Безнең тирәдә тычкан ояларын, үлән төпләрен иснәштереп йөргән маэмайлар исенә килгәнче, авыр гәүдәле зур симез куян Олы тау үренә турылап элдертә иде инде. Кызык чаба икән ул куян дигәнең. Ике колагын сыртына салган, үзе озын, көчле арткы тәпиләрен җиргә тидерер-тидермәс кенә баса шикелле, ә үзе, баскан саен югарыга калкынып, әллә никадәр ара очып-очып китә! Авырлыгы бөтенләй юк диярсең...

Мөбәрәкҗанның Карабае куянны беренче булып шәйләп алды, беренче булып эзенә төште. Ул чаба дип, Алабайлар да, йөнтәс койрыкларын болгый-болгый, нәрсәгә өргәннәрен үзләре дә белмичә, «һау-һау»лап кузгалды. Шулардан күрмәкче, минем Музгарка да сикеренеп, ыргаңлап китте. Кинәт ул да Олы тау үренә элдерткән куянны күреп алды, ахрысы, шунда ук, кәкре койрыклар өереннән аерылып, сулгарак чыкты. Чыкты да озын аяклары белән бар буена сузылып-сузылып алдыра башлады. Ул куян шикелле сикереп атылмый — ул үләнне дулкынлатып искән тар гына бер җил агымыдай оча, ул озын борыны очыннан башлап, елгыр койрык очына кадәр тоташы белән елкылдап, дулкынланып очкан карасу-соргылт-сары бер ук сыман иде...

Зур кара бер йомгактай йомылып, тәгәрәп, куянның юлын уң тарафтан кисә төшеп, иң алдан Карабай бара, аннан шактый калышып, куянның нәкъ эзенә төшеп, Музгарка оча, кәкре койрыклар аерылып артта калсалар да, туктар исәпләре юк — куян күренсен дә, имеш, эт чапмасын! — боларның койрыгына басардай булып, кычкырыша-шаулаша, без, бәләкәй сунарчылар, җил ярып йөгерешәбез. Кырык яуга бер куян...

Минем күз Музгаркада.

Менә кем икән ул! Менә аның бәхете нәрсәдә икән!.. Җәелеп-җәелеп, шундый рәхәтләнеп, уйнап кына, җилдәй җилеп кенә бара бит... Их, малай! Кара син аны, ничек оча ул!.. Айлар буе үзен-үзе белмичә, тик шушы бер сунар сукмагына төшәр өчен генә яшәгән икән бит, шушы җил ялкыны булып очар өчен генә туган икән лә...

Кара, кара, нинди җиңел, хәтта абайламыйча да, узып китте бит зур кара этне!

Куян үрләгәннән-үрли бара, тау һаман текәрәк, текәрәк күтәрелә. Алда — инде еракта — шәрә соргылт тау кабыргасында мин ике генә тере нокта күрәм: куянның аксыл-соры арт саны сикереп бара да, аның артыннан, менә-менә җитәм дип, ялкын булып Музгарка оча. Ике ара кыскарганнан-кыскара, өч кенә, ике генә ыргым кала шикелле...

Менә бервакытны куян дигәнебез, Олы тауның бер сыртын сикереп кенә узып, кинәт юк булды, аның артыннан барып, саргылт ялкын да күздән югалды...

Сыртның аргы ягында Тукмак Чишмәсе үзәне башлана. Ул үзән башында тау нугыты, кыргый сәрби куаклыклары калын япма булып үсә, түбәндәрәк вак каенлык...

Дөнья күргән бу олы куянның безнең ише малай-шалай иәртеп чыккан этләрдән генә эз югалттыру сәләте, күрәсең, булгандыр, — җәнлек исен юеш борынына әле беренче генә тапкыр элеп алган Музгарканы, билгеле инде, әлеге куаклыкта адаштырып, аптыратып калдырган иде...

Карабай да, гаепле кыяфәттә башын иеп, койрыгын кысып кына кире килеп төште (куянга түгел, бүрегә йөри торган эт иде шул ул). Өске урам малайлары, этләрен иәртеп, артларына борылып карамыйча гына, түбән төшеп киттеләр, печән кибәннәре арасыннан тагы да ераграк, Урман тавы ягына китеп бардылар, без исә, туктап тормастан, туры Олы тау түбәсенә менеп киттек.

Куянны югалтып адашкан Музгарка үз эзе белән кире шашынып килеп чыкты да, безне күргәч, чиный-чиный өскә ыргып, мине бәреп ега язды, тынычлана алмыйча, тирәмдә өзгәләнеп бөтерелде. Мин аңа кычкырмадым, дәшмәдем, башын күкрәккә бер кыстым да үз иркенә җибәрдем.

3

Тирләп-пешеп, мышный-мышный, иң биек маяклы түбәгә менеп җиткәч, кинәттән баш әйләнеп киткәндәй тоелды. Юкка гына Олы тау дип атамаганнар икән үзен! Безнең авыл каршындагы әнә теге зәңгәрсу-соры булып күренгән Уен тавы, Уй түбәсе, Кимә таулар да, уңдарак Бирге Дәүләткол аръягындагы Башкорт кыясы дип аталган урманлы-ташлы биек сырт та, кара урманлы Колшай таулары да, бу маяклы түбәдән караганда бала таулар гына, ә Олы тау аларның барысын да үз канаты астына алган олы бер анадай икән.

Кара, нинди ерак ларга бормаланып-сырмаланып китә икән бу таулар, сыртлар, үзәннәр! Ерагайган саен төсләре томансулана, күкселләнә, куера барып, күз аермас төтенсел-карасу төскә кереп, ерак офыкларга барып тоташа алар... Без әлегә бит-кулны юып, кушучлап

эчмәгән салкын сулы саф чишмәләр нихәтледер ул үзәннәрдә! Без җәйнең кояшлы көннәрендә әле таптамаган-гизмәгән чәчәкле-җиләкле болыннар, без әле җиләк-җимешләрен татып карамаган тугайлар, курайлы урманнар, без әле сайрауларын ишетмәгән кызыл түшләр, шәүлегәннәр, сандугачлар күпмедер бу җирләрдә!..

Авылларны әйт!.. Бу дөньяда мин якыннан күреп-йөреп белгән берничә генә авыл бар. Берсе — үзебезнең Аскы урамлы авыл Күгәрчен — ул Олы тауның бер ягында, ә аның икенче ягында Үрге Саз авылы. Күгәрчен ул иңе-буе белән диярлек күз алдында: әнә югарыгы очында, су буенда, куе усаклыгы, су тегермәне, колхоз сарык фермасының кайсысы читән, кайсысы бура абзарлары күренә. Түбәнге оч ераграк — анда куе, мәһабәт ябалдашлы Өч тирәк, тигез рәт булып тезелгән колхоз бакчасы топольләре. Авыл уртасында калку-калку ике ап-ак бина бар — берсе яңа салынган колхоз идарәсе, икенчесе — клуб. Тау астында, су буендагы мәктәп биналарының кызыл калай түбәләре генә күренеп тора... Ә Үрге Саз ягына йөз сиксән градус борылып карарга кирәк. Үрге Саз биредән якынрак ул. Алай да ике очы гына күренә. Чөнки бу башкортлы-руслы-чувашлы озын авылның урта өлешен Олы тауның бик текә бер янтавы каплый...

Ә болытларга якын бу түбәдән нихәтле авыллар күренеп тора күзләреңә! Әнә безнең Җидеболак буенда ук, Күгәрченнән чакрым ярым гына югарырак, Дәүләткол дигән чуваш хуторының йорт-куралары тезелеп баскан. Тагын да югарырак Бирге Дәүләткол, арырак — Аргы Дәүләткол башкорт авыллары агачлык-куаклыкка күмелеп утыралар. Икенче ягына әйләнеп карасаң, әнә-ә Ардат мордвасы озын бер урам булып сузылган. Ардат аръягында Мәкъсүт башкортының тирәкләре биек кара өем булып күренә. Эйек буйлары тугайлыгына сыенып кына, анда-монда Чирбәй, Чапык башкортлары, Дөмбәй руслары, Кызыл Яр чувашлары утырган. Әнә олы юлга аркылы сузылган Каран исемле рус авылы....

Мәсгут абый, озын нечкә кулын сузып күрсәтә-күрсәтә: «Әнә-ә-ә тегесе... Әнә-ә-ә тегесе»,— дип, исемнәрен атап тормаса, без, бәләкәйләр, бу авылларны белми дә карап торган булыр идек...

Хәзер уйлап карасаң, кайсысында гына булмаган без бу авылларның да, кемнәре белән сәлам бирешеп танышмаган-дуслашмаган, кайсыларының өйләренә кереп ипи-тоз татымаган да яхшы сүз ишетмәгән, кайсысында әйбәт дуслык, тугандашлык тапмаган!..

Югарылыктан ачылып киткән дөньяны күрү күңеленне бер шатландырып, бер сокландырып та, хәтта дулкынландырып та жибәрә икән. Бу дөньяда бер син генә түгелсең, бер синең генә өең, бер синең генә авылың да түгел,— син булсаң да, син бөтенләй булмасаң да яши килгән һәм яши бирәчәк таулар, чишмәләр, урманнар, кырлар бар икән. Син күреп, белеп, шатланып үз итәрлек күп авыллар, кешеләр, калалалар — Ил бар икән, шушы Ил кадәр Илең булуы белән генә синең дә авылың, синең дә өең, син үзең дә бар икәнсең...

И һавасы соң, һавасы соң бу түбәнең! Бу салкынча талгын җилдә — төпләре күренеп аккан йөгерек чишмәле дымсу үзәннәр сафлыгы да, җилләргә җилләнеп утырган кибәнле буйлар, яшел уҗымнар исе дә, бөркетле таулар сулышы да, күктәге болытлар җиләслеге дә, кояшлы күкнең чиксез иркенлеге дә — барысы бергә эчеп туйгысыз чишмә суыдай...

Бу түбә үзе шәрә. Үләне вак кына, энәдәй нечкә кыяклы. Яфраксыз, кипшенгән, төссезләнгән. Анда-монда бер-ике бөртек кылган, аксыл чәчен җилгә биреп, калкынып утырган була. Үлән төпләрендә вак кына кызыл таш кисәкләре ята. Тау бөркетләре бала очыра торган түбәдер бу. Маяктан бер читтәрәк Фатихлар үлән төбендә җиргә сеңеп яткан берничә каурый күреп алдылар. Канат төбе каурыйлары Мәсгут

абый берсен кулында бөтергәләп карап торды да: «Дүдәрлек булган бит бу, кыр үрдәге», — диде.

Бу түбәнең маягын, юан-юан дүрт багананы бер-берсенә авыш утыртып, ялгап үстерә-үстерә, шактый биек итеп куйганнар. Аркылы-торкылы араталары да юан, нык каптырып тоташтырылганнар. Җил-давыл егарлык түгел.

Үрге Саз малайлары бирегә еш менәләр икән. Маяк багаиаларында эреле-ваклы итеп язган исем-фамилияләре күп. Үткен пәке белән тирән уеп язган бер фамилияне күреп алдым да гажәпләнеп калдым: мин белмәгән кемдер минем исемнән — әйе, минем исемнән ясалган фамилиясен куеп калдырган... Безнең Күгәрчендә андый фамилия юк. Башкортча язып тормаган, русча итеп ярып салган. Бу биек урында илнең олы телен сайлаган. Күңеле шулай кушкандыр инде... Кызык, безнең якын тирәдә, менә Үрге Сазда гына, миңа кадәр дә минем исемле берәү яшәгән икән бу дөньяда. Исемен нәсел-ыруына фамилия итеп биреп калдырырга да өлгергән... Кем булгандыр, нинди язмышлы кеше булгандыр ул?

Тирә-яклар шундый киң, шундый иркен! Бу төссез-шыксыз тоелган көзге җирнең, көзге күкнең төсләре-төсмерләре шундый күп төрле — кич житеп, кояш баеганчы карап торсаң да, барыбер бөтенесен аерып та бетерә алмассың, күреп тә туймассың.

Ә маяк тирәсендә көзге жилләрдә күшегеп, зәгыйфьләнеп калган вак үлән жилдә калтыранып утыра. Без, теге куян дигәнне инде күптән онытып, әле бер якка, әле икенче якка исебез китеп каранабыз. Ә минем аяк очында уралып бәхетле бер эт — Музгарка ята. Борынын ботинка табаныма төрткән, ике күзен йомган...

Аның бүген бу дөньяга яңадан туган көне.

Әллә безнең дә нәкъ шундыйрак, бу дөньяга яңадан туган кебегрәк бер көнме бу?

Музгарка булмаса, аңа алданып чыкмасак, бу түбәләр түбәсенә арып-талып, тирләп-пешеп менеп йөрер идекме без?..

4

Абыйлар, Фатихлар, Музгарканы ияртеп, үзебезнең авыл ягына юл алдылар, мин Үрге Сазга төшеп киттем. Үрге Саз авылы — «Интернационал» колхозының сарык-сыер фермалары киң бер уентык такыр жирдә, сул кулда күренеп калды...

Маяклы түбәдә аяк очымда уралып яткан Музгарканы соңгы тапкыр күрәмдер дип уема да килмәгән иде...

Тагын бер атна укыдык, менә тагын атлый-йөгерә ялга кайтып киләм. Көн салкынайткан, кискен жиле дә бар. Юлдагы ат-арба, машина эзләре таштай каткан. Аксыл-соры салкын болыттан кар бөртекләре төшкәли.

Рамазаннар тыкрыгыннан төшеп тә житмәстән, түземсезлек белән сызгырып жибәрдем. Менә хәзер минем куяннар, төлкеләр алыр Музгаркам каршыма атылып килеп чыгар, өскә ташланыр!.. Сәлахетдин абзыйларның абзар турыларын да узып киттем, кабык капкалары, өй турыларын да... Зайидуллаларның киртә-коймалары башланды... Муенындагы каешыннан элэктереп, көчләп тотып торучы бармы икәнни? Бәйләп куйдылар микәнни?.. Юк, булмас!..

Йөгерә башладым. Әүвәл жиңелчә генә, аннары жан-фәрманга... Күңелне бертөрле коточкыч шом алды. Тыкрыкны уздым. Рәхмәтулла абзыйлар каршындагы сиртмәле кое янында бер ташка абынып егыла яздым инде. Маһирәттәйләр турыннан чабам... Әнә безнең капка, безнең өй...

Мин аһылдап ишегалдына килеп кергәндә, такта чоланнан, көрпәле җилпучын күтәреп, әни чыга иде.

Капкадан керә-керешкә үк:

— Әни, Музгарка кайда? — дип кычкырдым.

Әни миңа көтмәгәнчә гажәп җылы, күңел күтәргеч итеп елмаерга тырышты, ахрысы. Мин моңарчы аның болай елмаюын хәтерләмим...

— Улым, Музгаркаңны аттылар бит.

— Кем атсын ди аны? Ни сөйлисең син?..

— Әбрар абыеңның атасы, Миңгали абзыең...

Минем тавыш бик ятышсыз, алама яңгырагандыр, әлбәттә, чөнки үземне тыяр хәлдә түгел идем:

— Нигә? Нишләгән ул?!

Әнинең тавышы, киресенчә, мәгәр үзе дулкынланган булса да, тыенкы, йомшак, үзе тагын никтер гафу үтенгән сыманрак та ишетелде, гүя ул шушы тавыш белән миңа: «Улым, берни эшләп булмый хәзер, син ул хәтле өзгәләнмә инде...» — ди иде.

— Миңа гына ияреп барган иде лә... Йомышка гына кергән идем, — диде ул. — Миннән ишегалларында торып калгандырмы... Алгы өйләренә кергән, тиреләренә орынган, диме шунда... Әллә юри юхалап алып калганнар инде... Абайламаганмын да.

— Музгарка!.. Аның сасы тиреләренә кагыла торган этмени соң ул?!

Әни ачык чолан ишеге баскычына баскан, мин аның каршысында торган килеш, шулай сөйләшеп алдык.

Күзгә яшь тыгылды. Ничек өйгә кергәнмен, ничек җилкәдәге ике элмәкле капчыкны салып чөйгә элгәнмендер, хәтеремдә түгел...

Ял көнне безгә, әни янына, аның яшь дуслары — укытучы апалар килеп керде. Акман мишәре кызлары — Зифа, Зәкия, Хәлимә апалар. Безнең әни үзе дә укытучы булган кеше, үзе дә бирегә ерак җирдән килен булып төшкән. Моңлы-сагышлы, нечкә күңелле ул — чит-ят җирләрдән килгән хатын-кызга бигрәк тә ачык чырайлы була, андыйларны аеруча үз күрә торган иде. Шуның өстәвенә тагын бәйрәмчә пөхтә киенгән алсу йөзле, ачык карашлы бу җиткән кызларга инде үзләре эшкә килгән авылда, илгә-күзгә күренеп дигәндәй, урамнан узарга да бер сылтау кирәк булгандыр... Гадәтләренчә алар минем рус мәктәбендә ничек укуымны сораша башладылар (андый сораудан уңайсызланып тормасымны беләләр иде). Тик бу юлы мин аларга авыз ачып сүз әйтә алмый тордым. Тагын бер-ике сүз кушсалар, яшькә тыгылып, өйдән үк чыгып китәр хәлдә идем. Әни моны шунда ук сизеп алды да: «Аның бүген кайгысы зур әле», — дип, бу әйбәт апаларның сүзен ипле генә итеп читкә борды.

Әти минем хәлгә керешеп тормады, үзе тизрәк онытсын, дигәндер.

Шатланып, җан атып кайткан өйдә шулай гомеремдә беренче олы кайгыга тап булдым.

Төнлә башланган буран җирне тоташ ап-ак кар белән каплады. Минем генә көн кара иде. Фатихлар, Заһидуллалар белән Музгарканы ияртеп, буран ярып булса да, берәр уен корып йөргән булыр идек... Кая инде ул хәзер!

Үрге Сазга кире япа-ялгыз чыгып киттем.

Кар ярып юлдан бардыммы, җил ярып күктән бардыммы, — белмим... Фатир хуҗам чуваш карчыгы Анна әбигә барып кергәч үк, юл буенча күңелдә үзеннән-үзе бер-бер артлы тезелә килгән җырмы-шигырьме юлларын, яңа дәфтәр башлап, барысын бер тыннан кәгазьгә язып куйдым.

Нинди сүзләр, нинди юллар булгандыр анда, хәзер инде аларын кем хәтерли алсын, ди! Шунысын гына әйтә алам: Музгарканы малайларча җан атып яратуым, Музгарканың миңа булган гади сүзләр белән генә

әйтеп биргесез сизгер, кайнар, тугры дуслыгы, шул дуслыктан туган якты хыяллар да, вак табышка гомерен багышлаган бар гарип жан китергән, көнемнең кояшын сүндергәндәй тетрәндергеч фажига дә һәм, ниһаять, Музгаркам белән мәңгегә саубуллашу да — ул беренче язган ярты дәфтәрлек әйберемдә барысы да бар иде. Бик беркатлы әйтелгәндер, әмма барысы да бар иде.

Кем белә, тетрәнүемне шулай тиз арада кәгазьгә түгеп салу юлы ничектер үзеннән-үзе ачылып куймаса, мин бәлки жан зәгыйфьләнүеннән котыла да алмас идем.

Ул озын кышны мин шигырьләрне күп яздым. Күрәсең, кайгылы көнемдә сүз ләззәте аеруча татлы булып тоелгандыр. Күңел әкренләп ачыла барды. Русча да язып маташа торгач, бер-ике шигырь кисәге мәктәптә «Юность» дигән стена газетабызда да чыкты. Кышны узып, кояшлы көннәр елмая башлаганда, минем инде ике дәфтәр тутырып язган көлкеле бер пьесам да бар иде. Колхозның жиң сызганып, яңа жырлар жырлап эшләүче ударникларын, эчеп-исереп, түшәмгә төкереп яткан зур кашыклы ялкауларга каршы куеп, чын кешеләренә бик охшатып уйнала торган бер нәрсә иде ул... Без аны чуваш малайлары Петя Пименов, аннары Гоша Манторовлар өендә, түр якларына пәрдә корып, үзебез уйнап та күрсәткәләдек. Әниләре бот чабып көлешә торган иде. Соңыннан кичке урамда ертык бүрекле бер исерек баш, тешен кысып сүгенә-сүгенә, безне кыйнарга чамалап та йөрде...

Жәен, яңа язганнарым шәбрәк күренгәч, мин, юләр, беренче язган ул дәфтәрләрне, алачыкта битләп-битләп ертып, янып торган учакка ташлап утырдым... Малай чак шул — һәр нәрсә кабатланыр, әле тагы да яхшырак булып кабатланыр кебек тоелган юләр чак!..

Менә шулай итеп, без Музгарканы аламачы, тире-яры жыючы күршебез камыт аяк Миңгали абзый белән икәү уртактан бүлештек: ул аның елкылдап, бөтеркәләнеп торган яшь йонлы тиресен туңап алды, миңа исә фажигале яратуымның күңелдән һичкайчан китмәс шигърияте калды.

Мин, аларга кереп, тавыш куптарып йөрмәдем, Миңгали абзый исә үз эшенең миңа нинди тәэсир ясарын, билгеле инде, уйлап та карамагандыр...

Фатыйма түти Донбасска китеп бара...

1

Фатыйма түти инде сиксәнгә якынлый. Ир хатыны булган, колхозда эшләгән, балалар үстергән чаклары күптән узган.

Читтән карауга тормышының-язмышының бер гажәбе дә юк шикелле, рухына керсәң — тирән бер фажига. Һәм бу фажиганең олы гыйбрәте бар.

Минем әтинең бертуган сеңелесе ул Фатыйма түти. Мәфтуха түтинең бертуган апасы: «Ак тутасы». Мәфтуха түти укудан, китап сүзеннән өзелеп калган, ә Фатыйма түти, янәсе, «укымышлы»...

Мин аны малай чактан ук беләм. Көйсез-жыйнаксыз гына өй эчләрен, үзенең йорт тотмас илгизәрлеген (ягъни биләмчелеген), Ватан сугышыннан кайткач үзен ташлап киткән ирен, инде күптән башлы-күзле булып, аналарын үз почмакларына сыйдырсалар да, аның өчен бик үк жан атып тормаган балаларын...

Тирән каршылыклы бер язмыштыр бу!

Бер яктан, чал карчык булса да, үтә дә «бүгенге» кеше әле ул. Җылы өенең түрендәге кайбер авыл карчыклары кебек, шаулап-гөрләп торган бүгенге дөньяга бераз гына ятсынгандай, тавышсыз-тынсыз гына тәрәзәдән караштырып гомер кичерү кая ул! Фатыйма тутаң бүгенге илне айкапмы-айкый. Судагы балыкмыни. Ул йөреп торыр, ул ил гизәр. Бөтен авыллар, шәһәрләр, станцияләр, аэропортлар, поездлар, автобуслар — аныкы, пенсиясе — оек кунычында, бәйләвеч астында гына... Автобуслары, поездлары белән җирдән элдерткәндә дә, болытлар өстеннән самолетта очып барганда да ул үзен барыбер үз өендәге шикелле үк хис итә, үз өендәге кебек үк иркен тота. Янында утырып баручы әллә кемнәрнең бик җиңел генә телен чишеп җибәрү, сүзгә керешеп китүләр, теләсә кемнәрне тиз үк үзенә гәптәш, хәтта сердәш итеп, кирәге чыкканда әйберен күтәрешүче, юл өйрәтүче итеп алулар — аның өчен бер тиен көмеш! Илгизәрлек җәһәтеннән бүгенге яшьләр дә аңардан күп калыша: студент кешенең каникулы ике генә ай, эшче яшьләрнең отпускасы бер генә. Ә Фатыйма түтинең ел әйләнә каникул, ел әйләнә отпуск — әйдә гуляй!

Ләкин хикмәт менә нәрсәдә: нинди транспортларда йөрмәсен, кайларга бармасын, Фатыйма тутаң үзенең матди вә рухи дөньясын калдырмый. Ә аның бу дөньясының ачыткысы — теге яшел мәчетле-мәдрәсәле заман салган ачыткы...

Фатыйма түтине гомер буе белеп, кем икәнлеген тәки аңлый алмас идем бәлки, ничектер бер көнне язучыларыбыздан шактый үткен каләмле бер ханым шулай сүз арасында гына мәгънәле һәм бөтенесен аңлатырлык бер сүз әйтеп куйды бит: «Ике көнем бер төсле үтсә, дөньяның ямен күрми башлыйм...» Шушы бер сүзе белән гүя ки миңа Фатыйма түтинең күңел дөньясын ярып кына ачты да салды...

2

Буранлы бер декабрь көнендә ишектә звонок шалтырады.

Кара син аны! Кайлардан килеп чыккан диген?! Фатыйма түти лә баса! Уйламаган-көтмәгән җирдән...

— И-и-и, балакайлары-ым-сандугачларым! Исәннәр генәме се-е-ез, саулар гынамы!

Тавышын сызып кына чыгара, җырлап-моңлап сөйләшә. Шул инде, үзебезнең Күгәрчен авылы! Өстендәге зур якалы калын пальтосы изелгән, таушалган. Күп автобуслар, күп поездлар күргән чемоданы төсен җуйган, шомарудан ялтырап күренә...

Кочаклап, аркаңнан кагып күрешә.

Ни хаты, ни хәбәре — бер ни уйлап тормаган, мең чакрымнар узып килгән дә чыккан! Тере генә, мөлаем генә әби әле ул. Түгәрәк битле. Ямьшек борыны ике бит арасына чумып утырган. Бит очларыннан әле алсулык китмәгән. Күзләре үткен карый. Тавышы да сыныкмый, хәлсез түгел — сәламәт яңгырашлы. Йомшак күз карашыннан, бөтен чыраеннан юмарт күңеллелек тә, шуның белән берьюлы базымсыз тыйнаклык, хәтта ниндидер кимсенгәнлек билгесе дә беленә шикелле... (Әмма алдан ук шунысын әйтеп куярга була: табигате белән бер дә ул хәтле үк базымсыз тыйнаклардан түгел ул. Просто акыллы песи ул, иркә песи.)

Өс-башын алып элгән уңайга ук, ванныйда суның теләсә күпме агып торуына рәхәтләнеп, тәһарәт яңартып алды да, шомарган чемоданыннан кырык корама намазлыгын чыгарып, диван-карават өстенә менеп китте. Авыл әбиләречә мул тегелгән бөрмә билле, бала итәкле күк сатин күлмәктән, кәшимир яулыгы ияк астына китереп бәйләүле. Чәче генә юкарган, чаларган.

Менә түти безнең табын түрендә. Мин, аңа карап, үзем күрмәгән әби-бабайларны күз алдыма китерергә тырышам. Түти ул элек кара чәчле була торган иде. Төскә-биткә бабайга тарткан. Һинд чәен сөтсез-каймаксыз эчми икән, чәенә шикәр салмый (салган булсаң, аңарга яңаны яса...). Яратканы каймак та эремчек, Казанның җимешле сыроклары. Итле ашны капкан кашыгын санап кына авыз итә, хуҗаларның хәтере калмасын дигән кебек кенә. Безнең якның врачлары-сестралары һәркайсы аңарга «балам» гына икән. Бер төчкерсә, чемоданыннан ак капсуллы «ингофен», «нигокамф»ларын чыгара. Ниндидер иске китаплар, үзе генә белгән ниндидер «шифалы» үлән төргәкләре арасыннан...

Ул да, авылның барча шундый җегәрле карчыклары кебек, көннең-көне буе башын мендәргә бер тидереп ала белмәс, кул кушырып тик утыра алмас. Аңарга, һич югында, иске йон оек башы, иске бияләйләр сүтеп шуларга баш сабу, яңарту шикелле булса да шөгыльләр була торсын. Аякларын бөкләп, йомшак диван башына кунаклап алдымы — кулында эше, телендә сүзе. Ул йомгагы әкрен генә кыймылдап сүтелә, ул биш энәсе ялтыр-йолтыр биешә, ул хикәяләре бер-берсенә ялгана-ялгана агыла — тыңлый гына бел!.. Ялгызы калганда чемоданыннан саргаеп, тетелеп, керләнеп беткән иске китап калдыкларын алып укый. Гомере буе үзе аңламаган җөмләләрне, иреннәрен кыймылдатып, авызын мыр-мыр китереп укый... Мең дә беренче мәртәбә укый... Ә ялыга башласа, ялт киенә дә: «Әз генә йөреп керим әле», — дип, чыгып та китә...

Сүз арасында сорыйм:

— Ничек тапкансың әле безне, түти! Без бит яңа фатирга күчкән идек. Адресны да белмичә...

— И-и-и, тәкси әпкилә бит у-у-ул! Тәкси таба у-у-ул. Элекке думдагы күршеләрегез бик тә әйбәт кешеләр икән. Шулар әйтеп-әйтеп озатып куйды.

«Кышка каршы кем чыгарды икән бу карчыкны? Карлы-буранлы юлларга!» — дип уйланып алам.

— Түти, юлда бик ызаланмадыңмы соң? Күптәнме авылдан чыкканыңа?

— Әлләче. Ике ай булдымы икән? Өч аймы? Авылда күлмәкчән йөридериеләр әле. Донецкига барыйм, дигәнием. Донбасска китеп барам бит мин. Һадиләргә...

Түтинең ике улы авылда: зурысы шофер иде, хәзер терлекче, кечесе ат караучы. Ә уртанчы улы — шахтер. Хәрби хезмәтеннән соң комсомол путевкасы белән туп-туры шахтага төшкән.

Фатыйма түтинең җәйдән бирле шул шахтерлар каласына китеп баруы икән!..

Авылдан чыгып, Донецк маршруты белән фәләнчә йөз километрлар узгач, түти Уфа юлы өстендәге Аллагыват авылында тукталыш ясап кунак булган. Кызы Хәтимә шунда кияүдә. «Авылга кайтканда нигә кереп-күреп чыкмыйсыгы-ы-ыз? Өйләре рельсны үткәч, мәктәп каршында гына. Сыерлары матур. Болан хәтле! Колындай ике бозау китергән...»

Аллагываттан Донецк маршрутына кабат төшеп, Уфа ягына юлын дәвам итәм дигәндә генә, Фатыйма түтиең, кырт борылып, кире якка — Оренбург тарафларына китә дә бара. Донбасска аннан юл табылмасмы!.. («Вокзалда Шакирулла очрады да — әйдә безгә дә әйдә безгә! Оренбург автобусына утыртты да әпкитте...»)

Шакирулла Оренбург Каргалысында тора икән, борынгы Сәгыйт бистәсендә. («Менә синең бабаең, минем әти Мөэмин карт булганмы? Аның энесе булган Галләм, Галләм белән Гафифә җиңгинең бер кызлары булган Нәфисә, Нәфисәне Каргалыга кияүгә биргәннәр, Шаки-

рулла менә шул Нәфисәнең кияве була инде!.. Анда безнең кан-кардәшләр күп-үп ул. Сез йөрмәгәч-белмәгәч тә теге... И-и, әйбәт тә яшиләр инде! Теле-ви-и-изорлары дөньядагы нибарысын күрсәтеп, сөйләп тора. Өйләре шәп инде һәркайсының. Бер кызының кияве бозау симертүдә ди. Әйбәт, тату торалар. Шәүкәте шуфи-и-ир. Җәүдәте шуфи-и-ир. Зурлап каршылап, кунак итәргә кеше генә тапмыйлар диярсең...»)

Аштан-ашка, чәйдән-чәйгә, бөтен Каргалыны кырдырып йөргән безнең түти. Әмма шунысы бар: кая барса да, аның сукыр суфилыгы үзеннән алда йөрер. Кая керсә дә, песием генә керер, вәкарь белән тәһарәт алыр, ялтыр чемоданыннан кырык корама намазлыгын чыгарып, биш вакыт намазын калдырмас, тәсбих тартыр, тәһлил әйтер, тагын шундый без аңламаган-белмәгән әллә нинди дини йолаларын башкарыр — һәм ул үзенең ул йолаларын шундый җитдилек белән башкарыр ки, әйтерсең йорт хуҗаларының, бала-чаганың эшләре-шөгыльләре бер дә ул хәтле әһәмиятле түгел!

Кыскасы, яшьләр бу түтигә әз генә ятсынып, әз генә гаҗәпләнеп, әз генә көлемсерәп карасалар да, киң күңелле булырга теләп, чыдаганнар булса кирәк...

Ә намазлы карчык шундый да ихтирамлы сабыр мөнәсәбәтне, шундый кадер-хөрмәтләрне ташлап кая ашыксын ди! Ул барып җиткәнче, Донецк каласы үзенең киң урамнары, зур-зур һәйкәлләре, матур бистәләре, тирән шахталары белән кубып, әллә кая качармы әллә?! Фатыйма түтинең аның поездлары, самолетлары бик шәпләр, бик җитезләр бит — аңардан һичбер авыл, һичбер шәһәр бер кая китә алмый. Китә икән, любоеның артыннан барыбер куып җитәчәк!

Каргалы рәхәтләреннән соң түти, тагын кире борылып, Уфага юл тоткан. Утыртып, озатып җибәргәннәр. («Гәүһәрләрдә ике атна тордым. Дебетләрен аяда аялап, шәле-е-ен бәйләштем, үзләре өйдә юкта өй эшләре-е-ен караштырдым...) Гәүһәр апа — Мәфтуха түтинең зур кызы. Уфада яши. («Китмә дә китмә, тагын ки-и-ил дә тагын кил, — дип калды... Әйбә-ә-әт тора. Эше шул инде — бульниста сестра. Ялгызлыгы гына-а... Аерылган бит ул. Эчкән дә ташлашкан тегесе!.. Уллары еге-е-ет булып беткән икесе дә. Берсе артист. Филәрмуньяда биюче ди. Икенчесе художникка укый. Үткән җәйне Ленинградка барып, Эрмитаждан карап, рәсем ясарга өйрәнгәннәр, диме...»)

3

Фатыйма түтинең болай «Донбассларга йөрүе» беренче түгел. Уфада мөфтигә керергә дә гайрәте җиткән аның, мөфтинең дә китапханәсен айкап, ниндидер бер иске китап эләктереп чыккан ул...

Күгәрчендә, үзенең Шамиле белән Тәвилә килене торган йортта да шулай: таң йокысыннан уянгач, сөтләп чәй эчеп алдымы — Фатыйма түтиенне ай күрде, кояш алды! Бер карасаң, ул авылдан унбиш чакрымдагы совхоз үзәге Мәкъсүттә (автопарк, мастерской егетләре машинасына эләгеп килеп җиткән), икенче карасаң, автобуска тылкышып утырып, бөтенләй икенче якка — район үзәге Мракка барып чыккан!.. Тагын бер әйләнеп карасаң, әле ул Кызыл Яр чувашында, әле Дөмбәй русында, әле Дәүләтколмы, Сазмы, Чирбаймы башкортларында... Кая барса, шунда аның, өй саен диярлек, гомерлек дуслары, ахирәтләре, чәйдәшләре-сердәшләре табыла, кайда да безнең туганнар, кан-кардәшләр бар булып чыга... Ә без шуны гомер буе белмичә яшәп ятканбыз. (Әйтик, моннан йөз ел элек минем Мөэмин бабамның апасы Бибикамалны Үрге Дәүләткол башкортына кияүгә биргәннәрме? Биргәннәр. Аларның балалары булганмы? Булган. Хәерниса исемле кызларын, янә килеп, Үрге Сазга башкорт егетенә биргәннәрме?.. Уллары кай-

сысы бригадир, кайсысы тракторчы, балаларының балалары кайсылары кайда укыйлар... Менә шуларны гомерең буе белми-күрми йөрү — туганлык буламы инде, я?.. Фатыйма түти исә бөтенесен дә белә!..)

Фатыйма түтинең кая барса, шунда безнең башлар җитмәс мең төрле йомышы, мең төрле хәбәре булыр, төенчегендә әллә кемнәргә, ничек кайнатып, ничек тондырып, ничек шифаланасын әйтеп бирәсе үләннәре бар, юлда очрыйсы теләсә кемгә әйтергә аның мең төрле акыллы сүзе, мәкале, киңәше, гыйбрәтле кыйссалары тел очында гына торалар...

Улмы соң ире белән балаларын караудан, өй-йорт эшләреннән, ашсу хәстәрләүләрдән генә җан рәхәте табар кеше? Аның күңеле — әй эченә генә сыеп тора торган күңелме? Аның күңеле гомере буе әллә кайлардагы әллә кемнәрдә... Аңар әйтерсең лә хәтта бүген дә күрәсе, танышасы, сердәше, ахирәте буласы кешеләр җитми.

Әгәр дә бүген бөтен дөнья бер дуслык-туганлык гаиләсенә әверелеп, ил чикләре ачылса, Фатыйма түтиең иртәгә үк, таңнан торып сөтле чәен эчү белән, бер җаны бишкә ярылып, берьюлы биш кыйтгага чыгып китәчәк! Биш материкның бишесендә дә ул үзенә чәйдәш-сердәш ахирәтләр табачак, океан ар якларында, хокуксызлыкта, кысынкылыкта яшәгән индеецларны аркаларыннан кагып сөячәк, Пакистанда ул саргаеп беткән иске корьән хәдис табып шатланачак, Африкадан исә, Күгәрченгә кайткач ахирәтләренә бүләк итеп өләшеп йөрергә дип, бер кочак бит яулыклары күтәреп кайтачак... Токио белән Нью-Йоркның тын алгысыз төтенле урамнарыннан төкеренеп узачак, ә менә Париж, Рим, Флоренцияләрдә ниләр кылыр ул — боларына минем акыл җитми... Кешене аны каян ул хәтле белеп бетерәсең, ди?!

Әмма кайларда ниләр күрмәсең, ниләр ишетмәсең-белмәсең, берсенбер онытмыйча күңеленә җыеп йөри ул. Аннары инде шагыйрьләрчә хисләнеп, сурәтләп сөйли башласамы!..

Ник бу кадәр тынгысыз илгизәк җан, бу хәтле рухи куәт, бу сирәкләрдән-сирәк хәтер белән бу гаҗәп тә хикмәтле-бизәкле тел Фатыйма түтигә бирелгән дә, ник миңа бирелмәгән!

«Тик тора алмыйм, тик торсам, күп кайгы-хәсрәт күргән йөрәгем сызлый башлый, күңелем куба», — ди Фатыйма түти.

Сугыш вакытында яшь кенә балалары белән көтү көткәндә «ике аягын ат итеп, ике кулын камчы итеп» йөргән ул, «күз яше белән битен юып»...

Ул сиңа бер сүз сөйли башладымы, без профессорлардан ишетеп белгән теге анафора, метафора, гипербола, антитеза кебек шигъри алымнар бу карчыкның тел очына әллә кайлардан үзләре йөгерешеп килеп кенә торалар.

Минем әни үлгәч, Фатыйма түтиең «бәгырен җиргә куеп» елаган...

Донецкида шахтер Һадиенең кызы, сигезенчене бетергәч, ниндидер бер техникумга керә алмаган икән, Фатыйма түти шуңа үртәлүеннән: «Ел буе чаршау артында утыргандай утырды үзе! Укып! Керә алмады! Иптәш кызы үзен аяк астына салып таптап узып керде дә китте әнә! Укуы да ни генә ие...» — дип әйтә белә.

Җисемсез сүзгә дә менә дигән чагыштырулар таба ул: «Сөйләп кенә торган сүзем телемнән төшә дә югала... Әнә кебек...» Ә Күгәрчендәге Миңнислам абыйның уллары шундый да эшчән, шундый да тәртипләләр икән: «ялгыш кына да читкә басканнары юк...»

Көлдергеч шаян сүзләре дә аның капчык тулы. Инде шигырьгә, җырга күчсә, ул сине бөтенләй күмеп ташлый — югалып каласың. Кем кайчан нинди хәлләрдә нинди шигырь чыгарган, кем кемгә нинди җыр багышлаган — болар бит инде һәркемнең үзе генә белә торган сер булуы ихтимал... Үзенең якын кешеләрен әнә шундый күңел серләренә хәтле белеп тора, шуларны гомере буе хәтерендә йөртә ул.

Әйтик, минем әни — Күгәрченгә читтән, Оренбург ягыннан килен булып төшкән нечкә күңел — чит җирдә тормыш кырыслыгыннан, күңел нәүмизлегеннән зарланып-моңланып, хыялында гүзәл көенчә саклаган кемгәдер багышлап, менә мондый бер шигырь чыгарган:

Аһ, калдың ерак, инде тормыш алып китте мине!
Яшь түгә күзем, сагынганнан күңелем эзли сине.
Аһ, кайчан күрмәк насыйб булыр матур бу йөзләреңне,
Нур чәчеп, очкынланып торган нурлы бу күзләреңне?
Сагынам, аһ, саргаям, ләкин чара юк түзмичә.
Шунда да күрмәк телим, татлы өметем өзмичә...

Бүген Фатыйма түти сөйләмәсә, мин анамның шигырь белән сөйли алганын белмәс тә идем.

Әниемнең укучысы, ахирәт дусты, Мәкъсүт авылы кызы Хәлвә апаның соңгы шигырьләреннән берсе болай тәмамлана икән:

Каләмкәем, сине шуңа сөям,
Миңа сердәш булдың гомергә.
Васыять итеп әйтеп калдырамын
Кабергә дә бергә күмергә...

Ә безнең колхозның атаклы бакчачысы Галиулла абзый Баһапов утызынчы елларны кунак җыеп, ишегалды бакчаларында мәҗлес корып бер утырганда болай җырлаган:

Алтын гына микән бу дөнья,
Көмеш кенә микән бу дөнья?
Кадерләрен белеп көткән иргә
Сәхрә генә икән бу дөнья...

Ә Мөэмин бабамның шаян сүзле әтисе Мөслим карт сәке башында менә нинди сүзләр көйләп утыра торган булган: «Бер утырсаң галимнәр белән бергә, хисап ит син моны йөз ел гомергә...» «Галимнәргә иярсәң, яшел чапан киярсең, түр башында утырып, татлы тәгам җыярсың. Наданнарга иярсәң, кара чикмән киярсең...» Менә сиңа безнең бабайларның идеаллары, үзләренең «кара чикмән»ле язмышын каргаулары...

Мөслим бабай 1821 елны туган... Минем әни дә күптән инде дөньяда юк. Аның ахирәте Хәлвә апа да юк инде .Ә безнең колхозның атаклы бакчачылык бригадиры Галиулла абзыйны 1943 елны Украинада эсэсчылар, җәзалап-җәзалап та сүз ала алмагач, берәүләрнең бакча башына алып чыгып атканнар... Ә Фатыйма түти бүген, йомшак диванда аяк бөгеп утырган җиреннән, миңа аларның әйткән сүзләрен, чыгарган җырларын, шигырьләрен, иң нечкә күңел тибрәнешләрен тезепме-тезә...

Кем кушкан аңа гомере буенча һәр белгән кешесенең күңел хәзинәләрен хәтеренә алып, чәчми-түкми саклап йөртергә? Нинди программа буенча, кемнәр алдында имтихан тотар өчен, нинди диплом алыр өчен?..

Үзе чыгарган җырлары да күп ул Фатыйма түтинең. «...Бәхетләрем булмады. Бәхет тараткында миңа уң кулларын болгады»,— дияр ул, мәсәлән. Донецкида торганда, туган якларын сагынып, мондыен чыгарган: «Агыйделкәй суы ай тар микән, тар җирендә басма бар микән? Өзелеп-өзелеп сезгә җырлар җырлыйм, мине искә алучы бар микән?..»

Үзе диванда оекбаш бәйләп, ике кулында биш әнә биетеп утыра, үзе, укыган-белгәннәрен сөйли-сөйли, бервакытны бик шома гына иттереп, үткән-онытылган чорларга, Оренбург, Казан тарихларына кереп китә ул. Бара-бара, Сөембикә мөнәҗәтләрен үк сөйли башлый: «Сөембикә атым, нугай затым, хан бикәсе булган вакытым...»

Тик шунысы аеруча кызык, аның «тарих»ларында чын шәхесләр арасында Салсал батыр, Сәетбатталлар, Йосыф белән Зөләйха, Алып бабайлар хәтта шәбрәк тә хәрәкәт кылганнар булып чыга...

4

Бер карасаң, адәм ышанырлык түгел: ничек инде шушы Фатыйма түти үз язмышыннан канәгать булмасын ди? Аныңмы, ил гизеп, берсеннән-берсенә кунакка йөреп, кадер-хөрмәт күрер балалары юк? Аныңмы ил тулы якынлы-ераклы туган-тумачалары, чәйдәшләре, гәптәшләре-сердәшләре, ахирәт дуслары аз? Аныңмы дөньясы тар? Аныңмы, анда барма, монда йөрмә, дип, алай итмә, болай итмә, дип, бер генә бер тыючысы-чикләүчесе табылсын? Юк лабаса!..

Әмма Фатыйма түтинең шигъри моң тулы күңелендә аптырашлы, чарасыз ниндидер бер зар яши. Сүз арасында гомеркәе узуына ачынулары, үз гомерендә күргән-кичергәннәрен моң-зар дәрьясы итеп сурәтләп-сурәтләп әйтүләре бер хәл. Баш сызлавы, я бүтән төрле сырхавыннан сыкрангалавы инде табигый дияр идең. Әмма күңелле һәм шат мәҗлесләрдә дә Фатыйма түтинең сузып-җырлап сөйләгән сүзендә барыбер зар яңгырашы ишетелә. Шатлыклы хәлләр турында сөйләгәндә хәтта... Бүгенге көнгә-кояшка, бүгенге тормышка бөтенләй ятышсыз, ят, ниндидер үзәк өзгеч бер зар яңгырашы бу. Әйтерсең лә ул шатлыклы хәбәренең дә яңгырашы аркылы: «Ярый ла, сезнең күңелләр хуш та шат! Ә минем... Юк инде, булмас инде...» — дип әйтеп тора. Хәтта кайбер артистлар кыланганча ясалма шикелле тоелырлык була аның тавышындагы бу аһәң. Үзен кызгандырыр өчен юри мескенләнеп йөргәнлектән киләдер, дип уйларлык, тискәре үк бер тәэсир калдырырлык...

Ә бит Фатыйма түтинең сүз сөйләше мин белә-белгәннән бирле шулай! Гомере буе. Өметсез ачы бер зар аның күңеленә мәңгегә оялаган, рухына күчкән, табигатенә үк сеңгән, күрәсең. Ә үзе ул бу зарның асыл сәбәбен шушы картаймыш көннәренәчә бәлки белми йөри булыр.

Илдә Совет власте урнашканнан соң төрле милләт хатын-кызларыннан укымышлы галимнәр, шагыйрьләр, каләм ияләре күтәрелеп чыкты. Язучылар, профессорлар, хәтта академиклар. Чыңгыз Айтматов та «Беренче укытучы» повестенда шундый бер олы язмышның нинди көрәш белән яралуын тасвирлый...

Мин Фатыйма түтине тыңлап-тыңлап утырам да, ирексездән, сүзсез генә ачынам: улмы каләм иясе я фәннәр докторы була алмас иде? Улмы зур аудиторияләрне авызына каратып, кафедралардан белем нуры чәчмәс иде, яки халык иҗаты җәүһәрләре рухындагы шигърият үрнәкләре бирә алмас иде?

Бик тә, бик тә кирәк булган аңар Беренче Укытучы дигән бөек кеше!

Ликбез укуларына, наданлыгын бетерүгә ул — инде гаилә анасы — әйләнеп тә карамаган.

Аңлаганмы, белгәнме ул үзенең кем икәнлеген?

Күрәсең, саф күңелле бала яки үсмер чагында рухына нәрсә сеңдереп алсаң, шул гомереңә китәдер.

Аның бүген Казанга килүе дә — түр карчыгы булып кадер-хөрмәт эчендә тыныч утырыр өчен түгел икән лә. Аның теге, «әз генә йөреп керим әле» дип, киенеп чыкканда да «үз акылы үзендә» икән: һәм ул, бер йомыштан әллә ничә танышу, әллә ничә гәп үрчетеп, үзе белмәгән автобус, троллейбус, трамвай маршрутлары белән, адаша калса, «тәкси»гә эләгеп, бүгенге фән вә сәнгать үзәге нурлы Казанны аркылыга-буйга айкый икән лә! Әллә кемнәр аны урамнан ук чәйгә алып кереп китәләр икән, Казанның намазлы карчыклары өчен ул чыннан да «пырафисыр» икән ләбаса!..

...Ятим җиде балалы гаиләдән алар икәү генә сабакка йөргән: берсе минем әти — дүрт абыйсының бер энесе, икенчесе — шул биш абыйсының зуррак сеңелләре Фатыйма. Болары да үз әрсезлекләре белән генә укыганнар. Әти яшел мәчет каршындагы мәдрәсәгә йөргән. Дин

ягына ул алай ук күңел бирмәгән булыр: соңыннан мөгаллим дә булып киткән, партиягә дә кергән. Аннары совет мәктәбендә утыз биш ел укытып пенсиягә чыкты.

Фатыйма түти исә абыстайдан сабак алган. Яшел мәчет янындагы мәдрәсәнең янәшәсендә генә Әпҗәлил мәзин торган икән. Аның остабикәсе Сабира абыстай да, мәхәллә кызчыкларын җыеп, үз өендә укыткан. «Китап» укыган һәм укырга өйрәткән, вәгазь сөйләгән, сәдака бирүнең савапларын сөйләргә оста булган. Күп төрле өй эшләрен дә кызларның «үз теләкләре» белән эшләтә белгән.

Тирән тәэсирле Фатыйма исемле кызчыкның күңелендә беренче тапкыр шигъри хыяллар җилпенүе, тасвирлы сүзнең ләззәтен сиземли башлавы нәкъ әнә шул абыстайга йөри башлаган вакытларга туры килгән дә инде. Рухи азыкка сусап үскән шул чакларында «сират күпер»ле, «оҗмах»лы, «тәмуг»лы ислам мифологиясенә кайнар бер ихлас, сукыр бер ышану белән баш ташлап чумган да ул! Һәм шул бер чумудан, тынгысыз җаны белән, чын реаль дөньяда бүгенгечә үзен таба алмый йөри...

Үсмер чакларында үзен бер исерткән агулы буш хыялларын ул әле бүген дә хисләнеп, яшәреп китеп сөйләп ала: «Рамазан ае ахырында кадер кичәсе була... Күк капусы ачыла... Тәһарәтләр алып, абыстайларның капкасыннан гына су буена төшәбез дә күк капусы ачылганны көтеп йөрибез... Күк капусы ачылганда: «Я раббым, ике дөньяның рәхәтен бир! Иман бир, байлык бир!» — дип, теләк әйтеп калсаң, теләгең кабул була, ди иде абыстай... Менә бервакытны күк пәрдәсе ярылып, бер яктан агарып, нурлар бөркеп ачыла бара, ачыла бара, артыннан ябыла бара... Шул хәтле якты була инде, җирдә ни булса, шул күренә!.. Иөгерешеп керәбез абыстайга: «Ачылды-ы! Ачылды-ы! — дип...»

Бөтенләй булмаганны да телдән шулай бар иттереп сурәтли алган бу гажәп талантның «гомеркәе» шулай заяга узуына ничек ачынмассың?

«Күк капусы» да ачылган аңар... Иҗат сәләтләренә генә юллар ачмаганнар.

Бер көнне, ничектер, бер дә аны-моны уйламастан, кәгазь-каләм алып килдем дә: «Түти, — мин әйтәм, — синең исемең-фамилияң гарәпчә ничек языла, язып күрсәт әле?»

Менә шунда түтием ике күзен түгәрәкләндереп, ике кулы белән зур бер гөнаһлы эштән этәренгәндәй итеп:

— Ку-у-уй! Каләм тотканым юк мине-е-ем, безне укырга гына өйрәттелә-әр, — диде...

Аптырадым да калдым.

Бу — чын. Бу — Фатыйма түтинең бүгенге көне.

Аны образлы, шигъри фикерләү дәрте уянганда ук каләмсез калдырганнар.

Ничек инде аның шигъри моңнарында, тавышында-сөйләшендә серле зар яңгырамасын ди!

Сабира абыстае аны «күк капусы»ларын ачтырып, буш теләкләр теләтеп, чынбарлыктан бер аерып җибәргән, — шуннан бирле түтиең чын дөньяда үзен таба алмыйча, җаны талаңып йөри дә йөри...

Донецкида аның Һадие белән Румия киленененең Диләрә исемле кызлары бар. Нәни укучы бала. «Дилүк» дип йөртәләр үзен. Бу хәтле Фатыйма әбисе булыр икән лә! Калынча таза гәүдәле, елмаеп торган кыңбитле, зур көрән күзләре шундый эчкерсез ачык карый! Һич кенә дә тик тора белми. Үзе шундый ягымлы, иркә, үзе килеп сүзгә беткән татлы тел! Синең һәрбер күңел тибрәнешеңне сизеп кенә тора ул. Үзең дә абайламастан, чыраең аз гына үзгәрсә, бу кошкай шунда ук тезеңнән

төшеп очып китәчәк... Күңеленә үтеп керә торган мәхәббәтле бала. Сөйләндереп, сөеп туймассың...

Менә ул кем булып үсәр, ул нинди язмышлы кеше булыр икән — минем киләчәктән бер беләсе, күрәсе килгәнем шул.

*
* *

Атналар буе булды Фатыйма түти Казан каласында, ай тутырды. Ахры, күңеле булгандыр, кинәт самолетка билет алырга боерды.

Очты Фатыйма түти. Инде туры Донецкига...

Улмы соң көнен-көненә охшатып торыр кеше?!.

Ике язмыш

1

Күрәсең, яхшы кешеләр дә һәркайсысы үзенчәрәк, үзгәчәрәк бер төрле яхшы буладыр.

Мәфтуха түти белән Хәлимә апаны әйтүем. Берсе үзебезнең түти инде, әтинең сеңелесе. Минем балалар аны Алма әби дип тә йөртә: аларның жимеш бакчасында рәхәт күргәннәре бар. Икенчесе — РСФСРның атказанган укытучысы, илгә танылган хөрмәтле апа.

Икесенең тормыш юлы каян килеп шулай бер бәйләнү белән мәнге чишелмәс булып төенләнеп калган диген!..

Бер карасаң, алар берсе дә бәхетсез түгел, икесе дә чорның олы вакыйгаларын саф намус белән күтәрешкән, кичерешкән кешеләр, икесе дә асылда якты язмышлылар. Әмма күңелләрендәге уртак төеннең татлырак ягы Хәлимә апага булса, авыррак, ачырак ягы Мәфтуха түтигә туры килгән.

Мәфтуха түтине мин якыннанрак, яхшырак беләм булыр. Сугыштан соң студент елларымны, җәйге каникулга кайткан арада, кар базыннан чыккан, әни оеткандай тәмле катык ашыйсы килеп киткән чакларда, колхоз бакчасы аркылы, буадан гына туры чыгып, Мәфтуха түтиләргә баргалаганым бар.

Мәфтуха түти — юмарт күңелле, ачык чырайлы, кинәсез-карусыз кеше ул. Бәләкәч гәүдәле, түгәрәк ак битле, йомшак хәрәкәтле. Я ишегалларында, я бакчаларында, инде булмаса, җәйге кухняларында аш-су тирәсендәме бертуктаусыз кыбырдап йөреп торыр. Ягымлы йомшак карашы белән елмаеп каршылый ул сине, әкрен тавышы белән: «Кайттыңмы?.. Зур кеше буласыңмы инде?.. Әниегез дә сау булса, касылай куанырые менә...» — дип, өч сүз әйтә дә тыелып кала. Безнең әни сугыш вакытында үлгән. Мәсгут абый белән мин икебез, госпитальләрдә ремонтланып булса да, әйләнеп кайттык, тик өйдә әни белән ике энебез юк иде инде.

Сизгер дә кеше соң инде Мәфтуха түти! Син Уфадан, Казаннан гына түгел, хет Венера планетасыннан әйләнеп кайтып төш, ул барыбер синең каймаклап туглаган салкын катыкны сагынып, тансыклап кайтканыңны әллә кайдан белеп тора! Ике-өч сүз сорашкач, үзе каядыр чыгып китә, ничек югалуын күрми-абайламый да каласың.

Син түтинең кайсы балалары өйдә булса, шулары белән, аны-моны сораша-сөйләшә, йорт-кураларына күз йөртеп аласың, бергәләшеп бакчаларына, куе карлыган куаклары арасына кереп, бер-ике эре-эре әчкелтем-татлы кара карлыганнан авыз итеп, өйләренә керәсең, стенадагы пыялалы рамнарның берсеннән икенчесенә күчә-күчә, бераз уңа-саргая төшкән фоторәсемнәрдәге иреннәрен кысып, олы бер житдилек белән

күзенә текәлгән чырайларны беренче тапкыр күргәндәй булып онтыласың...

Ул арада... Ул арада түтиең, барлык бүтән эшләрен читкә куеп, кухнясыннан ак эмаль эчле зур бер савытын тотып чыга да читән буендагы калын салам куышлы кар базына юнәлә...

Истә лә ул авылның кар базы.

Түтиләрнең дә базы төшкән уңайга шактый караңгы тоелыр, бераз салкынча, бераз дымсу булыр. Түти үзе анда күп таптанмый. Аяк баскан саен, салам астындагы кар йомшак кына шыгырдап, изелеп куя. Ул кар катламы җәй башыннан бирле һаман әз-әзләп утыра, юкара бара... Түти самавардай юан корсаклы, киң авызлы саргылт-кызыл чүлмәкнең таш белән бастырып куйган фанер капкачын бер читкә, таш кисәге өстенә куеп тора да әле сугышка кадәрге үк имин-аман еллардан калган кызыл бизәкле агач кашыгы белән чүлмәгендәге таралмыйча бавырланып торган катыгын — сепараттан үткәргән сөттән оеткан катык! — батырып-батырып, зур-зур кисәкләп алып сала да, фанерын каплап, ташын кире бастырып куйгач, яшел кәстрүлгә күчә. Биредә аның каймагы. Әз генә саргылт төслерәк куе каймак. Түти шуны бизәкле кашыгын бик үк чумырмыйча гына, үзе генә белә торган бер юмартлык белән элеп ала да әлеге бавырлы катыкның уртасына каплап салып куя.

Бу базда, вак киртәле аерым бура эчендә, түтиләрнең әле яңага җитәрлек бәрәңгеләре дә бар...

Көзге кыраулы иртәләр җитеп, бәрәңгеләр алганда, бу базның юеш саламын бакалары-ниләре белән бергә себереп чыгарып түгәләр дә, тычкан-фәлән сизелсә, коры салам тутырып, ут төртеп, авызын томалап ыслап алалар. Тагын бер себереп чыгаргач, кар базың ялт итеп кала. Төбенә, ян-якларына коры салам түшәп, кышлыкка яңа бәрәңге салалар...

Түти түбәнге очы саламга һәм карга батып торган ике генә араталы баскычтан күтәрелә, савытын баз куышы алдындагы песи үләненә куеп, үзе чыга, базның капкачын кайтарып, сөян кысасына төшереп яба. Ул арада савытның тышкы эмаленә инде бөрчек-бөрчек бәреп салкын тир чыккан була, түтиең кулын юешли...

Тулы савытын, өйгә алып кергәч, түр өстәлгә китереп куя ул, калынча иреннәрен уйната-уйната, катыкны әйбәтләп туглый — бу эшен дә ул, учакка ут кабызу, мичкә ипи утырту, сыер саву, табынга аш китерү кебек үк олы бер эштәй күреп, җитдилек белән башкара... Карасаң, өстендә тәти кашыгы белән каймагы яткан эре-эре катык кисәкләре инде тоташы белән теге базда калган кәстрүлдәге каймактай булган да куйган...

— Әйдә әле, безнең сыер үпкәләп калмасын, катыгын гына булса да ашап кара әле,— ди ул һәм тәти кашыгын сабы белән сиңа каратып куя.

— Әйдә, ялгап ал тамагыңны...

«Әниең дә булмагач...» дигәнен күңелендә калдыра.

Мин әтиләренә тартым эрерәк сөякле, озынча битле һәм кара күзле ике үсмер кызны чакырам:

— Әйдәгез әле, иркәләрем, бергәләп тәмлерәк була ул. Кая кашыкларыгыз?

— Куй,— ди түти шунда ук,— алар ашадылар инде. Менә жизнәң дә бакчадан кайтыр, аш эчәрбез...

Сәмигулла жизнинең сугыштан кайткач колхоз бакчасында бригадир булып эшләгән вакыты иде.

Крестьян нәселеннән чыгып, уку-белемнән өлешсез калган Мәфтуха түти, минем ише крестьян эшенә бәлки инде һич әйләнеп кайтмас, инде жаны-тәне белән шәһәргә йөз тоткан бер студент егетне — бер кара-

ганда, танымагандайрак, сәерсенеп, икенче караганда, бик тә үз күреп, каймаклап тугланган катыгы белән шулай сыйлап утыра. Үзенең ана җаны белән карап ашата. Ипи тешләвеңнән, колак селкетеп, ияк биетүең, кашык уйнатуларыңнан ук ул үзенең әүлия күңеле белән синең саулык-сәламәтлегең, дәртең-гайрәтең, холкың-фигылең, хәтта пакьлегең нинди икәнен дә күреп утыра...

Җәй узып, мин кабат шәһәргә киткәндә, ул үз бакчасыннан жыеп, үзе койган берәр такта карлыган кагын, балга кайнаткан берәр банка җир җиләге вареньесын, берәр банка гәрәбәдәй сары балын китерә. Жизниләрнең үз умарталары бар...

Ә мин — ябык, чандыр студент — кышның-кыш буена, киләсе җәйге каникулга кайтканчы, түтинең салкын тир бәреп чыккан эмаль савытындагы каймаклы катыгы тәмен телдә сизеп йөртәм...

Үзен белә-белгәннән бирле өй арасындагы әлеге теге «тавык чүпләп бетерә алмас» вак эшләр белән мавыгып өйрәнгән ул түти, үзебезнең Күгәрченнән башка дөнья күрми, ил танымый үскән, бар кешене дә үзеннән күбрәкне күреп, күбрәкне белүче дип, үзеннән уңганрак, өстенрәк дип санарга күнеген беткән. Табигате-холкы белән дә үтә тыйнак, үтә йомшак, карусыз бер хатын инде ул. Күзе күрмәгән, күңеле ияләшмәгән берәр хәл була калса, шунда ук югалып, каушап та калучан, тик кечелеклелеге белән эчтән йомылып, моны ул сиңа бөтенләй сиздерми калуы да ихтимал.

Әмма да үз йорты эчендә хәстәрлелеге, ире белән балаларын һәрьяклап кайгырта белүе, аларның кайсысына кайчан ни-нәрсәләр кирәк буласын — иртәгәме, бер атнаданмы, кыш җиткәчме, җәйгә чыккачмы — кайсысының ниләр итеп күңелен күрәселәрен дисеңме — бу җәһәтләрдән инде Мәфтуха түтиең авыз тутырып әйтерлек академик. Сәмигулла жизни бүген ат жигеп берәр юлга чыгасы булса, түти инде аның башына киясе бүрегеннән алып, аягындагы оекбашларына кадәресен кичтән үк кулына алып, күздән кичереп, тишеген-ертыгын ямап, искесен яңартып, пөхтәләп, кыш булса, бияләй-пималарын мич эчендә утын агачлары өстенә үк куеп киптергән — бар кирәген алдан әзерләп, хәстәрләп куйган булыр. Арбасы яки чанасының утыра торган җиренә нәрсә алып чыгып каплыйсын, печән арасына кайсы җиргә нинди-нинди төеннәрен тыгып куясын, капканы ачып, жизнине озатып калганда, юлы бәла-казасыз, эше уң булсын, үзе исән-сау гына әйләнеп кайтсын өчен авыз эченнән генә нинди сүзләр әйтеп каласыларын — барысын да күңеле белән, җаны белән белә ул.

Аның бар тормышы — дөньяда шул бер ирендә дә дүрт бөртек баласында. Кул кушырып тик утыруны, ял дип тик йөрүне белер дә, аңлар да кеше түгел ул. Әгәр үзенең шушы алачыклы, бакчалы, мал-туарлы, учаклы-мичле, кырып юган идәнле, тәрәзә төпләрендә гөлләр үсеп утырган өйле кечкенә дөньясында мең төрле эшләрнең берәрсен онытып, үзе генә белгән тәртип жепләрен бер ычкындырып, чуалтып куйса, ул, гомумән, тереклектән үк өзелүен күргәндәй, тетрәнеп калачагын көт тә тор...

Уйлап карасаң, Такташ яшьтәше, Жәлил замандашы һәм чордашы лабаса! Ә үзенең тарихтагы урынын, исемен, данын эзләр булсаң, мәңге табасың юк. Бөтенләй күздән-хәтердән төшеп калган диярсең... Безнең олы тавышлы, гайрәтле ир Сәмигулла жизнине белүчеләр авыл түгел, район тулы. Түтине дисәң, үзебезнең авылның үрге очында да белүчеләр күпме генә икән? Булса, бригадада бергә эшләгән күрше-тирә дә, туган-тумача — бары тик шул!

Түтиме колхоз бакчасы оешкан көннән башлап Өчтирәк тирәсендә жир чокышмаган, тамыр каерышып, таллык төпләшмәгән? Улмы ташу узган саен буа буышып, бакча жирләрендә канаулар казышмаган, кырларда урман полосалары утыртышмаган, сугыш елларында сыеры

белән җигелеп сабан сөйрәшмәгән? Улмы иренә хатын, балаларына ана түгел?..

Сораша башласаң, «мин» дигән сүзен, фәлән эшләрне «эшләдем», төгән эшләрне «башкардым» дигәннәрен авызыннан келәшчә белән дә тартып ала алмыйсың. Алдынгылардан калышырга гарьләнә торган, начар эштән хурлана торган апакай, үзе һәр эштә төптән үк алынып каерса да, күзгә чалынасы, телгә алынасы кеше түгел. Ул гел арада гына йөргән, ул бер дә әллә ни майтармаган: «...төпләдек инде, эше шул булгач... канауларын да ердык... сабан да тартыштык... ирләр сугышта, атлар сугышта булгач ни...»

Аның үз гомерендә иң олы, иң җаваплы исәпләгән эше — кешегә кадер-хөрмәт күрсәтү, кешене кайгырту, ашату, сыйлау. Анда да әле ул табын тирәсендә тавыш-тынсыз гына, соры бер күләгәдәй, күзгә чалынмыйча гына йөри, иң кадерле сыйларын алдына китереп куйганда да, йомшак, оялчан елмаюы белән сүзсез генә: «Безнең ни, менә шушы гына инде... Сезгә ошаса...» — дигән кебек, уңайсызланып кына китереп куя.

Мин әтидән, безнең Вәҗия әбиебез төсе-бите, холкы-фигыле белән ниндирәк кеше иде ул, дип сораша башласам, әти кыска гына итеп: «Әнә Мәфтуха түтиең — бөтен булганы белән нәкъ үзе инде,— ди дә, тик Вәҗия түгел, Бибибәдервәҗиһа аның чын исеме»,— дип өстәп куя...

Бүтәннәр өчен анысын булдырып, монысын әзерләп торасы бурычларын үтә дә тирән белүче, ир белән сүзгә килүне, кычкырышу-сугышуларны коточкыч хурлык дип күрүче бу түтине мин инде тарихка керәсе буынның типик бер вәкиле дип беләм.

Чоры бүтән хәзер, заманы башка. Бүген һәр егет, һәр кыз күңеле тарткан, җаны сөйгән бер белгечлеккә омтыла, укый, белем ала, үз язмышын үз кулында тотарлык кеше булып үсә. Әмма, юк, кешенең иң яхшы, иң кешелекле ижат сәләтләре ачыла торган бөек бу заманда безгә Мәфтуха түти кебек фидакарь аналарның тансыклыгы кимеми, киресенчә, аның кебекләр аеруча кадерле була баралар...

Тормыш яңара. Җәмгыять тә, кеше белән кеше, кеше белән коллектив, кеше белән ил мөнәсәбәтләре дә, ир белән хатын, ата-ана белән бала арасы да — барчасы туктаусыз үзгәрә тора. Мөнәсәбәтләрнең нигезе яңара. Әмма тормыш дигәнең, мөнәсәбәтләр дигәнең никадәр үзгәрә торса да, мин шушы Мәфтуха түтинең кешегә, үзенең якыннарына булган сизгерлеген, кайгыртучанлыгын, ана күңеленең юмартлыгын үзебезнең буынга да, киләсе буыннарга да көрәп-көрәп алып өләшер идем. Җитәрлек ул аның күңел юмартлыгы, бар буыннарга да җитәрлек!..

Сәмигулла жизни — горур ир. Олы гәүдәле, таза буйлы, гайрәтле ир. Синең белән гәп корып җибәрсә, күкрәген киереп, бераз гына һаваланып, мактанып та ала белер. Әйтәсе сүзен бар кешегә ишеттерерлек итеп, күзенә карап турыдан ярып әйтүчән. Әгәр син берәр эшне кыекка бора калсаң, ул сине, уенын-чынын бергә кушып, ике сүзе белән дә җир тишегенә кереп качардай итә.

Шушындый ирнең дә бу кечкенә «соры чыпчык» Мәфтуханы сайларга ничек акылы житкән диген? Каян белгән ул үзенә аңардан да әйбәт юлдаш таба алмасын?!

Хәер, авыл җирендә һәр кеше һәркемнең күз алдында, «Вәҗия карчыкның бәләкәче» гел эчтән йомылып кына, эш тә эшне генә белүен димче карчыклар шәйләмәгәннәрдер дисеңме?..

Ә бит Мәфтуха түти жизнидән өч яшькә өлкәнрәк тә, шуның өстәвенә, тагы — ир горурлыгың чыдасын! — беренче ире аерып, ташлап киткән хатын да. Әле, шуның өстәвенә, бер баласы да була торып...

Элек бит ул безнең авылның өлкәннәре балигъ булган егеткә берәрсенең кызын «әйттереп» никахлаганнар да эшне «бетте-китте»гә исәпләгәннәр. Кешечә мәхәббәт хисләре уянуын көтеп тору булмаган. Ачтан үләселәре килмәсә, дөнья көтәргә өйрәнерләр әле, янәсе...

Безнең якта тагын «колак тешләү» йоласы да булган әле! Ике гаилә ата-анасы, киләчәктә кодалашу ниятеннән, берәүләренең сөт теше чыккан малаен икенчеләренең әле сөт төше дә чыкмаган кызчыгы янына җибәрәләр дә, кычкыртып колагын тешләтәләр була... Янәсе, буласы «кияү» үзенең буласы «кәләшенә» сөт тешләре белән алдан ук тамга салып куя...

Көлкегә чыккан йола!

Кешенең кешелегеннән күңелле генә шаярып, ачы гына көлгән йола!

Азмы булган шул иске йолалардан килгән мәхәббәт фажигаләре! Азмы булган ул шәригатьле гаиләләрдә гомере буе тавышсыз-тынсыз гына сыктап, тавышы чыгудан куркып яшәгән мәхәббәтле җаннар!

Әмма мәхәббәттә ике күңел берлегеннән, рухи берлектән дә көчлесе, бәхетлерәге юктыр...

Мәфтуха түтинең беренче ире Шәйхи Корбанаевның ниндирәк кеше булганын ни эти-әнидән, ни өлкән туганнардан ишеткәнем булмады. Сораша башласаң, белә торып үзебезнең нәсел горурлыгына кагылу була... Ара-тирә колак очы белән генә ишетүемчә, егерменче елларны ул да безнең авылның күренекле кешеләреннән саналган, аңлы, советчыл актив кеше булган. Әүвәл ул минем укытучы эти белән дә дус булганлыктан булса кирәк, кодалашулары да аңлашыла...

Ташлаган шул Шәйхи җизни безнең Мәфтуха түтине! Бүтәнгә өйләнгән.

Шулай да миңа ул никтер әйбәт кеше булгандыр кебек тоела. Ачык карашлы, якты хыяллы, тәвәккәл кеше итеп күз алдына китерәм мин аны...

Мәфтуха түти белән икесенең, әтисенә охшап, кара күзле булып туган Гәүһәр исемле кызлары йөгереп йөри башлаган бер вакытны, Шәйхи җизни, уйламаган-көтмәгән җирдән, үзенең ата-анасына каршы килеп, Мәфтухасын аерган да читтән килгән бер укытучы хатынга өйләнгән. Гәүһәр исемле кызчыкны да, алар икесе бер булып, үзләренә алганнар... (Шундый хәл килеп чыккач, абыйлар түтигә киңәш иткән: «Үзләре әйткәч, кызыңны илтеп бир инде. Кулыңда балаң да булса, бөтенләй ялгыз утырып калуың бар...» Менә шуннан соң алган ул түтине Сәмигулла җизни.)

Гашыйк ла булган бит безнең ил җанлы активист жизнәбез читтән килгән Хәлимә исемле бер укытучы апага!

Үзе ир хатыны икән. Өстәвенә, әле ире кайсыдыр авылның мулласы да, имеш...

Совет властеның беренче елларында яшь кенә Хәлимә үзенең муллясын ташлаган, остабикә абыстайлыгына төкергән дә, мендәрле-ястыклы җылы өеннән, бөек яңарыш кичереп яткан, әле ярлы илгә хезмәт итәргә чыгып киткән. Укытучы булып...

Ничек күрешеп, ничек табышканнардыр бу ике кеше, ничек берберсенә сокланышып, бәхетләреннән шашынып кавышканнардыр — авыл, бу хәлгә чиктән тыш гажәпләнеп калса да, күрәсең, авыз чайкауны килештермәгән: артларыннан пычрак ата торган чыш-пыш, гайбәт сүзен ләм-мим ишеткәнем булмады. Бәлки әле бу ике күңелне дөрес аңлаучылар күбрәк тә булгандыр. Муллалы-шәригатьле заманнарда да халык Йосыф-Зөләйхаларны белгән ләбаса, күңел түрләрендә олыдан-олы, кайнардан-кайнар, чыннан-чын мәхәббәт үрентеләрен хыялга өртелдереп булса да саклаган, җырларына-моңнарына салган бит!..

Бәлки дим... Бәлки Шәйхи җизни соңыннан, бар гомерендә бер генә тапкыр булса да, Мәфтуха түти пешергән ризыкларның тәмен, түти тәрбияләп тоткан җыйнак өйнең рәхәт җылылыгын, түтинең ягымлы тыйнаклыгын, ире өчен һәрчак бирелеп бетәргә әзер торуларын, күңеле нечкәреп киткән бер мизгелдә генә булса да, эчтән генә сагынып куйган чагы да булгандыр. Әмма... Әмма... Ah, ул икең бер җан, бер тәндәй булып, давыллар аркылы яңара барган ил сулышы белән бергә сулап, бергә янып-ялкынланып, уртак олы хыялларны бергә тормышка ашыра-ашыра, шуның тиңсез бәхетен татып яшәүләргә ниләр җитә икән!..

Ничек инде бу ике күңелне аңламаска! Синме, минме шушындый да кайнар, шушындый да олы мәхәббәт турында хыялланмаган! Бармы икән шушындый югары, изге хисле сөю-сөелүгә җан атып омтылмаган таш йөрәкләр!..

Күгәрчендә күпмедер торгач, кызчыкны алып, каядыр киткәннәр алар. Төрле җирдә эшләп, ахырда Уфада төпләнгәннәр...

3

Шәйхи җизнине күргәнем булмады. Хәлимә апа белән табышкач, уртак рухлы фикердәш һәм дус хатыны янында ул тагы да дәртләнеб-рәк, гражданин буларак тагын да үсенеп, үсеп киткәндер, биеккә үрләгәндер...

Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган диләр аны.

Ә Хәлимә апа белән, әлеге хәлләрдән соң күп гомерләр узгач, мин бер очрашканмын икән.

Хикмәтле очрашу булып чыкты ул. Үзем аны белмичә, гади юлдашларча гына сөйләшеп, хәтта рәтләп танышмыйча, янып-нан китеп тә барганмын.

Әүвәл бу очрашу миңа, юл кешесенең төрле җирдә төрле кешегә туры килеп, шунда ук аерылышканы шикелле, әһәмиятсез һәм истәлексез булып тоелган иде. Ә менә чирек гасыр диярлек гомер узгач, шул бер очраклы гына очрашу минем хәтердә кинәт терелеп, хәтта яңарып та китте... Кайвакыт шулай була бит ул: бөтенләй таныш булмаган берәү сиңа ниндидер бер яхшылык күрсәтә дә шунда ук диярлек синең игътибар күзеңнән төшеп тә кала. Соңыннан аны уйлап, эчтән генә рәхмәт әйткәндә исеңә төшерим дисәң, исемен дә белмисең...

Хәлимә апа белән очрашуым да шулайрак булып чыкты. Кызык, аны әллә кайчан шулай бер күрүемә мин бүген дә эчтән канәгатьмен. Хәлимә апа кебек кешене соңыннан булса да аңлар өчен, бу очрашу миңа кирәк булган икән.

Авылда Мәфтуха түтинең каймаклы катыгы белән ара-тирә сыйлангалап һәм ял итеп көч җыйгач, бер көнне нурлы Казанга талпынып тагын юлга чыктым.

Мракка кереп арбадан төшү белән, үзәк бер урынга ашыктым — кара-каршы тезелгән универмаг, сельмаг, продмаг, культмаг бар бит әле, якында гына юан-юан апалар такта өстеннән ел әйләнәсе көнбагыштыр, тозлы кыяр, кәбестәдер, сөт-катык, йомыркадыр, җәйгә чыксаң, төрле җиләк-яшелчәдер сатып торалар — менә шунда... Әллә кайдан ук исеннән сизгәнмен диярсең: Стәрлетамакка бара торган бер йөк машинасы тора икән, шоферы кабинада, машинасы кабызган, зур бер карт песи кебек калтыранып, мырылдап тора.

Машина әрҗәсендә пассажирлар шактый бар иде инде, мин дә капчык белән чемоданны шунда ыргыттым да менеп арага тыгылдым. Гажәп, машинасы минуты-секунды белән кузгалам, китәм дип тора, ә без августның кызу кояшыннан эсселәп утырабыз. Кемдер тоткарлый әле бу машинаны, кайдадыр бу машинадан көчлерәк кемдер бар, күрәсең...

Менә бервакытны, олы урамның таррак кына бер ян тыкрыгыннан чыгып, чуерташ түшәлгән калку шоссе аркылы нәкъ безнең машинага турылап, калынча таза гәүдәле, көчле хәрәкәтле, зур соры ридикюль тоткан бер башкорт апа ашыгып килеп житте. Үзе, шәһәр интеллигентларынча, жыйнак, шома, пөхтә киенгән. Янында җәйге кояшта янган үсмер улы да бар — зур маңгайлы, озынча битле, унөч-ундүртләрдә булыр. Улы кузовка житез генә менде дә әнисенә кул бирде. Кузов түренә куелган чехоллы ике зур чемодан аларныкы икән...

Болар менеп утыру белән, машина кузгалды, куе тирәкләр күләгәсендә уңга борылды да озын урам белән, ниһаять, безне Мрактан алып китте.

Кояш кыздырса да, юлда жиләс, Эйек буеның тугайлы-тирәкле яшел үзәннәрен карый-карый бару күңелне тиз үк тынычландырып, хәтта рәхәтләндереп тә жибәрде. Калтырана-сикеренә чапкан машина өстендә мин капчыкны чишеп, пешкән йомырка, ипи, тоз чыгардым.

Безне көттереп килеп утырган әлеге пөхтә апа, көтмәгәндә миңа таба борыла төшеп:

— Ничәнче курска барасыз? — дип сүз кушты.

Эчтән гажәпләнеп калдым: «Нинди әүлия карчык бу?..» Карчык дисәң, үзе карт та түгел, кырык биш-иллеләр арасындадыр, башында чәчәкле аксыл эшләпә, эшләпә астыннан күренгән куе кара чәченә көмеш жепселләр берәм-сәрәм генә күренә. Каян белә ул минем студент икәнне? Чандыр буй, житу чәчтәнме, гимнастерканың түш кесәсендәге блокноттан, авторучкаданмы? Әллә юл йөри-йөри шомарып төссезләнеп беткән фанер чемоданнанмы, аның тимер чыбыктан гына эшләнгән келәсендәге кадак белән генә ачылмалы йозагыннан чамалап алганмы?..

Кабина артында шактый уңайсыз урында да ничектер уңай да, килешле дә утыра иде ул апа. Аның кыланусыз, гади, жиңел хәрәкәтендә, үзен тотуында ниндидер табигый бер хөрлек тә, эчке бер мөлаем жыйнаклык та, үз бәясен үзе белүдән килгән бер төрле горур гына килешлелек тә бар иде.

Янында утырып барган юлдашларына күз салып, кыска-кыска гына сөйләшеп алуында эчкерсез ачыклыгы да, кешегә ихтирамлылыгы, чикчама дигән нәрсәне белүчән тыйнаклыгы да сизелә иде аның. Тузанлы юл читендәге менә бу вак таллы, курпылы үзәнгә, комбайн урып йөргән әнә теге арыш басуына, йомшак чалымлы үрләргә, ялпы гына тауларга ул, гәрчә үзе кешегә сиздермәгәндәй итсә дә, эчтән дулкынланып, күреп туймастай булып карап алгалый иде. Ара-тирә улына, берәр таугамы, елгагамы, ерактагы берәр авылгамы күрсәтеп, бер-ике генә сүз әйтә дә, янә сүзсез калып, күңеленнән нидер кичереп, уйланыпмы, моңланыпмы бара иде ул.

Ә миңа дәшкәндә аның карашы шундый иде, әйтерсең мине электән дә белгән, минем күңелне, омтылышны күптән аңлый һәм ул үзе — гүяки минем үзем дә белми йөргән олы жанлы бер теләктәшем.

Аның әүлиялык галәмәте мине гажәпләндереп куйды. Ләкин — кызык! — мин бу апа белән сөйләшә башлагач ук, аның бу беренче тәэсирен онытып та өлгердем. Әйтерсең ул тәэсир булмаган да, булса да урынсыз гына булган, жилгә очкан, ә бу апа исә үзенең күңеле, рухы, бар табигате белән гомер буе шундый кеше инде ул һәм бүтәнчә була да алмый...

Мин ничәнче курска баруымны әйттем. Ул: «Уфагамы?» — дип сорады. «Өфегәме?» — димәде, «Уфагамы?» — диде. Үзенең тулы шома бите, дугаланып торган биек кара кашлары, зур булса да кысык кисемле күзләре, бераз шешенкерәк сыман күз кабаклары башкорт икәнлеген ачыктан-ачык әйтеп торса да, үзе татарча, нәкъ безнеңчә, шома сөйләшә...

Мин бу апаның соравына, кайсы авыл, кем улы икәнемне, кайда, кайсы факультетта укуымны әйткәч, ул, күзен йомгандай түбән карап, бераз уйчанланып калгандай булды. Ләкин үзенең безнең авылда еллар буе балалар укытуы хакында, минем эти-әниләрне белүе, Шәйхи жизнинең Хәлимәсе нәкъ үзе булуы турында бер сүз дә әйтми тынып калды.

Минем өзек-өзек сорашуга ул гади генә иттереп жавап кайтарды:

— Эйек буенда ял итеп яттык та Уфага кайтып барабыз әле менә... Биишев дигән укытучы агайны ишеткәнегез бармы? Гыйбад Биишев. Шуларда яттык. Алар безнең туганнарыбыз була. — Сүзен түгәрәкләп: — Менә тагын яңа уку елын башлап жибәрәсе бар инде, — дигән сүзе миңа кинәт бигрәк тә таныш, якын булып яңгырады — әтиләрдән ел саен ишетә килгән сүз...

Инде хәзер мин уйга калдым: «Ә-ә-ә, Гыйбад агаймы? Карт укытучымы... Әкрәм исемле улы да бар. Ватан сугышы алдыннан мин Каранда укыганда, Әкрәм, ярты кыштан минем фатирга күчеп, бишенчедәме, алтынчыдамы укыган иде. Кызыл һәм тулы битле юантык кына кара малай. Бик сәләтле, тырыш, әмма үзсүзле дә иде ул. Бер-беребездән көнләшкәндәй, ярышып укый торган идек. Бер-беребезгә багышлап шигырьләр язганыбыз да бар... Мин ялга каршы Күгәрченгә кайтканда, ул Саньяпка кайта торган иде. Гыйбад агайның Саньяп авылында укыткан чаклары... Ә бит элегрәк Гыйбад агай Сәетколда да укытты әле! Минем абыйлар, «Биишев абый» да «Биишев абый» дип, бүтән кемне әйтсеннәр ди тагын!..

Ә менә хәзер ул Гыйбад агайлар Мәкъсүттә укыта икән, бу пөхтә апа да улы белән шулардан кайтып бара икән...

— Әкрәм өйдәме соң? — дип сорадым.

— Әкрәм хәрби хезмәттә әле ул, чит илдә. Озакка китте аның хезмәт срогы, — диде апа. — Сәлам хатлары килеп тора...

Шуннан ары бу пөхтә апа белән безнең әңгәмә ничектер үзеннән-үзе сүрелеп калды. Аның каравы, зур маңгайлы улы белән кинәт бик ачылып сөйләшеп киттек. Эйек буйлары кояшында янып каралган бу үсмер мине сөйләшкән-ачылган саен кызарта барды: мин студент башым белән дә ишетмәгән-белмәгән дистәләрчә китапны ул инде су урынына эчкән, теләсә кайсын башыннан ахырына кадәр сөйләп бирә ала. Үз китапханәләре дә бар икән...

Пөхтә апа Стәрлетамакка бара торган бу машинага, гәрчә рәсми үк булмаса да, баш иде, ахрысы. Мракта булды Мракта ул килмичә кузгалып китә алмый тордык. Акманга кергәч, ул тагын, кабина түбәсенә жиңелчә генә бармак кагып, машинаны туктатты да, улын ияртеп, бу авылның мәктәбен күреп килергә дип, урам буйлап китеп барды. Без аларның кире әйләнеп килүен көтеп, кибет күләгәсендә утырып калдык...

Юл кешесенең юлда булуына ни житә! Инде бер эләгеп киттеңме, аның иң рәхәте шул — машинаң туктамый жилдерә генә бирсен!

Ә безнең бу бару барумыни ул! Бу пөхтә апаның әле Акмандагы көттерүен онытып бетмәгәнбез, машинабыз тагын олы юлдан борылып, бөтенләй ят бер юл белән уңга керде дә китте... Стәрлегә бара торган нәрсә безне әллә кая Юмагужага ук алып керде дә тагын туктап калды. Пөхтә апа монда да: «Мәктәпләре анауы бит әле?» — дип, улы белән зур бакчалы бер бина ягына китеп барды. Тагын күләгәгә төшеп, уңга-сулга каранып, вакыт үткәнен көтеп утырдык... Кире олы юлга чыккач, Печәнчедә тагын, безне узып китүчеләрдән көнләшеп, юлга карап утырдык.

Машина юлга чыгып алгач, күңел тагын яңарып, рәхәт булып китә үзе...

Әмма бу апаның болай туктала-туктала йөрүендә бер хикмәт бар иде. Мин моны Акманда ук абайлагандай булдым. Машинаны туктатып, улы белән китеп барганда ул бер кәеф, бер халәттә булса, кире килгәндә бөтенләй икенче кыяфәттә күренә. Киткәндә ул, кемнәрендер күргә дәртсенгәндәй, үзенең дә кемнәргәдер күренәсен онытмыйча, өстен-башын жиңелчә генә төзәткәндәй итеп, бик жанлы, көчле, житез адымнар белән атлый... Ә кире килгәндә — бөтенләй бүтән кешемени! — ничектер кинәт таркалып, йомшарып калгандай, ниндидер уйларына, кичерешләренә бирелеп китеп, тирә-яктагы бар дөньяны онытkандай күренә иде ул. Бәбкә үләнле урамның тигезле-тигезсез жирләрен күрмәстән, әле әз генә сөртенеп, әле сизелер-сизелмәстәй чайкалып киткәндәй була. Күзен күтәреп беркемгә карамый, чыраенда ниндидер тирән уй, ниндидер олы моң бар. Күз карашы бары тик үз күңеле эченә төбәлгән төсле. Акманнан чыгып киткәндә дә беркемгә бер сүз кушмады, йөзен читкә борып, авылның артта кала барган озын урамыннан, су буйларыннан күзен алмый каерылып карап барды. Әллә чыраен яшерүе шул булды инде...

Машинабыз Печәнчедән чыкканда да, апа шулай ук йөзен читкә борып, артта кала барган урам очына, бәрәңге бакчаларына карап барганда итте: шунда, кызыл слюда төймәле ридикюленнән кечкенә челтәрле кулъяулыгын чыгарганда карасам, ни күзем белән күрим, апаның дымлы керфегеннән тулы шома битенә эре бер яшь тамчысы тәгәрәп төшеп бара иде...

Бу апаны, кайчандыр яшь чакларында үзе укыткан авылларына менә хәзер, Бөек Ватан сугышы узганнан соң, яңадан килеп, шулай туктала-туктала, укыткан балаларын барлап, язмышларын белешеп йөриләр дип, бу машинадагы пассажирлардан беребез дә уйламагандыр..

Төнен бергәләп Стәрлетамактан поездга утырып киттек.

Уфага килеп житкәндә, куе таллык буйлап тын гына аккан Дим суы да, тимер юлның челтәрле олы күпере астыннан кинә жәелеп, дугаланып яткан Агыйдел дә иртәнге таң нурларында ялтырап ята, олы, калку тау өстендәге гүзәл шәһәр дә, алсуланып, шул нурларда коена иде.

Поезд күпердән шәһәр ягына чыгу белән, апа, аның улы, мин беренче тукталышта ук төштек тә, әйберләрне күтәрешеп, текә таулы урамнан шәһәргә менеп киттек...

Моңарчы мин Уфа аркылы узган саен туп-туры Гоголь урамы башындагы пединститут тулай торагына, электән таныш студент егетләр янына кереп хәлләрен белешеп уза торган идем. Берәрсенең буш койкасында төн кунып киткән чаклар да булгалады. Бу юлы исә юлдаш апа белән аның улы икәүләп, кат-кат әйтеп, мине үзләренә чакырдылар. Олы кешенең сүзен аяк астына салуны килештермәдем.

Ник соң әле бу апа миңа ничектер үз тоела, ник ул миңа ничектер жылы карый — мин моны эчке бер рәхәтлек белән сизсәм дә, асыл сәбәбенә төшенмим, дип, ничек тә булса сүз кузгатырга базмадым, тыелып калдым — әллә нинди бер тойгы белән моның урынсыз килеп чыгасын сиздем шикелле. Әллә апа үзе, миңа сиздермичә генә, такт дигән нәрсәне шулай куя белгәндерме...

Өйләрендә апаның житеп килгән кызы да күзгә чалынып узды. Ул жил-жил килеп, рухланып йөри иде: берәр вузда укый башлар көннәре булмадымы икән...

Ике-өч бүлмәле шәһәр фатиры. Әйбәт жиһаз, чисталык-пөхтәлек. Апа миңа, якты тәрәзәле бер ян бүлмә күрсәтеп: «Уфада кунып китәр булсагыз, улым белән икегезгә урын менә шушында булыр», — диде.

Көндез әлеге тулай торактагы дус егетләр белән күрешеп, Мәжит

Гафуриның музей-йортына кереп йөрдем дә, кичке якта, хөрмәтле апалар өеннән күтәренеп, вокзалга төшеп киттем.

Саубуллашып, бусагаларыннан атлаганда, мин бу апаны — фронтта ятып калган Шәйхи исемле ирнең тол калган Хәлимәседер дип, китап яратучан бу үсмер малай белән аның кайсыдыр вузга йөз тоткан апасын — шул Шәйхи атлы ирнең ятимнәредер дип, Гәүһәр исемле кыз да шушы өйдән кемгәдер кияүгә чыккандыр дип, бөтенләй уйламыйча-белмичә үк чыгып киткәнмен...

4

Туган якларга кайтып, совхоз үзәге Мәкъсүткә барып чыккан саен, Гыйбад агай Биишевка бер сәлам бирәм. Минем Әкрәм дусның этисе бит ул. Ил агасы кеше. Безнең як совет мәктәпләрендә беренче булып эшли башлаган укытучылардан. Ике-өч ел саен китаплары, бала-чагасы, ястыклары белән авылдан-авылга күченә-күченә йөреп, бар дәртен ил агартуга багышлаган кеше. Хәзер пенсиядә. Балалары кайсы укытучы, кайсы инженер, кайсы журналист. Әкрәм исә хәзер башкортның танылган тел галиме.

Гыйбад агай минем теге чакта Казанга баргандагы юлдаш апаның кем икәнен бик ачык аңлатып бирде. Бу ике бертуган бер-берсенә торырлык булганнар икән.

Сүзгә сүз ялгана торгач, Гыйбад агай, кинәт күңеле җилкенеп киткән картларга хас бер кискен хәрәкәт белән, бер дәфтәр битенә үзенең эре хәрефле шома почеркы белән менә бу сүзләрне тезде дә чыкты:

«1919/20 — Үрге Мәкъсүттә
20/21 — Акманда
21/22 — Каскында
22/23 — Әүестәндә
23/24 — Ыуарыда
24/25, 25/26, 26/27, 27/28, 28/29, 29/30 уку елларын Етеболак Күгәрсенендә.
30/31 — ошо үзебеззең Мәкъсүттә, унан Йомагужала — 1931/32, 32/33 укуы йылдары,
33/34 — Сәетколда
34/35 — укуы йылыннан башлап Өфелә...»

Кызу-кызу шулай язды да, кәгазь битенең ак читенә «Хәлимә» дип өстәп, астына сызык сызып куйды...

Бераз тын утыргач, басынкы гына тавыш белән әйтте:

— Быйыл вафат булып куйды Хәлимәбез. РСФСРның атказанган укытусыһы ине. Ленин орденлы укытусы... — диде.

*
* *

Мәфтуха түти белән Сәмигулла җизни исәннәр.

Гәүһәр аларга, «әти-әни» дип, Күгәрченгә кайтып төшкәли. Җәйнең ямьле көннәрендә, җиләк-җимеш өлгергәндә. Ике улы егет булып килә. Берсе — биюче артист, икенчесе — хәрби хезмәттә. Мәфтуха түтинең оныклары...

Кышларын исә җизни белән түти: «Гәүһәр кызыбызга кунакка»,— дип, Уфага барып кайтканнар...

Ике хатын.

Икесе ике чор кешесе.

Икесе дә буыннан-буынга тапшырыла килгән кешелеклелек эстафетасын безгә бөтен көенчә, төгәл, кайнар көенчә китереп җиткергәннәр.

Болот Боотур,
якут язучысы

ПУШКИН ТАУЛАРЫ ИТӘГЕНДӘ

Сугышның дүртенче җәе. Менә өченче ай инде оборонада ятабыз. Безнең 826 нчы артиллерия полкы Сороть елгасының сул ягындагы наратлыкка урнашкан. Безнең артта — Новоржев, алдыбызда — Бөек елга. Аның ике як ярын да дошман биләгән.

Без — топограф-артиллеристлар. Бу тирәләргә килгәннең беренче көнендә үк топографик планшетларыбызның шакмакларына мәктәп елларыннан ук таныш исемнәр төште: Тригорское, Михайловское... Алар бездән авыр артиллерия белән атып алырлык кына ераклыкта. Күзәтү пунктыннан Пушкин тауларының ак йортларын күрергә мөмкин. Ә Святогорск монастыре безгә дошман өстенә ут ачу өчен — коточкыч хәл! — ориентир хезмәтен үти иде.

Бу җирләрне без март аенда алдык. Тирә-якта әле тирән кар ята, шагыйрь әйткәнчә, «Буря мглою небо кроет, вихри снежные крутя».

1944 елны Совет Армиясе дошманга ун тапкыр җимергеч удар ясады. Һәм иң беренче ударны Ленинград, Волхов һәм безнең 2 нче Балтик буе фронтлары гаскәрләре бирде. Безнең дивизия үзенең һөҗүмен февраль урталарында Иске Русса тирәләреннән башлады.

Дошманның коточкыч каршылыгын җиңеп, көнен дә, төнен дә сугышларны туктатмыйча, егерме биш тәүлеккә ике йөз илле километр юл үтте ул. Үз юлында уннарча шәһәрләрне, йөзләрчә торак пунктларын азат итте. Һәм менә шушы урман аланына килеп туктады. Без арыган, йончыган, пычранып беткән сугышчылар башта кыска ялга туктадык дип уйлаган идек. Көч җыябыз, яңа кораллар алабыз, өстәмә сугышчылар килә. Көн саен һөҗүмгә приказ көтәбез. Ә приказ юк та юк. Бер ай көтәбез... икенче ай...

Июнь ае җитте, «Светлые ручьи в кустарниках» күптән шаулап акты.

Озакка сузылган оборона солдат өчен нәкъ курорт кебек. Озакка сузылган походлар һәм кан коешлы сугышлардан соң бигрәк тә. Өч ай эчендә без позицияләребезне яхшылап ныгыттык, ышанычлы окоплар казыдык. Калын бүрәнәләр белән өчәр-дүртәр кат ябылган блиндажларда яшибез. Маскировка турында да кайгырттык. Тирә-

ягыбызда менә дигән тәртип, тыныч вакытның җәйге лагерьларындагы кебек. Хәтта парлы мунча да салдык. Үзебез тук, өс-баш җыйнак — регуляр армиянең батыр артиллеристлары. Бар нәрсә — орудие һәм автоматлар, котелок һәм кием төймәләре ялт итеп чистартканы, елык-елык итеп тора. Барыннан да бигрәк һөҗүм итеп килүче гаскәрнең сугышчыларына хас күңел күтәренкелеге, рухи ныклык бар иде бездә. Совинформбюро да көннән-көн шатлыклырак хәбәрләр китерә.

Төньяк боз океаныннан алып Кара диңгезгә кадәр җиңүче Совет гаскәрләренең һөҗүме бара. Әле кичә генә 1 нче Украина һәм Белоруссия фронтының өчесенең дә гаскәрләре һөҗүм башлавын хәбәр иткәннәр иде, бүген штаб писаре Михайлов килеп Витебск шәһәренең азат ителүен һәм фашистларның биш дивизиясе чолганышта калуын әйтте.

Хәзер безнең чират. Күпме торырга була инде? Без дә. бүген булмаса иртәгә кузгалырга тиешбез.

Полк һәм дивизия офицерлары белән бергә төрле рангтагы генераллар команда пунктларына һәм күзәтү ноктaларына юкка гына килгәләп йөрмиләрдер бит. Ул аларның җирле рекогносцировка ясаулары булырга тиеш.

Уйласаң шаккатарсың. Кайвакыт үзеңне сугышта түгел, ә ауга чыккандай хис итәсең. Сунарчы да бит уңышлы ау турында исенә төшерсә дәртләнеп китә, күп мәшәкатьләр, кыенлыклар кичерәсен белсә дә, барлык эшләрен алдан бетереп, юлга әзерләнә башлый. Соңгы вакытларда без дә шундыйрак бер хәл кичерә идек. Фашист оборонасын җимерүнең кыенлыкларын да беләбез, һәр метр җирнең кан коеп, күп корбаннар исәбенә яулап алыначагы да исебездә, шулай да сугышка ыргылабыз. Пушкин тауларын, Михайловскоены, Тригорскоены тизрәк азат итәсебез килә. Әгәр шунда «Алга!» дигән команда яңгыраса, бөтен солдат бер булып, «Ура!» кычкырып тыелгысыз атакага ташланыр иде.

Без инде сугыштан туеп беттек. Тизрәк аның бетүен телибез. Һәм бары тик җиңү белән генә тәмамлануын телибез. Ә җиңү турында аз гына да шигебез юк иде... Әгәр шунда үлеп калсаң?.. Ничектер үлем турында уйланылмады. Әзме күрдек без үлемне.

Көтеп тору белән тулы булган шундый көннәрнең берендә безне, топография взводы сугышчыларын, дивизион командиры Сергей Худоногов чакырып алды.

Чакырды да әйтте, алдыбызда торган дошман көчләре турында иң яңа мәгълүматлар бирерлек «тел» алып кайтырга генерал-майор үзе приказ биргән.

— Дивизия командирының приказын үтәү сезнең взводка тапшырыла, — диде майор һәм тәбәнәк буйлы, түгәрәк йөзле лейтенантыбыз Родинга мәгънәле итеп карап куйды.

Лейтенант кулын пилоткасына куйды да калын тавыш белән:

— Алып кайтырбыз! — диде һәм, әзерлегебезне тикшергәндәй, барыбызга да карап куйды.

— Операциягә взводыгыз белән бармассыз, билгеле, — диде майор, взвод командиры ярдәмчесе озын буйлы кара егет Макауга карап. — Ике кешене калдырырга кирәк. Сез, старшина, лейтенант урынында калырсыз. Тагын берәү... — дип, майор миңа карады.

Куркыныч һәм җаваплы эштән читләштерүдән дә зуррак хурлык юк солдат өчен. Миңа бик читен булып китте. Ләкин майор, ни өчендер елмаеп, карашын Певзнерга күчерде һәм:

— Сез калырсыз, — диде.

Мин җиңел сулап куйдым. Ә Певзнерга үпкәләп торырга да түгел: армиядә безгә караганда яңа кеше әле, барлыгы алты ай гына сугы-

ша, аннан соң тәбәнәк буйлы, бөкерерәк бу егет тышкы кыяфәте белән үк сугышчыга охшамаган, хәтта пилоткасы да шар шикелле түгәрәк башында белен кебек җәелеп ята.

Иртәнге аштан соң күнегүләр ясарга дип аланга киттек.

Безгә ярдәмгә полктан ике разведчик килде. Лысюк фамилияле пәһлеван егетне яратып та өлгергән идек. Ул кеше белән тиз аралаша, үзен бик иркен тота. Чын разведчиклар менә шулай булырга тиеш дип уйладык без. Икенчесен, кәкре борынлы Кавказ егетен, Аргун дип әйтәләр икән. Әллә исеме, әллә фамилиясе иде ул аның — белә алмадык. Ул да озын буйлы. Бөдрә чәчле бу сержант салкын карашлы кара күзләре белән кешегә төбәп карый һәм бик усал кебек күренә иде. Ә чынлыкта ул шаярырга ярата, үткен сүзле һәм гадәттән тыш итагатьле кеше булып чыкты.

Күнегүләр вакытында «фриц» итеп без элемтәче Иван Карасевны чакырдык. Безнекеләрнең олысыннан кечесенә кадәр аны Ваня агай дип йөртәләр иде.

Ул ике метр буйлы, киң җилкәле, повар Смотрицкийдән ашны ике өлеш күбрәк салдырып ала, ә дүрт бәйләм кабельне күтәреп йөрүне бернигә дә санамый.

Баштарак Лысюк белән Аргун җитез кыландылар. Ваня агай утырган снаряд чокырына шуышып килделәр дә икесе берьюлы аның өстенә ташландылар. Ваня агай кычкырырга һәм барлык көче белән алардан котылырга тиеш иде. Ләкин тәҗрибәле разведчиклар аңар эһ диярга дә ирек бирмәделәр, авызын томаладылар, кулларын каерып бәйләделәр дә урманга өстерәп киттеләр. Тора-бара Ваня агай разведчикларның алымнарын белеп бетерде, аны җиңел генә кулга төшереп булмый башлады, һөҗүм итүчеләрнең үзләрен дә күтәреп аткалады. Бервакыт разведчиклар һәм «фриц» ролен үтәүче шул кадәр мавыгып киттеләр, чын-чыннан бәргәләшә башладылар. Ә без, разведчикларга ярдәмгә киләсе кешеләр, дошманның борын төбендә үк торуыбызны да онытып, рәхәтләнеп көләргә тотындык. Ахырдан тәмам хәлдән тайган Ваня агай кулын селтәп китеп барды.

Төшке аштан соң лейтенант Родин, булачак операциянең планын билгеләргә дип, безне алгы сызыкка алып китте. Беренче ротаның траншеяларына килеп, нейтраль зонаны кичү өчен җайлы урын сайладык. Ике җирдәге күзәтү пунктыннан карап берничә ноктаны билгеләдек. Безнеңчә, алар дошманның окоплары һәм траншеялары булырга тиеш иде. Сиздермичә генә барып, шуннан «тел» алырга мөмкин дигән карарга килдек.

Оператив группаның юлын һәм төнге ориентирларны билгеләдек. Немецларның торган урынын аныклау өчен лейтенант минем белән Миша Ульяновка караңгы төшкәнче дошманның алгы сызыгын күзәтергә куштты.

Дивизион командиры майор Худоноговның команда пункты күзәтү өчен иң җайлы урын иде. Бу команда пункты урман авызындагы өч җәпле карт юкә агачының кәүсәләре арасында иде. Без агачка менәргә генә торганда укчы ротадан бер сугышчы йөгереп килде дә немец снайперының инде команда пунктына атканын һәм сак булырга кирәклеген әйтте. Шуннан соң без Миша белән икебез берьюлы агачка менсәк, дошманга күренеп торырбыз һәм фашист снайперына менә дигән мишень булырбыз дип уйлаштык. Чиратлап күзәтергә булдык. Снайпер ут ачса да, бер атудан ук тидерә алмас, күзәтче бер генә булганда агачтан төшәргә дә җайлырак булыр.

Агачка беренче булып Миша менде. Җирдән дүрт метр биек-

леккә ясалган урынга утырды, агач кәүсәсендә пуля эзләре таптым, диде һәм бинокль белән дошманны күзәтә башлады.

Акрын гына баеп барган кояш урман авызын, безнең карт юкә безне яктырта, ак чәчле Миша түбәннән җирән булып күренә. Ә минем хәзергә эшем юк. Плащ-палаткамны куе яшь нарат күләгәсендәге яшел үләнгә җәйдем дә чалкан яттым. Югарыда бөдрә болытлар йөзә. Бәлки кайдадыр яңгыр да явадыр. Кояш болыт астыннан чыкканда бик каты кыздыра башлый, үләннәрдән, чәчәк һәм агачлардан баш әйләндергеч хуш ис күтәрелә. Инде җәй уртасы булса да, үләннәр яшь әле, җете яшел.

Каядыр якында кош чырылдап куйды: «чырык-чырык». Иректән күтәрелеп карадым, тик бу кечкенә кошны тапмадым. Кинәт бик моңсу булып китте. Бала чактан таныш урыннар һәм кошлар сайрап торган сайылык-җәйләү исемә төште. Туган җирем Якутиядә дә хәзер җәй уртасы.

Андагы урманнарга барсаң иде хәзер, йомшак яшел ылыска төренгән яшь карагайларга сокланып йөрсәң иде! Кешенең йөрәгенә, җанына дәва булган хуш исне бер туйганчы иснәсәң иде. Авылымның саф каеннарын күз алдыма китердем... Ләкин ни бу?.. Якында гына пулемет тырылдады. Тиз-тиз генә атып алдылар да туктадылар. Алгы сызыктан ике генә чакрым ераклыкта торганда без мондый гына атышларга игътибар да итми идек. Ә хәзер миңа ни өчендер куркыныч булып китте...

Берничә минутка гына онытылып торып, еракта калган тыныч һәм бәхетле тормышны сагынганга шулай булгандыр бәлки. Ә монда үлем коралы тырылдап, куркыныч барын искә төшереп куйды.

Мин фронт тавышларына колак салып утырам. Сирәк-сирәк генә әле бер җирдән, әле икенче җирдән төрле калибрлы орудиелар ухылдап куя, пулеметлар һәм автоматлар аткалап тора, миномётлар чинап ала.

Нинди тиле гадәттер ул немецларның: көнен, төнен атып торалар, әллә үзләрен тынычландыру өчен, әллә без әле биредә куркып калмадык дип, исебезгә төшерү өчен шулай эшлиләр.

Ярым онытылып күзләремне кыскан көе бар тавышка колак салып ятам. Кайдадыр сул якта, бездән еракта, каты сугыш бара. Туктаусыз ату тавышларыннан җир зыңлап тора. Әйтерсең лә ул бөтенләй сугыш тавышы түгел, әйтерсең лә ул күпне күргән җирәнкәбезнең авыр сулавы, илереп ыңгырашуы. Ишетелер-ишетелмәс ату тавышлары торган саен көчәя бара, хәзер инде җиңел һәм эре калибрлы пушкаларның атуын аерып була. Димәк, артподготовка тәмамланды, атака башланды, инде артиллерия үз көенә атып, һөҗүмгә баручыларга булыша. Атыш я акрыная, я тоташ гөрелтегә әйләнеп тагы да көчәя.

Карт якутларның, ызгышып яшәгән борынгы заманнарда, бер-бере белән дошман кабиләләрнең барабаннар кагып, быргылар кычкыртып сугышка килүләре турында сөйләгәннәре искә төшә. Сугыш шаушуы һәм үлем! Бу минутта сугыш булган җирдә кемдер яраланып егыла, кемдер ыңгыраша, кычкыра. Йөзләрчә, меңнәрчә үлем... Ни өчен соң әле гел үлем турында гына уйланыла? Бүген төнлә үзем үлемгә каршы барасы булгангамы әллә?

Мишаның агачтан төшүе ишетелде.

— Василий, әнә теге янган әвеннең өч баганасыннан сулдарак, үзәндә миномётлар яшеренгән кебек. Алар тирәсендә фрицлар да йөри — башлары күренә. Ике йөз илле өч градуслы почмактан кара әле. Минем күзем талды.

Мин агачка мендем. Буссоль алдым да Миша биргән почмак белән үзәнне таптым. Беренче карашта шикләнерлек берни дә юк, тоташ

яшел үлән. Игътибар белән карагач, ниндидер карачкыл биеклекләр күрдем. Күземне алмыйча карыйм, хәрәкәтләнеп торучы ниндидер ноктала бер күренәләр, бер югалалар, әле бергә җыелалар, әле таралып китәләр. Һич шик юк — немецлар, ә мондый урында бары тик миномётларның гына торуы мөмкин.

Киңәшеп алгач, бу урынның координатларын билгеләп штабка хәбәр итәр өчен, Миша күзәтү пунктының икенчесенә китте. Мин дошманның алгы сызыгын күзәтеп калдым. Күзәтү пунктыннан торып алгы сызыкны күрү бәхете артиллеристларга сирәк эләгә. Безнең пехотаның траншеялары ачык күренә. Бүген төнлә без менә шуннан кузгалып китәчәкбез инде. Окопларда, аерым-аерым ояларда сугышчылар утыра, төсе уңган гимнастеркалары агарып күренә, кояшта каскалары ялтырый. Менә безнең позицияләрне дошманнан аерып торган нейтраль полоса — кайчандыр ул сукаланган булган, ләкин шул көе чәчелми калган — дүрт-биш йөз метрлы ялангач кыр. Анда бары тик чүп үләннәре үсә дә сирәк куаклыклар күренә. Кыр өстенә кышкы сугыш билгеләре — эреле-ваклы, тирәнле-сайлы снаряд чокырлары сибелгән. Аларның кайберләренә болганчык су тулган, кызыл балчыклы ярлары исә канлы җәрәхәтне хәтерләтә. Шушы сугыш елларында никадәр казылып, җәрәхәтләнеп беткән безнең җир-әнкәбез! Менә шуның өчен син авыр сулыйсың, ыңгырашасың икән.

Яшь урман арасындагы үзәндә безнең һәм немецларның янган танклары ята. Берәү... икәү... егерме өч ватык танк пушкаларын алга сузганнар да хәрәкәтсез калганнар. Әйтерсең лә казып табылган мамонт үләксәләре. Ә төньяктагы калкулыкта яндырылган авыл һәм хуторларның урыннары күренә. Кара кисәүгә әйләнгән баганалар белән ничектер җимерелми калган мич торбалары тырпаеп тора. Гыйбадәт кылгандай, ялкында көйгән башларын иеп ялгыз каеннар һәм корган тал агачлары утыра.

Көньяк-көнбатышка табарак урман артыннан күтәрелгән яшел калкулыкта ак ташлы берничә өй һәм чиркәү күренә. Святые таулары ул, хәзер бик хаклы рәвештә Пушкин таулары дип йөртелгән җир. Рус җиренең изге хисләрен саклаган урын. Баеп барган кояшның нурлары һәр совет кешесенең йөрәгенә якын булган Пушкин күмелгән Святогорск монастыренең алтын башларын яктырта.

Көзгедәй җемелдәгән бу күл буенда, шушы калкулыкта, шушы урман аланында кайчандыр бөек шагыйрь йөргән. Пушкин тарафыннан мәңгеләштерелгән бу җирләр менә йөз елдан артык инде халкыбызның күңелендә һәм йөрәгендә яши. Кинәт Пушкинның безгә алтынчы класстан ук таныш булган юллары күңелгә килә: «Луг, уставленный душистыми скирдами... где светлые ручьи в кустарниках шумят... двух озер лазурные равнины, где парус рыбаря белеет иногда, за ними ряд холмов и нивы полосаты, вдали рассыпаны хаты...» Әле беренче генә тапкыр күрелгән, әмма йөрәккә бала чактан ук якын булып калган җирләрне карап калырга тырышам, «балыкчы җилкәнен» һәм «буй-буй уҗым кырларын» күрергә теләгәндәй, бинокльне әле калкулыкка, әле күл өстенә юнәлтәм. Ләкин бу канлы елларда «сибелеп утырган өйләр», «канатлы тегермәннәр», «уйнап йөрүче көтүләр» ничек исән калсын, ди? Бүген биредә бар нәрсә икенче төрле — ямьсез булып каралып торган урман да, ташландык буш кырлар да, моңсуланып утырган калкулык та. Хәзер анда чит халыкның тавышы яңгырый, Пушкин җирләрен, димәк, синең дә җиреңне дагалы авыр итекләр таптый дип уйласаң, күңелгә бик кыен булып китә.

Ә бит күптән түгел, моннан өч ел элек кенә, биредә безнең бәхетле кешеләр яшәгән. Көләч йөзле колхоз кызлары шаян җырлар җырлагандыр. Бу кырларда ашлык диңгезе чайкалгандыр, тракторлар гөрләгәндер, ургыч машиналар кетертәгәндер. Калкулык өстендә «төтен-

ле әвеннәр», «канатлы тегермәннәр» урынына яңа авыллар утырган-дыр. Кичләрен аннан уйнап йөрүче балаларның тавышы, кызлар көлүе һәм, әлбәттә, егетләр кулындагы гармун моңнары ишетелгәндер.

Ә менә бүген, шушы минутта, үле тынлык, бер тавыш юк — тормыш барлыгын белдергән берни күрмәссең. Хәтта әле генә чыркылдаган кошчык та тынып калды. Күк йөзендә ник бер тургай, кырда бер чыпчык булсын. Барлык җан иясе бу җирләрне ташлап киткәндер, якут эпосы — олонходагы кара көчләр батыры булган сатана улының тәмугтан чыкканын көтеп торган баһадирдай канлы сугыш кырында бер үзем калганмындыр кебек тоелды. Әйе, чыннан да, бу шулай. Анда, басу түрендә, ярты лаш янган урман һәм калкулыклар артында теләсә кайсы минутта үлем уты сибәргә әзер торган явыз көчләр яшеренеп ята. Нейтраль полоса артында дини китаплардагы утлы сумала кайнап торган тәмуг түгел, ә чын тәмуг. Шул полосаны гына үтәргә кирәк, утлы өермәгә барасың да керәсең.

Уйга калсаң, гомернең үткәнен сизмисең дә икән. Таныш тавышлар да колакка керми.

— Ашыкмагыз. Немецларның күзенә кереп торуның кирәге юк.

Моны майор әйтә. Планшетын ачкан да картага карый. Аның янына лейтенант Родин килә. Ах-ух килеп Иван Карасев бушап калган катушкаларны җиргә ташлый. Элемтә юлының төзеклеген тикшерү өчен ул «туры бия»не чакыра. Атларын «студебеккерлар»га иң соңгылардан берсе булып алыштырган 2 нче гаубицалы батареяне без шулай дип йөртәбез. Элемтәне җайлагач Ваня агай телефон аппаратын миңа бирә, ә мин аны, күзәтченең кул астында булсын дип, юан ботакка элеп куям.

Мине алыштырган дивизион командиры агачка менеп, без күрсәткән урыннарны күзәтә башлый.

— Ипташ майор, сак булыгыз — команда пунктына немец снайперы аткан.

— Үзегез чакырып китердегез дә хәзер кисәтеп торасыз, — дип көлемсерәде майор.

— Артиллерия утын без үзебез дә юнәлткән булыр идек.

— Ой-ой! Батарея командиры итеп куяргамы әллә сезне?

— Маршал булырга хыялланмаган солдат — начар солдат.

— Ягез әле, наполеоннар — нинди почмак икәнен әйтегез, никтер тапкан ноктагызны күрмим.

— Ике йөз илле өч градус.

— Ә менә хәзер күренде. Чыннан да, нәрсәдер бар. Кешеләр дә кайнаша. Сиксән миллиметрлы батальон миномётлары булса кирәк. Аларны менә шундый җиргә генә куялар да. Әйдә, карап карыйк.— Майор телефон трубкасын алды да «туры бия»гә орудиене төбәргә кушты, координатларны әйтте. Орудие ата башлады.

Снарядларның кайда төшүен күрергә дип, без башка агачларга мендек. Беренче снаряд барып җитмәде, икенчесе узып китте. Бар да дөрес, димәк, майор аларны кысага алырга тели. Өченче һәм дүртенче снарядлар нәкъ дошманның өстенә барып төште. Майор батареяларга әзерләнеп торырга һәм барлык дүрт орудиедән да рәттән дүрт залп бирергә кушты.

— Огонь! — дип, майор әкрен генә телефон трубкасына кычкырды.

Ярты минуттан гаубицалар телгә килде — баш очыбыздан төн кошларыдай шыштырдап снарядлар очты. Ә берничә вакыттан соң немец миномётлары булырга тиеш урында кара фонтан күтәрелде.

Бинокль аша зур таш кантарлары һәм җимерелгән әйбер кисәкләренең һавага очуын күрдем.

— Тиде! Тиде! — дип кычкырдык без шатланып, — Тагын бир, туры бия. Тетмәләрен тет.

Барлык уналты снаряд та бер өемгә килеп төште, анда бер генә җан иясе дә калмагандыр, миномётларның да көле күккә очкандыр, мөгаен. Шәп эшлиләр артиллеристлар, берни әйтеп булмый, нәкъ өстенә төшерәләр.

— Я, топографлар, эшләрен бетердек, ахры. Разведчик кына булырлык сезгә, — ди майор утны туктаткач, аның бездән канәгать икәнен күзләре әйтеп тора иде.

Дивизион командиры Худоногов гомумән әйбәт кеше. Озын буйлы, төз гәүдәле. Башка офицерлардан аяк атлавы белән үк аерылып тора иде ул. Безгә аның бар җире ошый иде: биек ак маңгае, ягымлы зур күзләре, колакка ятышлы матур тавышы. Ул безгә Омск тирәсендә дивизия оешкан вакытта үк килгән иде. Ул чагында әле җитез генә яп-яшь лейтенант иде. Хәзер инде олыгаеп китте, җитдиләнде, дивизия оешкан көннән башлап хезмәт итүчеләргә аеруча хөрмәт белән карый, без дә аны яратабыз һәм ышанабыз.

Майорның бераз мәктәп куюы безгә чын бәйрәм китерде. Миша Ульянов шатлыктан нишләргә белми, хәзер барып майорны кочаклый дип торам. Минем дә Мишаның күңелен табасым килеп китте:

— Бу синең аркада, Миша. Дошманны беренче булып син күрдең.

Миша елмаеп мине кочып алды. Ләкин фронтта хисләребезне тыярга өйрәнгән идек инде. Бу юлы да, кызлар кебек хискә бирелүебездән оялып булса кирәк, бер-беребез белән көрәшкән булып кыландык.

Атыш нәтиҗәләрен тагын да яхшырак күрү өчен булса кирәк, майор биноклен күзеннән бик озак алмады. Кинәт ике пуля: берсе яннан сызгырып үтте, икенчесе агачка килеп керде.

— Төшегез, иптәш майор! — дип, икебез берьюлы кычкырып җибәрдек.

Ә майор телефон аппаратына үрелде, ләкин тиз генә ала алмады, шул вакыт пуля тиеп телефон аппараты ярылды. Майор курку хисен сиздермәде, йөзе генә кызарып китте һәм тиз генә агачтан төште.

— Әйдәгез, киттек,— диде ул.

Без урманга кереп киттек.

Юлда исемә төште: «Ваня агай кайда калды соң?» Кире йөгердем. Күрәм, ботактан телефон аппаратын алырга теләп, тыныч кына кулын суза. Аппарат төшми, селкенеп кенә тора. Ваня агайның ватык аппаратны алмыйча тынычланмаячагын беләм. Күп уйлап тормас, агачка да менеп китүе бар. Бу алып гәүдәне немец снайперы хәзер бәреп төшерер. Агачка тиз генә үзем менеп киттем. Шул вакыт майорның кырыс һәм боеручан тавышы ишетелде:

— Син нәрсә, акылдан яздыңмы әллә? Пуля тисен дисеңме... Төш тизрәк!

Ваня агай белән без урманга кергәч кенә үзебезнекеләрне куып җиттек. Майор бармагын чигә турында әйләндергәләп алды да ачуланып Ваня агайга дәште.

— Вакытын белергә кирәк. Менә караңгы төшсен, таң атканчы маташ, кабелең дә чолгарсың, аппаратны да алырсың.

Майор 2 нче батареяга китте. Ләкин бу вакытта немецлар тар-мар ителгән миномётлары өчен үч алырга теләделәр булса кирәк, ут ачтылар. Батарея тирәсендә уннарча снаряд ярылды. Ләкин без килеп җитүгә барысының да исән-сау икәнен күрдек. Кухня янында ярылган бер снаряд кыйпылчыгы гына ботка пешеп торган казанны тишкән иде. Дивизион командиры батареяны тезергә кушты, дошманның ут ноктасын юкка чыгарган артиллеристларны тәбрик итте һәм беренче орудие расчетына рәхмәт белдерде.

Кичке аштан соң блиндажга җыелдык. Ни өчендер сөйләшүче булмады. Мин алдагы төн турында уйламаска тырышып ятам.

Андрей Минин хат яза, егетнең борчылуы күренеп тора. Миша автоматын сүтеп тазартты, бүген иртән алган гранаталарын карап куйды. Аннары фин пычагын алып, бармагын йөзенә тидереп карады, кулына җайлабрак тотты да дошманга кадаган кебек итеп бер-ике селтәнеп алды, гомумән ул үзен бик кырыс һәм сугышчан итеп тота иде.

Кичке сәгать уннарга, сугыш коралларыбызны алып, штаб блиндажы янында сафка бастык. Майор Худоногов Миша белән мине сафтан чакырып алды да:

— Дошманның иң куркыныч ут ноктасын табып, аны тар-мар итүдә булышканнары өчен сержант Михаил Ульянов белән сержант Василий Соловьевка дивизион буенча рәхмәт белдерелә, — диде.

— Советлар Союзына хезмәт итәбез!

Ләкин җавабыбыз ни өчендер таркау һәм әкрен ишетелде. Саф алдында дивизион штабы начальнигы капитан Кузнецов күренде. Кечкенә буйлы бу арык кеше һич кенә дә командирга охшамый иде. Тавышы да картларча, өйдә сөйләшкәндәгечә артык төссез иде.

— Егетләр, сезгә бик мөһим һәм авыр задание үтәргә туры киләчәк. Без шикләнмибез: үзегезне дә хурлыкка калдырмассыз, командованиене дә җайсыз хәлгә куймассыз. Операциянең барышы белән дивизия дә, полк та һәм, билгеле, без дә кызыксынып торырбыз. Уңышлы юл телим сезгә.

Кемдер рәхмәт әйтте. Ә капитан безнең лейтенантның кулын кысты.

Бу күренешләр барысы да бик гади килеп чыкты, хәрбиләрчә булмады. Бәлки шуның өчендер капитанның хәерле теләкләр белән озатып калуына күңелебез булды. Шундый җаваплы заданиегә башка берәүне дә түгел, ә безне җибәрүләренә эчтән генә горурлана да идек.

Майор Худоногов безне 1 нче ротаның команда пунктына кадәр озата килде, юлда операция планын тагын бер кат исебезгә төшерде, без китә башлагач, «тел»сез кайтмагыз, дип артыбыздан кычкырып калды.

Траншеяларның берсенә җыелып билгеләнгән сәгатьне көтә башладык. Дошманның алгы сызыгыннан күзебезне алмыйбыз. Бар кешенең дә төнге фронт картинасын күргәне юктыр әле. Тирә-якны якты, ләкин салкын яктылык белән ялтыратып әледән-әле ракеталар оча. Алар сибелеп китәләр дә сүнәләр, фронт линиясен күрсәтеп тагын кабыналар. Немецлар чит җирнең караңгы төненнән куркалар, шуңа күрә ракеталар җибәреп, туктаусыз ут ачып үзләрен тынычландыралар булса кирәк. Төн карасын утлы пулялар телеп тора. Майланмаган иске тегү машинасы кебек тончыга-тончыга, пулеметлар ата, аларга автоматлар кушыла. Соңгы вакытта алҗып калган немец солдатларының сугышчан рухын күтәрү өчен бу атышлар шулай тәртипсез бара.

Күкнең көньяк ягында ерактагы пожар яктысы — чигенеп барган фашистлар авылларны, шәһәрләрне яндыралар.

— Яңгыр башланырга тора, ахры, — диде Лысюк, канәгатьлек белән.

— Әйе, яңгыр яуса, шәп булыр иде, — дип, Аргун да аның сүзен җөпләде.

— Немецларның яңгырдан берәр җиргә кереп качуы бар, — дип куйды безнең лейтенант.

— Юк, немец солдаты — тәртипкә буйсына торган, — диде Лысюк. — Куйган җирдән китми ул. Баштанаяк төренә дә басып тик тора — янына килеп җиткәнче ишетми дә, күрми дә ул сине.

Аларның сөйләшүенә колак салгач, мин бөтен күңелем белән яңгыр булуын теләдем. Ләкин ул, үч иткәндәй, сибәләвеннән туктады.

Лейтенант сәгатькә карады.

— Вакыт, дуслар! — диде ул һәм беренче булып траншеядан сикереп чыкты.

Алдан тәҗрибәле разведчик — саперлар Лысюк белән Аргун бара. Алардан соң лейтенант һәм Миша белән мин. Ә безнең арттан Андрей Минин һәм тагын ике солдат.

Нейтраль зонадан бераз гына иелеп бер-бер артлы үттек. Сакланып кына бардык. Мин үземнең тын алудан да тыелып атлавымны сиздем. Коралымны чытырдатып кысып тоткандым. Йөрәгем дөп-дөп тибә, аның тавышы колакка бәрә. Ә менә курку дигән нәрсәне сизмим. Әллә инде алдан таза гәүдәле разведчиклар барганга шулай, әллә төн караңгылыгы тынычландыра. Ул минутта бер генә теләгем бар иде: тизрәк дошманның алгы сызыгына барып җитәргә дә начар гына булса да бер фашны эләктереп, тавышсыз гына алып китәргә. Ләкин немецны окоптан алуыбызга күңелем белән ышанмый идем: аның без уйлаган җирдә утырмавы да бар бит әле. Тагын ауга чыккан вакыттагы кебек: җәнлекнең эзенә дә төшкән кебек буласың, ә бәхеткә ышанмыйсың — төрле хәлнең булуы мөмкин.

Ике йөз илле метрлап юл үткәч, җиргә яттык. Лысюк белән Аргун алга узып киттеләр дә караңгыга кереп югалдылар. Аларның әйләнеп кайтуын озак көтәргә туры килде. Каты гына яңгыр явып китте. Ләкин ул ялангач җир өстен һәм үләннәрне чылатты да туктады. Юеш көе хәрәкәтсез ятып бик туңдык. Немецлар ягыннан тонык кына тавышлар ишетелеп киткәли: тимергә тимер бәргән кебек тә, җиргә казык каккан кебек тә була. Игътибар белән тыңлагач кына төшендек: немецлар утын кисә, шул вакыт бер-берсенә кычкыргалап ала икән.

Берәр сәгатьтән Аргун кайтты:

— Сволочьлар, тезеп куйганнар шунда җыен юк-барны — миналардан әрчергә туры килде, — диде ул. Алга таба киттек. Җир тайгак. Корсакка, терсәкләргә, тез башларына балчык ябыша. Туктыйбыз. Як-якка каранабыз. Ә күк йөзендә әледән-әле ракеталар кабына, алар сүнгәнче хәрәкәтсез ятарга туры килә.

Бер урында Лысюк белән Аргун бигрәк озак яттылар. Йомгак күк бөтәрләнеп тын гына яттылар да кинәт мәче кебек сикерделәр. Шунда ук кире борылдылар. Димәк, окопта немецлар булмаган. Кызганыч!..

Тагын әкрен генә шуышып барабыз. Ярдәмгә килергә тиеш группа ун-унбиш метр сулданрак бара. Көтмәгәндә генә немецлар ягында хәрәкәт башланды. Анда да, монда да кычкырып сөйләшәләр. Без кичә аткан җирдә тимер шыкырдавы, көрәк тавышлары ишетелә. Ватык минометларны икенче җиргә күчерәләр, ахры.

Сизеп торасың, немецлар янәшә генә, хәтта аларның тын алулары да сиңа бәрелгән кебек. Ләкин биек үлән арасыннан берни күреп булмый. Минут үткән саен борчу арта бара. Лысюк белән Аргун җиргә сыенып әкрен-әкрен генә алга уза. Шул вакытны бездән ун адымнар ераклыкта ике немец сөйләшеп тора. Күбрәк берсе сөйләшә. Тавышы карлыккан, сүзләрен бик ачык әйтә. Әгәр без аларның телләрен белсәк, ни турында сөйләшүләрен аңламый калмас идек.

Яныбызда кинәт кенә нәрсәдер чытырдап куйды һәм күккә яктырткыч ракета очты. Беттек, безне күрделәр дип йөрәк кысылып куйды. Куркудан һәм каушаудан бер генә минутка югалып калдым. Ләкин ул-бу булмады. Ракета сүнде, тагын караңгылык чолгап алды. Тынычланып артыма борылган идем — чынлап торып куркуга төштем, күкнең көнбатыш ягы агарып килә. Димәк, озакламый таң атар, анда инде безнең үзебезне эләктереп алырлар. Биш метр читтә яткан лейтенант янына шуышып килдем дә артка таба күрсәттем. Ул да аптырап калды булса кирәк, әле яктылыкка, әле егетләргә карап торды да шуышып барып разведчикларны ашыктырырга кушты. Куркы-

ныч барын да онытып, терсәкләрем һәм тезләрем белән кызу-кызу шуышып тиз генә разведчиклар янына килдем һәм лейтенантның ашыгырга дигән приказын җиткердем.

Лысюк белән Аргун шунда ук сөйләшкән тавышлар ишетелгән якка киттеләр. Ә Миша белән без сикереп ярдәмгә төшәргә, кирәк булса ут ачарга әзерләнеп урыныбызда калдык, хәтта пычакларыбызны да әзерләп куйдык. Хәл кылгыч минутлар җитте. Борчылып көнчыгышка карыйбыз: андагы аклык күзгә күренеп зурая, бер кырыйдан алсулана да башлады. Безнең тирәдәге калкулыклар торган саен ачыграк беленә. Алдыбызда биш-алты адым гына ераклыкта дошман траншеясының чите күренә. Лысюк белән Аргун тагын хәрәкәтсез калды. Сикерергә хәзерләнәләр иде булса кирәк. Тагын баш очында ракета кабына. Шул вакыт куркынган яңгыравыклы тавыш:

— Стефан! Халло! — дип куя.

Ракета сүнгәннән соң куерган караңгылыкта разведчикларның кая китеп югалуын күрми калдым. Дәшми генә алышкан тавышларны, кешеләрнең авыр сулавын, ниндидер йомшак нәрсәгә сугуны гына ишеттем. Кемдер авыр итеп ухылдап куйды. Яткан урыннан кубып егетләргә ярдәмгә ташланасы килеп китте. Немецлар аңнарына килеп ата башламаса, үзеңнең кайда икәнеңне сиздермәскә, дигән приказ гына тотып торды. Кинәт мин үзебезнең егетләрнең немец окобыннан сикереп чыгуларын, одеалга төргән әйбер кебек ниндидер озын һәм кара бер нәрсәне өстерәп килүләрен күрдем. Тагын шул ук яңгыравыклы куркынган тавыш ишетелде:

— Стефан! Халло, Стефан!

Немец тагын нидер кычкырды, әмма аның өзек-өзек сүзләреннән мин бары тик «Сигнал!» дигәнен генә аңладым.

Чытырдап кызыл ракеталар күтәрелде. Ялгыз винтовка тавышлары ишетелде. Үзебезнекеләрнең шактый ерак чигенгәннәрен күргәч, Миша белән мин лейтенант янына килдек. Артыбыздан пулемет бәрергә тотынды. Унбиш-егерме минут йөгереп үттек тә, разведчикларга ераграк китәргә мөмкинлек бирү өчен, җиргә ятып, пулемет бәргән якка автоматлардан ата башладык. Аннары тагын торып йөгердек.

Ракеталар берсе арты берсе кабынып торды. Көн уртасындагы кебек якты булып китте. Аргун белән Лысюк «тел»не күтәреп йөгерәләр иде инде. Кинәт кенә лейтенант:

— Ятарга! — дип команда бирде.

Аны-моны уйлап тормыйча, җиргә капландым. Янымда гына мәче кебек чыелдап миналар ярылырга тотынды. Осколкалар сызгырды. Атыш әзрәк тына төшүгә бөтенебез берьюлы сикереп тордык та тагын йөгереп киттек. Тагын җиргә сыенып яттык. Өстебезгә снарядлар шартлавыннан күтәрелгән җир кантарлары, ташлар яуды.

— Торыгыз! — дип команда бирде лейтенант.— Йөгерергә! Кызурак!

Артыбызда ниләр булуын да күрмичә, бар көчебезгә йөгерәбез.

Окоплардан пехотачылар йөгереп чыгып каршыбызга килә башлагач кына айнып киттек.

Хәрби задание үтәлде һәм иптәшләребезнең барсы да исән дигән уйдан әйтеп бетмәс зур шатлык кичергән минутыбыз булды, ахры, ул.

«Безнең батарея сугышчылары»
дигән китаптан.

xxxxxxxxxxxxxx

Габдрахман Әпсәләмов

ФРОНТ ГАЗЕТАЛАРЫ РЕДАКЦИЯСЕНДӘ

1967 елда мин «Җилкапканы ачканда» дигән автобиографик характердагы бер нәрсә яздым. Анда бала чак һәм яшьлек истәлекләрем, фронт көндәлекләре тупланган. Балалык чоры истәлекләре, кыскартып, «Ялкын» журналында басылды (1971 ел). Фронт көндәлекләреннән кыска бер өзек «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында басылган иде (1942 ел). Истәлекләр, көндәлекләр һәм язмалар барысы бер сорауга — мин ничек яза башладым дигән сорауга җавап рәвешендә бирелгәннәр. Хәзер шул язмаларның соңгы өлешеннән укучыларга бер өзек тәкъдим итәм.

Шулай итеп, көндәлекләр генә түгел, минем эчке тормышымдагы ниндидер күзгә күренми торган түгәрәк тә төгәлләнә иде. Карелия урманнарында сугыш утларына кереп, иҗатыма җитешмәгән нәрсәне таптым бугай. Дөрес, сугыш әле бетмәгән, давыллар, өермәләр уйный, ләкин мин иҗат киләчәгемне ышанычлы күрәм, нәрсә турында язарга кирәген беләм. Үзенең эчке драматизмы белән өзлексез сугыш хәлләре кебек үк киеренке булса да, иҗат юлы мине куркытмый, мин бернигә карамастан, берни белән исәпләшмәстән, ул юлга басачакмын, чынлыкта күптән басканмын, тик миңа канатланыр өчен тормышны һәм кешеләрне белү генә җитешмәгән. Хәзер шуның мәгънәсен тирәнтен аңлыйм кебек. Әгәр әйтергә яраса, Карелия урманнарында тормыш мәктәбен үтеп, язучылыкка имтихан тоттым шикелле. Алда җиң сызганып эшлисе калды. Билгеле, йокысыз төннәрне, меңгазап белән тулы иҗади эзләнүләрне, эчке шикләнүләрне дә алда күрәм. Ләкин алар иҗат кешесе өчен табигый нәрсәләр, алар кулны бәйләми.

Сугыш һәм тормыш, үлем һәм яшәү, тыныч хезмәттән башканы уйламаган миллионлаган кешеләрнең кулга корал тотып, социалистик илне сакларга басуы, утка керүе, тиңдәше күрелмәгән батырлык, фидакарьлек күрсәтүе, үлемне җиңүе... Бу турыда сугыш кырында, окопларда, әлбәттә, күп уйланылган, ләкин тагын һәм тагын уйларга, тирән эчке мәгънәләрен төшенергә кирәк. Вакыйгаларга гади катнашучы буларак уйлануларың — бер, язучы буларак гомумиләштереп уйлануларың — икенче. Билгеле, моның өчен вакыт һәм мөмкинлек кирәк. Бәхеткә каршы, андый мөмкинлек миңа сугыш бетмәс борын ук туды, мин «Ватан өчен сугышка» газетасына күчеп эшли башладым. Монда мин үзем өчен яңа горизонт ачылганын күрдем. Элек үз отделениемне, үз взводымны, үз ротамны, ахыр килеп, үз батальонымны белсәм, хәзер минем алдымда — бөтен бер фронт, гаҗәп күп төрле сугышчылар һәм офицерлар, кешеләр язмышы, фронт белән тылның аерылмас бердәмлеге. Элек Татарстан бик ерак калган иде сыман, хәзер атна саен аннан төрле хәбәрләр алып торабыз.

Редакция кешеләре редакциядә генә утырмыйлар, әле берсе, әле икенчесе алгы частьларга чыгып керә. Тора-бара мондый командировкаларга беркадәр күнегәсең, газета өчен кызыклы хәбәрләр алып кайтасың, шуңа канәгать буласың. Баштарак

Габдрахман Әпсәләмов. Ул 1941 елның августында фронтка китә. Башта Карелия фронтының 67 нче диңгез бригадасы составында миномет расчеты командиры буларак дошманга каршы сугыша. Аннары (1943 елның җәеннән 1945 елның маена кадәр) шул ук фронтта чыга торган «Ватан өчен сугышка» газетасының җаваплы секретаре булып хезмәт итә. 1945 елның җәеннән 1946 елның апреленә кадәр Ерак Көнчыгышта шулай ук фронт газетасы редакциясендә эшли. Өлкән лейтенант чинында хәрби хезмәттән азат ителә.

һәр командировка минем офыгымны киңәйтә барды сыман, уйларымны җитезләтте кебек. Мин тирә-юнемә отделение командиры күзләре белән түгел, хәбәрче күзләре белән карый башладым. Уйларым да киңрәк һәм тирәнрәк ерганактан ага башлады кебек. Икенче төрле әйткәндә, миндә язучы фикерләве уяна иде. Күп нәрсәне чагыштырасың, кыюсыз гына булса да, гомумиләштерәсең дә. Шулай да канатланыр өчен әле күп нәрсә җитми иде. Ләкин нәрсә җитмәвен үзең дә яхшы белмисең.

Редакциядә көндәлек язмадым. Үлем куркынычы турыдан-туры янамагач, сугышчан иптәшләрдән дә аерылгач, көндәлек язган булып маташу ничектер уңайсыз булып китте, көндәлекнең эчке мәгънәсе югалды кебек. Хәзер, әлбәттә, үкенәм, редакция тормышының кабатланмас үзенчәлекле яклары үткәннәр дә киткәннәр, аларны инде, көндәлекләрне укыган кебек, гади генә иттереп күздән кичерә алмыйсың. Нигәдер иптәшләр дә редакция тормышы турында язмадылар. Шулай бик үзенчәлекле һәм үзенә күрә батыр тормыш эзсез югалырмы икән? Кайчагында башыма икенче төрле уйлар килеп китә: әгәр язучы иптәшләр минем көндәлекләргә игътибарлырак булган булсалар, мине бераз дәртләндерсәләр, мин, мөгаен, ул көндәлекләрне редакциядә дә дәвам иттергән булыр идем. Тәҗрибәле иптәшләр алга, ераккарак карарга тиешләр иде кебек. Минем үземнең моңа акылым җитмәгән. Гази Кашшаф, Афзал Шамов иптәшләрнең «яз» дигән сүзләре дә, күрәсең, азрак булган, мин башкаларның «киңәшләренә» күбрәк колак салганмын. Хәер, гаепне кемнәргәдер сылтау — иң җиңел юл, ләкин иң зур гаеп минем үземдә. Мин язмаганмын. Хәзер үкенсәң дә — терсәкне тешләп булмый. Бу хатаны инде яшь иптәшләр генә кабатламасын иде. Көндәлекләр — язучының киләчәк эше өчен бик кирәк нәрсә.

Мин килер алдыннан редакциядә зур үзгәрешләр булган. Элекке редактор урынбасары Александр Герасимов белән хәбәрче Минһаҗ Җамалиев резервка күчеп киткәннәр. Соңыннан Герасимовның Кенигсберг өчен барган сугышларда батырларча һәлак булганлыгын ишетеп бик кайгырыштык. Җамалиев турында бернәрсә дә ишетелмәде. Сугыштан соң да тавыш-тыны чыкмады. Хәер, ул Татарстанныкы түгел иде шул.

Майор Бари Корбановны редактор урынбасары итеп билгеләделәр (редактор булып рус газетасы редакторы санала иде). Хәбәрче булып Политуправлениедән бик булдыклы һәм гаять кешелекле өлкән лейтенант Мөхәммәтша Сабельев килде. Каюм Иманкулов әүвәлгечә корректор булып калды, мин редакциянең җаваплы секретаре итеп билгеләндем.

Безнең кечкенә генә коллектив бик тату яшәде, бердәм эшләде. Аннан соң бик күп еллар үтсә дә, мин Беломорск шәһәре читендә, Ак диңгез ярындагы ике катлы агач йортларда урнашкан редакциябезне һич онытасым юк. Беренче катта бер бүлмә, тәрәзә каршында бер-берсенә терәп куелган ике язу өстәле. Өстәлләр тирәсендә Бари абый, Мөхәммәтша, Каюм һәм мин утырабыз. Урам як стена һәм тәрәзә буенда, баш-башка, Бари абый белән Каюмның, мич буенда Мөхәммәтшаның караваты, каршы як стена буенда минем ятак. Бари абый Корбанов гражданкада да газетчы булып эшләгән («Кызыл Татарстан»да), соңыннан, армиягә алынгач, атаклы Казан дивизиясе газетасының редакторы булган (рус телендә), аннары безнең фронт редакциясенә күчерелгән. Мөхәммәтша Сабельев элек Зеленодольск шәһәрендә финанс органнарында эшләгән, газета эшендә тәҗрибәсе юк, ләкин табигате белән чын журналист, кирәк материалны таш астыннан булса да таба белә. Шул бетмәс-төкәнмәс тырышлыгы өчен без аны барыбыз да ярата идек. Һәр командировкасыннан ул шул хәтле күп һәм кызыклы материал алып кайта, без хәтта барысын газетага урнаштырып та бетерә алмыйбыз. Хәтеремдә, бер чыгуында ул шундый хәлгә очраган: алгы кырыйдагы бер подразделениедә кунган вакытында тревога куба, ике яктан да көчле атыш башлана. Мина кырында кемнәрдер йөри, шартлаулар ишетелә. Караңгыда анда ниндидер карачкы гына күренә. Аңа төзәп аталар, ә иртән барысы ачыклана: мина кырына аю кергән икән, тонге атышның сәбәпчесе шул булган. Соңыннан Мөхәммәтша аю ите ашаганлыгын да сөйләде...

Элекке укытучы Каюм Иманкуловның төп эше — корректорлык. Ләкин ул моның белән генә чикләнмәде, башта тәрҗемә итте, вак-төяк хәбәрләр язгалады, ә ахырда хәбәрче булды. Без хәтта көлә идек: әрмәннәр аны әрмән дип, кавказ халыклары кавказлы дип, еврейләр еврей дип, татарлар татар дип кабул итәләр иде. Борыны кылыч, йөзе кара тутлы, күзләре урман чикләвеге төсле карасу-саргылт, тик буе гына тәбәнәк. Без аңа, сөеп-яратып, Яманкулов ди торган идек. Сугыштан кайткач ул яңадан үзенең Бәрәңгесенә (Мари республикасы) китте, башта балалар укытты, аннары район газетасының редакторы булды. Кызганычка каршы, күп тә үтмичә, аның гомере фаҗигале төстә өзелде: мотоциклдан егылып вафат булды.

Мин многотиражкада, бигрәк тә «Совет әдәбияты» журналында эшләп журналистика буенча беркадәр тәҗрибә туплаган идем. Ләкин чын-чыннан журналистика мәктәбен фронт газетасында үттем. Газета эшенең ашыгычлыгы, материалның көненә генә түгел, сәгатенә кирәк булуы — мине тиз һәм кыю эшләргә өйрәтте. Мин уйлыйм, газета мәктәбен үтмәгән кешегә язучы булу бик кыендыр. Хикмәт бит, ахыр килеп, тиз язуда гына түгел, хикмәт бик тиз ориентацияләнә белүдә. Бу берникадәр урманда азимут белән йөрүгә охшый. Барасың, барасың, бер таныш сукмак очрамый, тирә-ягың адәм аяк басмаган чытырманлы кара урман, син бары тик азимутыңны гына беләсең. Газета эше дә нәкъ шуның шикелле. Әгәр «азимутың» — ягъни политик сизгерлегең дөрес булмаса, бик тиз «югалып», буталып калуың мөмкин. Мин, билгеле, өлкән иптәшләрдән — Бари абыйдан һәм рус журналистларыннан күп нәрсәгә өйрәндем. Аларның акыллы киңәшләре, барыннан да бигрәк иҗади үрнәкләре миңа күп ярдәм итте. Озаклап, тәфсилләп торырга бераүнең дә вакыты юк иде, барысын да эш арасында, ярты сүздән отарга кирәк. Миңа беркем кат-кат кисәтмәде, ләкин өлкән иптәшләрнең эш тәҗрибәсе — бөтен бер мәктәп иде. Мин менә шул телдән әйтелмәгән сүзләргә колак салырга өйрәнүемә әле дә шатланып бетә алмыйм, чөнки бу минем журналистлык эшемә генә түгел, иҗат эшемә дә бик зур ярдәм итте һәм хәзер дә итеп килә.

Еш кына теге яки бу иптәш синең газетада басылган мәкаләңне, хикәяңне укыган була, берничә җылы сүз әйтә. Синең түбән күккә тия. Аннары, фәлән солдатның яки сержантның мәкаләсен син эшкәртмәдеңме, дип сорый. Ул мәкаләдә кадерле энҗеләр сакланган икән. Син булсаң, күңел тагын да горурланып куя. Дөрес, бу турыда бераүгә дә әйтмисең, ләкин эчке сөенүгә тиң нәрсә бармы соң! Кеше әй-

берендәге (еш кына бөтенләй грамотасыз хатларда) энҗеләрне күрә һәм саклый белү, кирәк икән, шуны калку итеп күрсәтү — газетачы өчен бик мөһим бит.

Әдәби эш белән газета эшен мин бервакытта да кызыл сызык сызып аерып куймадым. Газета өчен язылган төрле мәкаләләр, кыска очерклар, сызмалар кай яклары беләндер минем хикәяләремдә дәвам итәләр иде. «Хикәя» дигәч, кайчакта күпләр, язучылар барысын уйлап чыгаралар, дип уйлыйлар. Бу бик үк дөрес түгел. Мәсәлән, мин хикәяләрем өчен материалны һәр вакыт тормыштан алдым, бары тик гомумиләштергәндә һәм исемнәр сайлаганда гына фантазиямә юл куйдым. Гомумиләштермәсәң, хикәя бер хәбәр булып кала һәм аның гомере бик кыска була. Азмыни бездә бер көнлек хикәяләр. Гомумиләштерү өчен исә заманны тою, тормышны белү, киң күләмдә аңлау кирәк. Әлбәттә, хикәя һәм гомумән сәнгать әйбере корыдеядән генә тормый. Чын сәнгать әсәрендә тирән эчтәлек, идея камиллеге сәнгатьчә эшләнештән бервакытта да аерылмый. Гомумән, шушы нәрсә чак кына бозылса да, сәнгать әсәренең сәнгать әсәре булуы бетә.

Фронт шартларында моңа ирешү кыен иде. Озаклап утырып эшләргә вакыт та, урын да, кәгазь дә юк. Хикәя тулысынча башта чарлана. Әллә үлем куркынычы һәр вакыт янда йөргәнгәме, урмандагы һәр агач артыннан автомат яңгыравын сагаеп көткәнгәме, фикер дә ничөктер үткен һәм житез эшли иде. Аннары мин шуңа күнегеп киттем. Ижатка тотыну нәкъ сугышка керү кебек, бөтен нервлар ахыр чиккәчә киеренке, сулыш ешайган, күзләр кысыла төшкән, акыл гажәп өлгер. Бар җиһан онытыла, бары тик максатың гына төньяк йолдызы кебек балкый. Билгеле, вакыт-вакыт ул югала, кара, калын болытлар астына керә, син караңгыда буталып бетәсең, дөрес юлны тапканчы жан тирләрең чыга. Аның каравы, тапсаң, шатлыгы ни тора! Ихтимал, шуңа күрә дә ижат шатлыгын бар шатлыкларның да тажы дип әйтә торганнардыр инде.

Шулай да ул хәтәр елларда безнең ише әле яңа гына борын төртә башлаган яшь язучыларга беренче планда ижат мәсьәләләре тормый иде. Без — сугышчылар идек, ә сугышчының беренче эше — жиңүне тәэмин итү. Без һәрберебез үзенә билгеләнгән өлкәдә шуны башкардык. Ничек кенә булса да сугышчылар газетасын сугышчан итәргә тырыштык. Шуңа без бөтен көчебезне, бөтен сәләтебезне бирдек. Башта ук газетаны редакция кешеләре кулы белән генә чыгарудан баш тарттык. Газета массовый булырга, беренче чиратта, анда сугышчылар катнашырга тиеш. Газета дубляж булганда моңа ирешеп булмый. Без дубляжны кире кактык, командование дә дубляжга ябышып ятмады.

Татар газетасы, гомуми юнәлештә рус газетасыннан аз гына да аерылмаган хәлдә, татар сугышчыларының йөрәгенә үтеп керә алырлык үз материалларын номер саен биреп барырга, газетаның үз активын, үз укучыларын тупларга тиеш. Үзгәрүчән фронт тормышында шунсыз файдалы эш эшләве мөмкин түгел. Газета һәр сугышчының ышанычлы иптәше, сердәше, киңәшчесе. Аның сизгер жаны бар, ул сулыша, кайнар йөрәге тибә. Бары тик шуны тоеп, аңлап, фидакарьләрчә эшләгәндә генә уңышка ирешергә мөмкин. Без шулай эшләргә тырыштык. Фронт хәлләре турында гына түгел, тылдагы тормыш турында да кызыклы хәбәрләр, хатлар, рәсемнәр булсын дидек. Жырны да, мәзәкләрне дә онытырга ярамый, солдатның елмаясы, көләсе килә.

Газетабыз номердан-номерга тулылана, яхшыра барды, аның журналист кадрлары үсте. Без башка фронтлар белән газеталар алмаша башладык. Башкаларныкы белән үзеңнең газетаңны чагыштыру файдалы. Әйтүе ансат, һәр фронтта диярлек татарча кызылармеец газетасы чыгып килә, һәммәсе үз өстенә төшкән катлаулы һәм авыр бурычны намус белән үтәп бара. Ул газеталарда байтак язучылар эшли, мин аларның ижатлары белән дә танышып өлгердем. (Сугыштан кайткач, «Фронт газеталары» исемле информацион характердагы бер мәкалә язган идем. Кызыксынучы иптәшләр булса, шул мәкаләгә күз салсыннар. «Совет әдәбияты» журналы, № 5, 1947 ел.)

Редакциядә жаваплы секретарь вазифасын югары чиндагы офицер башкарырга тиеш. Мин исә гади сержант кына идем. 1943 елның көзендә рус редакциясендә эшләүче бер иптәш[1] белән икебезне лейтенантлар курсына жибәрделәр. Без анда

[1] Журналист Алексей Кондратович. Сугыштан соң «Новый мир» журналы редакциясендә эшләде.

укымадык, имхтиханнар гына тапшырдык. Шулай итеп, атна-ун көн эчендә офицер булып кайттык.

Газета атнага өч тапкыр дүрт битле булып чыга башлады. Мин газетада туктаусыз эшләү, язышу белән бергә, вак-вак хикәяләр дә иҗат иткәләдем. (Бу эштә миңа редакциядәге иптәшләр һәр вакыт ярдәм итеп килделәр. Дөресрәге, андый ярдәм булмаганда мин яза да алмас идем.)

Фронтта язылган хикәя-очеркларымнан тупланып, 1944 елда Казанда «Төньяк балкышы» исемле җыентыгым басылып чыкты. Басарга шул ук елның 3 мартында кул куелган. Димәк, нәшриятка җибәрелүе 1943 елның ахыры яки яңа елның башы була. Икенче төрле әйткәндә, редакциядә мин бик күп эшләгәнмен. Күрәсең, эшкә бик сусалган чак булган.

Сугыш алдыннан минем бер җыентыгым чыгып калса да («Бәхет кояшы»), чынлап торып әдәби эшчәнлегем менә шул җыентыктан — «Төньяк балкышы»ннан башлана. Аңарчы мин эзләнгәнмен, күңел төбендә яткан кайбер үрентеләр зәгыйфь кенә баш күтәргән, ләкин үземнеке дип әйтерлек төп сызык булмаган. Сугыш уты эчендә мин менә шул төп орлыкны — туган ил романтикасын тапканмын. Әлбәттә, ул әзер табылдык булмаган, ул беркадәр калку күренсен өчен бик күпне белергә, эшләргә, язарга кирәк булган.

1944 елның җәй башында бугай, Кави Нәҗмидән ачык хат алдым. Ул «Батырлар китабы»н чыгара, анда минем Илдар Маннанов турындагы очеркым да беркадәр кыскартылып керә икән. Шуннан Кави Нәҗми батырлар турында яңа очерклар сорады, бу теманың әдәбият өчен бик мөһим икәнен әйткән. Бу кечкенә генә хат миндә бик күп уйлар уятты. Озакламый мин Казанга Советлар Союзы Герое Фәхри Заһидуллин турындагы очеркымны җибәрдем. Көннәрдән бер көнне газеталардан Советлар Союзы Геройлары исемлеген карый идем, кинәт Газинур Гафиятуллинның фамилиясе ялтырап китте. Миңа бигрәк тә аның исеме ошады: Гази — җиңүче, нур — нур инде. Җиңүче нур! Менә шул нәрсә минем хыялымны котырта башлады. Соңыннан Газинурның күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын каплаганлыгын белдем. Димәк, үлеме белән үлемсезлеккә атлаган Җиңүче Нур. Мин инде Газинурның башта безнең фронтта булганлыгын, мин яткан госпитальдә эшләгәнлеген алдарак әйткән идем. Герой исемен алуы безнең фронтта булмаган. Шуңа күрә аның турында очерк яза алмадым, әмма исеме күңелгә кереп калды. Мин аның турында торган саен тирәнрәк уйлана башладым. Газинурның батырлыгы гаҗәп, рухы искиткеч олы, ләкин ул яшен көбек тиз ялтырый. Сугышта булмаган кешеләр, бигрәк тә яшь буын, моны аңлармы? Ничек аңа шушы бөек батырлыкны сөйләп бирергә, ничек итеп аңардан Газинур алдында баш идерергә? Минем өчен бернәрсә ачык иде: бу темага ашыгып тотынырга ярамый. Әйдә, күңелдә ятсын, чарлансын. Өлгергәч, күл үзеннән-үзе каләмгә үрелер.

1944 елның язында ике фронт — Карелия һәм Волхов фронтлары управлениеләре бергә кушылды, чөнки Волхов фронты үзенең тарихи яшәвен төгәлләгән иде. Редакциядә дә үзгәрешләр булды. Волхов фронтыннан майор Габделхәй Хәбиб белән өлкән лейтенант шагыйрь Әхмәт Фәйзи килделәр. Безнең элекке редакторыбыз Бари Корбанов белән редакция сотруднигы Мөхәммәтша Сабельев резервка — Мәскәү карамагына киттеләр. Озакламыйча алар Ерак Көнчыгышка назначение алып, Хабаровск шәһәрендә «Тревога» исемле газета чыгара башладылар.

Бу вакытта Карелиядә — 19 нчы шлюз янындагы ике катлы агач йортларда рус редакциясе үзе генә калды. Безне, татар редакциясен, Ак диңгез эченә кертеп салынган молга туктаган редакция поезды вагоннарына күчерделәр. Бөтен составына бары тик өч кеше — Габделхәй Хәбиб, Каюм Иманкулов һәм мин[1]. Календарьда яз булса да, Ак диңгездә әле салкын җилләр котыра, кар ява. Вагонда, никадәр яксак та, салкын, җил бөтен җылыны өреп бетерә. Тирә-якта бер каралты юк, дүрт

[1] Яңа килгән казакъ редакциясен дә шул ук вагонда урнашкан булырга тиеш иде. Соңыннан алар гел безнең белән янәшә купеда булдылар. Казакъ газетасында майор Нурлан Карабаев (редактор), өлкән лейтенант Рәшит Биктимисов (газетаның төп эшчесе, жаваплы секретарь) һәм хәбәрчесе капитан Айтжанов эшләде. Аннары капитан Коробаев (бер-берсенә охшаган бу ике фамилияне мин һаман бутый идем) һәм корректор булып сержант Нурмагамбетов килделәр. Элек Нурмагамбетов безнең газетага еш языша иде. Сугыштан соң мин Алма-Атада ике тапкыр булдым. Берсендә Рәшитне, икенчесендә Нурмагамбетовны күрдем. Рәшит нәшриятта, Нурмагамбетов газетада эшли иде.

ягың ачык. Шуңа күрә, әзрәк җылы булсын дип, мин иң өске полкада йоклый идем. Бервакытны иртән уянып китсәм, ике кеше, иңнәренә шинельләр салып, пыш-пыш сөйләшеп утыралар. Аларның берсе безнең яңа редакторыбыз Габделхәй Хәбиб, икенчесе... шагыйрь Әхмәт Фәйзи булып чыкты. Аны, редакциянең башка сотрудниклары белән бергә, юлдан ук частьларга җибәргән булганнар, шуңа күрә ул безгә бер атна чамасы соң килде.

Элек Әхмәт Фәйзине күргәнлегем турында язган идем инде. Ләкин ул иртәнге вагонның иң югары полкасыннан аңа байтак карап тордым. Ул күзлеген салган, күзләрен еш-еш йомгалый, үзе, теш арасына нәрсәдер эләккән кебек, һаман читкә төкергәндәй итә. Аннары Хәбиб тә, редакциянең башка кешеләре дә шагыйрь турында көлке нәрсәләрне җитәрлек сөйләп өлгергәннәр иде инде. Ләкин Хәбиб — гражданский тормышта аны «Чаян Хәбиб» дип йөрткәннәр, чөнки ул «Чаян» журналында эшләгән — гомумән көлке әйберләр сөйләргә тиеш булганга, мин аның сүзләренә бик үк ышанып та бетми идем, көлдерер өчен юри мәзәк сөйли кебек, югыйсә, Әхмәт Фәйзи кебек зур шагыйрь турында ничек инде көлеп сөйләргә тел барсын. Хәер, бераз соңрак мин моңа тулысы белән ышандым. Әхмәт Фәйзи күзлек белән дә начар күрә иде. Шул беренче командировкасында ук ул бер подразделениедән икенчесенә барышлый, ялгышлык белән, мина кырына килеп кергән. Билгеле инде, аны күреп алган кешеләрнең котлары очкан — менә-менә шартлавы ихтимал бит. Ләкин, бәхеткә, ул бөтен мина кыры аша узып та (үзе, әлбәттә, моны белмәгән) хәвеф-хәтәргә очрамаган. Шуннан командирлар аны туры редакциягә кайтарып җибәргәннәр... Икенче вакытта ул редакциядә дежурный була. Редактор төнлә вагоннан чыкса, ишек төбендәге сакчы каядыр киткән. Редактор телефон шалтырата башлый, бөтен составны аякка бастыра. Дежурный Әхмәт Фәйзи аның вагоны янына йөгереп килә. Ачуы чыккан редактор шагыйрьне үзен сакка бастыра...

Моны сөйләгән чакта әллә никадәр шәрехләүләр кыстыралар, без эчебезне уып көләбез. Бигрәк тә Хәбиб сөйләгәндә. Чөнки ул сөйләргә бик оста, уйлап чыгарырга маһирлыгы гажәп, аның кайда чыны башлана, кайда уйдырмасы китә, берсен дә белмисең, барысы көлке. Русчаны начар белүче татар булып сөйли башласа, көлүдән бөтен вагон дер-дер килә. Руслар да аны тыңларга җыелалар иде.

Шул ук көннеме, әллә икенчесендәме, Әхмәт Фәйзи Мәскәүгә, резервка китте. Мин аны юлга кадәр озата бардым. Алдан Әхмәт Фәйзинең әйбер капчыгын салган чана бара, арттарак — шагыйрь белән мин.

Шуннан соң мин Әхмәт Фәйзине сугыш беткәч кенә күрдем. Бу вакытта ул инде гражданский киемдә иде.

Инде җир кипкәч, газетага корректор итеп сугышчы Мидхәт Яхинны алдык. Ул кешедән яшереп шигырьләр язгалый иде. Беренче шигыре сугыш ахырына таба «Совет әдәбияты»нда басылды да. Хәзер укытучы.

Безнең редакциягә Җиденче армиядән бер сержант шигырьләр һәм хәбәрләр җибәргәләп торды. Имзасын, бездә күренмәгәнчә, Гиз эль Габид дип куя иде. Шигырьләре саф татарча, язуы бик матур. Без аның белән кызыксына башладык, ахырда аны редакциягә хәбәрче итеп алырга булдык. Хәтерлим, ул редакциягә Карелия фронтында хәлиткеч һөҗүм башланыр алдыннан килде. Бу вакытта безнең составны молдан төп редакциягә якынрак торган кирпеч сарайлары янына күчергәннәр иде. Кирпеч заводы эшләми, түбәләре генә ябылу кирпеч киптерү сарайларында җил уйный, яныбыздагы аэродромда бертуктаусыз самолетлар гүли. Тышта җәй, ак төннәр. Юл аръягында гына — диңгез. Су күбәйгәндә дулкыннар юл янында ук чайпала, су азайганда зур-зур ташлар өскә калкып чыгалар. Менә шул вакытта безнең редакциягә Гиз эль Габид килде. Өстендә шактый агарган гимнастерка, башындагы пилоткасы да кояшта уңып беткән, шинелен беләгенә салган, иңбашында әйбер капчыгы, погоннарында сержант билгесе, күзлекле. Йөзе ябык. Фамилиясен сорап торырга да кирәк түгел иде. Кемдер, Иманкулов бугай, кычкырып җибәрде:

— Гиз килде!

Бик тиз таныштык. Аның фамилиясе дә, исеме дә бик гади булып чыкты: Габидуллин Гыйззулла, ә шигырьдә койрыкларын кырыккан, җитмәсә, көнчыгыш шагыйрьләренә охшатып, «эль» кушымчасын алган: Гиз эль Габид. Бу безгә көлке тоелды һәм без аңа, шаяртып, әлбәттә, Гиз эль Гыйфрит дигән кушамат тактык.

Газетага эшкә алсак та, Гиз җаны-тәне белән газетчы түгел, ул шагыйрь иде. Ләкин шагыйрь буларак та холкы белән бик үзенчәлекле. Газетага кирәк булган шигырьләрне без аңардан радиорубкага бикләп кенә яздыра ала торган идек. Әзер шигырен ишек асты ярыгыннан сузмыйча, кычкырып сүгенүенә дә карамастан, ишекне ачмыйбыз [1].

Озакламыйча безнең фронтта кайнар көннәр башланды: Карелия фронты гаскәрләре, борынгы Лодейное Поле шәһәре янында киң сулы Свирь елгасын кичеп, хәлиткеч һөҗүмгә күчтеләр. Бу һөҗүм дошманны эзәрлекли-эзәрлекли Финляндия җиренә бәреп керү һәм Финляндиянең сугыштан чыгуы белән тәмамланды. Бәрелешләр бик каты булды, дошманның төп көчләре тар-мар ителде. Хәзер безнең ике мең километрга сузылган төньяк чикләр торгызылды, бары тик ерак төньякта — Петсамо юнәлешендә генә гитлерчылар калды. 1944 елның көзендә монда да хәлиткеч сугышлар башланды. Дошман бер генә карыш җирне дә котырынып каршылык күрсәтмичә бирмәде. Ләкин аның көннәре санаулы иде инде. Ниһаять, Норвегия чигендә Киркенес шәһәре алыну белән зур илебезнең төньяк чикләре буенда кулына корал тоткан бер генә тере дошман да калмады.

Ерак төньякта сугышлар барганда безнең бөтен редакция — рус, казакъ, татар газеталары — поездга күчте һәм Мурманск тирәсендәге Кола дигән станциядә торды. Анда без 1944 елның 12 нче ноябрена каршы төндә «Ватан өчен сугышка» газетасының соңгы номерын чыгардык.

Коладан кайтканда Гиз эль Габид миңа багышлап түбәндәге шигырьне язган иде:

Төньяк белән саубуллашу

1

Саклар өчен бөек хокукларны,
Кеше булып яшәү хакында —
Өч ел буе канлы сугыш барды
Болан сукмаклары чатында.

Сугыш барды кышкы бураннарда,
Чәчәкләргә фәкыйрь язларда,
Ая адашырлык урманнарда,
Киек үтә алмас сазларда.

Очраса да безгә орышларда
Дөнья кадәр газап, читенлек,—
Җир читендә, Баренц ярларында,
Немецларны тар-мар китердек.

Сау бул, төньяк! Артык эш юк инде
Безгә синең шәрә тауларда,
Данга күмәр өчен Туган илне,
Без кыйныйсы бүтән яулар бар...

---

[1] Гиз эль Габид безнең редакциядә сугыш беткәнче эшләде. Башта Карелиядә, аннары бергә Ерак Көнчыгыш фронтта. Казанга бергә кайтып, газетада хезмәт иттек. 1946 елның ахырына таба армиядән демобилизацияләнгәч, ул яңадан Үрта Азиягә китте һәм әлекке һөнәре — укытучылык эшенә керешкән. Берничә ел үткәч, бик каты авырый башлый. 1955 елда күзләрен мәңгегә йома.

Гизнең шигырьләре газета-журналларда басылса да, үзе исән чакта аерым китап булып чыкмады. Ләкин аны белгән кешеләр күңеленда Гиз бәхәссез шагыйрь булып калды, аның китабы, һичшиксез, дөнья күрергә тиеш дип уйлыйбыз. Ул фронтта үлмәсә дә, барыбер шул чор шагыйрьләре җөмләсенә керә һәм аларның күренеклесе булып санала.

«Север» журналында (№ 3. 1965) Гиз эль Габид турында минем кечкенә генә бер истәлегем һәм мәрхүмнең русчага тәрҗемә ителгән берничә шигыре басылып чыкты.

(1968 елда «Беренче карлыгачлар» исемле күмәк җыентыкка Гизнең 31 шигыре кергән, Әдхәт Сынегуловның сүз башы бар.)

2

Өч ел безне чаккан котып җиле
Яратабыз диеп беләме!
Үксеп елый-елый арттан килә,
Аерылырга бездән теләми.

Поезд үтә таулар арасыннан,
Үзәннәрдә томан болгана.
Җөйләнмәгән иске яра сыман,
Йөрәгемдә сагыш уяна.

Солдат юлы дигән авыр юлны
Мин бит шушы илдә башладым,
Тирем белән тавын-ташын юдым,
Каным белән җирен ашладым.

Калдырсам да төньяк ташларында
Яшьлегемнең актык кисәген,
Монда мәңге калган дусларымның
Әрнүлерәк миңа исәбе...

Сау бул, төньяк! Кыргый гүзәллегең
Җырларымда саран чагылыр,
Тик син чыныктырган йөрәгем гел
Әрнеп, сөеп сине сагыныр.

1944 ел, декабрь.[1]
Киров тимер юлы.

Инде миңа шул хәтле нык тәэсир ясаган Карелиядән бөтенләйгә китәр алдыннан шуны да әйтәсем килә: «Ватан өчен сугышка» газетасының подшивкасын актаручы кеше булса, ул анда дошманның ерткычлыгы турындагы минем мәкаләләремә азмы-күпме игътибар итәр. Карелиядәге концлагерьлар турында махсус мәкаләм дә бар. («Куолоярви фаҗигасе», 12. X. 1944 ел.) Әлбәттә, телеграф белән җибәрелгән мәкалә озын түгел. Ләкин мин чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган лагерьда бик озак йөрдем, лагерь янындагы каберлекне ачу эшенә дә катнаштым. Бу коточкыч иде... Моннан башка да әлеге темага газетада минем мәкаләләрем бар. Әйтәсе килгәнем шул: мин бу турыда ул елларда ук җитди уйлана башлаганмын. Шуңа күрә тормышта бер этәргеч булгач, «Мәңгелек кеше» романын яздым. Ул этәргеч — романның баш герое, Бухенвальд концлагереның бөтен дәһшәтләрен күргән, гитлерчыларга каршы актив көрәшкән Баки Назиров белән танышу иде. (Романда аның фамилиясе Баки Назимов дип алына.) Ләкин фронт елларында үземнең күргәннәрем, кичергәннәрем һәм уйланганнарым булмаса, мин ул темага тотына алмас идем.

«Ак чәчәкләр» романының ерак тамырлары да Карелия фронтына барып тоташа. Роман алтмышынчы елларга караса да, врачларга булган кайнар мәхәббәт шул ук Карелиядә госпитальдә ятканда уянды. «Алтын йолдыз»да, аннары «Газинур»да врач образларын төрле яклап бирергә омтылу да шуннан килә. Ләкин бу әсәрләрдә генә медицина турындагы уй-фикерләремне әйтеп бетермәгәнмен, аларны әйтер өчен «Ак чәчәкләр»не язарга кирәк булды.

Мин барлык әсәрләремнең барлык тирән тамырларын күрсәтергә тырышмадым, дөресен әйткәндә, моны мин булдыра да алмас идем. Бу — кызыксынган әдәбиятчылар, тикшеренүчеләр эше. Мин фәкать тормыш чыганакларының язучы өчен никадәр әһәмиятле булуына гына басым ясадым. Тормыш чыганаклары никадәр тирән-

[1] Бу шигырьне Казанга Ростов-Дон шәһәреннән 1972 елда Гиз эль Габдиның тормыш иптәше мәрхүмә Мәрфуга Алтынбаеваның абыйсы Шәүкәт Алтынбаев шагыйрьнең архивыннан табып җибәрде. Шундый шигырь язганлыгын Гиз ул чакта ук миңа әйтте һәм укып та күрсәтте. Безнең мәшәкатьле чак иде, ерак төньякта сугыш хәрәкәтләрен төгәлләп, яңа урынга күченәбез. Шигырь озакламый онытылды. Соңыннан да Гиз аны телгә алмады, бастырмады да шикелле. Бәлки эшләнеп бетмәгән дип санагандыр.

нән ургылсалар, язучының шәхси тормышы аларга никадәр тыгыз бәйләнештә булса, иҗатына шул кадәр зәмин арта.

Ерак төньякта сугыш хәрәкәтләре тукталгач, Беломорскига кайттык, биредә күпмедер торгач, Ярославль шәһәренә күчтек. Монда бары тик русча «Боевой листок» басылды. Татарлардан һәм казакълардан ул листокны чыгару эшенә мин генә тартылган идем.

Ярославльдә без 1945 елның 9 маена кадәр тордык. Бөек җиңүне дә шунда каршыладык. Безне инде байтак вакыт бернәрсә аптырата иде: көнбатышта шундый зур һөҗүм барганда нишләп безне, бөтен бер фронт штабын, таратмыйча ерак тылда тоталар? Дөрес, армиядә бөтен нәрсә приказ белән эшләнелә. Моны һәркем белә, ләкин көтүе, һай-һай, авыр.

Шунда командование мине берничә көнгә Мәскәүгә җибәрде. Әнкәйләрне күрдем, Язучылар союзына, әдәби институтка барып чыктым. Аннары тагын Ярославльгә кайттым. Бүтән әллә ни зур эш булмаганга, редакция поездында «Алтын йолдыз»ны яздым. Көннәрнең берендә Ярославльдә хезмәт итүче өлкән лейтенант Мостафа Ногман белән таныштык. Ул гаҗәп матур җырлый. Ул чакта бер тупикта торган редакция поездында татарча бик күп җыр яңгырагандыр. Мостафа хезмәте буенча Мәскәүдә булгалый, Казанга да барып чыгарга уе бар икән. Шагыйрь буларак мин аны белми идем. Хәер, ул чакта без барыбыз да әле яңа яза башлаган кешеләр, кемгә булса җитлеккән язучы итеп карау дөрес тә булмас иде. Мостафа Ногман миндә яхшы тәэсир калдырды, мин аның белән әле яңа язып бетергән «Алтын йолдыз» романының беренче вариантын Казанга җибәрергә булдым.

9 май көнне, бөтен халык Бөек Җиңүне тантаналы бәйрәм иткәндә, безне сафка тезеп, яңа приказ укыдылар: махсус заданиене үтәргә барасыз, диелгән иде анда. «Махсус задание» безгә азмы-күпме таныш нәрсә инде, чөнки бу вакытта бөтен редакция Степановның «Порт-Артур»ын укый башлаган иде. Аннары китәсе көннәрнең берендә бер хатын безнең редакциядә хезмәт итүче иренә Мәскәүдән шалтыратты. Редакциядә телефоннар параллель, барысы берьюлы шалтырый. Гадәттә шәхси сөйләшү булганда бүтән вагоннарда трубкаларны куялар. Бу юлы кемдер әлеге ир белән хатынның сөйләшүләрен тыңлап торган, ахрысы. Хатын әйткән икән иренә: мин ишеттем, дигән, сезне Дарья Васильевнага җибәрәләр икән. Дарья дигәне инде Дальний, Васильевна дигәне — Восток икәнен белү безгә кыен түгел иде.

Юлда без бер ай чамасы булдык. Эш юк, редакция вагоннары иркен, купеларда, тар гына булса да, өстәлләр бар, телисең икән утыр да яз. Мин «Алтын йолдыз»ны Мостафага тоттырып, Казанга җибәргән булсам да, аны эшләүдән туктамадым. Күрәсең, күп нәрсә үземне дә канәгатьләндермәгән булгандыр, аннары тәҗрибә юк, беренче зур әсәр бит. Юлда, тәрәзәдән карый-карый, һаман уйлана бардым. Без илне төньяк-көнбатыш чигеннән көнчыгыш чигенә кадәр кичәбез. Төн китәсең, көн китәсең, атналар китәсең, ә илнең иге дә, чиге дә юк. Шул илне фашистлар җимәкче булган. Юк, җиңми торсыннар! Тора-бара илнең бу бөеклеге, бу күрелмәгән зурлыгы мине тәмам хисләндерде һәм шул тойгы — туган илнең зурлыгы белән горурлану тойгысы әкрен-әкрен язасы әйберемә дә күчте кебек. Мин «Алтын йолдыз»ны башкарак яктылыкта күрә башладым, барлык чикләнүләрне алып ташларга булдым. Мин, татар язучысы, баш геройларымны, әлбәттә, татар итәрмен, ләкин аларның газиз Ватаны Татарстан гына түгел, ә бөтен ил, шул илнең баласы булу аларга куәт бирә, җиңелмәс итә...

Ниһаять, без билгеләнгән урынга — Ворошилов-Уссурийск шәһәренә килеп җиттек. Билгеле, калага кермәдек, Градеково тимер юлында бер тупикта — шәһәр читендә туктадык. Килүнең икенчеме, өченчеме көнендә частьларга чыгып киттек.

Ерак Көнчыгыш! Китаплардан ул ничектер салкын Себер булып күз алдында калган. Ә монда эссе җәй, кырларда, болыннарда, урманнарда гаҗәеп күпшы чәчәкләр, төсләре бик ачык, аланнарда яки киң кыр уртасында җирдән нарзан чишмәләре ургып чыгып тора. Күпме телисең — эч. Усемлекләр, кошлар да монда әле без күрмәгән төсле лә р. (Әллә салкын Карелиядән, кырыс төньяктан соң шулай тоела идеме икән?) Хәер, солдат һәр җиргә бик тиз ияләшә. Бераздан безгә дә Ерак Көнчыгыш сопкалары бик якын, таныш сыман булып китте.

Ерак Көнчыгышта без татарча «Сталин сугышчысы» исемле газета чыгардык. Бервакыт безнең хәреф җыю цехы вагоны янды. Инде татарча хәрефләр юк, басу станогы юк, дип кайгырып торганда, Мәскәүдән, ГлавПУРККАдан, телеграмма килеп төште: газета чыгаруны туктатмаска, хәрефләр һәм станокны урында табарга, диелгән иде. Һәм без таптык, элеккедән дә яхшыракларны таптык. Безнең күңел күтәрелеп китте, хәтта бер-беребезне шаярта башладык:

— Ерак Көнчыгышта ни булмас дисең, монда татарча хәрефләр дә бар ич!

1945 елның 9 августына каршы төндә япон самурайларына каршы сугыш хәрәкәтләре башланды, без дә частьларга чыгып киттек. Урыны-урыны белән бик каты сугышлар булды, ләкин безнең армиянең куәтле һөҗүмен туктатырлык көч юк иде. Кытайны япон империалистларыннан тазарту көне килде. Мин бу турыда «Ерак Көнчыгышта» дигән очеркымда ярыйсы тулы итеп яздым («Совет әдәбияты» журналы, № 11, 1945 ел).

Хәрби корреспондент язмышы мине Владивосток шәһәренә дә алып килде. Биредә мин кызылармеецларга русча радио тапшырулар хәзерләргә тиеш идем. Тапшырулар да булды, газетага хәбәрләр дә язып тордым. Тын океан диңгезчеләре белән дә аралашып киттем. Элек диңгез бригадасында хезмәт итү диңгезчеләрнең рухын аңлауга бик нык ярдәм итте.

Владивосток шәһәрендә мин шагыйрь Салих Баттални эзләп карадым. Аның Ерак Көнчыгыш авиациясендә хезмәт итүен белә идем, редакциягә шигырьләре белән хатлары килгәләде. Ләкин үзен таба алмадым. Минем арттан килеп җиткән майор Хәбиб белән яшь язучы Сафа Сабировны да эзләдек. Аның диңгез офицеры икәнен, Владивосток шәһәрендә яшәвен шулай ук белә идек. Үзе белән бик танышасы килсә дә, адресы булмагач, кыска вакыт эчендә таба алмадык. Хәтта мондый эшләрдә аеруча сәләтле булган Хәбиб[1] берни эшли алмады.

Икенче Ерак Көнчыгыш фронтында татарча «Тревога» исемле, Байкал арты фронтында «Суворовча кысрыклау» исемле газета чыга иде. Без, Беренче Ерак Көнчыгыш фронты газетасы редакциясе, килгән көннән үк алар белән үзара элемтә урнаштырырга, газеталар алмашырга керештек. «Тревога» белән бәйләнеш ярыйсы булды, «Суворовча кысрыклау» белән, язучы Афзал Шамовтан хатлар алып торсак та, бәйләнеш эзлекле булмады.

Ерак Көнчыгышта мин, нихаять, Казаннан, китап нәшриятыннан «Алтын йолдыз» турында рецензия алдым. Кулъязмада 600—700 битле романга ярты битлек рецензия! Рецензиянең авторы — Гали Халит роман бернәрсәгә яраксыз дигән. Бу вакытта романның яңа варианты туарга торса да, мондый бәяне күтәрү бик авыр булды. Ярый әле, фронт тормышы күңел төшенкелегенә күп вакыт бирми. Мин аеграк акыл белән уйлый башладым: әсәрне барыбер ташламыйм, ул минем өчен чиксез кадерле, ләкин җитдирәк эшләргә кирәк. Аннары бу рецензиянең уңай ягы да бар иде: ул мине җиңел уңышлардан кисәтте. Бу бик вакытлы иде, чөнки сугыш инде бетәргә тора, озакламый тыныч хезмәткә кайтырбыз, үзеңнең көчле якларыңны гына түгел, көчсез якларыңны да белү бик кирәк. Шунсыз иҗат итеп булмый. Аннары фронт миңа бик күп материал бирсә дә, иҗатымда төп сызыкны табарга булышса да, әдәби осталык биеклекләренә мендермәде, аларны бик авыр хезмәттә яулап аласы бар иде әле.

Нихаять, 1946 елның апрелендә армиядән демобилизацияләндем. Озакламыйча үземнең элек эшләгән урыныма — «Совет әдәбияты» журналына кайттым. Шулай итеп, гомернең яңа чоры — тыныч хезмәт чоры башланды. Бу чор куркыта да, шул ук вакытта бетмәс-төкәнмәс ашкыну да уята иде. Миңа инде профессия сайлау белән вакыт үткәрергә кирәк булмады. Мин аңлы рәвештә, үземнең көчле һәм көчсез якларымны тоеп, авыр, сикәлтәле иҗат юлыннан киттем...

1967 ел,
май — ноябрь.

---

[1] Г. Хәбиб 1973 елның көзендә вафат булды.

Самат Шакир

УТЛЫ ЕЛЛАРДА ТУГАН ШИГЫРЬЛӘР ҺӘМ ЯЗМАЛАР

Безнең алда «Сталин байрагы» һәм «Ватан намусы өчен» дигән фронт газеталары. Вакытлар узу белән саргайган, кулдан-кулга йөреп читләре челтәрләнеп беткән, алгы сызыкта солдат гимнастеркасы кесәсендә йөреп, яңгырга эләккән бу газеталарда гвардия капитаны Нәгыйм Хафизов шигырьләре игътибарны җәлеп итә. Алар күп түгел, ләкин шул авыр елларның сулышы, дошманга каршы көчле нәфрәт, җиңүгә зур ышаныч бу шигырьләрдә калку итеп бирелгән.

Менә 1943 елның 5 июнендә «Сталин байрагы» газетасында басылган «Хат» шигыре. Бик күп авырлыклар күргән чал чәчле ана үзенең улына хат аркылы мөрәҗәгать итә.

— Хуш, улым, хуш!
Яхшы сугыш!
Исемең синең данга күмелсен.
Куркак булма! Әгәр илең сатсаң,
Мәңге каргыш, улым түгел син!

Кайсы шагыйрь ана турында хисләнеп, дулкынланып шигырь язмады. Нәгыйм Хафизов та анага багышлап сугыш кырында — окопта матур гына шигырь яза. Ана иң изге теләкләр тели улына, аның өчен төн йокламый кайгыра, борчыла. Аналар күңеле бик йомшак, әмма аның изге сүзләрен, изге васыятен үтәмәсәң, ул иң каты, иң кискен хөкемен дә чыгара.

Менә шул ук газетада басылган «Кулъяулыгы» шигыре. Бу темага сугыш елларында бик күп язылды. Яшь шагыйрь Нәгыйм Хафизов аны үзенчә бирергә тырыша.

Мин үз язмышымны, акыллым,
Синең мылтыгыңа тапшырдым.
Һәм мин кабергәчә көтәм сине
Ышанып һәм сагынып, батырым!
Җибәрәмен сиңа кулъяулыгы,
Кызыл атлас, сөюем билгесе.
Җилфердәсен җилдә байрак булып
Мылтык штыгында ул синең!

Сугыш кырларында — салкын окопларда, землянкаларда, блиндажларда һәм траншеяларда сугышчыларның күңелләрен күтәргән, аларны үзенең сулышы белән җылыткан, иң авыр вакытларда көч-куәт биргән нәрсә туган җирдән, андагы әти-әниләрдән, сөйгән ярлардан килгән хатлар булды. Бу турыда Нәгыйм Хафизов «Кыз хаты» дигән шигырендә йөрәккә сеңеп калырлык итеп яза. Кызның донор булып, сугышта яраланган егеткә үзенең канын бирүе дә сәнгатьле итеп сурәтләнгән.

Нәгыйм Хафизов
1943 ел.

Сиңа каным бирәм,
Тизрәк терел,
Батыр бул син, егетем, бу чакта.
Ике тапкыр каты бул дошманга,
Ике тапкыр артык үч сакла!
Ике тапкыр,
Чөнки хәзер без дә
Икәү менә дошман каршында.
Атакага барам мин дә бергә,
Синең белән,
Синең каныңда!

Нәгыйм Хафизов сугыш тынып торган сәгатьләрдә, башкалар ял иткәндә, «Сугыш көндәлеге» алып бара, шигырьләр яза. Аның семья архивында алгы сызыкта язылган шигырьләре саклана. Шулар арасында «Кошмарлы төн», «Чегән хатыны», «Кабер өстендә», «Хат», «Герой турында җыр» һәм «Озату» дигән шигырьләр сугыш дәһшәтен, андагы вакыйгаларны күрсәтүе буенча аерата характерлы. Аларда солдат-шагыйрьнең уй-кичерешләре, Ватан-анага булган мәхәббәте, сөйгән кызына биргән вәгъдәсенә турылыклы булуы ачык чагыла.

Нәгыйм Хафизовның тормыш юлын ачыклау өчен шактый эзләнергә туры килде.

Ул 1912 елда Чиләбе өлкәсенең Кунашак районы, Кунашак авылында крестьян семьясында туган. Яшьтән ятим калып, балалар йортында тәрбияләнгән. 1929 елда ул Уфага килә һәм типографиядә наборщик булып эшли башлый. Аннан соң Магнитогорскида металлургия заводында слесарь була, берникадәр эшләгәч, Урта Азиягә китә. Монда ул Ташкент финанс-экономика институтында укый һәм 1938 елда яңадан Уфага кайта. Бер ел район финанс бүлегендә инспектор булып эшләгәннән соң Кыргызстанга китә. Фрунзе шәһәрендә финанс техникумында политэкономия укыта. 1942 елны үзе теләп фронтка китә. Алгы сызыкта взвод командиры булып сугыша. Сталинград фронтында яралана, госпитальдән чыккач, яңадан алгы сызыкка килә. Орел-Курск дугасындагы сугышларда катнаша. Украина, Белоруссия, Молдавия, Румыния, Чехословакияне азат итеп Германиягә килеп керә. Нейсе елгасы буендагы сугышларның берсендә алтынчы мәртәбә яралана.

Нәгыйм Хафизов сугышларда рота, аннары батальон командиры дәрәҗәсенә күтәрелә. 1943 елда ул — полк штабы начальнигы ярдәмчесе. Фронтта күрсәткән батырлыклары өчен Хафизов «Ватан сугышы» ордены, «Сугышчан хезмәтләр өчен», «Сталинград оборонасы өчен», «Праганы азат иткән өчен» һәм башка медальләр белән бүләкләнә. 1946 елны Урта Азиягә кайта һәм фәнни-тикшеренү институтында экономист, соңыннан өлкән фәнни сотрудник булып эшли. Яралар һәм контузияләр Нәгыйм Хафизовның сәламәтлеген какшаталар. Ул 1968 елның 20 февралендә вафат була.

Без югарыда Нәгыйм Хафизовның «Сугыш көндәлеге» алып баруын әйткән идек. «Көндәлекләр»дә Сталинград сугышларының күп эпизодлары сурәтләнә. Менә шулардан берничәсе:

«11 август, 1942 ел.

Лагерьдан кайтып, ике көн эчендә имтиханнар тапшырдык. Миңа лейтенант званиесе бирделәр. Станоклы пулемет взводы командиры булачакмын. Училищеның кайбер курсантлары тылдагы частьларга җибәрелде, күпчелеге — Сталинградка. Мин соңгы төркемгә эләктем. Мин Көньяк фронтның иң җаваплы участогына барачакмын. Анда немецлар белән каты сугышлар бара. Мәдинә миңа болай дигән иде:

— Ватанга һәм миңа турылыклы бул. Әгәр дә безне сатсаң — борылып кайтма! Әйе, никадәр дөрес сүзләр!

19 августта безне озаттылар.

Безнең эшелон озын һәм куркынычлы сәфәргә — Сталинградка юл алды.

5 сентябрь, 1942 ел.

Сталинградка якынлашабыз. Яралылар юлда очрыйлар. Алар Сталинградның жимерелүе, аның турында бары тик истәлекләр генә калуын әйтәләр. Дошман шәһәр капкасында. Халыкны эвакуациялиләр, ләкин трактор заводы эшли.

6 октябрь, 1942 ел.

Арзамасово хуторы.

Артиллерия канонадасы ишетелә. Бу безнең ераккa ата торган тупларның дошман өстенә ату тавышлары. Кайвакытта алар бөтен көн буена дәвам итәләр. Хутор өстеннән көн буе һәм төн буе немец самолетлары очалар. Кайвакытларда һава сугышлары башлана.

Кичә Петя Подкопаев белән хуторда дежур тордык. Ул юллар чатында сакчы булды, мин патруль идем. Хутор өстендә дошман самолетлары әйләнә башлады, халыкны куркыту өчен үзләренең үтә якты ракеталарын яндырдылар, хәтта сиреналарын кычкырттылар һәм бездән ерак түгел генә йорт янына бомбаларын ташладылар. Мин, утырган хәлдә, үземнең Мәдинәм, туганнарым, әнием, китапларым турында уйладым. Алар хәзер нәрсә эшлиләр? Ә бәлки минем турыда уйлый торганнардыр. Минем әни ике командир анасы, ул шулар турында уйлый һәм кайгыра торгандыр. Нәжип абый хәзер кайда икән? Элемтәче-командир, зәңгәр күзле таза егет исән микән? Сугышның иң катлы вакытында ул Воронеж янында иде. Бәлки инде ул юктыр? Бәлки бу җыр яратучы хисле һәм моңлы, романтикалы егет һәлак булгандыр?

Мине Мәдинә озатып калган иде. Ул яшьле күзләрен миңа текәп:

— Сине, Нәгыйм, бик сагынырмын,— дигән иде.

Без ул вакытта саубуллашу җыры жырлый идек. Мин Мәдинәгә еламаска куштым. Ул, минем кадерлем:

— Еламаска мөмкин түгел, — дип, күкрәгемә башын куйды.

Уйлар, уйлар... Мәдинә, әни һәм сеңелләр, Нәжип абый — барысы да минем күз алдыма килеп бастылар. Һәм мин ирексездән моңлы итеп жырлап жибәрдем:

Телеграмм баганасы
Олы юлга маяк ул...

2 ноябрь, 1942 ел.

Менә инде дүртенче төн немецлар хуторга йокы бирми. Караңгы төшә башлау белән, хутор өстенә свастикалы самолетлар килә һәм көчле рәвештә бомбага тота. Җан тетрәткеч тавышлар белән бомбалар төшеп ярыла, тузан болыты күтәрелә, йортлар жимерелә.

12 ноябрь, 1942 ел.

...Яңадан маҗаралы сәяхәт башланды. Машина мине бомбага тотып жимерелеп беткән Котлубань совхозына хәтле генә илтте. Аннан соң мин җәяү генә киттем. Котлубань разъездында сугышканда Долорес Ибаррурининың улы Рубен Ибаррури һәлак булганлыгын әйттеләр.

Караңгыда берүзем җәяүләп барам. Далада берүзем. Салкын. Каршыга искән җил итәктән тарта.... Тирә-якта туплардан аталар. Башка төрле уйлар керә: «Әгәр мин ялгышып немецларга эләксәм?»

Кинәт минем янда туп шартлады, мин үзем дә сизми жиргә утырдым һәм һич кенә дә тора алмыйм...

29 ноябрь, 1942 ел.

Румыннар әйтәләр:

— Атака вакытында румыннар һәм итальяннар алдан бара, алар артыннан немецлар автоматлар белән саклап баралар... Ләкин барыбер немецларга үлем!

Румыннар, итальяннар җәйге киемдә, күбесе бик юка гимнастеркадан.

Менә инде дүртенче көн немецларның транспорт самолетлары сугыш кирәк-яраклары, азык-төлек һәм кешеләр ташый. Безнекеләр аларны уңышлы рәвештә бәреп төшерәләр.

15—16 декабрь, 1942 ел.

Бик киеренке эшлибез. Бүген иртән фронт штабына барып, барлык заданиене үтәдем.

Безнең халыкта патриотизм бик көчле!

31 декабрь, 1942 ел.

Барысы да ашханәгә Яңа елны каршыларга китте. Мин дежур булып калдым. Гыйният абый Ибәтуллин (Казанда, Крайний урамы, 59 нчы йортта торган) миңа паек китерде.

Фронтта канонада. Караңгы төнне яктыртып, үзенә хас тавыш чыгарып снарядлар оча, «Катюша»лар гүли.

Мин өстәл читенә утырып көндәлек һәм шигырь язам.

8 январь, 1943 ел.

Бүген 66 нчы Армиядән приказ оформить иткәннәр. Мине 99 нчы Кызыл Байраклы укчы дивизиянең 197 нче укчы полкына штаб начальнигы ярдәмчесе итеп билгеләгәннәр.

10 январь, 1943 ел.

Ашыгыч задание белән 226 нчы дивизиягә киттем. Дивизия һөҗүмгә хәзерләнә, сугышчыларга орденнар һәм медальләр тапшырырга кирәк.

Әйләнеп кайтканда, Ерзовкага җәяү килдем. Ерзовка бөтенләй җимерелгән. Сухая Мечеткада булдым. Бу урыннарда немецлар булганнар һәм аларны ноябрь һәм декабрь айларында моннан куганнар. Барлык кыр җимертелгән танклар, туплар белән тулы. Ун меңнәрчә кешеләр монда үзләренең башларын салдылар. Сентябрьнең беренче яртысында монда бик каты кан коюлы сугышлар булды. Бу турыда барлык сугышчыларга мәгълүм 129,6 биеклеге әйтеп тора. Монда яндырылган һәм җимертелгән танклар бик күп, шуның өчен «Танклар каберлеге» дип йөртәләр.

30 январь, 1943 ел.

Мин 17 январьдан бирле 99 нчы Кызыл Байраклы дивизиянең 197 нче укчы полкында.

Монда тормыш кызыклы, җанлы һәм куркынычлы, һәр көнне — сугышлар. 28 январьда аерата каты сугышлар булды. Бу көнне йөзләрчә туплар, миномётлар, «Катюша»лар һәм самолетлар фашистларны бик каты кыйнадылар. Коточкыч картина!

Сталинград трактор заводы һәм баррикадалы урамнар моннан бик ачык күренеп тора. Хәтта артка качучы немецлар да уч төбендәге кебек. Көчле ут ачканнан соң завод, хәтта йортлар төтен белән капланган. Бомбалар, миналар шартлавыннан һава зыңгылдап тора.

Яңа пополнение килә.

Безнең сугышчыларның кәефләре искиткеч яхшы.

— Кирәкләрен бирәбез ул илбасарларга! — диләр алар.

— Кыйнарга, бары тик кыйнарга! — ди һәр сугышчы ачу белән.

Алгы сызыкта булдым. Эш бик күп, инде өченче тәүлек йоклаган юк.

1 февраль, 1943 ел.

Сталинградны һавадан бомбага тоту дәвам итә. Безнең артиллерия һәм «Катюша»лар дошманны кыйный! «Катюша» — безнең горурлык ул! Бездә «Катюша» булу нинди зур шатлык!

Пленга алынган немец солдатлары һәм офицерларының саны көн саен арта бара.

2 февраль, 1943 ел.

Тын. Бер генә ату тавышы да юк! Юллар немец әсирләре белән тулган. Аларның өсте-башы ертылып беткән, одеялларга, бала юрганнарына төренгәннәр, көч-хәл белән генә селкенәләр.

Бу көнне Сталинград сугышлары тәмам булды. Кичә монда алгы сызык иде, бүген без тирән тылда».

Фашист илбасарларга иң каты удар булган урында сугышчы-яшь шагыйрь Нәгыйм Хафизов «Сталинград» дигән поэма язган. Ләкин ул поэма югалган. Бу турыда үз үзенең көндәлегендә дә әйтеп китә.

Батыр солдат фашистларны куа-куа Орел-Курскига килеп җитә. Ул икенче зур поэма язу өчен материаллар җыя һәм «Сугыш көндәлеге» алып бара.

«13 июль, 1943 ел.

Безнең участокта — Прохоровка станциясе районында бик каты сугышлар бара. «Комсомолец» совхозында — Прохоровкадан өч километр ераклыкта сугышлар аерата каты бара. Үзәк өзгеч авиамоторлар тавышы ишетелә. Йолдызлар һәм ай, бу вәхшәтне күрергә теләмәгәндәй, болытлар астына кереп качкан. Һавада меңнәрчә ракеталар һәм янып төшүче самолетлар.

Кичә иң зур — гигант танклар сугышы булды. Монда меңнән артык танк катнашты. Ике яктагы танклар лавинасы бер-берсенә каршы ыргылдылар һәм «Комсомолец» совхозы янында очраштылар.

Коточкыч сугыш гарасаты озак дәвам итте. Монда кыр киң булуга карамастан, сугышучы танклар өчен урын бик тар булды. Танклар бер-берсен таранга алдылар, җир өсте ут-ялкын белән тулды, тирә-як дерелдәп, зыңгылдап торды. Кыр өсте ут телләре, кап-кара төтен белән тулды, танклар яна иде.

Хәзер дә сугыш кыры яндырылган һәм җимертелгән танклар белән тулы.

Без Курскидагы иң зур сугышларда катнашабыз. Безнең командование алда торган бу зур һөҗүмгә бик яхшы хәзерләнгән.

20 июль, 1943 ел.

Кичә генә монда килдем. Бу Ясная Поляна авылы. Ул «Комсомолец» совхозы артында гына. Прохоровка да ерак түгел. Барлык йортлар җимерелгән, йорт хуҗалары немецлар тарафыннан куылган. Барлык юллар миналанган. Саперлар артыннан без юл ярабыз.

Чын сугыш көннәре. Сугыш, авыр сугыш!

Көн саен алга барабыз. Немецлар сугыша-сугыша чигенәләр. Бөтен кыр, юллар ватык техника, танклар, үзйөрешле орудиеләр һәм үлгән немец гәүдәләре белән тулы.

3 август, 1943 ел.

Безнең участокта бик каты сугыш. Безнекеләр һөҗүм итәләр. Бүген иртән үк һава гөрләп тора. Безнең йөзләрчә самолетлар дошман өстендә. Авыр туплар, үзйөрешле орудиеләр, танклар бертуктаусыз хәрәкәт итәләр. Бөтен җирдә «Т-34» танклары.

Башларын югары күтәреп һавага караган хәлдә, танклар өстенә утырган сугышчылар — яңа полклар үтә. Егетләр барысы да шат!

Һавада очучы самолетларга күрсәтеп, алар:

— Немец сволочьларга бирегез кирәкне, күрсәтегез безнең кем икәнне! — диләр.

Дошман чигенә.

5 август, 1943 ел.

Белгород районына килдек. Немец самолетлары бертуктаусыз безнең алгы сызыкны һәм юлларны бомбага тота.

Яхонтово авылыннан ерак түгел урманда булдык. Монда немецларның штабы торган булса кирәк. Алар озак торырга исәпләгәннәр, ахры. Тирә-якны дача хәленә китергәннәр, йомшак мебельләр, комфортны күреп хәйран калдык.

7 август, 1943 ел.

5 августта безнең гаскәрләр Орел һәм Белгородны азат иттеләр. Мондый вакытта шигырь язасы килә. Гасырлар буена онытылмаслык көннәр!

Дөнья әле моңа кадәр Курск дугасындагы шикелле гигант сугышны күргәне юк иде!»

Фронт газетасында эшләүчеләр солдат-шагыйрь Нәгыйм Хафизовны батырлыгы, кыюлыгы һәм тырышлыгы белән мактап искә алалар. Ул Бөек Ватан сугышыннан соң зур әсәр язу өстендә эшләгән. Әмма үлем аның бу планын тормышка ашырырга ирек бирмәде.

Нәгыйм Хафизовның әсәрләре күп түгел. Ләкин алар сугыш чорын, аның героикасын гәүдәләндерүе белән әһәмиятле.

Альберт Айнетдинов

ЮЛЛАР БАТЫРЛЫККА ЧАКЫРДЫ

ФРОНТ ГАЗЕТАЛАРЫ БИТЛӘРЕННӘН

„Хәрби журналист, — дип яза сугыш кырыннан язучы Абдулла Әхмәт,— оборона вакытында да, һөҗүм вакытында да алгы сызыкта. Дошман обороналарын беренче булып өзүче, аңа беренче ударлар ясаучы батырларны күреп, алар белән сөйләшә һәм әле генә булып үткән вакыйгалар турында фронт газетасы өчен материаллар оештыра. Мондый кайнар көннәрне ул сугышчы да, оештыручы да, кирәк булса, командир да булып китә...» [1]. Әйе, хәрби язучылар һәм журналистлар, бер окоптан икенче окопка күчеп, дошман уты астында, халкыбызның каһарманлыгын күрсәткән тарихи сәхифәләрне җыйганнар. Бөек Ватан сугышында татар теленда 16 фронт газетасы чыкканлыгы билгеле. Уртача алганда да, фронт газеталары битләрендә халкыбызның сугыш кырында күрсәткән каһарманлыгы турында төрле жанрдагы 300 меңнән артык материал басылып чыккан. Фронт газеталары хәтта республикабызның үзәк китапханәләрендә һәм архивларында да юк, ә бары тик аерым саннары һәм подшивкалары сугыш ветераннарында бар, тулы саннары исә үзәк хәрби архивта гына саклanган. Бик ихтимал, газета битләрендә сугыш кырында батырлык күрсәткән яки корбан булган әтиләребез, абыйларыбыз һәм апаларыбыз турында әлегә безгә билгеле булмаган истәлекләр бардыр. Ул тарихи сәхифәләрне ятим калып үскән балаларга, сугыш кырларында ирләрен, сөйгәннәрен югалткан хатын-кызларга җиткерү — ул безнең изге бурыч.

МӘСКӘҮ ЯНЫНДАГЫ СУГЫШЛАРДА

1942 елның җәендә, алда әйтелгән фронт газеталары чыга башлагач, хәрби хәбәрчеләр, язучылар 1941 елда тиңдәшсез батырлык күрсәткән кыю сугышчыларны эзләп очерклар, мәкаләләр яза башлыйлар. Фронт газеталарында Бөек Ватан сугышында халкыбыз күрсәткән батырлык сәхифәләре ачык чагыла.

1941 елның җәендәге сугышларда катнашкан лейтенант Сөләйман Ибраһимовка багышланган корреспонденциясен М. Садри «Ватан намусы өчен» газетасында бастырган. Менә аның кыскача эчтәлеге:

Гитлерчыларның һөҗүм итү юлын белү өчен «тел» алырга бурыч куела. Дүрт кешедән торган разведчиклар төркеме, лейтенант Ибраһимов җитәкчелегендә, фашистлар тылына үтеп керә һәм олы юл буендагы куаклар арасына урнаша. Озак көткәннән соң, бер машина күренә. Төз ыргытылган граната үз эшен эшли — машина әйләнеп төшә. Разведчиклар дошман капитанын әсир итәләр. Лейтенант Ибраһимов үз алдына куйган бурычны намус белән үти [1]. Бу сугышчан эпизод лейтенант Ибраһимов тормышыннан кечкенә бер күренеш.

1941 елның июль аенда казанлылардан торган 18 нче укчы дивизия Орша шәһәре янында чолганышта кала һәм каты бәрелешләрдә күп сугышчылар һәлак була. Шунда 91 нче, 127 нче, 134 нче укчы дивизияләр дә таркала. Дүрт дивизиядән калган сугышчылардан генерал-лейтенант Болдин И. В. җитәкчелегендә бер берләшмә оештырыла һәм дошман тылында хәрәкәт итә башлый. Корал, азык кулга төшерелә, хәрби тәртип урнаштырыла. Смоленск өлкәсендә берләшмә дошман линиясен өзеп үзебезнең якка чыгу операциясен әзерли. Төп бурыч — тылдан һәм алгы сызыктан бер үк вакытта удар ясау. Ләкин разведчикларның элемтә урнаштыру өчен ясаган тырышлыклары уңышсыз тәмамлана.

[1] «Кызыл Татарстан», 21 июль, 1944 ел.

[1] Лейтенант Сөләйман Ибраһимов Әлки районының Иске Салман авылында туган, сугышның азагына кадәр алгы сызыкта була, үндүрт мәртәбә яралана. Батыр сугышчы Ибраһимов Кызыл Йолдыз, I, II Дәрәҗә Ватан сугышы, «Кызыл байрак» орденнары белән бүләкләнә.

Бу кыен бурыч С. А. Таһиров белән К. Н. Осиповларга тапшырыла.

И. В. Болдин «Тормыш сәхифәләре» китабында сугышка кадәр үк разведчик булган офицер Таһировка шундый характеристика бирә: «Таһиров Татарстанда туган, әмма ул рус телендә яхшы сөйләшә... Аңа 30 яшьләр тирәсе, озын буйлы, каратут йөзле. Ул ягымлы һәм кеше белән тиз аралаша торган, тәҗрибәле, куркусыз разведчик» [1]. Таһиров һәм Осиповларның дошман тылына рейдлары турында Риза Ишморат «Ленин ордены» дигән очерк яза.

9 августның иртәсендә Таһиров белән Осипов, крестьян киемнәре киеп, атка атланып юлга чыгалар. Разведчиклар урманны 2—3 сәгать үтәләр һәм, атларын калдырып, маршрут буенча акрын һәм саклык белән көпә-көндез хәрәкәт итәләр. Бу хәрби хәйләнең бер төре дә: үзләрен «җиңелмәс» дип масайган фашистлар көндез узган-барганга әллә ни игътибар итми. Разведчиклар, җиргә сыенып, берничә машиналар колоннасын үткәрәләр. Дошман сакчыларын читләтеп үтеп, кичкә таба алар фронт линиясенә якынлашалар. Менә соңгы, ләкин иң кыен чакрымнар. Караңгылыкта кеше күләгәләре күренә һәм аерым-аерым әйтелгән рус сүзләре дә ишетелә. «Йөрәк урыныннан чыгардай булып сикерә башлады, күңел йомшарды...» — дип хәтеренә төшерә Таһиров, истәлекләрен сөйләгәндә.

Тавышсыз-тынсыз окоплар читенә җиткәч, Осипов үзебезнең кызылармеецка мөрәҗәгать итә:

— Ипташ, атма, без — партизаннар!

Әмма кызылармеец окоп казыганда куйган мылтыгына үрелә башлый. Моны аңлап, Таһиров яшен тизлеге белән мылтыкны читкә этәрә. Шуннан Таһиров һәм Осипов рәхәтләнеп кулларын кысалар.

Шушы ук төндә разведчиклар белән генерал Конев сөйләшә. Чолганыштан чыгу планы төзелә, ә Таһиров һәм Осипов операция планы белән яңадан үз берләшмәләренә кайтырга приказ алалар. Разведчикларны юлга чыгар алдыннан яңадан генерал Конев кабул итә. Шушы әңгәмә турында «Правда»ның махсус хәбәрчесе О. Курганов болай яза:

«Сез ничек үз берләшмәгезгә кайтырга уйлыйсыз? — дип сорады разведчиклардан командарм. Таһиров көлемсәреп куйды һәм җавап бирде:

— Бәрелешсез кайтырга уйлыйбыз» [2].

11 августның таңында Таһиров белән Осипов чолганыштан чыгу операциясен генерал-лейтенант Болдинга тапшыралар. Операциянең уңышлы үткәрелүе нәтиҗәсендә 1654 кешелек берләшмә Кызыл Армия сафына кушыла. Шушы оста үткәрелгән рейдка Баш командующийның 270 санлы 20 август 1941 ел приказы багышланган. Казан егете, кыю разведчик Таһиров С. А. Ленин ордены белән бүләкләнә [1].

1941 елның көзендә Совет Армиясе илбасарларны сизелерлек югалтуларга дучар итә. Фашистлар Ленинградны да һәм көньяк нефть районнарын да ала алмый. Шушы вакытта дошман «Тайфун» операциясен башлый — Мәскәүгә таба 77 немец-фашист дивизиясе һөҗүмгә килә. Искиткеч авыр шартларда илебезнең йөрәге — Мәскәү янында совет сугышчылары зур патриотизм, тиңдәшсез ныклык һәм кыюлык күрсәтә. Бөтен совет халыклары белән бергә Татарстан уллары да арысландай көрәшәләр. Мәскәү районының Белый Раст һәм Крюково арасындагы рубежда казанлылардан торган 352 нче укчы дивизия канлы көрәш алып бара.

Мәскәүне яклаучылар арасында Ватан сугышына кадәр Казан типографиясендә эшләгән наборщик, ә соңыннан полк штабы начальнигы капитан Әгъзәм Булгаков зур осталык белән командалык итә. Кыю офицер Ә. Булгаковка Афзал Шамовның «Мәскәү яныннан Кенигсбергка кадәр» дигән мәкаләсе багышланган. Менә шуннан бер өзек:

«1941 ел. Мәскәү янында каты, дәһшәтле сугышлар бара иде. Полк, немец гаскәрләренең көчле басымы астында, тигезсез сугышлар белән чигенә иде. Сугышның хәлиткеч минутларында полк командиры сафтан чыкты. Полк белән командалык итүне капитан Булгаков үз кулына алды. Немецлар үзләренең танклар белән ясаган атакаларын көчәйткәннән-көчәйтә бардылар.

— Безнең Ватаныбыз очсыз-кырыйсыз, ләкин безнең чигенергә урыныбыз юк! Безнең артыбызда Мәскәү! — диде Булгаков үзенең сугышчыларына.

Алар ул көнне немецларның ун атакасын кире кайтардылар. Гитлерчыларның дистәләрчә танклары, ут һәм корыч чәчеп, аларның окоплары өстеннән берничә мәртәбә үттеләр, ләкин Булгаков сугышчылары үз позицияләрендә калдылар, дошман пехотасын үткәрмәделәр.

Кич белән Булгаков полкны контратакага күтәрде һәм аны немецлар өстенә алып китте. Сугыш алмаш уңышлар белән төнгә кадәр дәвам итте. Нәтиҗәдә аны Булгаков җиңү белән тәмамлады. Сугыш кырында немецларның яндырылган танклары, үтерелгән йөзләгән солдатлары һәм офицерлары калды. Шуның өстенә йөзләп пленный да алынды.

Төнлә белән полкның күзәтү пунктына бригада командиры килде һәм, рус халкының гадәте буенча, Булгаковны кочаклап, каты итеп өч мәртәбә үпте.

— Приказны үрнәк рәвештә үтәвең өчен рәхмәт! — диде ул аңа...» [2].

---

[1] И. В. Болдин. «Тормыш сәхифәләре». Хәрби нәшрият. М. 1961 ел. 131 бит.

[2] «Красная звезда» газетасы. 16 август, 1941 ел.

[1] Хәзер запастагы полковник Таһиров С. А. Казанда яшь һәм яшьләр арасында зур патриотик тәрбия эше алып бара.

[2] «Алга, дошман өстенә», 18 май, 1945 ел.

Фашистлар, зур югалтуларга карамастан, йөз дә унҗиде башлы елан сыман,

Мәскәү шәһәрен уратып алырга, аны буарга барлык көчләрен куялар. Үзләренең «мактаулы» дивизияләрен, «сс» башкисәрләрен ташлыйлар. Ул дәһшәтле көннәр турында фронт газетасына җибәргән хатында гвардия лейтенанты Мәхмүт Рәҗәпов болай язган: «... Мәскәү янындагы сугышларда минем взводыма немецларның 18 танкысы ябырылды, ләкин мин каушамадым. Бу сугышта немецларның 5 танкысын җимердем...» [1]. Кыска, ләкин ачык итеп язылган хаттан күргәнебезчә, совет солдаты куркып һәм каушап калмый, ә хәрби осталык белән дошманны каршы ала һәм җиңеп чыга.

Дошманның диверсантлар группасы Мәскәү янындагы күперне шартлату өчен атака ясый. Сержант Кәрим Мөхәммәтов югалып калмый, кызылармеец Афанасьев һәм Рокыя Кәримовалар белән оборона оештыра һәм диверсантларга каршы ут ача. Өч совет сугышчысы иллегә якын дошманга каршы тора һәм күперне саклап кала. Сугыш кырында гитлерчыларның унлаган үле гәүдәсе кала. Шулай кичәге колхозчы һәм эшче дошманның арт сабагын укыта [2].

1941 елның октябрь-ноябрь айларында дошманның көче сынганлыгы ачык күренә. Ул көннән-көн үсә барган каршылык киртәләрен очрата. Илбасарлар башка һөҗүмгә күчә алмыйлар. Әнә шул корычтай нык, батыр сугышчылар арасында көчле рухлы, ялкын йөрәкле Казан егете политрук Закир Бохараев та була. Ул үз ротасын көненә унар тапкыр, өер булып килгән дошман яуларына каршы, атакага күтәрә. Бохараев сугышчылары Совет Армиясенең һөҗүм башлаган көннәрен зур шатлык белән каршы алалар.

«Җиңү байрагы» газетасыннан укыйбыз: «6 декабрь. Менә шул төнне политрук Закир Бохараев үзенең саперлар ротасы белән дошман оборонасындагы мина кырларыннан совет пехотачылары һәм танклары өчен юл ачарга китә... Кешеләр, төн шундый салкын булуга карамастан, күбесенчә, яланғач кул белән эшлиләр...

Иртә белән безнең гаскәрләр, һөҗүмгә күчеп, Бохараев саперлары ясаган юллардан үтәләр» [1].

«Немецларны Мәскәү янында тар-мар итүгә мин дә катнаштым, — дип яза фронт газетасына лейтенант Л. Шәрипов. — Бу вакытта мин рядовой разведчик идем әле. Шулай бер көнне командирыбыз безне чакырып алды да сугышчан задание бирде. Без дошманның ерак түгел җиргә урнашкан безнең частьларыбызга өзлексез атып торган орудиеләренең кайда икәнлеген белеп кайтырга тиеш идек.

Төнлә белән 4 разведчик, лейтенант Габбасов командалыгында, заданиене үтәргә киттек. Төн караңгы, һич нәрсә күренми. Тик ара-тирә дошман ракеталары гына һаваны яктырталар. Менә без калкулыкка якынлашабыз. Һичбер тавыш ишетелми, тынлык. Алда лейтенант, аның артыннан без, җирдән шуышып, чокырга төшәбез. Бездән 200 метрлар ераклыкта землянкадан төтен күренә. Тукталабыз. Лейтенант миңа бер яктарак күренгән кара түмгәк янына барып, аның нәрсә икәнлеген белеп килергә куша. Җирдән шуышып түмгәккә якынлашам. Күрәм: минем алдымда немецларның пушкасы тора, ә аның янында бер немец йоклый. Шул вакытта, үзем дә сизмәстән, автоматтан атып үтерәм дигәндә, башыма уй төште: тукта, мин әйтәм, моңа атсам, башкалары землянкадан чыгарлар да иптәшләремне һәлак итәрләр. Без моны тере килеш алып китәрбез,— дим.

Тиз генә барып бу турыда лейтенантка хәбәр итәм. Шулай итеп, без дошман орудиеләренең кайда икәнлеген белеп алабыз һәм сак кына барып башына капчык кидерәбез дә немецны чокыр астына сөйрәп төшерәбез. Менә бер вакыт ул, ничектер җай китереп, ямьсез тавыш белән кычкыра башлый. Без тиз генә яңадан аның авызын томалыйбыз, ләкин немецлар бу тавышны ишетеп алалар һәм котлары очып, землянкадан йөгереп чыгалар да төрлесе-төрле якка ата башлыйлар. Ә без, чокыр аслап, үз юлыбызга юнәләбез. Барыбыз да исәнсау килеш, «тел»не штабка алып кайтып тапшырабыз» [2]. Сугышчан бурычны үр-

[1] «Ватан намусы өчен». 4 декабрь, 1944 ел. М. Рәҗәпов Кызыл Йолдыз, 1 Дәрәҗә Ватан сугышы һәм Богдан Хмельницкий орденнары белән бүләкләнгән.

[2] «Ватан намусы өчен». 1 май, 1945 ел. К. Мөхәммәтов сугышка кадәр 1 нче Май районының Киров исемендәге колхозда эшләгән. Р. Кәримова Казанда мәктәп директоры булган.

[1] «Җиңү байрагы». 20 август, 1945 ел. Югарыдагы өзек л-т А. Салеевның «Казан егете» исемле очеркыннан китерелде.

[2] «Ватан намусы өчен». 21 март, 1944 ел. Соңыннан Л. Шәрипов укырга җибәрелә һәм офицер була. 1944 елда ул батырлыклар күрсәткән өчен яңадан Кызыл Йолдыз һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә.

нәкле үтәгән өчен Л. Шәрипов Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Мәскәү янында дошманны тар-мар итү сугышларында Фатих Мифтахов [1], Гани Хәйбуллин [2], Харис Мусин [3], Хәбиб Юсупов [4], Рәхим Фатыйхов [5], Фарваз Хәсәенов [6], Абдулла Нуруллин [7] һәм татар халкының меңләгән уллары батырлык үрнәкләре күрсәтәләр. Алар үзләренең каннарын илебезнең йөрәге— Мәскәү өчен түгәләр. Шушы каһарманнар турында хәрби журналист Шәрәф Мәдәррис сокланып һәм горурланып менә ничек язды:

Эх, шул килеш кинәт җиргә катып
Һәйкәл булып басып калсачы, —
Туган җирен канга, тиргә батып
Яулап алган татар солдаты [8]!

СТАЛИНГРАДНЫ САКЛАГАНДА

«Сталинград! Никадәр батырлык һәм горурлык бар бу сүздә, — дип яза фронтовик К. Гаделшин (Г. Кутуй). — Синең өчен барган каты сугышлар көнендә, немецлар тарафыннан тупка тотылган, бомбалар астында калдырылган көннәрдә күрдем мин сине. Ләкин син, Сталинград, безнең көчебезне, куәтебезне чагылдыргандай, бирешмәдең һәм син, батыр шәһәр, җиңеп чыктың» [9]. Идел буенда дошманны тар-мар итү җиңел булмый. Без ул авыр сугыш көннәрен оныта алмыйбыз. Сталинград баһадирларының исемнәрен горурланып искә алабыз.

Сержант Петя Королев отделениесе күп милләттән тора. Алар бер семья булып каннарын кызганмыйча Идел далаларын саклыйлар. «Кызыл Армия» газетасы менә шул отделениенең батырлыгын түбәндәгечә яктырта.

«Сталинград өчен барган көрәш вакытында Хәбиб әле тик снарядлар ташып торучы гына иде. Ящик-ящик снарядлар ташыды ул. Авыр ящикларны өстерәп, кирпеч ватыклары өстеннән үрмәләргә дә, пулялар выжлап торган ачык урыннарны йөгереп-йөгереп үтәргә дә туры килде аңа.

Баш өстендә дошман самолетлары... Якында гына бомбалар ярыла, биек стеналар гөрселдәп ава...

Караңгы төн. Ату тавышы бер минутка да туктамый. Ракеталар, тирә-юньне яктыртып, салмак кына җиргә төшәләр. Ракета очкан саен, җиргә ябышырга һәм үрмәләп хәрәкәт итәргә кирәк. Снаряд ящигы кулларны талдыра.

Хәбиб орудие янына килеп җитсә, ни күрсен: орудие тик тора, аның янында кемдер ыңгыраша. Наводчик Зөфәр, кара кашлы матур үзбәк егете, каты яраланган. Иелеп караса, отделение командиры Петя Королев үлгән...

— Сәлимов, ориентир вышка... — Яралы Зөфәр Турсунов, Хәбиб аның яраларын бәйләгәндә, шулай дип кенә әйтә алды.

Ракета яктысында тригонометрик вышка ачык күренеп калды. Хәбиб орудиесен турылап куйды.

Төнлә хәрәкәт итүче укчылар алга узып киттеләр. Хәбиб белән бергә снаряд ташучы Федченко да килеп җитте.

— Турсуновны санротага илт, снарядларны тизрәк ташы, безнең хәл турында батарея командирына аңлат, — диде аңа Хәбиб. Үзе, бераз арткарак китеп, шнурны тартты. Снаряд чыжылдап очты. Тагын... тагын.

Таң алдыннан, орудие расчетына яңа кешеләр килгән вакытта, Хәбиб һушын югалтып, снаряд гильзалары арасында ята иде...» [1].

Менә шундый баһадирлыкның тагын бер мисалы.

КЫЗЫЛ АРМИЯ

Идрис Исмәгыйлов, унбишләп иптәше белән, ачык далада траншеяда ята. Разведчиклар китергән мәгълүматларга караганда, шушы урында немецларның танк һөҗүмнәре көтелә. Шуңа күрә безнең сугышчылар яна торган сыекча тутырылган шешәләр, гранаталар әзерләп куялар.

Менә дошман танклары якынлаша. Исмәгыйлов белән украин егете Сидоренко, гранаталар тотып, алар киләсе юлга шуышалар. Кинәт бер-бер артлы көчле шартлау яңгырый һәм дошманның ике танкысы туктап кала. Бераздан тагын берничә танк өстендә төтен баганасы күтәрелә. Менә шулай дошманның атакасы кире кайтарыла һәм каты яраланган Исмәгыйлов аңын югалта [2].

1942 елның август һәм сентябрь айларында Идел буенда аеруча зур куркыныч туа. Биредә илебезнең бәйсезлеге һәм азатлыгы хәл ителә. Безнең гаскәрләргә дошманны туктату, бер адымга да чигенмәү бурычы куела.

«Бер адым да чигенмәскә!» дигән лозунг астында сугышчылар арасында политик эш алып барыла. Мәсәлән, батарея комиссары кече политрук Мөхәммәт Едиханов сугыш алдыннан кызылар-

---

[1] «Алга, дошман өстенә». 5 апрель, 1945 ел. Ф. Мифтахов Татарстанның Теләче районы, Урта Мишә авылында туган.
[2] «Ватан өчен». 27 апрель, 1943 ел.
[3] Шунда ук.
[4] «Кызыл Армия». 11 октябрь, 1945 ел.
[5] «Кызыл Армия». 8 сентябрь, 1945 ел.
[6] «Җиңү байрагы». 19 август, 1945 ел.
[7] «Фронт хакыйкате». 26 июнь, 1944 ел.
[8] Шунда ук.
[9] «Кызыл Армия». 4 февраль, 1945 ел.

[1] «Кызыл Армия». 18 сентябрь, 1945 ел. Сәлимов Хәбиб госпитальдә терелеп яңадан сугышларда катнаша һәм Берлинга барып җитә. Ул дүрт орден һәм 3 медаль белән бүләкләнә.
[2] «Ватан намусы өчен». 4 август, 1945 ел.

мецларны дошман үтә алмаслык киртә булырга чакыра. Моны туган ил таләп итүен һәр кеше аңлый. Сугышчылар үз бурычларын менә ничек үтиләр:

«Комиссар Едихановка 13 кешедән торган кечкенә генә төркем белән 250 немецка каршы героик көрәш алып барырга туры килә. 14 совет сугышчысы 160 фашистны үтерә, әмма үзләре бары тик бер генә кешене югалталар. Едиханов житәкчелегендә барган бу каты бәрелешне генерал күзәтә һәм аларның каһарманлыгына хәйран кала. Алар бөтенесе дә орденнар белән бүләкләнәләр, ә Едихановның үзенә, аның оста командирлыгын тәкъдир итеп, Александр Невский ордены бирелә». ...Сапер, коммунист Хәйрулла Шакиров Сталинград янында йөзләгән мина куя. Аның миналарына эләгеп дошманның өч танкысы шартлый [1]. Пулеметчик Сәлимгәрәй Әхмәтҗанов бер сугышта гына 27 гитлерчыны дөмектерә [2].

14 сентябрь кичендә Купоросное һәм Краватка районындагы рубежда 13 кешедән торган күп милләтле группа өстенә алтмыштан артык гитлерчы ташлана. Өч көн, өч төн сугыш бара. Фашистлар 34 үле гәүдәләрен калдырып чигенергә мәҗбүр булалар. Шунда татар егете С. Галимҗанов Сталинградта корбан булган этисе өчен дошманнан үч ала [3].

Бөтен дөньяга билгеле булган Сталинград трактор заводында татар халкының уллары сугышканнармы соң? Бу сорауга кыска, ләкин кызыклы бер хәбәр җавап бирә.

«Татарстанда туып үскән, Урал шахталарының берсендә шахтер булып эшләгән Рәхиб Хәсәншин гражданнар сугышы вакытында атаклы Беренче Атлы армиядә эскадрон белән командалык иткән.

Буденныйчы — атлы гвардеец улы Мансур Хәсәншин Бөек Ватан сугышында катнаша һәм артиллерия батареясы белән командалык итә. Сталинградны саклау өчен каты сугышлар вакытында Мансур Хәсәншин бигрәк тә зур батырлыклар күрсәтә. Сталинград трактор заводын, изге Иделнең һәрбер карыш җирен күкрәге белән саклап, яшь офицер-артиллерист Хәсәншин, үзенең батареясы белән, дошманның 28 танкысын, 9 артиллерия батареясын һәм 800 гә якын гитлерчыны юк итә...» [4].

Ирләр белән бергә йөзләгән татар кызлары Сталинградны саклыйлар. Роза Вәлиева-Деткова хәзер Матбугат йортында эшли, ә ул 1942 елның җәендә үз теләге белән сугышка китә. Зенитчы Роза өчен Сталинград сугышы җиңел булмый, күп кенә иптәшләре аның күз алдында һәлак булалар, әмма ул югалып калмый, һәр вакыт зенит орудиесе расчетларына самолетларның дөрес координатларын күрсәтә.

Медицина хезмәте лейтенанты Сара Камалова Буа шәһәрендә яши, ә сугыш башлану белән Кызыл Армия сафына баса. Ул Сталинград шәһәрендә 11 гитлерчыны юк иткән. Яраланган 7 сугышчы белән чолганышта калгач, аларны 20 километр сазлык аша алып чыккан. Командование аны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкли.

Сталинград сугышының алгы сызыгында комсомоллар һәм коммунистлар торалар. «Мин Сталинград сугышына коммунист булып керергә телим», — дип яза гаризасында Мәскәүне саклауда катнашкан татар егете Вазыйх Фатыйхов. Партиягә кабул ителгән көнне арыслан йөрәкле бу егет кыюлык күрсәтә һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә [1].

Совет Армиясе кискен һөҗүмгә күчәр алдыннан — 1942 елның ноябрь аенда гына да төрле милләттән 550 кеше партия сафына алына. Алар арасында 120 татар, 95 казакъ, 57 үзбәк һәм башкалар була [2].

Дошманны Идел далаларыннан куганда коммунистлар тиңдәшсез каһарманлык күрсәттеләр. Алар арасында — Советлар Союзы Геройлары Зәки Шәймәрдәнов, Фәхрази Галиев, Камил Якупов, Фәхри Гайнетдинов, Нәкыйп Сафиннар... Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллинның 38 нче укчы дивизиясе Идел буенда дан казана. Аңа герой шәһәр исеме бирелә. Шуны да әйтергә кирәк, сталинградчылардан беренче фашист генералын плен алучы да Гани ага Сафиуллин була [3].

Чолганыштагы дошман гаскәрләрен тар-мар итүгә бертуган Мостафиннар да катнаша. Шамил — орудие командиры, Исмәгыйл — наводчик, Габид — орудие коручысы. Алар бер ай эчендә немецларның 4 танкысын һәм 200 ләп немец солдатын һәм офицерын юк итәләр [4]. «Азизов Фәйзи — шофер, — дип яза Ибраһим Гази (псевдонимы — л-т И. Зарипов). — Ул ташыган бензин белән безнең самолетлар оча, танклар йөри. Ул китергән сугыш припаслары дошман өстенә ут булып явалар...» [5].

Сталинград сугышының соңгы көннәрендә батырлык күрсәткән бик күп сугышчылар турында да фронт газеталарында материаллар бар. Менә алар: разведчик Фәһим Галимов [6], коммунист

---

[1] «Ватан намусы өчен». 7 апрель, 1945 ел. Х. Шакиров Чепья районының Арбор авылында туган. Ул Сталинградтан Берлинга кадәр 7 мең мина куя һәм 9 мең дошман минасын зарарсызландыра.

[2] «Ватан намусы өчен». 28 март, 1945 ел.

[3] «Ватан намусы өчен». 8 сентябрь, 1944 ел. С. Г. Галимҗанов Сталинградта 56 фашистны юк итә. Ул Берлинга кадәр житә һәм аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

[4] «Ватан намусы өчен». 2 февраль, 1946 ел.

[1] «Кызыл Армия». 17 декабрь, 1944 ел.

[2] СССРның Үзәк хәрби архивы. Ф. 32, 26734 тасвирлама. 4 эш. 12—13 битләр.

[3] «Алга, дошман өстенә». 3 март, 1944 ел.

[4] «Совет сугышчысы». 24 июнь, 1944 ел.

[5] «Кызыл Армия». 5 апрель, 1945 ел.

[6] «Кызыл Армия». 5 апрель, 1945 ел.

Нияз Зарипов[1], старшина Габделбарый Хәбибрахманов[2], комсомолец Газиз Яруллин[3], майор Шәмсетдин Бәдретдинов[4] һәм башкалар.

1943 елның 3 февраль иртәсендә Мәскәү радиосының дикторы Левитан халкыбызга шатлык хәбәре җиткерә: «Сталинград бөҗрәсында калган дошман гаскәрләре тар-мар ителде». Ул көннәрдә «Рус армиясе дөньяны таңга калдырды»,— дип язды «Санди экспресс» газетасы (Англия). «Совет Армиясенең тиңдәшсез батырлыгы гасырлар буенча онытылмаячак», — диелә «Нью-Йорк геральд Трибюн» газетасының 43 ел, 5 февраль санында (АКШ).

Хәзер Лондон шәһәренең иң матур мәйданнарының берсенә Волгоград исеме бирелгән. Парижда Сталинград исемендәге метро станциясе һәм мәйдан бар. Анда шкатулкада Мамай курганыннан алып кайтылган туфрак саклана. Франциянең патриотик уллары һәм кызлары язучы Жан-Ришар Блокның ялкынлы сүзләрен онытмаганнар. «Тыңлагыз, парижаннар! Фашистларның 1940 елның июнь аенда Парижга беренче булып бәреп кергән 100, 113, 295 нче укчы дивизияләре Сталинград янында юк ителгәннәр — руслар Париж өчен үч алды. Руслар Франция өчен үч алыр».

Сталинград янында дошманның җиңелүе сугыш барышында тамырдан үзгәреш башлану иде. Совет сугышчылары үзләренең хәрби осталыклары үсүен күрсәттеләр. Идел буендагы бәрелеш техника сугышы гына түгел, ә ике капма-каршы ихтыярның да көрәше иде. Менә шунда совет сугышчысы бөтен дөньяны гүзәл сыйфатларын күрсәтеп хәйран калдырды.

Дәвамы бар.

---

[1] «Ватан намусы өчен», 7 октябрь, 1944 ел. Н. Зарипов республикабызның Октябрь районы, Кәкре Атау авылында туган. Ул күп орденнар һәм медальләр белән бүләкләнгән.

[2] «Суворовчы», 4 сентябрь, 1944 ел.

[3] «Фронт хакыйкате», 17 март, 1945 ел.

[4] «Ватан намусы өчен», 20 июль, 1944 ел. Ш. Бәдретдинов сугышка кадәр Казан шәһәренең Волков урамында торган.

Ш. Зәйни

ФРОНТТА ОЧРАШУЛАР

ЯҢА ГАЗЕТА

Бу хәл 1943 елда, Октябрь бәйрәме алдыннан булды. Мин хезмәт иткән 1 нче Украина фронты гаскәрләре, Киевне алгач, Житомир, Коростень юнәлешендә гитлерчыларны кысрыклауларын дәвам иттерделәр. Дошман, безгә каршы үз резервындагы барлык танк частьларын ыргытып, Совет Армиясенең һөҗүмен ничек кенә булса да тоткарларга, Киевне яңадан кайтарып алырга маташты. Совет армиясе Житомир һәм Коростеньны вакытлыча калдырып чыгарга мәҗбүр булды. Безнең 141 нче дивизия Житомир янындагы Черняхов станциясенә чигенде. Без МТС биналарына урнаштык. Фашистлар безне аннан да бәреп чыгарырга тырыштылар. Ләкин, максатларына ирешә алмыйча, кире чигенергә мәҗбүр булдылар.

Бу вакытта мин пулемет взводы командиры ярдәмчесе һәм рота парторгы идем. Шулай бер көнне, атышлар тынып торган арада, батальон штабына газеталар алырга бардым. Анда миңа, башка газеталар белән берәттән, тагын бер яңа газета биреп җибәрделәр. Ни күзләрем белән күрим: газета татар телендә басылган. Исеме — «Ватан намусы өчен». Анда басылып чыккан материаллар арасында Гали Хуҗи һәм Мөхәммәт Садри шигырьләре дә бар. Газетаның соңгы битеннән аның редакторының исемен эзләргә тотындым. Күзем Риза Ишморат дигән сүзләргә төште. Блиндажга кайттым да Риза агага хат язарга утырдым. Иң җылы, иң кадерле сүзләремне юллыйсым килә иде аңа. Ләкин безгә дошман белән тагын берничә тапкыр якалашып алырга туры килде. Хат икенче көнне генә язылып бетте. Мин Риза агадан җавап көтеп яши башладым.

Әмма аннан хат килгәнче шактый вакытлар үтте. Без Черняхов станциясен бер тапкыр калдырып чигендек, аннары, көтмәгәндә һөҗүм итеп, яңадан кайтарып алдык. Гитлерчылар, станцияне турыдан һөҗүм белән алып булмаслыгын абайлап, аны унбиш-егерме чакрымнан читләтеп үттеләр. Без дошман тылында торып калдык һәм Совет Армиясе һөҗүмгә күчеп, Житомир, Винница өлкәләрен азат иткәнгә кадәр, Украина партизаннары берләшмәсенең куркусыз командиры Ковпак частьлары белән берлектә, дошман тылында гитлерчыларны тар-мар итү сугышларында катнаштык.

Көннәр бер-бер артлы уза торды. Тик аларның берсе дә миңа Риза агадан хат-хәбәр алып килмәде.

КӨТЕЛМӘГӘН ОЧРАШУ

1944 елда Славута шәһәрендә Риза Ишморатның үзе белән очрашырга насыйп булды.

Минем, элек үзем хезмәт иткән дивизиядән китеп, Славута шәһәрендә урнашкан

Зәйни Шаһимораторов Мәскәү, Сталинград, Курск шәһәрләре өчен барган сугышларда катнашты. Беренче Украина фронты составында Прага шәһәрендә сугышны тәмамлады.

запас полкның партбюросында эшли башлаган чагым иде. Шунда безгә Казаннан, Татар дәүләт академия театрыннан Асия Масагутова, Рокыя Ибраһимова һәм башка артистлар составында махсус концерт бригадасы килеп төште. Шул уңай белән миңа фронт политидарәсенә барырга туры килде. Анда мин сугышка хәтле партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре булып эшләгән Р. Хәмидуллин белән очраштым. Без, иске дусларча, кул бирешеп күрештек. Бер-беребездән хәл-әхвәл сораштык, Казанны, анда үткәргән вакытларны искә алдык. Ул хәзер фронт политидарәсендә эшли икән. Шуннан файдаланып, мин аңардан «Ватан намусы өчен» газетасы һәм аның редакторы Риза Ишморат турында, редакциянең кайда урнашуы турында сорадым.

— Монда алар, Славутада,— дип, Хәмидуллин миңа редакциянең адресын ук язып бирде.

Мин килеп җиткәндә, капка төбендә кемнедер көтеп торган машина менә-менә кузгалырга тора иде. Шул вакыт йорттан Мөхәммәт Садри килеп чыкты һәм әлеге машинага таба юнәлде. Аны күрүгә мин:

— Мөхәммәт, синме бу?! — дип кычкырып җибәрдем. Моны ишетүгә ул җәһәт кенә борылды да күз ачып йомганчы минем яныма килеп басты. Ләкин без аның белән иркенләп, җәелеп китеп сөйләшә алмадык. Мөхәммәт миңа: — Ярый, хуш хәзергә, Зәйни дус! Минем алгы сызыкка юл тотуым. Газетага хәбәрләр әзерлисе бар. Яңадан күрешергә язсын! — диде дә, машинага утырып, күздән дә югалды. Мин аны кул болгап озатып калдым һәм редакция урнашкан бина ишеген ачып кердем. Редакция дисәң — редакция, типография дисәң типография буларак көйләнеп җитмәгән бу бинаның бер башында — өстәл сыман нәрсә янында — Риза ага, бар дөньясын онытып, полоса укып утыра иде. Менә ул, ишектән керүчегә күтәрелеп карамыйча, кырку гына тавыш белән:

— Ничә тапкыр язарга кирәк? Ник бу хәрефне алыштырмадың? — дип сорады һәм алыштырылырга тиешле әлеге «гөнаһлы» хәрефне зур итеп полоса читенә язып куйды. Минем, уенын-чынын бергә кушып: «Белмәдем бит, Риза абый! Белгән булсам, килеп алыштырган булыр идем»...— дип җавап кайтаруыма, ул кинәт урыннан калкынып, солдат елгырлыгы белән өстәл артыннан сикереп торды. Без, кочакларыбызны җәеп, бер-беребезгә ташландык. Аның погоннарында өлкән лейтенант йолдызлары җемелди, күкрәген орден, медальләр бизи. Ул минем хатны алган, үзе дә җавап язган. Ләкин миңа гына аның җавабын алып укырга насыйп булмаган.

Шул чак, кулына ниндидер кәгазьләр тотып, редакциягә шагыйрь Гали Хуҗи килеп керде. Мине күрүгә, бирегә ни өчен кергәнлеген дә онытып:— Зәйни, бу син түгелме соң? Валлаһи, син бит бу! Менә сиңа югалган кешең! — дип кочаклап ук алды. Ул чактагы шатлыкны, сугышта утны-суны кичкән һәм көтмәгәндә очрашкан солдатлар шатлыгын сөйләп-аңлатып бирерлек көчкә ия булган сүзләр бармы икән?!

Полкыбызга Казаннан артистлар килүен әйтеп, мин аларны концертка чакырдым. Алар бик теләп риза булдылар. Ә Риза ага безнең полкка минем белән үк килде. Башта мин аны полк командирының политик эшләр буенча урынбасары һәм партбюро секретаре белән таныштырдым. Аннан Асия Масагутова һәм Рокыя Ибраһимова урнашкан бүлмәгә алып кердем.

Кичке концертны бергәләп карадык. Руснық атаклы җырчысы Русланованың фронтка килеп биргән концертын исәпләмәгәндә, сугышта бу безнең беренче тапкыр зур концерт тыңлавыбыз иде. Рокыя Ибраһимованың баянда уйнавын, моңлы итеп җырлавын бөтен зал йотылып тыңлады һәм көчле алкышлады.

ХӘБӘРЧЕЛӘР КИҢӘШМӘСЕ

Риза ага белән безнең икенче очрашуыбыз Тернополь районындагы бер авылда булды. Көннәрнең берендә мине полк штабына чакырып алдылар да, фронт политидарәсенә хәбәрчеләр киңәшмәсенә барырга куштылар. Бару белән Риза аганы эзләп таптым. Ул инде капитан иде. Муеннан эшкә чумган. Әлеге киңәшмә дә аның инициативасы белән чакырылган. Барлык оештыру эшләре аның җилкәсендә. Гали Хуҗи һәм Мөхәммәт Садриның да туктап, озаклап сөйләшеп торырга вакытлары юк...

Бу киңәшмәдә мин өлкән язучыбыз Госман ага Бакиров белән дә очраштым. Беренче бөтендөнья сугышының ачы газапларын татыган, гражданнар сугышы дәһшәтләрен башыннан кичергән, Ватан сугышына кадәр укытучы булып эшләгән, балалар өчен драма әсәрләре язган өлкән педагог һәм әдип Сталинград сугышларында миномет батареясы белән командалык иткән һәм шул батареяның парторгы булган. Киңәшмәдә сөйләнгән докладларны, чыгышларны ул зур дикъкать белән тыңлый. Аңа караганнан соң, үзеңне син сугыш кырында итеп түгел, мәктәптә, класс өстәле янында басып торган кебек хис итәсең.

Киңәшмәгә башкорт әдипләреннән Гыйлемдар Рамазанов һәм Гали Ибраһимов та килгән иде. Соңыннан алар белән бергәләп төшкән рәсемебезне Риза ага «Ватан намусы өчен» газетасында бастырып та чыгарды.

Фронт политидарәсе начальнигы генерал С. С. Шатилов белән очрашуыбыз киңәшмәнең иң кызыклы, иң истәлекле минутлары булды. Үзенең чыгышын ул бик кечкенә нәрсәләрдән башлап китте дә халыкара хәл, совет сугышчылары алдында бу этапта торган бурычлар турында сөйләүгә күчте. Киңәшмәдән соң да без аның күңелләребезгә кереп калган ялкынлы сүзләре тәэсирендә яшәдек.

Киңәшмә узгач, мин Риза агалар янында берничә көн кунак булдым. Риза ага минем «Ант» дигән шигыремне һәм «Сакта булган мажара» исемле скетчымны алып калды. Озакламый алар газетаның ике санында бер-бер артлы басылып чыктылар.

БЕРЛИН — ПРАГА

Германиянең Заган шәһәренә килеп урнашкан «Ватан намусы өчен» газетасы редакциясенә Риза агалар янына мин янә сугылдым. Бу вакытта мин политработниклар хәзерли торган кыска сроклы курсларны тәмамлаган һәм Өченче гвардия Армиясенең 287 нче укчы дивизиясендә батальон парторгы булып хезмәт итә идем. Бик күпергә теләсәм дә, бу килүемдә Риза аганы редакциядә туры китерә алмадым. Ул Берлин өчен барган сугышлар зонасына киткән булып чыкты. Редакциядә мин Гали Хуҗи, Мөхәммәт Садри һәм Усман ага Бакиров янында кунып, Берлинга юл тоттым. Ул чакта 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре Берлинга төньяк-көнчыгыштан, 1 нче Украина фронты гаскәрләре көньяк-көнчыгыштан һөҗүм итә иде. Безнең Өченче Армия частьлары да Одерны, Шпреены кичеп, Берлинның көнбатыш өлешенә барып чыктылар. Потсдам районында алар 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре белән кушылдылар һәм Эльба буенда союзниклар армияләре белән очраштылар.

Шундый кайнар көннәрнең берсендә Чехословакия халкының баш күтәрүе хакында хәбәр алдык. Чехлар, радио аша мөрәҗәгать итеп, Совет командованиесеннән ярдәм сорады. 1 нче Украина фронты командованиесе генерал-полковник В. Н. Гордов командалыгындагы безнең Өченче Армияне, генерал-полковник А. С. Жадов командалыгындагы Бишенче Армияне һәм генерал-полковник П. С. Рыбалко командалыгындагы Өченче танк Армиясен Прагага ярдәмгә җибәрде. Аларның өчесе дә гвардия Армияләре иде. Чехословакияне Германиядән аерып тора торган Рудный таулары, калын урманнар аша үтеп, без Праганы фашистлардан коткарырга ашыктык.

8 нче һәм 9 нчы майда безнең гаскәрләр капитуляция актына буйсынырга теләмәгән илбасарларга каршы сугышалар иде әле. Бу сугыш каты, ләкин кыска булды. Фашистлар, коралларын ташлап, совет сугышчылары алдында тез чүгәргә мәҗбүр булдылар.

Праганы азат итешүдә катнашкан солдат буларак, совет һәм чех халыкларын мәңгегә дуслаштырган кайбер мисалларга тукталып үтәсем килә. Чех туганнар безне, үзләрен фашизм коллыгыннан азат итүчеләрне, кочак җәеп, шатлык яшьләренә күмелеп каршы алдылар. Лауни шәһәрендә бәйрәмчә киенгән кешеләр: картлар һәм карчыклар, егетләр һәм кызлар, кулларына төрле ашамлык һәм эчемлекләр тотып, безгә сый-хөрмәт күрсәтергә тырыштылар. Прага залларының берсендә безнең өчен зур концерт куелды. Цирк артистлары, махсус программа әзерләп, азат итүчеләр хөрмәтенә сокландыргыч чыгышлар ясады.

«ВАТАН НАМУСЫ ӨЧЕН» ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕНДӘ

Шуннан соң Риза ага белән безнең тагын бер очрашуыбыз Австриянең башкаласы Венадан ерак түгел, Штоккерау шәһәрендә булды. Бу вакытта мин офицерлар запас полкында хезмәт итә идем. Риза ага минем кайда икәнлегемне сорашып белгән һәм Штоккерауга мине «Ватан намусы өчен» газетасына эшкә чакырырга килгән иде. Ул инде майор чинында. Теге чакта Берлин урамнарында барган сугышларда яраланган. Хәзер исә госпитальдән ныгып, тазарып, терелеп чыккан. Йөзе шат, күзләрендә елмаю чаткылары... Мине ул Вена шәһәренә алып китте. Мин редакциядә эшли башладым. Газета рус, украин, татар, үзбәк, казакъ телләрендә чыга. Баш редакторы — С. Жуков. Аңардан тыш һәр газетаның үз редакторы бар. Аларның һәркайсы баш редакторның урынбасары булып санала.

«Ватан намусы өчен» газетасының татарчасын иң башта шагыйрь Әхмәт Ерикәй чыгара башлаган. Язучы Газиз Иделле дә редакциягә килеп, анда шактый вакыт эшләп киткән. Мин килгәндә редакциядә Риза агадан тыш, Гали Хуҗи (җаваплы секретарь), Мөхәммәт Садри, Госман ага Бакиров һәм журналист Габдулла Шәриповлар эшли иде. Озакламый Госман Бакиров белән Габдулла Шәрипов, демобилизацияләнеп, туган җиргә кайтып киттеләр. Аларның берсен Кемерово егете Шәйхи Әптерәшитов, икенчесен мин алыштырдым.

Газета өч көнгә бер тапкыр чыга. Риза ага газета чыккан көнне кичен безне үз янына җыя да киләсе сан өчен нәрсәләр эшләргә кирәклеген аңлата, һәркайсыбызга конкрет эш йөкли. Без үзебезгә тапшырылган бурычны җиренә җиткереп үтәү өчен бөтен көчебезне куябыз. Гали Хуҗи белән Риза ага миңа русча язылган мәкаләләрне татарчага тәрҗемә итәргә булышалар. Мөхәммәт Садри һәм Шәйхи Әптерәшитов хәрби частьларга чыгып китә. Газета эшеннән бушаган араларда үз әсәрләребезне ижат итәбез. Гали Хуҗиның «Россия», «Гражданин, солдат, шагыйрь» поэмалары, Госман Бакировның «Ут» повесте, «Каенсарга кайту» хикәясе, Мөхәммәт Садриның «Ай турында баллада»сы, генерал Рамазанов турындагы очерклары, минем «Имән әкияте» дигән балладам, «Жиңү язы» исемле нәсерем, Шәйхи Әптерәшитовның герой сугышчылар турындагы очерклары менә шул чагында туды.

Бу редакциягә килгәч миңа украин шагыйре Андрей Малышко, рус язучысы Борис Горбатов, шагыйрь Илья Френкель, үзбәк драматургы Зиннәт Фәтхи белән дә якыннан танышырга туры килде.

Риза ага белән без Венаның атаклы «Бург» театрында Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясен, немец драматургы Г. Лессингның «Зирәк Натан» дигән драматик әсәрен карадык. Даны бөтен дөньяга билгеле Вена операсы театрында Д. Вердинең «Отелло»сын тыңладык. Венаның сәнгать һәм табигать музейларында булдык, аларда тупланган җәүһәрләр бездә беркайчан да онытылмаслык матур тәэсир калдырды. Шенбрун паркында Италия походы чорында полководец Суворов яшәгән манараны, Венаның үзәк каберлегендә бөек композиторларга салынган һәйкәлләрне тамаша кылдык. Бу каберлектә Бетховен, Моцарт, Шуберт, Франц Зуппе, Брамс, аталы-уллы Штрауслар күмелгән. Аларның һәйкәлләрен чәчәкләр бизи. Шул чәчәкләр уртасында су атып торган фонтаннан бу дәһиларның үлемсез моңнары яңгырап торгандай тоела.

Венада чакта без А. П. Чехов һәм М. Горький әсәрләрен немец теленә тәржемә итүче Гиршман атлы антифашист драматург белән очраштык. Ул безгә Чехов әсәрләрен ничек тәрҗемә итүе, аларны кайсы театрларда куйдыруы хакында сөйләде, Чеховның аңа язган хатларын укыды. Аннан соң ул безне Венадагы комедияләр театрына чакырып, Австрия артистлары башкаруында Чеховның «Дядя Ваня» спектаклен күрсәтте.

БЕР СЮРПРИЗ

Венада яшәгәндә минем исемдә калган кызыклы очрашуларның берсе — Австрия Коммунистлар партиясе тарафыннан уздырылган бер кичәдә катнашуым булды.

Бөек Октябрь революциясенең 28 еллыгын каршылап, редакциябездә тантаналы бәйрәм мәҗлесе уздырдык та яшәгән җиребезгә кайттык. Кайту белән Риза ага миңа үзе белән бер җиргә барырга тәкъдим итте.

Торган урыныбыздан ерак булмаган «Симпель» дигән кабарега барып кердек. Без килеп керүгә, сәхнәгә бер кеше килеп чыкты да залны Октябрь революциясенең 28 еллыгы белән тәбрик итте. Аннан сәхнә алдындагы оркестрга ым какты. Оркестр Советлар Союзы гимнын уйный башлады. Без, бөтен зал белән бергә, аягүрә торып бастык. Гимн уйналып беткәч, әлеге кеше Октябрь революциясенең дөньякүләм әһәмияте турында доклад ясады. Аңа залдагылар гөрләтеп кул чаптылар. Аннан соң ул сәхнәдән төшеп безнең яныбызга килде һәм тантана мәҗлесендә катнашуыбыз өчен рәхмәт әйтте. Оратор Австрия Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты члены булып чыкты. Үзәк Комитет Вена шәһәрендәге барлык кабареларда, залларда шушындый кичәләр үткәрә икән. Ул кичәләргә Совет Армиясеннән дә кунаклар чакырылган. Аларның берсенә Риза ага да чакырылган булган. Әмма, бер сюрприз булсын әле дип, миңа ул серне алдан ачмаган. Кичәнең икенче бүлегендә Вена артистлары рус, украин, белорус, грузин биюләре белән берәттән, татар, башкорт һәм башка милләтләрнең биюләрен дә башкардылар.

....1946 ел ахырында, демобилизацияләнеп, без туган-үскән җиргә кайтып киттек. Кайтканда Риза Ишморат һәм Гали Хуҗи белән бергә, Венгрия, Румыния җирләре аша уздык. Мәскәүдә шагыйрь Әхмәт Фәйзидә кунак булганнан соң Казан туфрагына аяк бастык.

Хисам Камалов

БЕЗНЕ НАМУС УТКА КЕРТТЕ

Мин 1943 елның ноябренда сугышка алындым. Суслонгерда берничә ай хәрби өйрәнүләр үткәч, безне туры алгы сызыкка — 2 нче Балтик буе фронтының Пушкин таулары дигән урынына китерделәр. Ә 1944 нең июль аенда инде зур һөҗүмгә күчеп, берничә каланы алдык. Әмма Латвия чиген үткәндә мине беренче мәртәбә дошман угы җиргә егып калдырды.

Госпитальдән чыккач, Латвияне азат итү сугышларында катнаштым. Танкка каршы ата торган 76 мм пушка батареясында элемтәче булдым. Шул чакта икенче мәртәбә авыр яраландым. Миңа бары 18 яшь иде. Кыскасы, Курляндия сазлыкларында бик күп кан-яшь түктем, шуңа күрәдерме, ул җирләр миңа хәзер дә якын...

●

1

Латвия — синдә яшь чагым
Калды минем, акты каным.
Тик язмышны мин әрләмим,
Дәгъва белән каһәрләмим,
Әрнесә дә ипсез күңел.
Юк, дим, приказ гына түгел,
Ил каршында бурыч йөртте,
Безне намус утка кертте.

2

Күпләр өчен синең җирең
Сират күпере булды. Кире
Чыгалмады алар уттан.
Баш куйдылар яман уктан.
Тик очраклы исән калып,
Алар каршында сүз алып,
Батырлыгың сөйләү читен.

Ватан өчен корбан итү
Яшь гомерне — аннан зуррак
Батырлык юк! Булма чукрак!

3

Качып үлем уеныннан
Сыендым җир-куеныңа.
Җирең мәрхәмәтле, төкле.
Әмма кайчак тамак илтте
Мине сезнең ихатага.
(Әйтми булмый бу хакта да.)
Латышлар шәп сыйладылар,
Саранланып тормадылар...
Бик тә эшчән уңган халкың,
Шундук сиздем матур холкын:
Алар алдашуны белми,
Һич тә урлашуны белми,
Йозак та юк, угры да юк,
Бер-берсенә ышаныч күп.
Шуңа сокландым исә мин —
Барысын күргән россиянин.

4

Сезгә ирек яулап үлгән
Солдатларның рухы, беләм,
Югалмаган, балкый төсе.
Ирекнең була төрлесе.
Шуны уйлап, яраларым
Сызлавыннан арынып ятам.
Нәрсәгәдер Курляндия
Кырларын мин сагынып ятам.

1974.

ШАГЫЙРЬНЕҢ БӨЕКЛЕГЕ

1976 елның 26 апрелендә татар әдәбияты классигы Габдулла Тукайның тууына 90 ел тула. Республикабызның культура тормышында зур вакыйга булган бу бәйрәмне әзерләү һәм үткәрү өчен Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов җитәкчелегендә республика комиссиясе төзелде. Комиссия составында партиянең Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Н. И. Демидов, ТАССРның культура министры Ә. С. Миндубаев, танылган шагыйрьләр Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, прозаик Габдрахман Минский һәм башка җәмәгать оешмаларының вәкилләре бар.

Партиянең Татарстан өлкә комитеты бюросы карары белән расланган юбилей планында билгеләнгәнчә, халкыбызны шагыйрьнең иҗаты белән киңрәк таныштыру, татар әдәбиятының реалистик үсешендә тоткан зур ролен, рус, татар һәм башка халыклар арасындагы дуслыкны пропагандалау өлкәсендәге хезмәтләрен күрсәтү күздә тотыла. Моның өчен Г. Тукай әсәрләрен күбрәк бастырып чыгару, аның портретларын, скульптура бюстын, шагыйрьнең тормышына багышланган фотоальбом, төрле сувенирлар, маркалар, конвертлар, открыткалар һ. б. эшләү планлаштырыла.

Журнал редакциясе үзенең укучыларын юбилейга әзерлекнең барышы белән таныштырырга теләде, һәм журналның җаваплы секретаре юбилей комиссиясе председателе М. Х. Хәсәновка берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.

Җ а в а п л ы с е к р е т а р ь: Мансур Хәсәнович, Габдулла Тукайны бүгенге татар поэзиясенең юлбашы дип әйтсәк, аны тарихи шәхескә генә әйләндерү булып калмасмы? Тукай иҗатының бүгенге көн әдәби хәрәкәтендә катнашы бармы? Булса, сез аны нидә күрәсез?

М. Х. Х ә с ә н о в: Шагыйрь Сибгат Хәкимнең матбугаттагы бер чыгышын хәтерлисездер. Тукайларны эзлим, дигән иде ул. Шагыйрь әдәбиятка килгән яшь көчләргә Тукай югарылыгыннан карап бәя бирә. Алар иҗатында Тукайдагыча гражданлык хисләрен, поэзия осталыгын күрергә тели. Димәк, Тукай иҗаты бүгенге көн әдәбиятының үсеш дәрәҗәсен билгеләүдә катнаша. Тукай критерийлары бүгенге әдәбиятка партия тарафыннан куелган таләпләргә органик өлеш булып кергән. Шуңа күрә шагыйрь иҗатына тарихчылар өйрәнә торган әдәби мирас дип кенә карарга ярамый. Ул бүгенге әдәби процесста актив катнаша. Әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең иң яхшыларына ел саен Г. Тукай исемендәге республика премияләре бирелү — ул үзе шуны күрсәтмимени?

Бу премиягә лаек булган кешеләр арасында татар совет әдәбияты һәм сәнгатенең иң күренекле шагыйрь һәм прозаиклары Әхмәт Фәйзи, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нәкый Исәнбәт, Ибраһим Гази, Фатих Хөсни, Габдрахман Әпсәләмов, Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, композиторлары Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһанов, Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин, Александр Ключарев, Мансур Мозаффаров, Рөстәм Яхин, Әнвәр Бакиров, рәссамнары, скульпторлары һәм сәхнә осталары Бакый Урманче, Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов, Николай Кузнецов, Эрнст Гельмс, Әнәс Тумашев, Хәлил Әбҗәлилов, Илһам Шакиров, Шәүкәт Биктимеров, Хәзби Фазлуллин, Ширияздан Сарымсаков, Шәхсәнем Әсфәндиярова, Наилә Гәрәева, Ринат Таҗетдинов, Айрат Арсланов, Фәхри Насретдинов, Марсель Сәлимҗанов, Ревдар Садыйков һ. б. бар.

Җ а в а п л ы с е к р е т а р ь: Республикабызның әдәбият, сәнгать ияләренең Тукайга багышлап иҗат иткән нинди яңа әсәрләре халыкка җиткерелә?

М. Х. Х ә с ә н о в: Тукайның тормышы, аның иҗат батырлыгы күпләрнең игътибарын җәлеп иткән. Аның шәхесенә, әсәрләренә Әхмәт Фәйзи, Фәрит Яруллин, Әнвәр Бакировлар мөрәҗәгать итеп, зур әсәрләр яздылар. Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты Советлар Союзының зур театрларында куелды, Болгария, Польша, Чехословакия, Монголия, Англия һ. б. илләрдә барды.

Юбилейга әзерлек көннәрендә республикабызның иҗат көчләре зур дәрт белән яңа әсәрләр өстендә эшлиләр. Язучы һәм әдәбият галиме Ибраһим Нуруллин Тукай турында әсәр яза. Ул Мәскәүдә «Молодая гвардия» нәшриятының планына кергән. Аны «Жизнь замечательных людей» сериясендә чыгару күздә тотыла.

Тукайга багышлап композиторларыбыз опералар язалар.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы телевидение һәм радиотапшырулар комитеты «Кырлай» исемле телевизион нәфис фильм эшләп чыгарды. Бу фильмны зур экраннарда да күрсәтәчәкләр.

Җ а в а п л ы с е к р е т а р ь: Ә Тукайның үз әсәрләре укучыларыбызга ничегрәк җиткереләчәк?

М. Х. Х ә с ә н о в: Тукайның кайбер әсәрләре инде басылып та чыкты. Мәсәлән, 1974 елда «Советская Россия» нәшрияты шагыйрьнең бер томлык «Сайланма әсәрләр»ен һәм аерым китап итеп «Шүрәле» поэмасын бастырып чыгарды.

Узган ел Татарстан китап нәшрияты рәсемле аерым китап итеп «Бу кайчак була» шигырен чыгарды. Юбилей уңае белән Г. Тукайның дүрт томлык әсәрләр җыелмасын бастырып чыгару планлаштырылды.

1975 елда Композиторлар союзы Тукай сүзләренә язылган җырлар җыентыгын, Тукай шигырьләре һәм җырлары язылган грампластинкалар чыгаруны күздә тота.

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, шагыйрьнең югарыда әйтелгән дүрт томлыгын әзерләү өстенә, «Тукай турында замандашлары» дигән җыентык, шагыйрьнең тормыш һәм иҗаты турында брошюра чыгарачак.

Җ а в а п л ы с е к р е т а р ь: Галимнәребезнең эшләре моның белән генә чикләнмидер, билгеле?

М. Х. Х ә с ә н о в: Тукай мирасын өйрәнү, шуңа бәйләп күп проблемаларны хәл итү юбилейга гына кайтып калмый, әлбәттә. Габдулла Тукай татар сүз сәнгатен дөнья күләменә алып чыккан шагыйрь. Тукай иҗатына бәйләп, Октябрьга хәтле булган иҗтимагый фикер үсеше проблемаларын өйрәнү дә көн тәртибендә тора. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты, КИЯЛИ, Казан һәм Алабуга педагогия институтлары галимнәре бу проблемалар өстендә күптән эшлиләр, татар совет әдәбиятында һәм сәнгатендә Тукай традицияләрен тикшерәләр.

Җ а в а п л ы с е к р е т а р ь: 1972 елның 5 маенда Татарстан Министрлар Советы Тукай-Кырлай мемориалын төзү турында карар кабул иткән иде.

М. Х. Х ә с ә н о в: ТАССР Министрлар Советы 1974 елның 23 июлендә Г. Тукай мемориалын төзү һәм Яңа Кырлай авылын яңартып коруны тизләтү һәм яхшырту өчен өстәмә карар да кабул итте.

Җ а в а п л ы с е к р е т а р ь: Димәк, бу эш күптәннән башланды?

М. Х. Х ә с ә н о в: Әйе, эш күптәннән башланды һәм план бик зур. Ул шагыйрьнең 100 еллык юбилеена әзерлекне дә искә алып төзелгән. Ә 90 еллык бәйрәмгә аның беренче этабы төгәлләнәчәк.

Җ а в а п л ы с е к р е т а р ь: Бу планның тормышка ашырылуы ничегрәк бара соң?

М. Х. Х ә с ә н о в: Шактый эш эшләнде дә инде. Узган ел көзен район үзәге Арча поселогыннан Яңа Кырлайга кадәр булган 18 км арага каен һәм акация агачлары утыртылды. Арча белән Кырлай арасындагы юлга асфальт җәелә. Аның өчтән ике өлеше эшләнеп тә бетте инде. Кырлайлылар авылларында зур буа ясадылар. Аның ярларына юкә, имән, тал, каен, өрәңге, акация һ. б. төр агачлар утыртып, әйбәт кенә парк ачтылар.

Яңа Кырлай авылын, шагыйрь яшәгән еллардагы үзенчәлекләрен дә саклап, хәзерге таләпләр югарылыгында яңарту күздә тотыла. Узган ел 350 урынлы культура йорты салынып бетте. 320 укучыга исәпләнгән, яхшы җиһазландырылган кабинетлары булган 3 катлы мәктәп салу төгәлләнеп килә. Мемориаль үзәктә кунак йорты, магазин, кафе-столовой, көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты булган сәүдә комплексы эшләнәчәк.

Авылда водопровод, канализация үткәрелә. 3100 метр су торбалары, 2 артезиан коесы инде сафка керде.

Киләчәктә тагын бер зур матур бина салыначак. Анда «Тукай-Кырлай» колхозы идарәсе, авыл Советы һәм элемтә бүлеге урнашыр. Шунда ук укытучылар өчен яңа йортлар да салыну күздә тотыла.

1975 елда музей йортына капиталь ремонт ясалачак. Ә киләчәктә музей өчен яңа бина салу планлаштырылган.

Колхозның материаль-техник базасын ныгытуда һәм экономикасын күтәрүдә дә күп эшләр эшләнә.

Әйдәгез әле, бу саннарны, санап чыгуларны куеп торыйк та, бер ун ел алга күчеп, үзебезне Габдулла Тукайның 100 еллыгына киләбез дип хис итик. Машинабыз асфальт юлдан Яңа Кырлайга бара, ди. Ике ягыбызда куе кара урман. Агач араларыннан Тукай әсәрләренең геройлары — скульпторларыбыз ясаган сыннар күренеп китә. Менә без Яңа Кырлайга килеп керәбез. Яшеллеккә төренгән зур, мәһабәт йортлар яныннан үтеп, чәчәкле юллардан барабыз да һәркем өчен кадерле булган шагыйрьнең музей-йортына керәбез...

Буш хыял яки матур әкият кенә түгел болар. Безнең тормышыбызның чынбарлыгы. Партиябез һәм хөкүмәтебез кайгыртуы нәтиҗәсе буларак, инде төзелеп яткан Тукай-Кырлай мемориалы. Татар халкының бөек шагыйрә хыялланган тормышның бер картинасы.

Хәниф Хөснуллин

Халкы җиккән атта

I

Атлар килә, атлар килә,
Үр артыннан үр менә.
Алар илтә, Апуш, сине
Тукай булыр көнеңә.
Артта Кырлай... Артта Урал...
Уралдан биек нужа:
Дилбегәсен какмыйча да
Килгән атларны уза.
Чаптыр тизрәк, каула, кучер,
Баш өстендә ялгыз ай.
Боек күңелләр күгендә
Габдулла балкыр шулай,
Сөйсәң җырын, сөйсәң телен,
Дөньясын сөйсәң әгәр, —
Тарта үзенә, тарта халкың
Йөрәге типкән шәһәр.
Ә юллары — чакыр-чокыр,
Юлдан авыр — заманы.
Авыр сулап каршы ала
Авыр заман Казаны.

II

Атлар килә, атлар килә,
Көрт аша юллар яра.
Ак атлар — Тукай иҗаты,
Тормышны иңләп бара.
Йөзгә исә, каршы исә,
Азагы бармы җилнең?!
Чорның салкын җилләреннән
Тыны кысыла илнең.
...Атлар килә, атлар килә,
Елдан елларга басып.
Алар өчен гасырлар һәм
Күңелләр түре ачык.
Һәрбер буын, бәйрәм ясап,
Аларны каршы ала.
Эзләрендә Тукай исемен
Йөрткән урамнар кала.
Кырлай, Казан, горурланып,
Бөек улыңа кара:
Халкы җиккән атта Тукай
Дәверләр аша бара.

Чаллы, 1974.

Вәзих Исхаков,
башкорт язучысы

ТУКАЙ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Язучы блокнотыннан

Берничә ел инде генерал Якуп ага Чанышевның тормыш һәм көрәш юлын өйрәнеп, аның хакында документаль повесть язу белән мәшгульмен. Шушы максат белән былтыр көз Урта Азиягә барып, анда Беренче аерым татар бригадасы сугышчылары үткән эзләрдән йөреп, танышып кайткан идем.

Шул сәфәр вакытында хәтсез хәбәрләр ишетергә, кызыклы гына вакыйгалар белән танышырга туры килде. Шуларның берсе Урта Азиядә Тукай белән «очрашу» булды.

...Без, бер төркем язучылар, кечкенә автобуска утырып, Үзбәкстан язучылар союзының иҗат йорты — Дүрмәннән Ташкентка кайтып киләбез. Монда Мәскәүдән һәм башка калалардан килгән кунаклар белән бергә үзбәк язучыларыннан Иркен Насыйров, Гани Җиһангиров һәм шагыйрьләр Сәяр Фәйзуллаев, Азиз Абдразаков һәм Рәззак Әбдрәшитов та бар. Үзара сөйләшәбез. Сүз, билгеле, әдәбият, әдәби бәйләнешләр һәм дуслык хакында бара.

Шунда, сүз арасында, үзбәк шагыйре Сәяр Фәйзуллаев яттан шигырь сөйләргә тотынды. Башлап:

Яз язу, ләкин кызыкма һичвакыт шөһрәткә син;
Бик төренмә, иртәгүк ертык булыр, чүпрәккә син.
Тапмасам шөһрәт, сизалмаслар, димә, күңелемдәген:
Зур тәрәзә бар, дип аңла дөньяга күкрәктә син.

Ул сөйләп бетерүгә, Азиз Абдразаков миңа таба борылды да:

— Кем шигыре бу, беләсезме? — диде.

Алар моңарчы бары үзбәкчә генә сөйләшкәнгә һәм шигырьне дә үзбәк телендә укыганга, мин ни дип әйтергә дә аптырап калдым. Ләкин нәрсәсе беләндер бик таныш, күңелгә бик якын шагыйрьнең шигыре иде бу.

Шунда әңгәмәгә Рәззак Әбдрәшитов кушылды. Әмма сүз белән түгел, ул да шигырь белән:

Яшь вакытта яшьнәдем,
көчле вакытта күкрәдем;
Яшьнәмим дә, күкрәмим дә,
утсыз инде күкрәгем...

Мин кычкырып җибәрүемне сизми дә калдым:

— Габдулла Тукай лабаса!..

Оят булса да әйтим инде, кайчандыр Габдулла Тукай традицияләрендә тәрбияләнеп, кече яшьтән үк аның шигырьләрен ятлап һәм, нихаять, беркадәр вакыт Башкортстан дәүләт университетында Габдулла Тукай иҗаты буенча лекцияләр укып

йөргән кеше булсам да, мин үзбәк шагыйрьләре алдында бөтенләй югалып калдым. Чөнки алар Габдулла Тукай шигырьләрен үз телләрендә яттан күп беләләр һәм гаҗәеп бер ярату белән дулкынланып укыйлар. Өзеп-йолкып «Шүрәле»дән бер өзек китердем дә:

— Мин башкорт язучысы бит, иптәшләр,— дип акланырга ашыктым.

Алар исә шигырь уку белән генә чикләнмәделәр.

— Безгә еш кына татар яшьләре белән аралашырга туры килгәне бар,— дип сөйләп киттеләр.— Ләкин алар Тукай иҗатына гади генә итеп карарга өйрәнгәннәр. Ә бит Тукай шәрыкнең ифрат бөек шагыйрьләренең берсе ул! Безнең өлкән буын әдипләребез Габдулла Тукай әсәрләрен тоташы белән яттан беләләр иде...

Табигый, бу сүзләр тынычлыгымны югалтты. Чыннан да, минем дә күп тапкырлар Казанда булганым бар. Татар яшьләре, бигрәк тә язучылары белән еш кына очрашып торам. Ләкин, кызганычка каршы, аларның Габдулла Тукай турында сокланып, ялкынланып сөйләүләрен нигәдер хәтерләмим.

Бу хәл мине уйга калдырды. Һәм шул чак Башкорт дәүләт университетында укытып йөргән еллардагы бер вакыйга исемә төште. Читтән торып укучы студентларга Габдулла Тукай иҗаты турында лекция укырга тиеш идем. Монда инде барысы да тәҗрибәле, күпчелеге мәктәптә әдәбият һәм ана теле укытучылары җыйналган иде. Шулардан берсе:

— Һәй-әй, Тукайны күпме өйрәнергә була инде?! — дип ычкындырмасынмы.

Лекцияне башларга өлгермәвем сәбәпле, сорарга мәҗбүр булдым:

— Сез, алайса, Тукай иҗатын бик яхшы беләсездер инде?!

— Белмәскә әллә! Бала чактан алып, күпме шул бер Тукайны тыңларга мөмкин!

Кызганыч, әмма бу факт иде. Егерме җиде яше тулар-тулмаста үлгән, шул кыска гына гомере эчендә азмы михнәт чиккән һәм, ниһаять, әдәбиятыбызга үлемсез әсәрләр калдырган, татар әдәбиятының мәңге сүнмәс бер йолдызы хакында әйтелгән сүзләр иде бу...

Лекцияне бөтенләй икенче планда башларга туры килде. Шунда бер нәрсәне аңлап котым очты: әлеге шушы кеше әдәбият укытучысы лабаса? Ул балаларга Габдулла Тукай иҗаты турында ниләр сөйли икән?..

Әгәр Ташкенттагы сөйләшү булмаса, бәлки мин боларның берсен дә хәтерләмәс тә, язмас та идем. Ләкин үзбәк шагыйрьләренең әйткәннәре йөрәгемне тетрәтте һәм кулыма каләм алырга мәҗбүр итте.

Үзбәкстанда «Габдулла Тукай белән очрашуым» моның белән генә бетмәде әле. Ике көннән соң, Бохара шәһәренә баргач, бөек шагыйрь белән тагын да «күрешергә» туры килде.

Чит калада мин гадәттә берүзем йөрергә яратам. Кешеләрдән сораша-сораша, шәһәрнең әле теге, әле бу төбәген карап, танышып йөрүне хуп күрәм. Бу юлы да шулай итәргә булдым. Мине Иске Бохара, аның күп сандагы мәчетләре, әмирнең резиденциясе булган регистан кызыксындыра иде.

Бохара безнең илебездәге иң борынгы калаларның берсе. Ләкин ул артык зур түгел. Бүгенге көндә анда нибары 135 мең кеше яши. Менә шушы шәһәрдә революциягә кадәр бөтен Урта Азия халыкларын изеп яшәгән Бохара әмире Сәлим-хан торган. Монда 130 мәчет эшләп, берничә мең шәкерт укыган, диләр. Бохара ишаннары яшьләрне дин белән агулап, аларның аңын гасырлар буена томалап килгәннәр. Әмма хәзер монда икенче хәл: бай җиһазландырылган Бохара педагогия институтында гына сигез меңнән артык студент белем ала. Ә күпме техникумнар, училищелар һәм башка уку йортлары бар анда!

Әнә шул шәһәрнең иске өлешендә, 1920 елда безнең якташларыбыз — Беренче аерым татар укчы бригадасы сугышчылары Бохара әмиренең гаскәрләрен тар-мар итүдә катнашып, зур батырлыклар күрсәткәннәр. Хөсәен Мәүлетов, Гали Касыймов, Галимҗан Акчурин, Якуп Чанышев, Йосыф Ибраһимов, Александр Тальковский, Кәрим Хәкимов кебек халкыбызның батыр уллары үзләренең исемен мәңге җуелмас данга күмгәннәр.

Монда аларның якты истәлеген саклаган урыннар да юк түгел. Мәсәлән, Бохараның крайны өйрәнү музеенда бу батырларның фотолары куелган.

Бохараның борынгы тар урамнары буйлап бара торгач, төз генә бер урамга

килеп чыктым һәм урам исеменә күз салдым. Анда **«А. Тукаев күчәсе»** дип язылган иде. Үзбәк телендә «га» авазы кыскартылып (әйтик, Газиз — Азиз, Гариф — Ариф) әйтелүен белә идем инде. Димәк, бу Абдулла Тукаев урамы була?

Урамда беренче очраган кешедән сорарга ниятләп, акрын гына атлый бирдем. Ләкин, үкенечкә каршы, урам буп-буш иде. «Әллә берәр ихатага керимме икән?» — дип уйлап кына килгәндә, өлкән яшьтәге бер әбигә тап булдым. Ул ачык калиткадан тышка карап тора иде. Үзбәкчәли сәлам бирдем.

— Ассолам! — диде әби дә үзбәк телендә.

Ипләп кенә сорашырга керештем:

— Бу урамда күптән торасызмы?

— Туа-туганнан бирле.

— Милләтегез кем?

— Еврейка мин. Бохара еврейкасы.

Әби үзбәкчә шул кадәр саф сөйләшә иде, бермәлгә мин хәтта телсез калгандай булдым. Урамның ни өчен Тукаев исеме белән аталуын сорадым.

— Әллә инде,— диде карчык,— мин ул кадәресен белмим. Укыган кеше түгел мин.

Ары киттем. Инде хәзер үземне эчке бер кызыксыну биләп алды. Тагын кемне очратырмын икән, янәсе.

Бу юлы озак барырга туры килмәде. Шулай ук калитка ишеген ачып, бусагада утырган чалмалы картны күргәч, аның янында туктадым.

Сүз иярә сүз чыкты. Янә сораша башладым:

— Бу урамда күптәннән торасызмы, үзегез кай яктан килгән кеше?

— Күптән,— диде бабай.— Мин үзем Бохарада туып үскән кеше. Тукаев олуг кеше булган, диләр...

Юк, мондый җаваплар гына мине канәгатьләндерә алмады. Ни булса шул, әрсезләнеп булса да берәрсенең ихатасына керергә кирәк дип килгәндә, якында гына хихылдап хатын-кыз көлгәне ишетелде. Тәвәккәлләп эчкә үттем.

Ап-ак халат кигән биш кыз көлешә-көлешә пылау ашап утыралар иде. Ят кеше кергәнен күргәч, тынып калдылар.

— Саумысыз, кызлар!

Кызлар бер-берсенә карашып алды. Аннан, «син кем, ни кирәк сиңа?» дигән сыман миңа текәлделәр.

— Аптырамагыз, кызлар, мин ерактан килгән бер мөсафир...

Аларга кем икәнлегемне әйттем һәм баягы сорауларымны кабатладым.

Кызларның өчесе үзбәк, икесе татар кызы булып чыкты. Алар якындагы азык магазинында сату итәләр һәм бирегә төшке ашка кайтканнар икән.

— Тукаев зур шагыйрь булган,— диде кызларның берсе.— Әтием аның турында гел сөйли иде.

— Үзең татарча укый беләсеңме?

— Мин үзбәк мәктәбен тәмамладым. Шулай да Габдулла Тукай шигырьләрен беләм.

Кызлар кызлар инде: шырык та шырык көлә, мине сыйга кыстый башладылар.

— Утырың, әүкат җыең!

Ирексездән тагын Ташкент, тагын да үзбәк шагыйрьләре күз алдыма килеп баскандай булды.

— Тукай бөек ул!..— дигән иде бит алар.

Мәрхүм Габдулла Тукай, билгеле булуынча, бервакытта да тар милләтчелек белән «чирләми». Ул үзенең бөтен булмышы, табигате-холкы һәм иҗаты белән интернационалист, халыклар дуслыгы җырчысы була. Менә шуңадыр инде безнең чорда да ул безгә замандаш булып кала һәм Советлар Союзындагы иң карт калаларның берсендә, шагыйрь туган җирдән бик еракта, аның исеме кушылган урам бар һәм анда үзара тату рәвештә ничәмә милләт вәкилләре яши!..

Гали Халит

ИҖАТ МЕТОДЫ ҺӘМ СТИЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

ИКЕНЧЕ МӘКАЛӘ

I

Гомумән сәнгать стильләренең тарихын иҗат методлары тарихы белән тыгыз бәйләнештә генә күз алдына китерергә мөмкин. Шуңа күрә дә, мәсәлән, индивидуаль стильләр сәнгатьнең, әдәбиятның соңгырак чорларында гына формалашкан күренеш итеп санала.

Сәнгатьтәге нормативлыкның бер күренеше саналган **стиль аныклыгы** (стилевая определенность) нигездә капитализмга кадәрге формацияләрдә барлыкка килгән, ягъни реализмга кадәрге методларга хас нәрсә. Аның характерлы үзенчәлекләре итеп, бер яктан, **дөньяны идеаллаштыруның** билгеле бер ысулына таянуны, ә икенче яктан, **сәнгатьле иҗат ирегенең** булмавын күрсәтәләр. Соңгы момент исә иҗтимагый үсешнең ул чорларында шәхес ирегенең булмавы белән аңлатыла. «Шуңа нисбәтән сәнгатьчә иҗат законнары да иҗат итүченең **индивидуальлегенә** буйсынмаган көч итеп, берсүзсез үтәлергә тиешле **канун** итеп каралган»[1]. Реализм өстенлек итә башлагач, ди Каган, **стиль аныксызлыгы** (стилевая неопределенность) төп принципка әверелә, ягъни сәнгать чараларының алдан табылган, хәзерләнгән системасы кире кагыла, сәнгатьле аңның чынлык диалектикасы һәм сәнгатьле иҗат ирege әйдәүче булып китә. Шул сәбәпле стиль иреклегенә дә киң юл ачыла. Димәк, индивидуаль стильләр — автор шәхесенең үз йөзе, үз индивидуальлеге көчәя, үсә бару нәтиҗәсе. Матур әдәбияттa индивидуаль стиль, автор үзенең әдәби героеннан аерылгач, ягъни бу герой үзе мөстәкыйль төстә яши һәм үз теле белән сөйли башлагач, ачык төскә керә. Поэзиядә лирик герой үз настроениеләрен, үз кичерешләрен гәүдәләндерүче булып мәйданга чыккач, индивидуаль стильләр тәмам ачылып китә. Гомумән, язучының индивидуаль стиле «художестволы иҗатның һәм поэтик сурәтләрнең индивидуаль ирege»[1] өстенлек итә башлау белән үзенә тиешле урынны яулый. Бу күренеш бигрәк тә критик реализм әдәбиятында киң колач ала һәм аңа кадәр яшәп килгән гомуми, норматив стиль кысаларын тирәннән үзгәртә, җимерә.

Критик реализмга кадәр чорларда индивидуаль стильләр бөтенләй булмаган дип нәтиҗә ясарга ярамый, әлбәттә. Монда индивидуаль сәйләмнең аңлы сәнгать факторына әйләнү-әйләнмәү мәсьәләсе беренче булып тора. Мондый факторга әйләнү нигездә XIX—XX йөз-

[1] М. С. Каган. Лекции по марксистско-ленинской эстетике. 1971, 730—731 битләр.

[1] В. В. Виноградов. Проблема авторства и теория стилей. 1961 ел, 56 бит.

ләргә туры килә. Моңа кадәр дә индивидуаль стильләр зур талантлар иҗатында күпмедер күләмдә шактый сизелерлек эз калдырган. Ләкин шулай да алар күп очракларда индивидуаль стильнең билге-элементлары, төсмерләре генә булып торганнар: теге я бу иҗат методының гомуми стиль һәм жанр нормаларына буйсынганнар һәм шул нормаларны тагын да камилләштергән, үстергәннәр, ул нормаларга бөтенлек биргәннәр. Норматив стильләрдә, мәсәлән, жанр стильләренең, ягъни теге яки бу жанр нормаларына бәйле стильләрнең өстенлек итүе күзгә ташлана. «Классицизм эпохасының героик поэмасы югары стильне таләп иткән, ә поэма-бурлеск түбән стиль белән язылырга тиеш дип саналган. Сөйләм стилендәге шундый ук аерымлык ода белән сатира арасында да булган. Художестволы метод буларак, классицизмга хас гомуми стиль үзенчәлекләре, жанрларның канунлаштырылган стильләренә караганда, икенче планга чигенгән. Реализм эпохасында инде без факторларның үзара башка мөнәсәбәтен күзәтәбез... Метод факторы жанр факторыннан өстен булып китә»[1].

Көнчыгышның классик әдәбиятларына күз салганда, аларда да әнә шуңа охшаш нормативлыкны күрергә мөмкин. Аларда да стильләр жанр кысаларында нык сакланган. Газәл, мәснәви, робагый, дастан, кыйсса һ. б. жанрларның үз нормалары, сурәтләү чаралары гасырлар буенча бер язучыдан икенчесенә күчә килгән. Мәсәлән, газәлнең төп эчтәлеге мәхәббәт ләззәте һәм сагышы мотивларыннан гына торырга тиешлеге, дастан-кыйсса сюжетларының, образларының бик аз үзгәреш белән генә әсәрдән әсәргә күчә килүе — болар һәммәсе гомуми стиль норма һәм традицияләренең бик тотрыклы, хәтта консерватив булуы, ә индивидуаль стильләрнең зәгыйфьлеге турында сөйли. Дөрес. Көнчыгышның бөек шагыйрьләре теге я бу жанрны, тема һәм мотивны тагын да үстергән, яңарткан һәм камилләштергәннәр. Ләкин шулай да алар гомуми кабул ителгән стиль кысаларын җимермәгәннәр, ягъни үз стильләрен тудыруда аңлы максатны күзәтмәгәннәр, ә күптән билгеле кысалар эчендә калып, иҗади кыюлык эшләгәннәр.

Бигрәк тә мәгърифәтчелек реализмы һәм романтизм өстенлек итә башлагач, әдәбиятта шәхеснең абруена, роленә, шәхес белән җәмгыятьнең мөнәсәбәтенә игътибар арту нәтиҗәсендә, индивидуаль стильләр өчен дә җайлы шартлар алгарак чыга барган. Романтик әдәбиятта лирик жанрның һәм психологизмның өстенлек алуы да шәхеснең роле көчәюдән аерылгысыз була. Нәкъ шул җирлектә романтик әдәбият, индивидуаль стильләргә юл ачу өчен, элекке чикле нормалар белән көрәш алып бара. Дөрес, романтизм әдәби стильләрдәге нормативлыкны тәмам җимерә алмый. Әмма сәнгатьтә шәхси башлангыч, шәхси ирек өчен ул алып барган көрәшне критик реализм тагын да үстерә. Критик реализмның өстенлек алуы индивидуаль стильләрнең киң колач белән чәчәк атуына юл ача. Критик реализм вәкилләренең иҗтимагый тормыш закончалыкларына һәм кешенең эчке дөньясына бик тирән үтеп керүе моңа кадәр сәнгатьтә какшамас, җимерелмәс итеп каралган норма һәм кысаларны нигезеннән какшатты, үзгәртте. Язучы, чынбарлыкны һәм кешене реаль, тормышчан мөнәсәбәтләрендә сурәтләү өчен, үз тавышы, үз пафосы, үз стиле белән сөйләү иреген алга этәрергә тиеш булды. Шулай итеп, критик реализм индивидуаль стильләргә киң иркенлек бирде, чөнки шуннан башка зур иҗтимагый тормыш стихиясен һәм кешеләр мөнәсәбәтен төрле яклап, тирәнтен ачып сурәтләү мөмкин түгел. Индивидуаль стильләрнең критик реализмда көчәюе художникның чынбарлыкка һәм кешегә эстетик мөнәсәбәте тирәннән үзгәрү нәтиҗәсе иде. Мәсәлән, роман, эпопея жанрларының зур урын алуы һәм аларның элекке чорлардагы проза белән чагыштырмаслык күләмдә киң колач белән чынбарлыкның һәм кешеләр мөнәсәбәтенең күп якларын ирекле сурәтләве электә кабул ителгән жанр нормаларын бер читкә этәрде. Аларда язучының чынбарлыкны сәнгатьле итеп ачудагы яңалыгы, оригинальлеге тулы гәүдәләнде.

Әйткәнебезчә, критик реализм, жанр принципларына корылган стильләрне кире кагып, жанрны әдәби стильнең бер элементы итеп калдырды. Мисал өчен

---

[1] А. Н. Соколов. Теория стиля. 1968 ел. 127 бит.

Көнбатыш поэзиясендәге элегия, ә Көнчыгыштагы газәл жанрларын гына алып карыйк. Озак заманнар тик сагышлы уй-тойгыларны җырлау өчен генә җайлы саналган элегия һәм мәхәббәт темасына гына багышланырга тиеш дип каралган газәл, әнә шул күрсәтелгән тематик чикләнгәнлекне бетереп, кешенең күп төрле кичерешләрен, шагыйрь һәм лирик герой дөньясының төрле якларын чагылдырган форма булып киттеләр. Әйтик, Пушкин поэзиясендәге элегия — ул инде һич тә иске мәгънәдәге элегия түгел. Ул — Пушкин стиленең тик бер элементы гына. Тукай поэзиясендәге газәл дә традицион газәлгә тик формасы белән генә охшый, ә эчтәлеге белән бөтенләй башка. Моның бер мисалы итеп «Көзге җилләр» шигырен искә алу да җитә. Монда мәхәббәт мотивының эзе дә юк, ә газәл формасы — Тукай стиленең бер элементы гына булып кала. Чөнки Пушкин элегияләрендә дә, Тукай газәлләрендә дә, эчтәлек белән бергә, шигъри стильнең элекке, традицион жанр нормаларыннан бөтенләй башка булган, ягъни яңа эчтәлек талэпләренә туры килгән сурәт чаралары өстенлек алган. Димәк, жанр стиле җимерелгән. Бу инде реализм алып килгән ирекле, индивидуаль стиль күренеше иде.

Әмма жанр стильләренең юкка чыгуы — ул әле һич тә жанр традициясе һәм нормаларының бөтенләй югалуы дигән сүз түгел. Берише жанрлар реализмда да үзләренең традицион нормалары белән яшиләр. Мәсәлән, әдәбияттагы баллада, мәсәл, эпиграмма, пародия яки музыкадагы балет кебек жанрларны гына алыйк. Аларның эчтәлеге яңару белән бергә, бик электән үк аларга хас булган жанр билгеләренең дә сакланып килүен күрербез: стильнең төп факторы — балладада сюжет, мәсәлдә аллегорик сурәт һәм мораль, эпиграммада кыска шигъри форма белән әйтелеп, билгеле зат исеменә төбәлгән ачы көлү һ. б. шуның кебек очракларда жанр стиленең кайбер билгеләре тотрыклы булып калуы турында сөйләргә мөмкин. Иҗат методының жанрларга мөнәсәбәте нисби, ягъни жанр методны түгел, ә метод жанрны сайлый, методка карап жанрның урыны билгеләнә. Мәсәлән, романтик стильләр шигырь, ә реалистик стильләр проза жанрларында үзләренең төрле якларын, сәнгатьле алым һәм чараларын тулырак, күбрәк күрсәтәләр.

2

Стильләр үсешенә сәнгатьле сөйләү формалары ноктасыннан караганда, ике чор барлыгын күрсәтәләр: беренчесен поэзия чоры, икенчесен проза чоры дип атыйлар. Әдәбиятта боларның теге я бусы өстенлек итеп яки бер-берсен алмаштырып килергә мөмкин.

Поэзия чорындагы шигъри сөйләмдә тотрыклы һәм традицион гыйбарәләр, алымнар, «формулалар» һәм элекке әдәбияттан алынган өзекләр — «цитаталар» мул кулланыла. Моның бер характерлы үрнәге итеп Көнчыгыш классик әдәбиятын алырга мөмкин. Монда шигырь сәнгатьле сөйләмнең өстенлек иткән формасы булды, һәм аның нык эшләнгән нормалары барлыкка килде. Поэзия чорында аерым шигъри тел яши. Күп сүзләрнең канунлаштырылган, үзләренә беркетелгән мәгънә һәм сурәт билгеләре саклана. Алар төрле язучыларда шул билгеләре белән кулланыла. Әйтик, хатын-кыз матурлыгы сурәтләнә икән, һәр очракта диярлек, ул традицион эпитетлардан, билгеле чагыштыру һәм сыйфатлардан башка була алмый.

Көнчыгыш әдәбиятларында поэзия чоры бик озакка сузылды, һәм аның традицияләре проза чорында да матур әдәбиятның башка тармакларына, жанрларына йогынты ясап торды. Поэзия стильләренең татар проза һәм драматургия стильләренә дәвамлы тәэсир итеп килүен шуның бер гәүдәләнеше дип карарга кирәк. Бу күренешнең тотрыклы дәвамлылыгы берише әдәбиятларда романтик тенденцияләрнең көчле булуына да бәйләнгән. Чөнки романтик тенденцияләр гадәттә поэзия өлкәсендә күбрәк һәм озаграк сакланучан булалар.

Проза чорының нигездә критик реализм үсеше белән бәйле булганлыгы күренә. Аның иң характерлы ягы — поэзия чорына хас нормаларны кире кагуында һәм әдәбияттан кысыклап чыгаруында. Проза сәнгатьле сөйләмнең ирекле прнципларын алга куя һәм милли телнең бөтен тармакларын эченә ала. Проза теләндә сүзнең күп төрле индивидуаль төсмерләрен ачу һәм куллану мәйданы гаять киң. Реализмга ка-

дәрге поэзиядә әле автор һәм герой сөйләмнәре бер-берсеннән аерылмый дияр-лек һәм аны күрсәтү төп максат та түгел. Автор һәм персонаж сөйләмнәренең аермасын күрсәтү — проза стиленең әһәмиятле бер тенденциясе. Мондый аерма шигырьгә тик проза чорында гына керергә мөмкин. Прозада реализм көчәю нәтиҗәсендә, шуның белән бәйле күренеш буларак, поэзиянең прозалашуы тема һәм мотивларда гына түгел, ә тел-стиль чараларында да нык сизелә башлый. Тукайның «Авылда авырып яту» дигән шигыреннән китерелгән бер өзек үзе генә дә моңа үрнәк була алыр дип уйлыйбыз:

Мин әле аурыйм авылда, монда кайттым кыш көне;
Ял итә монда агайлар, җәйдә калган эш көне.
Сызганып, мин дә агайлар белә ялкаулык итәм;
Туйдым инде хәстәлектән, яз көтәм, саулык көтәм.

Бу өзектә (ачык иҗекләрнең чиратлашуыннан башка) традицион шигъри сөйләм нык үзгәргән. Әгәр дә аның ритмик структурасын сүтеп, проза теленә күчерсәк, иң гади сөйләм килеп чыгачак. Әмма шул сөйләм Тукай реалистик стилендә гаять тормышчан мәгънәле шигырь тудыруга хезмәт итә.

XIX йөз азагына табан рус әдәбияты тирәннән прозалашты. Поэзия икенчерәк планда калды. А. Толстой һәм А. Чехов кебек язучыларның әсәрләрендә рус прозасы шигъри сөйләм һәм стиль йогынтысыннан никадәр читләшкәне бик ачык күренде. Бу язучылар үз стильләренең поэзиядән тәмам котылган булырга тиешлеген аңлап иҗат иттеләр. Чөнки кырыс реализм прозаның һәм гомумән әдәбиятның стильләрендәге кырыслыкны да котылгысыз рәвештә талап итә иде. Ләкин реализмдагы бу тенденцияне прозаның бөтен яктан поэзиягә каршы торуы яки аңардан бөтенләй читләшүе дип аңларга ярамый. Проза һәм поэзия заман рухы белән генә түгел, ә стильләре белән дә үзара йогынты ясашып, багланышып тәрәккый итәләр. Чөнки аларның иҗат методларындагы уртаклык, гомумилек сөйләм һәм стиль чараларының төрлелегенә, башкалыгына карап һич тә югалмый.

XIX йөз ахырында рус әдәбиятында проза чоры өлгереп җитсә дә, поэзия чоры да бөтенләй үк артка чигенмәде. Шуның бер кызыклы мисалы булып, ике гасыр арасында бик тә үзенчәлекле шигъри проза стиле мәйданга чыкты. Ул башлап М. Горький иҗатында күренде һәм XX йөзнең беренче чирегендә шактый киң җәелде. 20 нче елларда-гы совет әдәбиятларында урын алган орнаменталь стильне дә шул шигъри проза стиленең бер төре итеп карарга кирәк. Гомумән алганда, мондый фактлар поэзия һәм проза сөйләмнәренең билгеле синтезы барлыкка килү хакында сөйлиләр. Романтизм һәм реализм мөнәсәбәтләренең яңа чорына бәйләнештә шигъри телнең дә яңаруы, проза стиленең дә икенче пафос алуы иде ул. Гомумән, XIX йөз азагында һәм XX йөз башында дөнья сәнгате киң мәгънәсендә лиризм белән сугарыла. Сәнгатьнең төрле өлкәләрендә һәм стильләрендә экспрессивлык характерлы тенденция булып китә. Эмоциональлек һәм экстатиклык[1] киеренке, кискен төс ала. Менә шул процесста иҗат методлары һәм стильләр арасында чикләр ачыклыгы да шактый кими, хәтта югала.

Бу вакытларда поэзия чорына хас лиризмның һәм эмоциональлекнең күп кенә әдәбиятларда кабат күтәрелеп китүе, үзенең элек булмаган сыйфатларын ачып җибәрүе традицияләрнең терелүе, яңаруы гына түгел иде. Мондый лирик уянышны кешелек җәмгыятенең зур тарихи тетрәүләр белән бәйле рухи халәтенең сәнгатьтә бер чагылышы итеп санарга кирәк. Димәк, теге я бу әдәбиятларда поэзия чорының кабатлануын яки дәвам итүен ике гасыр аралыгында дөнья сәнгате кичергән лиризмнан читтә карап булмый.

Югарыда сөйләнгәннәрне истә тотканда, татар әдәбиятында поэзия чорының озаккарак тартылуы һәм аның традицияләре тотрыклы булуы күренә. Безнең проза шигъри сөйләмне тулаем кысрыклап чыгарган чорны үтеп өлгермәде. Аның өстәвенә дөнья сәнгатендә киң колач алган лиризм да һәм, шуның бер төре буларак, рус әдәбиятында көчәеп киткән шигъри проза да аңа йогынты ясады. Шуңа күрә татар әдәбиятында шигъри проза өчен кирәкле шартлар һәм җирлек җитәрлек иде. Анда шигырь стиленә гаять якын торган

[1] Экстатиклык — экстазга бирелү, үтәгырларның гадәттән тыш булуы.

һәм хәтта күп кенә очракларда шигырь жанрының бер төре итеп саналырга хаклы нәсер киң таралды. Бу инде, реализмнан бигрәк, романтизмга хас лирик жанрның активлашуын күрсәтте. Прозада да, драматургиядә дә лиризм үзен көчле сиздерде. Лирик драма формалашты. Аның бер төре турыдан-туры халык поэзиясе яки традицион-шигъри эпос стиле белән бәйләнгән булса («Галиябану», «Таһир-Зөһрә» һ. б.), икенчесе исә XX йөз башы рус драматургиясендә барлыкка килгән лирик-психологик драматургиягә якын торды. Мәсәлән, Ф. Әмирханның «Тигезсезләр»ендә А. П. Чехов драматургиясенең «Сеңелләр», «Акчарлаклар», «Чия бакчасы» кебек үрнәкләре белән аваздашлык табарга мөмкин. Г. Ибраһимовның романтизм рухы белән тирәннән сугарылган прозасында гына түгел, Ф. Әмирхан һәм Ш. Камалның нигездә реалистик стильдә язылган прозасында да поэзия стиленә яки шигъри прозага якынлык — лиризм ачык иде. М. Фәйзи драматургиясендә инде поэзиянең драматургиягә ничек хәлиткеч йогынты ясавы бигрәк тә тулы гәүдәләнде. Музыкаль драма әсәрләрендәге сентименталь стиль һәм прозадагы нәсер стиле 20 нче еллар дәвамында да бик характерлы әдәби күренеш булып калды. Бу факт — безнең әдәбиятта поэзия чорының билгеләре һәм аларның романтизм белән бәйләнеше тотрыклы булуына бер ачык дәлил дә.

3

Хәзерге совет әдәбияты белемендә стильгә бәйләнештә байтак катлаулы мәсьәләләр күтәрелә, һәм аларның күпчелеге хәл ителүне көтә. Стильне аңлау чикләре бик киң икәнлеге күренә: берәүләр: стиль тик үзен тудырган метод белән генә тарихи һәм оригиналь була, икенчеләр: стиль берлеге тик бер метод чикләрендә генә барлыкка килә, ә өченчеләр: стильләр метод кысаларыннан чыгып, чор стиле булып та китәләр һәм интернациональ колач алалар, диләр. Моннан күренә ки, әдәбият белемендә стиль төшенчәсе киң һәм күп төрле мәгънәдә кулланыла икән: аны аерым әдәби әсәрдән алып, язучы иҗатына, бөтен әдәби юнәлешкә, әдәби агымга, чорга һәм милли сәнгатькә кадәр куллану бар. Әмма стильнең төрлелеген яклаучылар арасында да бу мәсьәләгә мөнәсәбәт шактый чуар. Мәсәлән, шуның бер мисалы итеп, чор стиле һәм милли стиль төшенчәләрен аңлауда төрлерәк карашлар яшәгәнлеген әйтергә мөмкин. Кайбер белгечләр чор, заман стиле барлыгын дәгъва итәләр. Ә икенчеләре, сыйнфый көрәш һәм төрле идеологияләр өстенлек иткән җәмгыятьтә мондый стиль була алмый, чөнки ул җәмгыятьнең сәнгать өлкәсендәге каршылыкларын килештерү мөмкин түгел, диләр. «Чор стиле юк, әмма сәнгатьтә үз чорын тудыра торган стиль генә бар»,[1] — ди, мәсәлән, А. Н. Соколов. Гомумән алганда, бөтен бер чордагы сәнгать, әдәбият өчен уртак стиль турында сүз алып бару кыен кебек. Шулай да билгеле бер чорда башка стильләрдән аерылып торган һәм заманның эстетик рухын, пафосын көчлерәк, тулырак чагылдырган стиль турында сөйләү урынсыз түгел. Мәсәлән, рус поэзиясендә Пушкин, бездә Тукай стильләре үз заманнарында өстенлек иткән, ягъни шул мәгънәсендәге чор стильләре итеп каралырга мөмкин. Егерменче еллар совет поэзиясендә, мәсәлән, Маяковский иҗаты белән бәйле стильнең дә шул мәгънәдә каралырга хакы бар. Монда бөек язучының стиле әйдәүче, үрнәк булып торса да, чор стиле дигәндә, бер иҗат методы белән, бер әдәби юнәлеш белән бәйләнештә иҗат иткән язучыларга уртак стиль турында сөйләү отышлырак шикелле. Шул рәвешчә, аерым язучының үтә индивидуаль стиленнән бигрәк, аның стиленең башкаларга якын һәм уртак билгеләрен күз алдында тотканда, чор стиле төшенчәсен бөтенләй кире кагу бик үк урынлы булмастыр. Берише белгечләр чор стиле урынына шул чорда теге я бу күләмдә аерылып торган һәм әйдәүче, төп әдәби методның иң характерлы тенденцияләрен чагылдырган стиль юнәлешен алуны урынлырак саныйлар.

Шуның кебек үк, милли стильгә мөнәсәбәттә дә ике караш бар. Берәүләр милли стильне сәнгатьтәге стиль гомумилегенең, бердәмлегенең иң югары дәрәҗәсе дип аңлыйлар. Ә икенче белгечләр гасырлар буенча үсеп килгән

[1] А. Н. Соколов. Теория стиля. 184 бит.

милли стильләрне бер ноктага, бер бөтен стильгә җыярга тырышуны тарихи чынбарлык белән исәпләшмәү дип бәялиләр. Шулай да ике чиктәрәк торган мондый карашларның бусы хак, бусы хак түгел дип кисеп кую да бик үк дөрес булмас иде. Аларның икесендә дә теге я бу күләмдә хакыйкатькә якын килү бар. Бердәм милли стильне инкарь итү белән бергә, милли традицияләрнең стильдә бик тотрыклы сакланганлыгын һәм шул моментның милли стиль бөтенлеге, бердәмлеге турында фикер йөртергә сәбәп булуын күрсәтәләр [1].

Милли стиль төшенчәсе әдәбиятларның милли үзенчәлегеннән аерылгысыз. Ә милли үзенчәлек исә әдәбиятларның тарихи үсеш процессында туплана килгән идея-эстетик традицияләренең иң тотрыклы, иң яшәүчән һәм алдынгы өлешеннән барлыкка килә, яңа заман билгеләре белән байый һәм яңа заман таләпләренә карап үзгәрә. Шуңа күрә милли стильне һәр вакыт бертөрле итеп, катып калган хәлдә күз алдына китерергә ярамас. Без моның аеруча җанлы мисалларын совет әдәбиятлары тарихыннан күрәбез. Пролетар революциядән соң чәчәк аткан милли әдәбиятлар социалистик реализм стильләрен, һичшиксез, үзләренең милли традицияләре, формалары һәм башка күп төрле сәнгатьле чаралары, буяулары, төсмерләре белән баеттылар, ягъни социалистик реализм җирлегендә үзләренең милли формаларын һәм стильләрен тагын да үстерделәр. Хәтта электә язма традицияләре булмаган әдәбиятлар беренче мәртәбә үз милли форма һәм стильләрен ачтылар. Бу процесста язма әдәбият һәм халык иҗаты традицияләре, һичшиксез, зур роль уйнады.

Милли стильләр турында сөйләгәндә, төп билге булып сәнгатьле, художестволы фикерләүнең милли төсмере, нюанслары торуын истә тотарга кирәк. Ләкин бу билгене абсолютка әйләндерергә ярамый. Чөнки төрле милләт язучылары арасында метод һәм стиль якынлыгы, уртаклыгы — бик борынгыдан килә торган законлы һәм киң таралган күренеш. Әдәбиятларның үзара бәйләнеше фәкать коры идеяләр якынлыгыннан, уртаклыгыннан гына тормый. Идея-эстетик мөнәсәбәтләр, милли кысалардан һәм үзенчәлекләрдән күп читкә чыгып, интернациональ характер алалар. Метод һәм стиль күренешләрендәге уртаклыклар, әлбәттә, иҗтимагый-тарихи һәм идея-эстетик процесснең якынлыгыннан, уртаклыгыннан чыгып каралырга тиеш. Әйтик, рус поэзиясендә В. Маяковский, әрмәндә Е. Чаренц, бездә Һ. Такташ метод һәм стильләренең уртаклыгын, якынлыгын бу шагыйрьләрне әдәбият мәйданына чыгарган иҗтимагый-тарихи процесска бәйле идея-эстетик пафос уртаклыгы белән генә аңлатырга мөмкин. Ни өчен алар бер-берсенә якын һәм ни өчен алар арасында Маяковский тәэсире көчлерәк? — кебек сорауларга шул ноктадан гына беренче җаваплар табылыр. Әмма төрле милли әдәбиятлардагы метод һәм стиль уртаклыгы, якынлыгы, ягъни аларның чын интернациональ төсмерләре һич тә миллилекне бетерү, җимерү исәбенә үсми, ә киресенчә, миллилекнең интернациональ эчтәлеген һәм мөмкинлеген үстерү, баету исәбенә генә була ала. «Һәр милли илдә социалистик реализм, — ди француз язучысы Луи Арагон, — үзенең тамырларын конкрет милли чынбарлыкка батырганда гына гомуми кыйммәткә ия була ала» [1]. Шуңа күрә милли әдәбиятларның һәм культураларның бер-берсенә якынлашуына, интернациональ җирлеге нигуга аларның милли формаларын бетерү, кысыклап чыгару дип караган теорияләрнең тарих белән исәпләшмичә ясалган уйдырма булуы турында сөйләп торасы да юк.

Тулаем алганда, әдәбиятларның һәм аерым язучыларның милли үзенчәлеге методларда түгел, ә стильләрдә тулырак гәүдәләнсә кирәк. Чөнки методлар нигездә чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәтнең төп юнәлешен, эчтәлеген билгеләгән типологик принциплар системасыннан гыйбарәт. «Реализмның, романтизмның һәм бүтән юнәлешләрнең гомуми принциплары сәнгатьнең барлык төрләре өчен бердәм» [2] булуын һич тә онытырга ярамый. Шуңа күрә аларның милли төсмерләреннән бигрәк, уртак сыйфатлары алгарак чыга, аларда эстетик категориянең гомуми билгеләре хәлиткеч

[1] А. Н. Соколов. Теория стиля. 194 бит.

[1] «Генезис социалистического реализма в литературах стран Запада» исемле җыентык. 1965 ел. 211 бит.

[2] «Великая Октябрьская социалистическая революция и мировая литература» исемле җыентык. 1970 ел. 15 бит.

булып кала. Ә стильләр исә шушы гомумилекнең конкрет милли җирлектәге формаларыннан гыйбарәт. Әлбәттә, иҗат методлары милли-тарихи җирлектән югары яки аңа битараф хәлдә була, дигән нәтиҗә ясарга кирәкми. Әйтик, романтизмның да, реализмның да милли үзенчәлекләренә күз йомып булмый. XIX йөздәге рус романтизмы һәм реализмы һич тә инде шул чордагы инглиз яки немец романтизмы һәм реализмы белән бер түгел. Чөнки аларның формалашуы башка-башка милли-тарихи шартларда барды. Бигрәк тә иҗтимагый-идеологик каршылыклар һәм милли аерымлыклар белән тулы җәмгыятьтә бу методларның да милли төсмерләре кискенрәк булуы табигый. Шулай да бу төсмерләр аларның типологик, уртак, генетик билгеләреннән өстен була алмый. Аларның милли үзенчәлеген башлыча стильләр аша күрү җиңелрәк, чөнки методның үзенчәлеге стильләр аша гәүдәләнә. Бигрәк тә инде социалистик реализм әдәбиятларында, иҗат методының идея-эстетик принциплары бердәмлеге тулаем тәэмин ителү җирлегендә, милли үзенчәлек мәсьәләсе башлыча стильләр сферасына карый. Әмма шуның белән бергә милли стильләрнең үзара мөнәсәбәте мәсьәләсе дә безнең әдәбият белеменең көн тәртибенә куелуны көтеп кала.

Әгәр дә без милли әдәбиятлардагы иҗат методларының үзара бәйләнеше һәм йогынтысы тарихи зарур һәм котылгысыз күренеш булуын икърар итәбез икән, шул методлардан аерылгысыз булган милли стильләрнең дә үзара бәйләнешен күрмәү һич мөмкин түгел. Үзебезнең әдәбияттан бер мисал китерик. Мәгълүм ки, Тукай поэзиясе татар шигъри стиленең яңа дәверен ачып кына калмады, ул гомумән төрки поэзияләр тарихында зур яңалык, ачыш һәм алга үсеш факты да иде. Димәк, стильләр, бигрәк тә шигъри стильләр, милли телгә һәм әдәби традицияләргә аеруча бәйле булып күренсәләр дә, аларның милли кысалардан күпкә киң сыйфат-билгеләре барлыгы да күренеп тора. Теге яки бу әдәбият традицияләренең икенче милли әдәбиятка йогынтысы яки күчеше мәсьәләсен караганда, хәтта киң мәгънәсендә стильләр традициясе һәм бәйләнеше турында да сөйләргә мөмкин. Әлбәттә, тел һәм традицияләр ягыннан бер-берсенә якын булган милләтләр әдәбиятындагы стильләр бәйләнешен телләре һәм традицияләре башка-башка булган милли әдәбиятлар һәм стильләр арасындагы мөнәсәбәт белән бер итеп карап булмый. Мәсәлән, татар әдәбиятындагы стильләрнең төрки әдәбиятлардагы стильләр белән уртаклыгы һәм рус әдәбиятындагы стильләр белән бәйләнеше кебек моментлар тарихи-әдәби процессның төрле аспекттагы, төрле пландагы чагылышлары итеп алынганда гына объектив бәяләнергә мөмкин. Беренче очракта телләрнең, эстетик чыганак һәм традицияләрнең бик борынгыдан килгән якынлыгы, уртаклыгы эз салган булса, икенчесендә исә аерым чорларда барлыкка килгән типологик охшашлыкларның роле һәм гомумән әдәби йогынтының билгеләре алгарак чыга. Мәсәлән, Тукай һәм Сабир стильләре арасындагы бәйләнеш белән Тукайның Пушкин яки Лермонтов стильләреннән өйрәнүен әнә шул югарыда әйтелгәннәрнең бер мисалы итеп карарга мөмкин булыр иде.

4

Билгеле булганча, социалистик революция белән әдәбиятка искиткеч зур эпик эчтәлек килеп керде. Башта ул тарихи борылышның һәм революцион массаның патетик образы булып гәүдәләнде. Монда әле субъектив стильләр алгарак чыктылар. Аларда лирик-экспрессив стихия көчле булды. Шулай итеп, революция романтик сәнгатьнең тагын да күтәрелеп китүе өчен кирәкле шартларны һәм пафосны көчәйтеп җибәрде. Азат ителгән шәхеснең халык героикасы белән рухлануы өскә бәреп чыкты һәм революцион романтизмның төп пафосы булып әверелде. Шуңа нисбәтән әдәбиятның төрле жанрларында патетик һәм риторик стильнең хәтта галәм киңлекләренә төбәлгән тавышы яңгырап торды. Бу тавышта революциянең барлык милләтләргә уртак, якын аһәңе яңгырады, әмма аның күп төрле милли тембрлары һәм камертоннары да бар иде. Революция башындагы татар әдәбияты моны тулысынча раслый. Аны да бу чордагы совет әдәбиятларының иң характерлы пафосы булып киткән революцион романтика сугарды. Романтик агымнарның төрле традицион төсмерләре мәйданга чыкты. Берише роман-

тиклар иҗатында һәм стиленда элекке сурәтләр җирлегендә яңа идеяне һәм теманы гәүдәләндерергә теләү ачык иде (Ф. Бурнаш поэмалары, М. Фәйзи драмалары). Алар, күптән билгеле интим-мәхәббәт сюжетларын саклап, шулар аша чорның революцион үзгәрешен күрсәтергә омтылдылар. Ләкин бу романтик агым стиленең артык идиллик һәм сентименталь буяулар белән өртелүе яңа идея пафосын каплап, басып та торды. Романтик агым һәм стильнең тагын бер төре гыйсъянчылык хәрәкәте белән бәйле булды. Монда инде беренче агым стиленә каршы булган тенденцияләр, буяулар күбрәк урын алды. Гыйсъянчы шагыйрьләр үткәндә җәберсетелгән, кыерсытылган гади кешене югары күтәреп, аның искелеккә каршы протестын, нәфрәтен шәхес иреге идеалы ноктасыннан күрсәттеләр (Һ. Такташ, Н. Исәнбәт, К. Нәҗми һ. б.). Бу образ да күп кенә ягы белән үткәнгә бәйле иде әле. Еш кына «мин» булып сөйләгән бу геройга тормышчан конкретлык җитмәде. Аның кыяфәтендә гомумилек, абстрактлык, риториклык ярылып ятты. Шулай да поэзиянең революцион пафосына якын стильне эзләү юлында гыйсъянчылык зур кыюлык күрсәтте. Сөйләү шигыре өстенлек алды.

Революцион чынбарлыкка һәм реализмга бик якын торган романтик агым аеруча нәтиҗәле булды. Бу агым революция алдыннан Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Камал, Г. Ибраһимов, Ш. Бабичлар иҗатында нык сизелә башлаган һәм романтик реализм дип аталырга хаклы әдәби хәрәкәтнең дәвам итүе, үсүе һәм яңа шартларда тирәннән үзгәрүе иде. Аның иң характерлы сыйфатлары аеруча Г. Ибраһимов прозасында һәм эстетик карашларында киң колач алды. Язучының революциядән соңгы әсәрләрендә реализм белән романтизмның көчле синтезы барлыкка килде һәм татар совет прозасында яңа иҗат методының эчтәлеге, юнәлеше һәм стильләре ничек формалаша баруның әһәмиятле үрнәге булды.

Мәгълүм ки, социалистик реализм такыр юлдан гына бармады. Аның стильләре дә даррәү генә күкрәп чәчәк атмады. Кыенлыклар белән тулы эзләнүләр үтә-үтә олы юл табылды. Вульгар социологизм, совет әдәбиятының иҗат методын бик беркатлы, яссы аңлап һәм аны коеп куйган бер фәлсәфи калыпка әйләндереп, барлык стильләрне дә шул калыпка салып кына үлчәгән чакларны да искә төшермичә булмый. Совет әдәбиятының методы бердәм булгач, аның стильләрендә дә бердәмлек булырга тиеш дигән таләп стиль өлкәсендәге традицияләргә һәм яңалыкларга каршы куелды. Әйтик, 30 нчы еллар әдәбиятында «производство темасы өчен көрәш» кебек лозунгларны тормышка ашыруда еш кына вульгар социологизм карашлары хәлиткеч роль уйнау аркасында, татар прозасында, мәсәлән, эпиклык һәм психологизм шикелле әһәмиятле мәсьәләләрнең артка этәрелүен дә онытмаска кирәк.

Билгеле ки, совет әдәбиятының беренче елларында ук аның алдына зур иҗтимагый-тарихи һәм революцион вакыйгаларны киң эпик сурәтләрдә күрсәтү бурычы килеп басты. Классик әдәбиятның, бигрәк тә критик реализмның бай мирасына таянмыйча, ул бурычны хәл итү мөмкин түгел иде, әлбәттә. Эпиклык тенденциясенең көчәюе безнең әдәбияттә беренче нәүбәттә реализм үсү өчен кирәкле шартлар белән бәйләнгән иде. Еллар узу белән совет әдәбиятындагы эпиклык аның төрле жанрларына һәм стильләренә йогынты ясап, аларны тирән үзгәрешләргә китерде. Бигрәк тә проза өлкәсендәге эпиклык һәм психологизм мәсьәләләре социалистик реализмның классик реализмга тирән бәйләнеше барлыгын исбатладылар. Шуның нәтиҗәсе буларак һәм яңа иҗтимагый шартлар тәэсирендә 20 нче елларда ук инде совет әдәбиятында роман жанрының эпик эчтәлеге киңәйде, эпопеяга табан борылыш башланды. Бу инде прозадагы жанр һәм стиль күренешләренең чынбарлыкны киң колачлы итеп сурәтләү юлыннан үсә баруларын күрсәтә иде.

Тәүге елларда совет әдәбиятындагы эпиклыкны инкарь итүләре дә, өзгәләнгән, йолкынган «динамик» стильне аңа каршы куеп, шуны «яңа эпос» дип тәкъдим итүләр дә аз булмады. Шулай ук халык, масса хәрәкәтләрен, образын күрсәтүгә генә басым ясаулар вакыты-вакыты белән аерым әдәби геройның тип-шәхес, характер буларак формалашуын кире кагуга да китерде. Яңа чынбарлык белән нык бәйле социалистик реализм принциплары үсә барган саен,

аерым герой характерын һәм аның психологик дөньясын тулы сурәтләү ихтыяҗы да көчәйде. Шундый геройдан башка совет әдәбиятында эпопея жанрының һәм эпик стильнең югары формаларын тудыру мөмкин түгеллеге ачык аңлашылды. Ләкин бу тенденция һич тә халык хәрәкәтләрен, масса образын сурәтләүне кысыклап чыгару исәбенә булмады, ә нәкъ чын эпосның нигезендә яткан шул хәрәкәтләр, шул образ белән аерылмас, органик мөнәсәбәттә булган герой алга куелды. Шулай итеп, совет әдәбиятында яңа эпосны һәм аның героен тудыру өчен хәрәкәт киңәя барды. Совет әдәбияты тарихында аның дан казанган матур үрнәкләре күп. Шундыйлардан, мәсәлән, М. Шолоховның «Тын Дон» эпопеясе үзе генә дә социалистик реализм эпосының бөтен дөньяга танылган бөек сәнгать әсәрләрен бик тиз арада тудыра алуын исбатлады. Аның үзәгендә гаять катлаулы революцион-сыйнфый көрәшләр аша үткән геройлар язмышы тора. Шулардан аеруча Григорий Мелехов язмышы үзенчәлекле итеп, тормышчан-тарихи фаҗигасе белән киң планда тасвир ителә. Бу фаҗиганең иҗтимагый-тарихи чынлыгы Григорий Мелехов психологиясен революциягә һәм халыкка мөнәсәбәт яктылыгында тирән итеп күрсәтү җирлегендә ачыла. Язмышы гаять трагик бу геройны сурәтләү осталыгына, новаторлыгына ирешүдә М. Шолоховның Л. Толстой шикелле даһилар тудырган эпик традицияләрне, эпик стильне дәвам иттерүе шулай ук зур роль уйнады.

Татар әдәбиятындагы эпиклык һәм психологизм турында сөйләгәндә, бу мәсьәләнең, әлбәттә, үз кыенлыклары һәм үзенчәлекләре барлыгын истә тотарга кирәк. Социалистик революциягә кадәр татар әдәбиятында эпопея жанры һәм аңа хас психологизм традицияләре өлгереп җитмәде. Бу хәлнең совет чорындагы эпиклык һәм психологизм үсешенә дә мөнәсәбәте бар иде. Чөнки эпиклык һәм психологизм реалистик әдәбиятның югары дәрәҗәгә күтәрелү нәтиҗәсе буларак мәйданга килә. Татар әдәбиятының озак вакытлар поэзия чорын үтүе һәм поэзиянең прозага да, драматургия дә көчле тәэсир ясап торуы реалистик эпиклыкка һәм психологизмга кирәкле шартлар өчен бик үк уңай булмады, ә традицион романтизмның һәм хирыс психологизмының[1] тотрыклылыгына күбрәк булышты. Бу тотрыклылык татар совет әдәбиятында да үзен сиздерә килде. (Аның характерлы билгеләрен бүгенге әдәбияттан да табарга мөмкин. Шундыйлардан берсе, мәсәлән, сәнгать, мәхәббәт һәм җыр культының бөтен жанрларда яшәүчәнлеге, аның һәр вакыт лирик ситуация һәм коллизияләрне көчәйтү өчен кулланылуы һ. б.) Шунысы әһәмиятле: совет шартларында татар әдәбиятындагы романтизм һәм реализм сыйфатларының бер-берсе белән керешүе, синтезы методта да, стильләрдә дә тирәнәя барды. Бу ике башлангычның юлдашлыгы метод һәм стильләр структурасында һәр вакыт күренеп торды һәм тора. Егерменче еллар дәвамында ук инде татар совет әдәбияты реализм һәм романтизм синтезы җирлегендә эпик әсәрләр тудыруның матур үрнәкләрен бирде. Бу момент, әйткәнебезчә, Г. Ибраһимов прозасында тулы гәүдәләнде. Аның революциядән соңгы әсәрләре татар прозасын эпик һәм психологик планда баета башлау, бытовизм кысаларыннан чыгарып, тарихи чынбарлыкның зур вакыйгаларын алу һәм аерым геройларны үз эчке дөньясы белән җанлы шәхесләр буларак калку итеп тасвирлау ягыннан әһәмиятле иделәр. «Безнең көннәр»нең беренче редакциясендә ук инде тарихи вакыйгалар, «тарихи ташкыннар» эченә кергән геройлар язмышы белән очрашабыз. Икенче редакциясендә язучы заманның тарихи-эпик колачын ачып җибәрде. Аның өч кисәктән торырга тиешле эпопея итеп языла башлавы да бик гыйбрәтле иде. Татар совет прозасының беренче яңа, индивидуаль стильләрен тудыруга өлеш керткән язучылардан Ш. Камал, М. Гафури, Ш. Госман, К. Нәҗми, М. Галәү һ. б. ның традицияләре дә эзсез калмады. Ш. Камалның «Таң атканда», «Матур туганда» кебек романнары шулай ук әһәмиятле иҗтимагый-тарихи вакыйгаларны һәм геройлар язмышын эпик сурәтләүнең үзенчәлеге белән аерылып торды. Алар-

[1] Рус әдәбият белемендә бу төшенчәне «восточный психологизм страстей» дип тә атыйлар. Аның төп мәгънәсе кеше интим кичерешләреннең, хисләреннең югары дәрәҗәдәге чагылышын сурәтләүдән гыйбарәт булып, күбесенчә, мәхәббәт дәрте һәм газабы белән бәйләнештә күз алдына китерелә.— Г. Х.

да язучының кечкенә хикәя-новеллалар жанрында һәм «Акчарлаклар» повестенда формалашкан психологик алымнары роман структурасында уңышлы кулланылды. Дөрес, Ш. Камал әле роман стилен эзләү юлына гына баскан иде. Шуңа күрә аңарда яңа материалның стиль алымнары белән ярашмау, бытовизмга бирелгәләү очракларын да, хикәяләү манерасының билгеле күләмдә таркаулыгын да табарга мөмкин. Шуңа да карамастан, Ш. Камалның роман стилендәге җәенке, киңәйтелгән сурәтлелек детальләргә бай эпик стильне эзләү юлындагы характерлы тәҗрибәләрдән берсе итеп бәяләнергә хаклы. Фактларны тулаем алып караганда, егерменче еллар прозасында ук инде эпик стильнең традицияләр белән тирән бәйләнештә реалистик җирлектә яңарып төрләнүе ачык күренер. Әмма татар совет прозасында эпик һәм психологик стиль проблемасы, социалистик реализмның туктаусыз үсүе, тормышның аңа булган таләпләре һаман артып торуы сәбәпле, бервакытта да үзенең әһәмиятен киметмәде, ә киресенчә, көчәя, арта гына килде.

Бигрәк тә сугыштан соңгы еллардагы татар прозасы эпиклыкның һәм эпик стильләрнең тагын да көчәеп китүе белән аерылып тора. Бу чор, барыннан да әүвәл, үткән һәм хәзерге заманның зур темаларына багышланган зур күләмле проза әсәрләре күпләп язылуы белән характерлы. Халыкның ирек өчен революцион-сыйнфый көрәше, Бөек Ватан сугышындагы героизмы һәм тыныч төзелеш елларындагы батыр хезмәте соңгы чордагы романнарның бик әһәмиятле эчтәлеген һәм алардагы эпиклыкның да төп юнәлешен, пафосын билгелиләр. Болар арасыннан К. Нәҗминең «Язгы җилләр», И. Газиның «Онытылмас еллар», Г. Бәшировның «Намус», М. Әмирнең «Саф күңел», Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел», Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», «Газинур», «Мәңгелек кеше», Ә. Фәйзинең «Тукай», А. Расихның «Ямашев», Ш. Маннурның «Муса» кебек романнарын алып карасак, аларда заманның зур тарихи хәлләре белән бәйләнештә сурәтләнгән геройларның, хәтта тарихи шәхесләрнең образларын күрербез. Әнә шул хәлләрне һәм геройларны ничек сайлауда, ничек сурәтләүдә язучыларның эпик стильләре тегеля бу яктан үзләренең индивидуаль сыйфатларын ачалар. Без бу очракта, мисал өчен, бер үк вакытларда дөньяга чыккан ике әсәрне — «Язгы җилләр» һәм «Намус» романнарын гына искә алып үтәбез. М. Горькийдагы һәм Г. Ибраһимовтагы эпиклык традицияләрен үзенчә дәвам иттереп, К. Нәҗми самодержавиегә каршы киң халык хәрәкәтләре эчендә гади кешеләрнең революцион характерлары җитлегүен һәм төрле язмышларын күрсәтә. Монда язучы стиленең үзенчәлеге, бигрәк тә массачыл күренешләрне, аерата публицистик пафос белән сурәтләүдә ачылыбрак китә. Шулай ук берничә герой мөнәсәбәтен һәм язмышын эзлекле үстереп баруы да әсәрдәге эпиклыкның сюжет бөтенлеген тудыра. Гомумән, К. Нәҗми романы татар совет прозасында үзенчәлекнең кына сиздереп килгән публицистик стильне сайланган темага мөнәсәбәттә шактый тулы һәм бай файдалануы белән аерылып тора. Әмма шуның белән бергә, мондый стильнең тарихи вакыйгалар һәм геройлар арасындагы бәйләнешне күрсәтүдә иллюстративлык ягына алып китүе дә мөмкин. Бу, әлбәттә, схематизмга да китерә. Мондый иллюстративлыкны билгеле күләмдә «Язгы җилләр» стилендә дә табарбыз. Бу очракта К. Нәҗми эпик стиленең электән үк килә торган кимчелектән тәмам котылып җитмәве күренә иде. Ләкин моңа карап, гомумән социалистик реализмда публицистик стиль сәнгатьчә тулы хокуклы була алмый дигән нәтиҗә чыкмый әле. Монда сүз һәр стильнең үзенчәлеген никадәр тулы һәм урынлы ачу-ачмау турында гына бара.

Г. Бәшировның «Намус» романында исә аның төп герое булган Нәфисәнең тормыш тарихын психологик яктан ачарга омтылыш стиль үзенчәлеген билгеләде. Бу үзенчәлекнең лиризм, лирик пафос белән сугарылган булуы әһәмиятле. Бу очракта инде поэзия чоры белән бәйле лирик-психологик стиль традицияләренең билгеле күләмдә яңаруын һәм үстерелүен күрәбез. Шул рәвешчә, «Язгы җилләр» һәм «Намус» кебек роман үрнәкләре генә дә эпик стильләрнең төрле индивидуаль төсмерләре барлыгын бик ачык исбатлый икән: аларның берсендә публицистик пафос, ә икенчесендә лиризм характерлы стиль

тенденциясе буларак урын алган. Әйтергә кирәк: «Язгы җилләр» һәм «Намус» романнарындагы эпик стильләр татар прозасында үсә килгән традицион стиль агымнарының киңәя, һаман яңара баруын күрсәттеләр. Алардан соң язылган романнар турында аерым-аерым сүз алып барсак, без аларда да индивидуаль стильләрнең төрле якларын, традицион-лык белән новаторлыкның керешүен таба алырбыз. Бу төрлелек һәм керешү татар прозасының индивидуаль стильләр палитрасы, хәзинәсе елдан-ел байый баруы хакында сөйли. Әгәр дә татар совет әдәбиятының бөтен жанрлары буенча социалистик реализм үсеше белән бергә стильләр хәрәкәтен киң мәгънәсендә күз алдына бастырырга тырышсак, бу мәсьәләнең әдәбият белемебез алдында гаять бай һәм кызыклы тикшеренүләргә, зур фәнни һәм әдәби ачышларга, бик гыйбрәтле нәтиҗәләргә китерә торган өлкә, дөресрәге, күтәрелмәгән чирәм икәнлеген икърар итәргә туры килер.

Социалистик реализм җирлегендә индивидуаль стильләрнең генә түгел, типологик стильләрнең дә, стиль агымнарының да күп төрләре мәйданга килүе мәгълүм инде. Реалистик, романтик, объектив, эпик, лирик, психологик, экспрессив, импрессионистик, публицистик һ. б. шундый стиль төрләре, төсмерләре, юнәлешләре социалистик әдәбиятларга киң мәгънәсендә хас булуын безнең хәзерге әдәбият белеме ачык күрсәтә. Сүз монда бер совет әдәбияты турында гына бармый, ә бөтен дөнья күләмендә социалистик әдәбиятның нинди формаларда һәм стильләрдә гәүдәләнүе һәм бу стильләрнең үзара мөнәсәбәте, бәйләнеше турында бара. Ә совет әдәбияты, социалистик реализм әйдәүче буларак, социалистик әдәбиятларга тирән йогынты ясау белән бергә, аларның да тәҗрибәләрен, казаныш-табышларын уртаклаша, гомумән, бөтен дөнья алдынгы эстетик хәрәкәте белән тыгыз мөнәсәбәттә, бәйләнештә үсә. Социалистик реализм әдәбиятының сәнгатьчә мөмкинлекләрен, стильләрен нормативлаштырырга, чикләргә тырышкан теорияләрнең үле булып туулары турында әйтеп торасы да юк. Чөнки социалистик реализм — тарихи прогресс белән иң тыгыз бәйләнештә туктаусыз үсә, үзгәрә, байый торган иҗат методы ул. Аңа дөнья күләмендә барган эстетик казанышлардан, стильләрдән читтә торган бер утрау итеп карау һич мөмкин түгел. Социалистик реализм — үзенең төп идея-эстетик принципларына хезмәт иткән сәнгать чараларыннан, стильләрдән тулысынча файдалану көченә ия булган иҗат методы.

Әдәбият белемендә метод һәм стильләр турында күп һәм төрле фикерләр әйтелсә дә, аларга бәйләнештә хәл ителергә һәм ачыклык алырга тиешле мәсьәләләр әллә ничаклы әле. Бу очракта без һич тә аларның һәммәсен яктырту һәм кисеп җавап бирү максатын куймадык, совет әдәбият белеме күтәргән кайбер әһәмиятле мәсьәләләрнең мәгънәсен кыскача гына булса да укучылар каршына бастырырга теләдек. Чөнки күп кенә мәсьәләләргә капма-каршы ноктадан торып җавап эзләүләр дә аз түгел.

Нәтиҗә итеп шуны әйтергә кирәк: сәнгатьтә, әдәбиятта эстетик идеал, метод һәм стиль кебек мәсьәләләр, теоретик яктан гына түгел, иҗат практикасы өчен дә һәр вакыт актуаль булып торды һәм торачак. Чөнки таланты булган бер генә художник та болардан башка үзенең сәнгать остасы икәнлеген күрсәтә алмый.

Зәет Мәҗитов

ҺӘР ШАГЫЙРЬНЕҢ ҮЗ ТАВЫШЫ

1

Бөек Ватан сугышы елларында татар поэзиясендә совет солдатының фронт тормышын, уй һәм хисләрен иң уңышлы гәүдәләндергән шагыйрьләрнең берсе Ф. Кәрим булды. Әмма Ф. Кәрим ялгыз түгел иде. Солдат образын иҗат итүдә аннан башка шагыйрьләрнең дә зур өлеше бар. Иң әһәмиятлесе шунда, фронтовик-сугышчы образын сурәтләүгә һәр шагыйрь үзенчә, яңача якын килергә тырышты.

Оригиналь һәм таләпчән шагыйрьләребездән Әхмәт Фәйзи иҗатында, мәсәлән, солдат образы турыдан-туры сугыш эпизодларында күрсәтелми диярлек. Сугыш эпизоды телгә алынган тәкъдирдә дә ул шагыйрьнең сугышка үз мөнәсәбәтен белдерүдән, аны лирик я публицистик планда бәяләүдән гыйбарәт. Ә. Фәйзи шигырьләрендә солдат образы, кагыйдә буларак, лирик геройның фикерләрен, аның кичерешләрен ачу өчен алына. Шушы рәвешчә, үзәккә лирик герой һәм аның сугышка мөнәсәбәте куела. Күп кенә очракта бу лирик мөнәсәбәт, публицистик-патетик төсмер алып, күтәренке пафослы гомумиләштерүгә дә әйләнеп китә.

«Алдыбызда, дуслар, биеклек» (1942) дип башланган лирик шигырьгә күз салыйк. Шигырьнең исеменә караганда, анда бер биеклек өчен барган кызу сугыш эпизоды сурәтләнергә тиеш иде кебек. Ләкин алай булып чыкмый, чөнки шигырьдә теге яки бу эпизодны конкретлаштырып күрсәтү бурычы да куелмый. Хәлиткеч сугыш барганда лирик герой нәрсә уйлый, ниләр кичерә — шагыйрь беренче планга шуны чыгара.

Алдыбызда, дуслар, биеклек,
Ул биеклек — безнең даныбыз,
Туган җирегезгә колак куеп,
Бер минутка тынып калыгыз...

Шигырьнең шушы беренче строфасында ук инде Ә. Фәйзигә хас гомумиләштерү үзенчәлеге сизелә. «Туган җиргә колак куеп, бер минутка тынып калыгыз», ди шагыйрь. Әлеге чакыру аша туган җир каршында җаваплылык мәсьәләсе куела. «Ул биеклек — безнең даныбыз» дип, лозунг характерында әйтү дә шуннан килеп чыга. Аласы биеклек — җаваплылык. Шул җаваплылыкка турылык — даныбыз. Күренә ки, «алдыбызда, дуслар, биеклек» дип, бик конкрет эпизод сурәтләүне вәгъдә иткән беренче юл, чыныңда, лирик уйлануны, публицистик фикер әйтүне мотивлаштыра торган башлангыч нокта, сүз башы гына икән. Әмма шигырь конкретлыктан мәхрүм түгел. Киресенчә, шигырьнең үзәгендә бик конкрет, бик ачык хис һәм фикер ята. Бу «мин»нең дусларына дәшеп сөйләгән сүзләре:

Нинди җылы булып аның яшәү
Сулышы бәрә минем хисемә,
Ерак калган йортым, хатыным, улым
Һәм вәгъдәмне төшерә исемә.

«Ерак калган йортым, хатыным, улым» дип төгәлләп, конкретлаштырып санау сөйләмгә табигыйлек бирә. Шигырьдә туган җире алдында олы җаваплылык сизеп яши торган сугышчы образы сынлана башлый. Аның туган

йорты, хатыны, баласы ераkта калган. Хәзер шагыйрь безне лирик геройның яшәү һәм үлем, батырлык һәм куркаклык, турылык һәм хыянәт турындагы карашлар даирәсенә алып керә.

Ә. Фәйзинең шигъри гомумиләштерү принцибын аңлар өчен, тагын бер кат әлеге әсәрдәге «ерак калган йортым, хатыным, улым һәм вәгъдәмне төшерә исемә» дигән юлларны искә төшерик. Чынлыкта шигырьнең тематик композициясен оештыра торган пружина итеп нәкъ менә шушы детальләр алына. Алар, градация ясап, кабатлау-санау формасында киләләр һәм шигырьнең кырыс һәм салмак, энергияле ритмын тудыруга катнашалар:

Илең, йортың, намусың, антың онытып...
Ашым, суым, һавам — бөтенесе...

Ритмик энергияне көчәйтүдә шагыйрь шулай ук анафоралар һәм ялгауларны да активлаштыра:

Алдыбызда, дуслар, биеклек,
Ул биеклек — безнең даныбыз.

Яшәү матур, үлем чиркәнеч,
Чиркәнечрәк ләкин тагын да...

Шигырьнең бөтен композицион структурасы ритмны көчәйтүгә катнашкан шигъри детальләргә таянып төзелә. Шигырьнең беренче өлешендә телгә алынган детальләр (туган йорт, хатын, бала, вәгъдә) алга таба яңа фикер белдереп, көчәйтелеп кабатланалар:

Чиркәнечрәк ләкин тагын да
Илең, йортың, намусың, антың онытып
Чигенеп калу үлем алдында...

Һәм, ниһаять, бөтен шигырьне тәмамлап, детальләрнең эчке мәгънәсен бергә туплап, баштагы өлештә «улым» дип санап кына үтелгән деталь «минем газиз улым» дип үстерелеп кабатлана:

Чигенәм икән, минем газиз улым
Атасының йөзенә төкерсен!

Хәзер инде без шигырьнең бөтен яңгырашыннан килеп чыга торган хис, фикер энергиясе турында сүз йөртә алабыз.

Нәрсәдән гыйбарәт соң ул? Алдыбызда — биеклек, алдыбызда — хәлиткеч сугыш. Ватан язмышын, туган җир, туган йорт язмышын, хатыннарыбыз, балаларыбыз язмышын хәл итәргә тиешле бөек тартыш бара: яшәү матурлыгына чиркәнеч һәм коточкыч үлем яный. Куркыныч дошманнан илне тик үлемнең күзенә туры караучы батыр солдат кына коткара ала. Шуңа күрә дә шигырь уртасында мөрәҗәгать объектының «дуслар»дан «йөрәк»кә әйләнүе табигый күренеш:

Ян, алайса, йөрәк, янгын булып,
Үч ялкыны белән чыныксын...

Шигырьнең «мин»е үз-үзен үлем алдында горур булырга чакыра. Шунысын да әйтик, бу үз-үзеңә дәшеп әйтү зур мәгънәле публицистик фикерне декларатив яңгыраштан коткара, аңа лирик көч бирә. Ә инде моның артыннан килгән юллар йөрәк каны белән язылган ант сүзенә әйләнәләр:

Чигенәм икән, миңа харам булсын
Ашым, суым, һавам — бөтенесе.

«Харам булсын ашым, суым, һавам» тәгъбирләре бу юлларны чын халыкча, солдатча яңгырашлы итә. Шигырьне тәмамлап килгән соңгы юллардагы: «чигенәм икән, улым йөземә төкерсен!» — дигән кискен сүз бер буынның икенче буын каршындагы җаваплылыгын гәүдәләндергән тирән шигъри мәгънә алып килә, әмма табигый һәм гади итеп, халыкча әйтелә. Шулай итеп, шигырьнең лирик герое гади сугышчы, рядовой солдат булып күз алдына баса. Шагыйрь аңлы рәвештә геройның кем булуын, профессиясен, индивидуаль үзенчәлеген күрсәтми. Шигырьнең герое — гомумән совет кешесе, үз Ватанын саклап үлемгә каршы көрәшкә чыккан куркусыз сугышчы, бала атасы. Ә. Фәйзинең, лирик шагыйрь буларак, хис һәм фикер гомумиләштерү үзенчәлекләреннән берсе әнә шунда. Ә. Фәйзи образ һәм предмет сурәтеннән бигрәк, хис хәрәкәтен, фикер үсешен бирергә, теманың фәлсәфи тирәнлеген ачарга омтыла. Шуңа күрә аның шигырьләренә уйлану, фикер йөртү хас.

«Фронт юлында» (1943) шигырендә дә сугышчы образы турыдан-туры сугыш эпизодында сурәтләнми. Монда да сугыш эпизоды фон буларак кына, бер-

ничә штрих белән генә гәүдәләндерелә («Кичке шәфәкъ түгел, туплар уты тетрәп яна күкнең читендә»).

Шушы фонда ике сугышчы («мин» һәм «син») очраша, сүзсез генә аңлашып тукталалар, берсе икенчесенең тәмәкесеннән ут ала. Беренче карашка, гадәти һәм очраклы күренеш кебек. Һәм ул гади генә, табигый генә сурәтләнгән дә. Әмма соңгы, йомгакларга тиешле строфа тагын зур гомумиләштерү алып килә:

Аерылыштык. Сүзсез очрашуның
Күңелемдә калды дулкыны,
Син, көрәшче, гүя йөрәгемә
Кабызып киттең йөрәк утыңны.

Бер йөрәкнең икенче йөрәккә ут кабызып китүе уртак Ватан азатлыгы өчен көрәшүчеләрнең күңел берлеген, максат берлеген ачып сала. Күренә ки, Ә. Фәйзи фашизмга каршы изге көрәш алып барган совет кешесенең — солдатның образын фәлсәфи гомумиләштерү ясый торган психологик-лирик рәсем белән ачуны беренче планга чыгара. Солдат образы һәм лирик герой Ә. Фәйзи шигырьләрендә рухи бер бөтен булып китәләр. Бу, барыннан да элек, ил язмышы турында уйлау, Ватан иминлеген шәхси иминлектән өстен кую, иң югары кешелеклелек һәм интәшлек тойгысы. «Ераста, ераста» (1943) шигыре, мәсәлән, оригиналь формада, дәлилле һәм ышандыргыч итеп лирик геройның зур җаваплылык тойгысын гәүдәләндерә. Шигырь һәр кайсы икешәр строфа тәшкил иткән өч кисәктән тора. Беренче кисәктә: күк күкри, яшеннәр телгәли һаваны. Һәм ана баласын юата — «Бу күкрәү бит бездән ераста, ераста...» Икенче кисәктә без әлеге баланы «күкрәүнең һәм утның эчендә» күрәбез. Тик халык язмышын уйлап яшәгән сугышчы һәм шагыйрь сүзләренең ныклы, ышанычлы булуын һәр кисәкне тәмамлап килә торган композицион эпифора (ераста, ераста) гаять уңышлы беркетә. Ышанычлы, энергияле, эчке бер күтәренкелеккә ия булган сөйләм барлыкка килә. «Син барасың бүген көнбатышка» (1942), «Бу яз» (1943) шигырьләрендә дә лирик герой һәм солдат образының масштаблы гомумиләштерү белән сурәтләнгән психологик рәсемен күрергә мөмкин. Ә. Фәйзинең фронт шигырьләре әнә шундый.

Хис һәм фикерне беренче планга куеп гомумиләштерү тенденциясе шагыйрь иҗатында сугыш дәвамында гына формалашкан сыйфат түгел, әлбәттә. «Аккош» (1927), «Перчатка җыры» (1927), «Шәһәрдә яз» (1934), «Яшьлек» (1938) кебек шигырьләрендә Ә. Фәйзинең нәкъ шушы сыйфаты төсмерләнә. Боларның аеруча күренеклесе — «Яшьлек» шигыре. Поэзиядә тантаналылык, күпшылык шактый көчәеп киткән бер чорда Ә. Фәйзи зур теманы — киләчәкнең яшьлек ягында булуын, яшьлекнең, яңаның туу көчен гөл образында гаять оста итеп сурәтли. Зур таш багананың төбенә яшь гөл шытып чыккан. «сыгылып тора яшь гөл, багананы җилкәсендә тотып». Бер уку белән хәтергә уелып кала торган бу гипербола безне тирән фикерле нәтиҗә ясауга алып килә: туу көче, яшьлек һәм яңаның үсү мөмкинлеге гомумиләштерелгән фәлсәфи фикер буларак кабул ителә.

Әмма югарыда без караган фронт шигырьләрендә яңа моментлар да бар. Яңалык, барыннан да элек, тематика үзгәрүдә күренә. Фронт чоры лирикасында шагыйрь кешенең Ватан алдындагы җаваплылыгы, иле каршындагы намусы мәсьәләсен үзәк урынга куеп сурәтли башлый. Шигырьләргә чорның драматизмы үтеп керә һәм кичереш киеренке-калку төс ала, хис кыллары тыгызрак тартыла. Ритмика да, тыгыз-тыныч агышын югалтып, риторик эндәш һәм сораулар, анафора һәм эпифоралар белән куертыла, төрләләндерелә. Кыскасы, сугышка кадәр формалашып килгән стиль үзенчәлеге Ә. Фәйзидә яңа тема һәм яңа чор хисләренә бәрабәр үсеш юнәлеше ала. Һәм шагыйрь нәкъ шул сыйфатлары белән татар поэзиясенең гомуми сафында үз урынын били дә.

2

Ватан язмышы хәл ителгәндә намус һәм җаваплылык хисен байрак итеп яшәүче лирик герой образы фронтовик шагыйрь Гали Хуҗиев шигырьләрендә дә үзәк урынны алып тора:

Солдат булып кулга корал алдым,
Куркынычта илем язмышы, —
Һәр кайгыдан өстен шушы кайгым,
Һәр кайгыдан авыр һәм ачы[1].

Әмма сурәтләү үзенчәлекләре ягыннан Г. Хуҗиев Ә. Фәйзидән күп аерыла. Юк, биредә сүз талант дәрәҗәсе төрле булу турында гына бармый. Ә. Фәйзи талантының күпкырлы һәм тирәнрәк булуы — бәхәссез. Без бу моментны

[1] Г. Хужи. Туган җир. Казан, 1946 ел, 18 бит.

исәпкә алабыз. Әмма биредә сүз нигездә бер-берсенә охшаш яки якын торган тема һәм идеяләрне, бер үк чор кешесенең күңел дөньясын һәм яшәешен шигъри гәүдәләндерү алымнарындагы, ягъни шигъри гомумиләштерү принципларындагы аерма турында бара.

Г. Хуҗиевның «Ераста син, йөрәктә син» (1943) шигыре Ә. Фәйзинең «Ераста, ераста» шигыре белән бер елда язылган һәм тематик яктан да аңа аваздаш. Шулай да ике шагыйрь теманы ике төрле ача, лирик герой — солдат образының кичереш һәм уйларын сурәтләүдә бер-берсеннән аерыла. Без инде Ә. Фәйзи шигырьләренең үзенчәлекле яклары турында сөйләгән идек. Аның иҗатында киң масштаблы көрәш фонында («Хәзер мин күкрәүнең һәм утның эчендә») алынган геройның психологик-лирик рәсемен бирү беренче урында тора. Г. Хуҗиев исә фонны конкретлаштырырга, детальләр белән предметлаштырырга, героен конкрет ситуация эченә куярга ярата. «Ераста син, йөрәктә син» шигыренең кайбер юлларына күз салыйк:

Аерылдык без дуслар аерылганда,
Сау кайтуым теләп озаттың...

Солдат булып кулга корал алдым...

Безнең артта мәгърур Сталинград...

Көрәшә ул көнне-төнне белми,
Ялкын камый ташлы ярларны...

Салкын окоп, салкын юеш туфрак...

Баш күтәрми ташлар арасыннан
Саклыйм шулай Идел буйларын...

Шигырьдән аерып алып китерелгән бу юллардан әсәрнең гомуми сюжетын күзаллау әллә ни читен түгел. «Мин», сөйгәне белән саубуллашып, фронтка китә. Солдат булып кулына корал ала. Сталинград җирендә — Идел ярында сугыша. Бу — шигырьнең җиңелчә генә бер сюжет төсмере алган тасвирлау сызыгы. Шушы сызыкка параллель рәвештә Г. Хуҗиевта, кагыйдә буларак, һәр вакыт лирик геройның сугыш шартларында, фронтта кичергән уйлары һәм хисләре үрелеп бара. Соңгысы, әлбәттә, шагыйрь әйтергә теләгән төп фикерне, төп тойгыларны укучыга җиткерү хезмәтен үти. Күпчелек очракта алар, лирик-публицистик характерда булып, туры һәм ачык әйтелгән кичереш һәм уйларны белдерәләр. Г. Хуҗиевның бу лирик юлларына еш кына җыйнак формада шактый бай фикер сыйдырылган була. Бу лирик юлларны шагыйрь халыкча гади һәм тыйнак-табигый итеп әйтергә омтыла. Г. Хуҗиевның сугыш еллары лирикасын нәкъ менә шушы сыйфаты укучыларга таныткан да. Сугыш елларында Г. Хуҗиев белән булган очрашуларын искә алып, башкорт шагыйре Гыйлемдар Рамазанов түбәндәге юлларны яза:

«Без, йокламыйча, дуслар белән сөйләшеп чыктык. Яңа әсәрләр, шигырьләр укыдык. Үзенең ягымлы сыйфаты белән китаплары аша күптән билгеле булган шагыйрьнең яңа шигырьләрен укуы онытылмас тәэсир калдырды. Ул шигырьләр шул көннән бирле истән чыкмыйча, күңелдә яңгырап торалар.

Айдагы кыздай ераста,
Ераста, ераста син,
Ләкин һаман да йөрәктә,
Йөрәктә, йөрәктә син...

Солдатның саф хисләре иде бу шигырьләрдә»[1].

Г. Рамазанов, һичшиксез, каләмдәш дустының сугыш чоры лирикасына хас төп үзенчәлекне дөрес тотып алган. «Ераста син, йөрәктә син» шигыренең лирик сызыгын караганда да без нәкъ шушы үзенчәлекләрне күрербез. Шигырьнең лирик юлларына мөрәҗәгать итик:

Йөрәкләрне кайгы яндырганда
Уртак өмет безне юатты...

Һәр кайгыдан өстен шушы кайгым,
Һәр кайгыдан авыр һәм ачы...

Монда тормыш һәм мәхәббәт сүнми,
Сүнмәс иткән көрәш аларны...

[1] «Кызыл таң» газетасы. 1962 ел. 17 октябрь.

Бу юлларда лирик геройның төп хисләре белдерелә. Аның өчен «ил кайгысы һәр кайгыдан өстен, һәр кайгыдан авыр һәм ачы». М. Җәлил, Ф. Кәрим һәм Ә. Фәйзи шигырьләрендәге кебек үк, туган ил һәм сөйгән кеше бердәй кадерле. Сугышның авыр шартларында да солдат яшәү рухын һәм мәхәббәтен сүндерми. «Салкын окоп, салкын юеш туфрак җандай җылы» аңа, чөнки ул җирен ярата. Ул — гади солдатларның берсе. Аның язмышы башка солдатлар язмышы белән уртак. Шушы олы хисләрнең һәм фикерләрнең барысын бергә туплап, аны оештырып, җылылык бирә торган төп хис буларак, бу шигырьдә мәхәббәт һәм сагыну, сөйгән кешесенең мәхәббәтеннән алынган көч гәүдәләнә. Шигырьнең соңгы строфасы нәкъ менә шушы хисне калку итеп күрсәтә:

Ераста син, ләкин йөрәктә син,
Кайда булсам, ниләр күрсәм дә;
Син һәр вакыт — якын көрәштәшем,
Суга төшсәм, утка керсәм дә.

Шулай итеп, Г. Хуҗиев шигырьләренең композициясе ике сызыкның: сюжет төсмере алган вакыйга (башлануы һәм үстерелеше белән) сызыгының һәм лирик-публицистик сызыкның параллель үстерелүенә нигезләнеп корыла һәм шигырьнең йомгак өлешендә бу ике сызыкны берләштергән уртак нәтиҗә ясала. Шигырьнең характерына карап, йомгак өлешендә я тасвирлау сызыгы, я лирик сызык беренче планга чыгарга мөмкин. «Ераста син, йөрәктә син» шигырендә лирик-публицистик фикер сызыгы җиңеп чыккан. Ләкин һәр ике очракта да Г. Хуҗиевта йомгаклаучы строфа үзенең характеры белән башкалардан аерыла, ягъни авторның алда сөйләгәннәрне бер төенгә туплап, алдагылардан тыгызрак, отышлырак сүзләр белән шигырьне тәмамлавы сизелеп тора.

Г. Хуҗиев шигырьләре Ә. Фәйзи шигырьләреннән кайбер бүтән яклары белән дә аерыла. Шуларның иң күзгә бәрелеп торганы — фронт вакыйгаларының вакыт һәм география ягыннан һәр вакыт диярлек сиземләнеп баруы. Бу да Г. Хуҗиевның югарыда без сөйләгән төп үзенчәлегеннән килеп чыга, ягъни шагыйрьнең фронт тормышын, солдат характерын конкрет-дәлилле формада, табигый һәм гадәти фонда ачарга омтылуы белән бәйле. Дөрес, Г. Хуҗиев шигырьләрендә буяулар һәм төсмерләр, тасвирлауга алынган предметлар, табигать күренешләре Ф. Кәрим һәм Ш. Мөдәрристәге кадәр төгәл һәм тулы, күпьяклы һәм бай гәүдәләнеш таба алмаган. Шуңа карамастан, Г. Хуҗиев шигырьләрен бергә җыеп укыганда сугыш барган урыннар да, лирик геройның теге яки бу шигырьдәге хисләре нинди шартларда туулы да шактый тулы күз алдына килә. Моны шигырьләрнең астына куеп барылган географик адреслар да тулыландыра. «Туган җир» шигыренең астына — Воронеж яны, 1942 ел дип, «Тополь» шигыренә — Дон, 1943 дип, «Дуслык» шигыренә — Белград яны, 1943 дип, «Днепр дулкыннары» шигыренә — Киев яны, 1943 дип куелган икән, без инде лирик геройның фронт юлын да төсмерлибез. Һәм шигырьләрдә, чыннан да, лирик геройның хисләре шушы җирләрдәге сугыш вакыйгаларына бәйләп сурәтләнгән. «Исеңдәдер, дустым» (1942) шигырендә, мәсәлән, Идел буе, Сталинград өчен барган сугыш вакыйгалары шактый җентекләп тасвирлана. Әмма сугыш күренешләре монда да лирик хис белән үрелеп бирелә. Лирик герой шушы сугышларда үзен үлемнән коткарып калган санитарка кызга мөрәҗәгать итә. Шигырь лирик мөрәҗәгать — хат яки монолог төсен ала. Шигырьдә фронтовикның сугышта туган иптәшлек һәм дуслык тойгылары, мәхәббәт хисе йолдызсыз һәм айсыз Сталинград төнен тасвирлау белән үрелеп бара һәм солдатның сугыштагы хәлен күз алдына бастыра.

Солдат юлы, Идел ярыннан, Сталинград янынан Донец аша, Днепр буйларына таба сузыла. Һәм менә «Днепр дулкыннары» (1943), «Днепр» (1943) шигырьләре туа. Әйткәнебезчә, Г. Хуҗиев шигырьләрендә география генә түгел, вакыт та гәүдәләнеш таба бара. Әгәр «Сентябрь», «Днепр дулкыннары» шигырьләре көз табигатен сурәтләсә, «Учак җылысы»нда (1943) без «Декабрьның бозлы төне, күге аяз, йолдызлы...» дигән юлларны укыйбыз. Кыскасы, Г. Хуҗиевның лирик шигырьләрендә солдатның сугыш кырларында үткән юлы туган җир табигате белән тыгыз бәйләнештә, шактый конкретлаштырылган рәвештә күрсәтелә.

Ләкин, Ә. Фәйзидәге шикелле үк, Г. Хуҗиев шигырьләренең дә үзәгендә солдатның сугышта кичергән уй һәм хисләрен, ягъни рухи дөньясын күрсәтү бурычы тора. Бу яктан ул Ә. Фәйзидән дә, башка шагыйрьләребездән дә аерылмый.

Г. Хуҗиевның сугыш еллары поэзиясендә лирик геройның һәм солдатның күңел дөньясы ничек, кайсы яклары белән ачыла? Аның поэзиясендәге төп образның кешелек сыйфатлары нинди? Шушы сорауларга җавап эзләп карыйк.

Барыннан да элек бу геройның татар халкы вәкиле, Идел буйларында үскән һәм яшәгән кеше булуын әйтергә кирәк. «Туып-үскән алтын бишегем син, җимешең, суың татлы» дип мөрәҗәгать итә ул туган җиренә («Туган

җир»). Туган җир һәм Идел синонимнар шикелле кулланыла: «Синең язмыш, Идел, безнең язмыш, һәрбер тамчың үз синең» («Идел, Идел»).

Идел образы Г. Хуҗиевның күп шигырьләрендә туган җирне сынландыра, конкретлаштырып сурәтли торган образ буларак кулланыла һәм солдатның туган җиренә булган чиксез тирән, олы мәхәббәтен ачуга хезмәт итә:

Кайна, Идел, утлы көннәреңдә
Ярларыңа сыймыйча,
Тынгы тапмас солдат йөрәгенә,
Сиңа тынгы булмыйча...

Бу юлларда без Г. Хуҗиев лирик героеның дошманга нәфрәт белән тулышкан йөрәген һәм аның туган җиренә олы мәхәббәте драматик киеренкелеккә җиткән тойгы буларак сурәтләнүен күрәбез. «Ярларыңа сыймыйча, кайна, Идел» дигән мөрәҗәгать халык ачуын, халык йөрәгендәге ярсуны сынландыра. «Идел, Идел» шигыренең соңгы строфасы лирик геройның Идел баласы булуын тагын да җылырак, шигъри яктан көчлерәк итеп күрсәтә:

Минем хәзер синең язмышыңны
Уйламаган көнем юк;
Кайтарырбыз язгы агышыңны,
Кояш шаһит, Идел-йорт!

Шигырьдә чын хис, йөрәк авазы халыкча гади итеп, хәтта җанлы сөйләм теленә якынайтып әйтелгән. Шул рәвешчә, Г. Хуҗиев лирикасының төп герое шигырьдән — шигырьгә диярлек Идел-йорты белән бәйләнештә ачыла. Ул Идел буйларын, Идел ягында калган әнкәсен, сөйгәнен сагына, ул Идел язмышы өчен борчыла, Идел ярларын дошманга бирмәс өчен утка ташлана, ул Иделенә дәшеп, аны дошманга бирмәскә ант итә. Бер үк вакытта аңа Идел нык-лык һәм куәт биргән кадерле көч, халык күңеленең тирәнлеген, зурлыгын белдергән образ да булып кабул ителә. Күрәбез, Идел, Идел-йорт, Идел-ана, Идел-кыз һ. б. формаларда шигырьдән шигырьгә күчеп барган бу образның Г. Хуҗиев поэзиясендә, аның идея-тематик төсмерендә әһәмияте гаять зур.

Г. Хуҗиев шигырьләренә үзенчәлекле лирик яңгыраш бирә торган моментларның тагын берсе — һәр шигырьнең диярлек тылда калган сөйгән кешеләрне сагынып искә алу хисләре белән сугарылган булуы. Солдат йөрәгендә көннән-көн көчәя барган сагыну тойгысын шагыйрь вакыт-вакыт тирән драматик кичереш, өзелеп сагышлану дәрәҗәсенә җиткереп тә сурәтли:

Уйна, дустым, гармонеңны,
Күңел дәрткә күмелсен,
Сагынуымның, януымның
Ялкыннары сүрелсен.
Баштан китсен борчылулар
Ярсыз-ялгыз көннәрдә...

Бу юлларда («Гармонь», 1943) лирик геройның хисләре, халык җырының традицион алымнарына таянып, чын җылылык белән гәүдәләндерелә. Ләкин бу моң, бу сагыну һич тә өметсезләнеп өзгәләнү түгел. Моң Г. Хуҗиев шигырьләрендә (һәм, гомумән, башка шагыйрьләр иҗатында да) туган җиргә булган мәхәббәт белән бәйле. Моң — совет солдатының кешелекле җанын, рухи байлыгын күрсәтүче тирән хис. Шуңа күрә дә:

Кемдә моң бар синдәгечә,
Синдә туган җир моңы,
Һичберәү дә сөймәгәнчә,
Сөя солдат җир-суын,

— дигән юллар оптимистик рухта яңгырый. Г. Хуҗиев шигырьләрендә сурәтләнгән солдат «кайда гына булса да, җир-суым дип юана; яраланып егылса да, җиренә таяна».

«Учак җылысы» (1943) шигырендә солдатның сугыш тынып торган арадагы рухи халәте сурәтләнә. Декабрьның бозлы төне... Аяз күк... Йолдызлар... Окоп... Учак яна, солдат учагы. Шагыйрь фронт тормышының шушы көндәлек күренешен солдатның тирән һәм зур уйларын, рухи дөньясын гәүдәләндерүгә хезмәт иттерә. Шигырьнең икенче строфасына игътибар итик:

Янды учак төне буе...
Һәркайсыбыз шул чакта
Бөтен илнең җылылыгын
Сиздек шушы учакта.

Сугыш еллары поэзиясендә еш очрый торган гипербола бу (учакта бөтен ил җылысын тою). Ләкин шигырьдә ул купшы булып та, схематик фикер бу-

лып та яңгырамый, чөнки алдагы строфа тагын конкрет-гадәти күренешне тасвирлауга күчә:

Көнчыгышта яна офык,
Алтынланып таң ата.

Таң ату, йолдызларның уйларын ераккa алып китүе кебек сурәтләр әсәрне кабат халык иҗатының традицион сурәтләре белән, халык җырлары белән якынайта. Бу — Г. Хуҗиевның сугыш еллары поэзиясенә хас стиль сыйфатларының берсе. Г. Хуҗиевның фронт поэзиясе нәкъ менә шушы сыйфатлары белән Бөек Ватан сугышы чоры татар әдәбиятында мактаулы урын алды. Дөрес, Г. Хуҗиев поэзиясендә кимчелекләр дә булды. Шигырьдән шигырьгә бер үк детальләрнең кабатлануы, вакыт-вакыт тасвирчылыкка бирелү моментлары анда шактый очрый. Ләкин бу кимчелекләр, беренчедән, Г. Хуҗиевның сугыш еллары поэзиясенә керткән өлешен юкка чыгармый, икенчедән, ул кимчелекләр Г. Хуҗиевның сугыш еллары поэзиясендәге стиль үзенчәлекләре белән дә бәйле. Без тасвирлау сызыгы һәм шуның лирик сызык белән параллель баруын, вакыт һәм география ягыннан конкретлыкны аның сугыш еллары поэзиясендә күренгән төп сыйфатлар дип әйттек. Аның иҗатындагы мәгълүм кабатланулар, тасвирчылык күренешләре шушы стиль үзенчәлеген һәр вакыт сакларга тырышу, сурәтләр арсеналын киңрәк колачлы итә алмау белән бәйле иде. Әмма болар Г. Хуҗиевның Ватан сугышы чоры поэзиясенә керткән төп өлешен — совет солдатын сугышның кайсы гына фронтында да туган иленә турылыклы, киң совет Ватанын бердәм Ватан итеп яратып, бар халыклар белән үзен тугандаш итеп сизеп йөрүче кешелекле кеше итеп гәүдәләндерә алуын юкка чыгармыйлар. Г. Хуҗиев поэзиясенең лирик герое да безнең күз алдына олы йөрәкле солдат булып килеп баса.

3

Ф. Кәрим, С. Хәким, Ш. Мөдәррис, Ә. Фәйзи, Ш. Маннур, Г. Хуҗиев, М. Садри һәм З. Нури кебек фронтовик шагыйрьләр иҗатында, һәр авторның үз стиленә хас рәвештә, солдат образының күпьяклы һәм үзенчәлекле сыйфатлары ачылды. Без аны дошманга каршы сугыш күренешләрендә дә, окопта ял иткәндә дә, ерак тылда калган кадерле кешеләрне сагынып уйлаган чакта да күрәбез, аның авыр сугыш шартларындагы уйлары һәм хисләре белән дә гаять тулы танышабыз. Бу — татар поэзиясенең сугыш елларында ирешкән зур казанышы.

Шунысы әһәмиятле, кайсы гына шагыйрь иҗатын алып карасак та, кулына корал алып кешелекнең явыз дошманына каршы көрәшкә чыккан солдат саф һәм олы йөрәкле, чын патриотик хисләргә, югары идеалларга ия булган гражданин сыйфатында гәүдәләнә. Шуның белән бергә, бу гражданлык сыйфатлары яланғач һәм туры сызыклы формада бирелми. Шагыйрь солдатның «вак сыйфатларына», «йомшак якларына» да күз сала. Кешене һәрьяклап кеше буларак күрсәтү тенденциясе сугыш урталарына таба үзәк юнәлешкә әйләнә. Сугыш елларында Ерак Көнчыгышта хезмәт иткән С. Батталның бу чор поэзиясендә, мәсәлән, бу яктан ифрат кызыклы шигырьләр очратырга мөмкин.

Салих Баттал — поэзиягә 20 нче еллар уртасында ук килеп кергән тәҗрибәле шагыйрь. Шул чагында ук инде С. Батталның үзенчәлекле стиле төсмерләнә. Мисалга 1925 елда язылган «Яшьлек!» шигырен алыйк[1]. Лирик геройның абыйсы гражданнар сугышына китә. Ә ул «ник мин баралмыйм» — дип, әрнеп кала. Лирик геройның карап торуга беркатлы булып күренгән бу соравы һәм соңгы строфада бу хиснең әзен дә калдырмый торган тирән фикерле, акыллы сүз әйтү — С. Баттал поэзиясендә еш очрый торган алым — шушы шигырьдән үк башлана:

Мин еламыйм «яшьлек югала!» дип,
елаучылар, әйдә, еласын! —
Шинель! Яшьлегемне сиңа бирәм,
яшьлегемне шинель урасын!

Соңгы строфа С. Батталның тыштан караганда мәзәк сыман тоела торган, ләкин чынында үз чорының җаваплылыгын тирән сизеп яшәүче героена хас характер сызыкларын укучыга уңышлы җиткерә.

Баттал икәнемне онытсам да,
Постта икәнемне онытмам!

Яки:

Инструктор, әйдә, кайтыйк инде,
җирдән инде ерак киткәнбез;

[1] Салих Баттал. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан. 1959 ел. 114 бит.

динле кеше моннан егылса да,
ясин чыгар, төшеп җиткәнче...

— кебек көтелмәгән аналогияләр — С. Баттал стиленең характерлы сыйфатлары.

С. Баттал сугыш чоры шигырьләрендә дә үз стиленә турылыклы булып кала. Бу аның «теманы тотып алуында» ук күренә. Шагыйрь әйтерсең лә теманы үзәгеннән түгел, ниндидер читкә чыгып торган бер җебеннән ача башлый. Һәм һәр вакыт диярлек ул җитди теманың да бер «кызыклы ягын» таба белә. «Казармада төн» (1942), «Юл капчыгы» (1942), «Берлинга һөҗүм» (1943), «Шинель» (1943), «Иптәшләрнең берсе хат яза» (1943), «Солдат хаты» (1943) кебек шигырьләрнең кайсын алып карасаң да, С. Баттал стиленең шушы ягын — теманы кызыклы бер яктан ачуны күрергә мөмкин.

«Шинель» шигыре — бу яктан иң характерлы әсәрләрнең берсе. Монда шинель тарихы сөйләнә, ләкин шул тарихтан солдат тормышы күз алдына бастырыла. Монда да тема нәкъ «Батталча» тотып алына һәм кызыклы ягыннан карап ачыла. Солдат иске шинеле белән саубуллаша. Бу саубуллашу читен гаҗа, чөнки: «Ул шинель бит тәне белән бергә, яраланып кат-кат кызарган: санитарка аны шул шинельдә ут астыннан сөйрәп чыгарган». Солдатның утлар-сулар кичкән, кырык үлемне җиңгән кеше булуы, шулай итеп, иске шинель аша күрсәтелә. Солдат яшәү һәм үлем турында да уйлый. Аның үлемнәрне җиңеп чыккан ныклыгын, чыдамлылыгын да күрәбез. Баттал бу якны да үзенчә ача:

«Мин үләрмен, шинель, син калырсың» —
кайчак солдат шулай уйлады.
Шинель тузды менә, солдат кала —
Яңа җиңгә күчә куллары.

Ягъни солдат әле яңа шинель кигәч тә күп батырлыклар эшләр. «Батталча» елмаю бу образның кешелеклелек сыйфатын тулырак ачуга ярдәм итә. «Шинель» шигыренең соңгы строфасы да шундый: «Яңа шинель китте разведкага, иске шинель калды боегып...»

«Солдат хаты» — солдат образын, аның кешелек сыйфатларын аеруча көчле итеп сурәтләгән шигырьләрнең берсе. Ул С. Баттал стиленең үзенчәлекләрен тагын да тулырак раслый төсле.

Ераста, тылда солдатның сөйгәне — Сәрвәре калган. Ләкин солдатның күптән инде сөйгәненә хат язганы булмаган. Ниһаять, бүген ул хат язарга утырган. Шигырь тулысы белән шушы хаттан гыйбарәт. Сугыш еллары поэзиясендә бу алым — хат формасы башка шагыйрьләрдә дә актив кулланылды. Аларда сагыну хисләре, «хатларың килсә, миңа көч бирә» дигән кебегрәк фикерләр үзәктә тора. Ә менә С. Баттал монда да темага үзенчәрәк якын килә. Ул моңарчы ни өчен хат язмый торуының сәбәбен сөйли. Аның кулында сөю билгесе итеп Сәрвәре биргән балдак йөргән булган. Көннәрнең берендә солдат әнә шул сөю билгесен — бармагындагы балдагын югалта... Алга таба ул балдак югалуның «серен» сөйләүгә күчә:

Шул ук балдак белән бергә
Шул көнне, шул ук җирдә
Дошман югалтты таныгын,
Экипаж белән бергә.

Дошман танкын җимергәндә бер кулын өздергән тыйнак, сабыр, ир йөрәкле сугышчы образы күз алдына әнә шулай бастырыла. Фаҗига турында сөйләр чакта, шагыйрь, «шаяртып», «кызык сөйләп» маташа.

Бүген шатлык: хирург миңа
Тапшырды балдагымны!
Тик хатым ямьсез... Кичер, бел
Сулагай язганымны...

Шигырьнең соңгы строфасы шушы «балдак» белән «фаҗига» арасындагы үзенчәлекле «баланс»ны тагын яңа бер ягыннан килеп йомгаклап куя:

Күңелең бизмәсме миннән? —
Шуны уйлыйм инде гел.
Балдак табылды бит, җаным,
Кул гына берни түгел!..

Беренче карашта абсурд фикер булып тоелган бу строфада, әлбәттә, яшерен тирән мәгънә салынган: солдат үзенең изге Ватан өчен сугышуын яхшы белә. Корбансыз мөмкин түгел. Яраланучылар да күп. Сөйгән ярларына кулъяулыкларын югалтып кайтучылар да булыр. Ләкин сөйгән ярлары моңа карап

кына үз мәхәббәтеннән йөз чөермәс. Балдакның табылуы мәхәббәтнең югалмавы дигән сүз. Шигырьгә әнә шушы эчке мәгънә салынган.

Конкрет детальләрне поэтик сурәт итеп куллану — Бөек Ватан сугышы чоры татар поэзиясендә гаять актив күренеш. Бу күренеш бигрәк тә сугышның урта чорында — 1942 ел урталарына таба көчәйде. Сугышның конкрет һәм җанлы эпизодларына үтеп керү, солдат образын табигый һәм сурәтле итеп ача башлау, снаряд һәм пуля яңгырлары астында да совет кешесенең рухи дөньясындагы гуманистик сыйфатларның үсә баруын күрү һәм, гомумән, поэтик сурәтләү колачының киңәюе, тематиканың тирәнәюе һәм баюы совет халыклары поэзиясенең реалистик көчен күрелмәгәнчә баетып, үстереп җибәрде. Образ һәм хис төгәллеге өстенә, детальләр төгәллеге дә кушылды. Совет халыклары поэзиясенең кайсы вәкилен генә алып карасаң да, сугышның урта чорында (1942—43) көчәю тенденциясе алган шушы сыйфатларны табарга мөмкин.

«Великая Отечественная» циклыннан аерым китап итеп чыгарылган «Священная война» томында[1] латыш шагыйре Валдис Лукскның «Солдат кружкасы» дигән шигыре бар. Шигырь кружка турындагы түбәндәге сүзләр белән башлана:

Спутница суровых дней солдатских,
Кружка, потемневшая в боях,
Все в тебе смешалось: капли пота,
Белый снег, болотная вода.

Чөнки бергәләп күп солдат юллары үтелгән, күп хәлләр баштан кичкән. Шул кружка солдатның күп җырларын яттан белә, бөтен кайгыларын, бөтен эшләрен күргән, барлык поход юлдашларын таный. Ачык ки: кружка хакында сөйләү аша солдатның сугыштагы язмышы гәүдәләндерелә. Солдатның кружкага дәшеп әйткән сүзләре шигырьгә табигый бер җылылык һәм дәлиллелек, ышанып сөйләү элементлары өсти:

Боевая верная подруга,
Общая теперь у нас судьба,—
Мы людскую утоляем жажду,
Все до капли отдаем другим.

Солдат образы белән параллель куеп сурәтләнгән шушындый детальләр төп образны, аның рухи дөньясын ачуда үзенә бер төрле индивидуальләштерү ролен үтиләр, гомумиләштерүне табигый яңгырашлы итеп бирүгә булышалар. Бөек Ватан сугышы чоры совет поэзиясендә 1942 елдан башлап күзәтелгән бу сыйфатлар, нечкиксез сурәтләү көченең, поэтик детальләрнең баюы, төрлеләнүе белән бәйле иде. Сугыш елларында татар поэзиясе үсешенә сизелерлек өлеш керткән Салих Баттал иҗатында да бу үзгәрешләрнең чагылмавы мөмкин түгел иде.

Татар совет әдәбият белемендә иҗаты бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән кызыклы шагыйрьләрнең берсе Бари Рәхмәт булды диргә мөмкин. Кагыйдә буларак, сирәк яза торган бу шагыйрьнең иҗаты Бөек Ватан сугышы елларында шактый гына активлашып китә. Бари Рәхмәт поэзиясенең үзенчәлекле ягы — юмор. Хәтта иң җитди темаларны ачуда да ул юмористик бер деталь яки сурәт куллана белә. Менә «Җырларым» (1942) шигыре[2]. Әсәрдә шагыйрь үзенең фронтка китүе турында сөйли, кеше өчен иң авыр момент — аерылышу күренеше сурәтләнә. Ләкин шушында да шагыйрь юмористик деталь тапкан:

Хуш! Хуш-ш! дигән кебек «пыш-пыш» килеп
Поезд әкрен генә кузгалды.

«Сәлам хат» (1943) шигыре «мин»нең фронттан тылга, сөйгән кешесенә җибәргән хаты формасында язылган. Бу яктан ул күпләр белән, шул исәптән С. Батталның «Солдат хаты» шигыре белән дә аваздаш кебек. Әмма юмористик детальләре, аларның җитди теманы ачудагы рольләре ягыннан Б. Рәхмәт үзенчә эш итә. Шигырьнең беренче строфасында ук «яратасың икән, яратмыйсың икән» антитезасы күзгә бәрелә. Татар халык җырларының традицион алымнарыннан берсе булган бу антитеза шигырьнең төп аһәңен халык иҗаты белән якынайта.

Өченче строфадагы беренче ике юл нәкъ халыкча итеп әйтелгән:

Безнең хәлне сорап баксагыз,
Бик исән-сау гына ятабыз.

Строфаның соңгы юллары исә юмористик аһәңне югары нотага җиткерә:

Кулда мылтык, билдә граната,
«Фашист» дигән кошлар атабыз.

---

[1] «Священная война». Коллектив җыентык. 1966 ел, 390 бит.
[2] Бари Рәхмәт. Казан, 1957 ел, 74 бит.

Дүртенче строфа бөтенләе белән анафорадан төзелгән:

... Әллә нишләп...
әллә язар вакыт...
әллә инде...
әллә ташладыңмы...

Шушы анафора, риторик сораулар белән белдерелгән градацияле санаулар белән кушылып, монда да лиризмны юмор белән үрә. Соңгы строфаның беренче ике юлы исә юмористик сызыкны йомгаклау ролен үти:

Яз әле дим, иркәм, яз, бәбкәм!
Яз дим, күгәрченем, каз бәбкәм!

Тышкы яктан ялварулы үтенечкә охшаган бу эндәшүләр тирән һәм җитди хисне шаярту алымы белән әйтү тәэсирен тудыра. Строфаның соңгы ике юлы исә шаяртудан ерак инде:

Өч почмаклы бер хат юлласаң,
Ял булыр иде дим йөрәккә.

Лиризм белән юморны кушып, шагыйрь нәрсәгә ирешә соң? Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, Ш. Мөдәррис, С. Баттал кебек шагыйрьләр поэзиясендәге кебек үк, Б. Рәхмәт тә фронтовик-солдат образының кешелек сыйфатларын шигъри сурәтләү максатын үзәккә куя. Солдатның сөйгән кешесенә язган хаты — аның уйларын һәм хисләрен ачу формасы. Хат шушы солдат теле белән язылган һәм аның характерын күрсәтүдә әһәмиятле роль уйный. Халыкчан тәгъбирләр аның гади халык улы булуын ачык сиздерә. Лиризм — сугыш шартларында да тупасланмаган солдатның күңел көзгесе. Юмор, берьяктан, аның сугышта күпне күргән батыр солдат икәнен, икенчедән, үз батырлыгына карап масаймый торган тыйнак кеше булуын белдерә. Үзенең фронтта ниләр эшләвен ул «фашист дигән кошлар атабыз» дип кенә әйтеп үтә. Ә менә шушы күпне күргән тәҗрибәле солдатның: «әллә инде сөйми башладың, әллә ташладыңмы, аппагым» дигән икеләнүләре аның күңелендә бер генә хиснең дә тупасланмавын шигъри гәүдәләндерү ягыннан гаять отышлы. «Яз әле дим, иркәм, яз, бәбкәм! Яз дим, күгәрченем, каз бәбкәм!» эндәшләрендәге ялвару формасында белдерелгән юмористик үтенеч, «иркәм», «бәбкәм», «күгәрченем», «каз бәбкәм» градациясе солдатның олы сагыну һәм мәхәббәт хисләре белән тулы йөрәген ачып сала. Шулай итеп, Б. Рәхмәттә юмор солдат күңелендәге хисләр гаммасын гәүдәләндерү функциясен үти. Б. Рәхмәт поэзиясе М. Җәлил, Ф. Кәрим, С. Баттал, Г. Хуҗи, Ш. Мөдәррис, Ш. Маннур, Ә. Фәйзи кебек шагыйрьләр иҗатыннан торган татар поэзиясе оркестрына үзенчәлекле тавышка ия булган бер курай төсле кушыла. Аның сугыш елларында иҗат ителгән кайсы гына әсәрен алып карасак та, нәкъ шушы сыйфатны — халык иҗатына аваздаш яңгыраган лиризмга юмористик бизәкләр кушып сурәтләүне күрербез. «Исән булсак, бетмибез» (1943), «Синең хакың бар» (1943), «Хатлар яна» (1945), «Пыр тузды, таралды» (1945), «Без кайтырга чыктык» (1945) һ. б. шигырьләрнең һәркайсы югарыда әйтелгән фикерне раслый ала.

Сугыш беткән көннәрдә язылган «Без кайтырга чыктык» шигыренә генә күз салыйк:

Җитен чәчләр белән,
Көмеш кашлар белән
кайтам мин.
Әйтмәссең бит кайткач,
Кайттыңмыни, картлач,
шайтан, дип.

«Җитен чәчләр белән, фронтларда байтак нужа күреп» кайтырга чыккан солдат образы юмористик буяулар белән сурәтләнә. Әмма бу сурәтләү елмаю гына уятып калдыра торган «буш» юмор түгел. Биредә драматик кичереш дәрәҗәсенә якынлашкан лиризм солдат образының күңел яктылыгын, күзләрендә шатлык яшьләре тулы елмаюын сынландыра. Б. Рәхмәтнең сугыш чоры шигырьләренә әнә шундый сыйфатлар хас. Һәм шушы ягы белән ул сугыш еллары татар поэзиясендә, солдат образын, совет кешесенең күңел яктылыгын күрсәткән шигъри сәхифәләрнең берсе буларак, үзенә лаеклы урын алырга хаклы. Б. Рәхмәт стиле, күренә ки, Ә. Фәйзи, С. Баттал, Г. Хуҗиев шигырьләрендә сизелгән стиль үзенчәлекләреннән шактый аерыла.

Кыскасы, әйтергә теләгәнебез шул: төп мотивларда, проблема һәм тематикада, совет сугышчысы образының мораль олылыгын, гуманистик характерын ачуда шагыйрьләрдә уртак моментлар хәлиткеч як булса да, җентекләп караганда һәр шагыйрьнең үз үзенчәлеген, яраткан сурәтләү алымнарын төсмерләргә була

КамАЗ КИТАПЛАРЫ

Татарстан җирендә гигант автомобиль комплексы төзелә башлауга нибары берничә ел вакыт узды. Ә КамАЗны инде үзебезнең илдә генә түгел, дөньяның бик күп почмакларында беләләр. КамАЗ — дөнья халкының игътибар үзәгендә.

Төзелешнең данын бик тиз арада ераклларга таратуда журналистларның һәм язучыларның да өлеше бар. Яңа шәһәр һәм автозавод төзелә башлауга Чаллыдан фоторепортерлар һәм журналистлар кайтып кермәде, биредән язучы өзелмәде. Республика газета-журналларында һәм үзәк матбугат битләрендә төзелешкә багышланган беренче очерклар, публицистик мәкаләләр, шигырьләр басыла башлады. Кыска гына бер ара эчендә дистәләрчә мәкалә һәм очерк җыентыклары, шигырь һәм поэмалар, роман-повестьлар, сәхнә әсәрләре дөнья күрде.

Журналыбызның бу санында без сезне шул китапларның кайберләре белән таныштырып узарга булдык.

Г. ПАУШКИН. На земле Челнинской. Рус телендә. Татарстан китап нәшрияты. 1971 ел. Тиражы 4500 данә. Бәясе 28 тиен

Кама буендагы төзелешкә башлап аяк баскан язучыларның берсе Геннадий Паушкин була. «Чаллы җирендә» — гигант төзелешкә багышланган беренче китап.

Китаптагы очерклларда автомобиль комплексы төзелешенең башлангыч этабы сурәтләнә. Аларның һәркайсы тормышны тирәнтен өйрәнеп, җаваплылык хисен нык аңлап язылган. Төзелешнең гомуми панорамасын, колачын һәм масштабларын сурәтләү белән бергә, Г. Паушкин төзелештән кызыклы язмышлар, үзенчәлекле характерлар эзли. «Чаллы җирендә» җыентыгы, барыннан да бигрәк, кызыклы образлары белән игътибарны җәлеп итә.

Менә төзелеш штабы начальнигы Валерий Стекольщиковның көндәлек дәфтәреннән алынган язмалар. Аларда Стекольщиковның бөтен характеры, холкы-гадәте чагыла. Шунда ук ташчылар бригадасы бригадиры, ВЛКСМның Үзәк ревизия комиссиясе члены Вазыйх Мәүликов турындагы очерк урын алган («Өч очрашу»). КамАЗ төзүчеләрнең атаклы бригадиры Виктор Филимоновны илебезнең бөтен төбәкләрендә беләләр. Ул — укучыларга Геннадий Паушкин ачкан күпләгән геройларның берсе. «Биеклек артында биеклек» дигән очеркны укыганда без түбә ябучы Шәрифуллин, партия эшчесе Огородников, электке чик сакчысы, хәзер төзелештә сварщик булып эшләүче Антонов белән танышабыз.

Г. Паушкин очерклларының тагын бер үзенчәлекле ягы шунда, ул очерклларда Чаллы һәм КамАЗ темасы илнең ерак үткәне, бүгенгесе белән янәшә куеп, чагыштырып барыла. Билгеле булганча, автозавод «Гигант» колхозы җирләрендә салына. Бу колхозның председателе Зыя Закиров авторның яшьлек дусты да икән. Бөек Ватан сугышының башыннан алып ахырына кадәр алар бергә булганнар. Сугышның бөтен авырлыгын, кыенлыгын бергә күргәннәр, бергәләп дошманны куганнар. Җыентыктагы очерклларның берсе «Гигант» колхозы, аның председателе Зыя Закиров турында сөйли. Очеркның иң дулкынландыргыч битләре төрле милләт кешеләре арасындагы дуслык хисләрен тасвирлауга багышланган.

Геннадий Паушкинның «Чаллы җирендә» китабы ВЛКСМ Үзәк Комитетының дипломы белән бүләкләнде.

Батыр на Каме. Рус телендә. Төзүчеләре Д. Вәлиев, М. Глухов һәм Р. Максудов. Җаваплы редакторы һәм кереш сүз авторы М. Мусин. Художниги И. Әхмәдиев. Татарстан китап нәшрияты. 1972 ел. Тиражы 6000 данә. Бәясе 1 сум 24 тиен

Татарстан җирендә тугызынчы бишьеллыкның иң зур төзелеше — Кама автомобиль заводы һәм яңа шәһәр салына башлауга, журналистларның һәм язучыларның, сәнгать кешеләренең төп игътибары әлеге төзелешкә юнәлде. Республика газета-журналларында, шулай ук үзәк матбугат битләрендә Кама елгасы буендагы гигант төзелешкә, анда эшләүчеләрнең хезмәтенә һәм тормышына багышланган материаллар басыла башлады. Шул материалларның иң яхшыларын бергә

туплап, Татарстан китап нәшрияты махсус җыентыклар чыгарып килә. «Камадагы батыр» — әнә шул сериядән чыккан китапларның беренчесе.

Җыентыкка «Социалистическая индустрия», «Советская Россия», «Литературная Россия», «Советская Татария» газеталарында һәм башка матбугат органнарында 1971 елда басылган иң яхшы очерклар, мәкаләләр, репортажлар тупланган. Аларны укып, без КамАЗ төзелешенең зурлыгы һәм колачын күз алдына китерәбез, анда эшләүчеләрнең тормышы һәм хезмәте, 1971 ел дәвамында алар башкарган эшләр белән танышабыз.

Характерларына һәм жанрларына, нинди мәсьәләгә багышланган булуларына карап, китаптагы материаллар төрлесе төрле зурлыктагы дүрт бүлеккә бүлеп урнаштырылган. «Бишъеллыкның удар төзелеше» дип исемләнгән беренче бүлек КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Табеев мәкаләсе белән ачыла. Мәкалә авторы безне КамАЗ төзелешенең әһәмияте һәм үзенчәлеге белән таныштыра, ул автомобиль заводын һәм Чаллы шәһәрен төзү буенча 1971 елда башкарылган эшләр турында сөйли, төзүчеләр алдында торган мөһим бурычларга тукталып. Ф. Табеев башлаган сүзне Кама автомобиле заводының генераль директоры Л. Васильев дәвам иттерә. Ул беренче мәкаләдә күтәрелгән аерым мәсьәләләрне тагы да ачыклый һәм конкретлаштыра төшә, КамАЗ төзелешенә бәйле башка проблемаларга туктала.

Икенче бүлек «Исәнме, Кама!» дип исемләнгән. Бу бүлеккә татар һәм рус язучылары, республика һәм Мәскәү журналистлары тарафыннан язылган мәкаләләр һәм очерклар, юлъязмалар һәм репортажлар тупланган. Ул материалларның берничәсендә КамАЗ төзелешенең гомуми характеры һәм үзенчәлеге, масштабы һәм колачы турында сөйләнә. Р. Кутуйның «Үзгәртелгән җир» («Земля преображенная»), А. Злобинның «Куен дәфтәреннән» («Из записной книжки»), М. Зарипов белән Г. Орловскийның «КамАЗ булачак!» («КамАЗ будет!»), Д. Вәлиевнең «Бүгенге дөнья — ул тизлек» («И мир сегодня — это скорость») исемле мәкаләләре, мәсәлән, әнә шундый. Шулар арасыннан Д. Вәлиев мәкаләсе аеруча әйбәт тәэсир калдыра. Ул КамАЗ төзелешенең эченә кереп, аны өйрәнеп, төзелеш мәсьәләләрен белеп язылган.

Бу бүлектәге материалларның иң зур күпчелеге төзелештәге аерым кешеләргә, ул кешеләр башкарган конкрет эшләрне сурәтләүгә багышланган. Әлеге материалларны укыганда без шәһәр һәм завод төзелешендәге атаклы бригадирлар, прорабларны, алдынгы монтажчылар, ташчылар һәм малярлар белән, уңган сатучылар һәм тәрбиячеләр белән, алар башкарган матур эшләр белән танышабыз.

Китапның өченче бүлеге КПССның Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре Р. Беляевнең «Батыр аякка баса» («Становление батыра») дигән мәкаләсе белән ачыла. Мәкалә авторы партиянең шәһәр комитеты башкарган күп төрле эшләр хакында сөйли. Шуннан сүз төзүчеләргә — бетончыларга, штукатурчыларга, шоферларга, ташчыларга бирелә...

«Безгә Ватан кушты» («Нам Родиной велено») дип исемләнгән соңгы бүлеккә КамАЗ төзелешендә эшләүчеләр арасындагы социалистик ярыш хәрәкәтен чагылдырган материаллар тупланган. Бүлек Р. Сәләхов җитәкчелегендәге монтажчылар бригадасының КамАЗдагы барлык төзүчеләргә адресланган ачык хаты белән башлана. Шунда ук В. Деребизов җитәкчелегендәге монтажчыларның, М. Никишин җитәкчелегендәге бизәүчеләрнең, П. Кемаев җитәкчелегендәге автоскреперчыларның, К. Хәмитов җитәкчелегендәге шоферларның Р. Сәләхов бригадасы чакыруына җавап хатлары урнаштырылган. Биредә **шулай ук КамАЗ хакында сөйли торган** фактларга, төзелеш елъязмасына кин урын бирелгән.

Китап В. Зотов, Е. Грабилин, Э. Хәкимов, М. Шакиржанов һәм Р. Якуповларның төзелеш күренешләрен, андагы кешеләрне, төзүчеләрнең хезмәтен, тормыш-көнкүрешен һәм ялын сурәтләгән фоторәсемнәре белән бизәлгән.

Поступь батыра. Төзүчеләре Д. Вәлиев, М. Глухов һәм Р. Максудов. Җаваплы редакторы М. Мусин. Художнигы И. Әхмәдиев. Татарстан китап нәшрияты. 1973 ел. Тиражы 11000 данә. Бәясе 1 сум 60 тиен

Бу — Кама автомобиль заводын һәм Чаллы шәһәрен төзүчеләргә багышланган очерк, мәкалә һәм репортажлардан төзелгән икенче җыентык. Аңа «Правда», «Известия», «Социалистическая индустрия», «Советская Россия», «Неделя», «За рубежом», «Литературная газета», «Литературная Россия», «Социалистик Татарстан», «Советская Татария», «Татарстан яшьләре», «Комсомолец Татарии», «Волжская коммуна» газеталарында һәм «Новый мир», «Молодой коммунист», «Огонек», «Юность», «Коммунист Татарии», «Казан утлары», «Азат хатын» журналларының 1972 елгы саннарында басылган материаллар сайлап алынган.

Әлеге материалларда завод һәм шәһәр салу буенча бер ел дәвамында башкарылган эшләр, ирешелгән казанышлар турында сөйләнә. Ул материалларны укыганда, без «Камадагы батыр» китабы буенча электән билгеле булган танышларыбызны очратабыз, гигант төзелешнең яңа геройлары белән танышабыз.

Китап күренекле татар шагыйре, Г. Тукай һәм М. Горький исемендәге премияләр лауреаты Сибгат Хәкимнең «Хыялларны канатландырган көч» дигән кереш сүзе белән ачыла. Кыска гына мәкаләдә шагыйрь КамАЗ төзелешенең сулышын һәм пафосын, зурлыгын күрсәтә алган.

Беренчесе кебек үк, бу җыентык та дүрт бүлектән тора. «Бөтен ил төзи» дип исемләнгән беренче бүлеккә егермедән артык мәкалә һәм очерк кергән. КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Троицкий безне 1972 елда автозавод һәм шәһәр төзү буенча башкарылган эшләр, төзелеш барышында туган яңалыклар, төзелеш оешмалары алдында торган бурычлар белән таныштыра. Р. Биктәһировның «Кама батырының «автопортреты» дигән язмасы да кызыксыну белән укыла. Мәкалә авторы КамАЗ төзелешенең төрле объектларында эшләүче гаҗәеп кызык язмышлы, бай биографияле кешеләр тапкан. В. Романюк үзенең «Тере бәйләнеш» исемле мәкаләсендә Волга автомобиль заводы белән КамАЗ төзелешен чагыштыра, алар арасындагы охшаш якларны һәм аерымлыкларны күрсәтә, әлеге ике зур төзелеш арасындагы бәйләнешкә аеруча нык игътибар итә. И. Ачильдиевнең «Мотор белән сыналды» («Проверено мотором») дигән язмасы Ярославль мотор заводының уйлап табучыларына багышланган. Билгеле булганча, КамАЗ машиналарына куелачак моторлар шул заводның конструкторлык бюросында иҗат ителә. КамАЗ парткомы секретаре А. Родыгин мәкаләсе — заводның киләчәге һәм аның кешеләре турында. Н. Хохловның «Кама колачы» («Камский размах»), Г. Баклановның «Гигант төзелә» («Гигант строится»), Х. Гардановның «Биеклек» («Высота»), В. Тузовның «Кама өстенә гигант күтәрелә» («Встает гигант над Камой») дигән мәкалә һәм очерклары да яратып һәм кызыксыну белән укыла.

Китапның икенче бүлеге дә нигездә шундый үк мәкаләләрдән һәм очерклардан тора. Характерлары, күтәргән мәсьәләләре ягыннан алар беренче бүлектәге материаллардан әллә ни аерылмыйлар диярлек. «Новый мир» журналының җаваплы секретаре Ф. Видрашкуның «Вахта» исемле очеркы Чаллы шәһәренең партия оешмасы һәм аның беренче секретаре Р. Беляев турында. Р. Сабиров («Новаторлар төзелеше») бик конкрет, гади һәм ачык итеп КамАЗ төзелешендә кулланылган яңалыклар белән таныштыра. Ю. Бычков белән Н. Ольшевскийны («Әгәр яңәшә булсагыз») үзешчән сәнгать коллективларының эше, төзелеш һәм сәнгать мәсьәләләре борчый. Р. Вәлиев, Ж. Кәлимуллин һәм Г. Паушкиннарны зур төзелештә эшләүче оригиналь кешеләр кызыксындыра.

Язучылар һәм профессиональ журналистлардан тыш, җыентыкның һәр ике бүлегендә төзүчеләрнең үзләренә дә шактый күп урын бирелгән. Шагыйрьләр шигырьләре белән катнашалар, В. Филимонов, А. Улесов, З. Гыйззәтуллина кебек танылган эшчеләр үз тәҗрибәләре белән уртаклаша.

Кама елгасы буендагы гигант төзелеш көннән-көн үсә, көннән-көн киңрәк колач җәя бара. Шуңа бәйле рәвештә, аның даны да үсә килә. КамАЗны хәзер дөньяның бик күп илләрендә беләләр, аңа сокланалар, аңа гаҗәпләнәләр. Җыентыкта чит ил журналистларыннан ике кешенең КамАЗ төзелешенә багышланган мәкаләсе урын алган. Аларның берсе — француз журналисты Серж Лейракның «Камадагы гигант» исемле мәкаләсе. Мәкалә француз укучыларын Кама елгасы буенда барган гигант төзелеш белән таныштыру максатыннан чыгып язылган. Серж Лейрак, КамАЗның зурлыгы, төзелеш эшендә кулланылган яңалыклар турында язып киләкилә дә, мәкаләсен болай дип тәмамлый: «Шул рәвешчә Татарстанның бу ерак почмагында кыю, тәвәккәл, үз эшләрен әйбәт белүче кешеләр формалаша. Соңгысы бигрәк тә мөһим. Палаткалар шәһәрчеге романтикасы үлде дип әйтү — әле һич тә романтикага гомумән хөкем чыгару дигән сүз түгел. Камилләшкәннән-камилләшә барган бүгенге заман техникасыннан максималь төстә файдаланып, катлаулы бурычларны башкару осталыгы беренче планга чыга. СССР үсте. Беренче бишьеллыклар чорындагы көрәк һәм кәйлә романтикасы үз урынын машина романтикасына бирде».

Германия Халык Республикасында чыга торган «Форум» исемле газетаның корреспонденты Ганс Эггерт 1972 елда КамАЗ төзелешендә булып китә. Үз иленә кайткач, ул Чаллыда алган тәэсирләре нигезендә «Кешеләр тәрбияли торган КамАЗ» («КамАЗ, который делает людей») исемле очерк яза. Аның бу очеркы совет кешеләренә карап гаҗәпләнү һәм соклану хисләре белән сугарылган.

...Р. Сәләхов җитәкчелегендәге монтажчылар бригадасы башлап җибәргән социалистик ярыш хәрәкәте тиз арада бөтен төзелешкә тарала. Шул ярыш хәрәкәте

төзүчеләр арасында зур хезмәт күтәренкелеге уяткан көннәрдә КамАЗга А. Стаханов, П. Кривонос, А. Бусыгиннар язган хат килеп төшә. Бу хат Чаллыда яңа хезмәт энтузиазмы кузгатып җибәрә. Җыентыкның соңгы дүртенче бүлеге беренче бишьеллыклар каһарманнары язган шул хат белән ачыла. Әлеге хат артыннан ук А. Стахановның КамАЗ төзелешендә эшләүчеләргә адресланган яңа хаты урнаштырылган. Бу бүлектә шулай ук В. И. Ленин исемендәге Магнитогорск металлургия комбинаты эшчеләре һәм ветераннарының, «Днепрострой» һәм Днепрогэс эшчеләре һәм ветераннарының Кама автомобиль заводын төзүчеләргә язган хатлары белән танышырга мөмкин. Иң ахырдан Кама автомобиль заводын төзүчеләрнең культура һәм сәнгать әһелләренә адресланган хаты китерелә.

Бу җыентык та КамАЗ төзелешенең төрле якларын чагылдырган фотолар, художникларыбызның төзелеш кешеләренә багышланган рәсемнәре белән бизәлгән.

КамАЗ — крупнейшая и важнейшая стройка пятилетки. Әдәбият күрсәткече. Төзүчеләре Ф. Гафурова, Н. Нуруллина, М. Делешова. Казан. 1973 ел. Тиражы 3000 данә

В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсенең милли әдәбият һәм крайны өйрәнү бүлеге укучыларны даими төстә Кама автомобиль заводы һәм шәһәр төзелешенә багышланган әдәбият белән таныштырып бара. Гигант төзелеш турындагы материаллар тупланган беренче күрсәткеч 1972 елда басылып чыккан иде. 1973 ел ахырларында аның икенче чыгарылышы дөнья күрде.

Соңгы күрсәткечкә 1973 елның апрель башларына кадәр республика газета-журналларында һәм үзәк матбугат битләрендә басылган мәкалә-очерклар, репортажлар, матур әдәбият әсәрләре сайлап алынган. Тема-проблемаларына карап, ул материаллар төрле бүлекләргә бүлеп урнаштырылган. Аларның саны ике дистәгә якын: партия һәм совет оешмаларының КамАЗ төзелеше турындагы документлары һәм материаллары; КамАЗ — бөтенсоюз комсомол удар төзелеше; Чаллы шәһәре; Кама автомобиль заводының кешеләре турында; Төзелешләр һәм буыннарның хезмәт перекличкасы; КамАЗда социалистик ярыш; КамАЗ — алдынгы тәҗрибә мәктәбе; КамАЗның дуслык бәйләнешләре; Темплар һәм темплар; Удар төзелешнең мәшәкатьләре; КамАЗ төзүчеләрнең көнкүреше һәм ялы; КамАЗда иҗат интеллигенциясе; КамАЗ әдәбиятта һәм сәнгатьтә; Сүз КамАЗ төзүчеләргә бирелә; КамАЗ шагыйрьләре...

Бер сүз белән әйткәндә, әдәбият күрсәткече КамАЗ белән бәйле барлык мәсьәләләрне иңләрлек итеп төзелгән. Ул агитаторлар, пропагандистлар, укытучылар, китапханә хезмәткәрләре, гигант төзелеш белән кызыксынучы барлык укучылар өчен файдалы кулланма булачак.

Б. КАМАЛОВ, Ж. КӘЛИМУЛЛИН. Дуслык таулар күчерә. Татарстан китап нәшрияты. 1973 ел. Тиражы 3000 данә. Бәясе 16 тиен

Язучы Б. Камалов белән журналист Ж. Кәлимуллинның бу китабына автомобиль комплексы һәм яңа шәһәр төзелешендә эшләүче яшьләргә багышланган очерклар, публицистик мәкаләләр, репортажлар тупланган. Аларда автогигант төзүчеләрнең фидакарь хезмәт үрнәкләре гәүдәләнә, авторлар безгә төрле милләт вәкилләренең бердәм тату гаилә булып яшәүләре, белем һәм культураларын үстерүләре, тирән дуслыклары һәм мәхәббәтләре турында сөйлиләр.

Китап «Җитмешенче еллар горурлыгы» дигән мәкалә белән ачыла. Төзелешнең зурлыгы һәм үзенчәлеге турында күтәренке рух, ялкынлы тел белән сөйли башлаган публицистик мәкалә укыган саен тармаклана, киңәя бара. Мәкаләдә авторлар зур төзелешкә бәйле барлык мәсьәләләрне иңләргә тырышалар.

1972 елның 1 мартында КамАЗның яшь төзүчеләре башкалабыз Мәскәүдә, ВЛКСМ Үзәк Комитетының конференц-залында беренче бишьеллыклар каһарманнары М. Виноградова, А. Бусыгин һәм И. Гудов белән очраштылар. «Хыял-канатлар, реаль канатлар» — шул очрашуны тасвирлауга багышланган репортаж.

Очеркларның иң зур күпчелеге — КамАЗның алдынгы бригадирлары турында. Аларны укыганда, без Р. Сәләхов («Бригадир Рәис Сәләхов»), В. Мәүликов («Так держать, улым!»), Л. Шәмсетдинова («Күңел»), В. Шатунов («Төпчек ул»), Г. Филяшина («Бригада башлыгы») кебек атаклы җитәкчеләр белән, алар җитәкләгән бригадаларның эше, тормышы белән танышабыз. Әлеге бригадирларның һәркайсы — бөтен илгә танылган кешеләр. Алар хакында бик күп мәкаләләр, очерклар язылган. Алар турында кабатланмаган, яңа сүз әйтү — шактый кыен эш. Авторлар моны яхшы аңлыйлар. Алар үзләренчә язарга, әлеге геройларның башкалар күреп җиткермәгән яңа якларын ачарга омтылалар. Һәм еш кына шул максатларына ирешәләр дә.

Җыентыкка тупланган очерклар белән танышып барганда, моңарчы чыккан әсәрләрнең берсендә дә күренмәгән яңа геройлар очрый. Шуларның иң кызыклысы — идарә башлыгы Зөфәр Садретдинов. «Ул һаман солдат» дигән очеркта без аның ифрат гыйбрәтле һәм бай тормыш юлы белән танышабыз. Садретдинов — башлап Б. Камаловлар ачкан герой. КамАЗда эшләүче бөтенсоюз «Дуслык» отряды турында «Бөтенләйгә калырмын, ахры»... дигән язма да әйбәт тәэсир калдыра.

«Дуслык таулар күчерә» җыентыгына нигездә төзелешнең башлангыч этабын чагылдырган мәкалә-очерклар тупланган. Авторлар моның белән генә тукталып калмаслар дип ышанасы килә.

Р. ВӘЛИЕВ. Шәһәр булсын бүләгем. Документаль повесть. Татарстан китап нәшрияты. 1973 ел. Тиражы 2000 данә. Бәясе 13 тиен

Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлагач, яшь журналист Равил Вәлиев Чаллы шәһәренә җибәрелә. Турыдан-туры үз һөнәре буенча эшли башлагачты, аңа байтак вакытлар Вазыйх Мәүликовның комсомол-яшьләр бригадасында гади ташчы булып йөрергә туры килә. Шул чагында ул яңа Чаллы шәһәрен төзүче атаклы бригада турында көндәлекләр алып бара. «Шәһәр булсын бүләгем» исемле бу повесть шул көндәлекләр нигезендә язылган.

Хәер, укучы әсәр белән күпмедер дәрәҗәдә таныш дияргә була. «Казан утлары» журналының 1972 елгы 2, 3, 4 саннарында аның күп өлеше басылды. Һәм «Каурыйлар чыныкканда» дип исемләнгән әлеге язмалары өчен Р. Вәлиев журналның махсус премиясе белән бүләкләнде.

Билгеле, әсәрнең яңа варианты шактый тулыландырылган, зурайтылган.

Повесть кечкенә-кечкенә аерым бүлекчәләрдән тора. Һәр бүлекчә бригада тормышына бәйле теге яки бу конкрет эпизодны сурәтләүгә багышланган. Әсәрне укыганда, без бригаданың бик күп кызыклы кешеләре белән очрашабыз: шигъри җанлы, тыйнак табигатьле Әлфинур Әхмәтова, министрлар кебек киенеп йөри торган Ганс Нәбиев, «аглый белән таглый» кебек йөрүче Арча егетләре, Миша белән Володя, тагын бик күпләр... Авторның төп игътибары әнә шул кешеләргә юнәлгән. Ул төрле хәликлы, төрле язмышлы яшьләрдән, төрле милләт вәкилләреннән торган бригаданың таза бер коллектив булып оешуын күрсәтә алган.

Бригада кешеләрен үзара якынайтуда, бер-берсе белән дуслаштыруда Муса Җәлил шигырьләре зур роль уйный. Герой шагыйрьне алар үз бригадаларының почетлы члены итеп алалар, һәр көнне аның өчен дә норма үтәп баралар.

Төзелеш эшендәге күп төрле яңа алымнар башлап В. Мәүликов бригадасында сынала, яңача эш ысулларын башлап алар куллана. Йорт салуда Липецк ысулы, тырышлык коэффициентын куллану, бригада подряды белән эшләү һ. б. Повесть авторы укучыларны әнә шул алымнар белән дә таныштыра, безгә аларның асылын, мәгънәсен аңлата.

Повесть җыйнаклыгы, төзеклеге белән аерылып тора. Автор нигездә бер бригада кешеләре, алар башкарган эшләр турында гына сөйли кебек. Әмма әсәрне укыганда без төзелешнең бөтен колачын, бөтен сулышын тоеп-сизеп торабыз.

Б. КАМАЛОВ. Урамнар киңәя. Повесть һәм хикәяләр. Татарстан китап нәшрияты. 1973 ел. Тиражы 11000 данә. Бәясе 39 тиен

Прозаик Барлас Камалов «Урамнар киңәя» дип исемләнгән яңа повестенда Кама автомобиль комплексын төзүчеләр турында яза. Әсәрдә илнең төрле почмакларыннан Чаллыдагы төзелешкә килгән кешеләр турында сөйләнә, аларның бердәм эшчеләр коллективына кушылып

китүе, гадәт-холыклары, характерлары формалашуы күрсәтелә. Яшүсмер Яфиз Сәмитов, кранчы Вәдүт Шәйхаттаров, укытучы Рәйхан, сугыш һәм хезмәт ветераны Григорий Самородкин да, Морзахан абзый белән Зөһрәбану түти дә хәтердә калырлык образлар булып чыкканнар.

...Көннәрнең берендә Чаллыга, Морзахан абзыйның шыгырдап торган таза йортына уйламаганда-көтмәгәндә берьюлы берничә кеше кайтып төшә.

Морзахан абзыйның үз улы Вәдүт моңарчы Төмән якларында эшләп йөргән икән. Армия хезмәтеннән соң, ул шул якларга ташпулатлар төзешергә киткән булган. Биредә кичке мәктәптә укып, кулына аттестат ала. Шунда ул ире үлгән тол хатын Рәйханны очрата. Бер-берсен яратышалар, семья корып җибәрәләр. Һәм менә, Рәйханның беренче иреннән туган Айдар исемле малайны да ияртеп, автомобиль заводы төзергә, яңа шәһәр салырга дип, Чаллыга кайтып төшәләр.

Кайтучыларның тагын берсе — Яфиз исемле үсмер егет, Морзахан абзыйга ерак булса да кардәш тиешле кеше. Уналты яше дә тулмаган килеш, Сергачтагы мәктәп-интернаттан качып килгән. Кызыклы яңа тормыш, романтика үзенә тарткан. Повестьны укыганда, без аларның, төрле кыенлыкларны җиңеп, автогигант төзүчеләр сафына кушылып китүләре белән танышабыз. Автор безне аларның яңа урындагы тормышы, хезмәте белән таныштыра.

М. ХӘБИБУЛЛИН. Тау белән тау очрашмаса да. Повесть. Татарстан китап нәшрияты. 1974 ел. Тиражы 10 000 данә. Бәясе 34 тиен

...Җәйге ялга кайткач, Зөлфәт үз авылларындагы бер чибәр кыз белән таныша. Яратышып китәләр. Егет кызны ничек тә үзенеке итәргә була. Миңа кияүгә чык, Казанга алып китәм, ди. Кыз, иң яхшысы Чаллыга китик, анда зур төзелешләр башлана, ди. Матур кызның шул сүзенә ышанып, Казандагы менә дигән эшен, көйләнгән тормышын ташлап, Зөлфәт Чаллыга кайта. Көч-хәл белән начар гына эшкә урнаша, торыр урын юнәтә. Инде сөйгәне Мәснәвияне дә алып килим дип, авылга кайтса, матур кыз кияүгә чыккан... Зөлфәт, үпкәләп һәм рәнҗеп, яңадан Чаллыга китеп бара. Баксаң, моның кулыннан Мәснәвияне тартып алган кара мыеклы Ислам исемле егет тә Зөлфәт эшли торган автохуҗалык шоферы икән. Сүз дә юк, болар баштан ук бер-берсен яратышмыйлар.

Ислам һәм Зөлфәт — әсәрнең төп геройлары. Алар арасындагы конфликт бүлектән-бүлеккә үсә, көчәя килә. Билгеле, алар бер матур кызны бүлешә алмаган өчен генә дошманлашып китмиләр. Сәбәпне тирәннәнрәк эзләргә кирәк. Төп сәбәп — аларның характер үзенчәлекләрендә, дөньяга карашларында. Һәр икә образга әсәрдә зур урын бирелгән. Шулай да Ислам ныграк хәтердә калырлык булып чыккан. Ислам — әлегә үзенең төп юнәлешен тапмаган кеше. Ислам — хәрәкәт кешесе. Ислам — көтелмәгән хәлләр, сюрпризлар кешесе. Бер тәнкыйтьчебез язганча, без аны баштанаяк мажаралар эчендә күрәбез. Аның үлеме дә әнә шундый мажараларның берсе. Зөлфәт алдында сер бирәсе килмичә, машинасы белән ныгып җитмәгән боз өстенә кереп китә һәм батып үлә... М. Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да» дигән повестенда шул вакыйгалар сөйләнә.

Күрәсез, бу повесть та КамАЗ турында. Әсәр төзелештә эшләүче шоферлар тормышын сурәтләүгә багышланган. Авторның төп игътибары бердәм коллектив формалашуын һәм яңа кешеләр тууын сурәтләүгә юнәлгән.

Мы строим КамАЗ. Төзүчеләре В. Белокопытов, Р. Биктәһиров һәм Е. Лисин. Художнигы Э. Зарипов. Татарстан китап нәшрияты. 1974 ел. Тиражы 5000 данә. Бәясе 1 сум 7 тиен

Бу китап Камаздагы автомобиль гигантын төзүче бетончылар, ташчылар, балта осталары, монтажчылар, бульдозерчылар, шоферлар, экскаваторчылар тарафыннан

язылган. Китапка кергән кечкенә-кечкенә мәкаләләрендә алар иптәшлек һәм дуслык хисләре, яшьлекләре, яратып башкарган хезмәтләре турында сөйлиләр, кайгы-хәсрәтләре, шатлык-сөенечләре белән уртаклашалар.

Беренче бүлек «КамАЗ — ул...» дип исемләнгән. Бу бүлектә кыска-кыска җөмләләр белән төзелешнең төрле якларын (колачын, зурлыгын, үзенчәлеген, бүгенгесен, киләчәген һәм башка якларын) характерлый торган мәгълүматлар китерелә. Ул мәгълүматлар белән танышкач, КамАЗның тулы картинасы күз алдына килеп баса.

«Әтиләребез Магнитка төзегән, без КамАЗ төзибез» дип исемләнгән икенче бүлектәге материалларның кайберләре белән алдарак бер танышкан идек. Әйтик, беренче бишьеллыклар герое Алексей Стахановның КамАЗ төзүчеләргә адресланган хаты «Батыр адымнары»нда, ә Р. Сәләхов җитәкләгән монтажчылар бригадасының ачык хаты «Камадагы батыр»да бар иде.

«Без КамАЗ төзибез» исемле китапта автозавод һәм шәһәр төзелешендә эшләүче алдынгы бригадаларның җитәкчеләренә күп урын бирелгән. Без сүз алып бара торган шушы икенче бүлектә комплекслы бригада бригадиры, Социалистик Хезмәт Герое А. Новолодский «Улларың синең санап бетергесез, Магнитка!», «Стальконструкция» трестының монтажчылар бригадиры В. Деребизов «Горурлык хисе», штукатурчы-малярлар бригадасы бригадиры Л. Шәмсетдинова «Төзелеш дәвам итә» һәм монтажчылар бригадасы бригадиры, партиянең Татарстан өлкә комитеты члены В. Филимонов «Өченче биеклек» дигән мәкаләләр белән катнашалар. Ул мәкаләләрне укыганда, алар җитәкләгән бригадаларның кешеләре, һәр бригаданың хезмәт фронтында ирешкән уңышлары белән танышасың. Алай гына да түгел, бүгенге көн геройларының тормышка карашлары һәм рухи дөньялары ачыла, бүгенге төзүчеләребезнең ифрат киң карашлы, һәр яктан өлгергән кешеләр булуын күреп сөенәсең.

Бригадирлар башлаган сүзне алга таба гади эшчеләр дәвам иттерә. «Миңа теләсә нинди эш бирегез» дип исемләнгән өченче бүлектә сүз бульдозерчыларга һәм шоферларга, балта осталарына һәм таш чыларга, аш осталарына һәм сатучыларга бирелә. Алар үз һөнәрләре турында, бергә эшләгән иптәшләре турында сөйлиләр.

Кама автомобиль комплексын төзүдә илнең бөтен почмакларыннан җыелган 100 меңләп эшче, 60 лап милләтнең уллары һәм кызлары эшли. «Дуслык! Дуслык! Дуслык!» дип исемләнгән соңгы бүлек төрле милләт вәкилләре арасындагы интернациональ дуслык хисләре турында сөйли. Анда төрле милләт егетләренең дуслык турындагы мәкаләләре урнаштырылган. З. Айтпаев Чаллыга ерак Казагыстаннан, Л. Пинтурия Грузиядән килгән. Л. Станкевич — белорус егете, В. Пан — кореец. «Бишьеллыкны — өч елда» исемле мәкаләнең авторы У. Наурбиев Чечен-Ингушиядән. Әйе, КамАЗдагы кайсы гына бригаданы алып карасаң да, анда бик күп төрле милләтләрнең вәкилләрен очратырга була. КамАЗ төзелешендә чын интернационализм хисләрендә тәрбияләнгән яңа буын үсә.

...Җыентык төзелеш кешеләрен, аларның хезмәтен һәм тормышын яктырткан бик күп фоторәсемнәр белән бизәлгән. Художник Э. Зариповның график рәсемнәре китапка үзгә бер күркәмлек өстәп, ямь биреп тора.

Ә. БАЯНОВ. Ут һәм Су. Роман. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1973 ел. Тиражы 15000 данә. Бәясе 55 тиен

Чаллыдагы төзелеш әле чын-чынлап колач җәеп, көчәеп кенә килә иде. «Казан утлары» журналында Ә. Баяновның «Ут һәм Су» исемле яңа романы басыла башлады. КамАЗ турындагы бу роман төзелешкә багышланган беренче шигырьләр һәм очерклар белән бер үк вакытта дөнья күрде. 1973 елда инде Татарстан китап нәшрияты аны аерым китап итеп чыгарды.

Әхсән Баянов — асылда шагыйрь кеше. Прозага ул шигырьдән килде һәм аңа шагыйрьлеген дә алып килде. Бу — «Ут һәм Су» романында да сизелә. Әсәрдә шигърият белән проза, прозаның кырыс реальлеге белән поэзиянең шартлы алымнары чиратлаша. Аның бу романын кызыклы һәм үзенчәлекле иткән сыйфатларның берсе әнә шул булса кирәк.

Бу роман тагын фикер байлыгы, эзләнүчән рухы белән игътибарны җәлеп итә. Автор табигатьне саклау мәсьәләләре белән баш ватa, аны кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, КамАЗ төзүчеләрнең хезмәте, тормышы белән бәйләнгән күп төрле башка мәсьәләләр кызыксындыра.

Бу романның уңышлы һәм кимчелекле яклары, сәнгатьчә үзенчәлекләре турында күп язылды. Бигрәк тә Р. Мостафин мәкаләләрендә аңа төпле бәя би-

релде. Аның бу әсәр турында әйткән фикерләре белән килешми мөмкин түгел.

Романның эчке конфликтын һәм драматик киренкелеген дөньяга ике төрле караш, капма-каршы ике характер билгели. Аларның берсе — Фәез Насыйбуллин, икенчесе — Борис Филинов. Икесе дә төзелеш институтын тәмамлаган белемле инженерлар, икесе дә күп төзелешләрдә булган тәҗрибәле төзүчеләр. Әмма тормышка карашлары, эшкә мөнәсәбәтләре капма-каршы. Участок начальнигы Фәез Насыйбуллин бөтен вакытын, көч-энергиясен төзелешкә багышлый. Таңнан алып кичкә хәтле ул төзелеш буйлап чаба, прораблар белән тиргәшә, кичләрен игечиге булмаган киңәшмәләрдә, төрле утырышларда уздыра. Борис Филинов исә — сәгатьтән-сәгатькә кадәр генә эшләргә, эшкә вакытында килеп, вакытында кайтып китәргә гадәтләнгән кеше. Моның өчен аны тиргиләр, үгетлиләр, шул ук вакытта аңа таяналар да. Чөнки ул талантлы инженер, үз эшен искиткеч шәп белә торган кеше.

Фәез белән Борис шәхси тормышларында да бер-берсеннән нык аерылалар. Фәез романтик табигатьле егет, хыялындагы мәхәббәтен эзли, Кама-Камиләләр белән «саташкан» кеше. Борис хатын аерган тол ир, үз күңелен күреп, үз рәхәтен көйләп яши: машинасында чибәр кызлар, квартирасында күңелле мәҗлесләр...

Шул рәвешчә, әсәрдә югары романтик омтылыш белән исәп-хисапка корылган аек акыл бәрелешә. Авторның симпатиясе ачыктан-ачык романтик табигатьле Фәез ягында. Чөнки төзелеш вакыт белән дә, кыенлыклар белән дә санашмый торган энтузиастлар, Фәез кебек фидакарь егетләр җилкәсендә бара.

М. ХӘСӘНОВ. Кама таңнары. Роман. Татарстан китап нәшрияты. 1973 ел. Тиражы 15000 данә. Бәясе 39 тиен

КамАЗ төзелеше үзенең зурлыгы һәм колачы белән генә түгел, моңарчы бер кайда да күрелмәгән кызу темплары, техник коралланышы, хезмәтне оештырудагы яңалыклары белән дә таң калдыра. Кама автомобиль комплексы салуга илебезнең йөзгә якын проектлаштыру һәм фәнни-тикшеренү институты катнаша. Яңа Чаллы шәһәре һәм автомобиль заводы иң яңа ысуллар белән салына. КамАЗ алдынгы совет фәненең һәм техниканың соңгы казанышларын файдаланып төзелә.

Мәхмүт Хәсәновның «Кама таңнары» романы төзелештәге фән кешеләренә багышланган. Әсәрдә сүз координация-информация үзәгендә эшләүче галимнәр, инженерлар турында бара.

Талантлы һәм тәҗрибәле инженер Имам Котдусов, аның ярдәмчеләре Николай Соснов, Даниал Ризванов төзелешне үзен һәм төзелеш белән идарә итү эшләрен фәнни нигезләргә салу өчен тырышалар. Шул юлда аларга күп төрле кыенлыклар күрергә, төрле кешеләр белән

очрашырга, аерым җитәкчеләр белән әчелешле булырга туры килә. Шулай романга гыйбрәтле тормыш юлы узган Вәгыйз Гайнановлар, иске тәҗрибә, кичәге алымнар белән генә эшләргә гадәтләнгән Колуннар килеп керә.

Романның төп герое — Имам Котдусов. Әсәрдә сурәтләнгән барлык вакыйгалар тегеләйме-болаймы Имам язмышына килеп бәйләнә, романдагы күпчелек образлар Имамны ачу, аны тулыландыру өчен кертелгән. Автор бу образының шәхси тормышын сурәтләүгә дә зур игътибар бирә. Имамны без төрле хәлләрдә, төрле ситуацияләрдә очратабыз, аның шәхси тормышына бәйле Зинаидалар, Һәдияләр белән танышабыз.

Имам Котдусов хезмәттә һәм шәхси тормышта үз бәхетен таба. Әсәр оптимистик рухта язылган юллар белән тәмамлана.

КамАЗ. Төзүчесе А. Ланщиков. Художнигы А. Катин. «Молодая гвардия». 1974 ел. Тиражы 50 000 данә. Бәясе 54 тиен

Бөтен союз укучысын КамАЗ белән таныштыру ниятеннән чыгып төзелгән бу җыентык күп кенә яктан Татарстан китап

нәшрияты чыгарган «Камадагы батыр», «Батыр адымнары» дигән китапларны хәтерләтә. Җыентыкка вакытында үзәк газета-журналларда һәм Татарстан матбугатында басылган мәкалә-очерклар, репортажлар, шигырьләр тупланган. Автозавод һәм яңа шәһәр төзүчеләр тормышының төрле якларына багышланган ул материаллар Кама ярларында барган төзелешнең зурлыгын, колачын күз алдына бастырырга булыша.

Кама автомобиль заводының генераль директоры Л. Васильевның «КамАЗ — иң мөһим төзелеш» һәм КПССның Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре Р. Беляевнең «КамАЗдагы кешеләр һәм эшләр» дигән мәкаләләре безгә электән таныш. Алар «Камадагы батыр» һәм «Батыр адымнары» исемле китапларда да бар иде. Р. Биктәһировның «Кубиклар» турында баллада»сы заманында безнең журналда («Казан утлары». 1973 ел 9 сан.) басылды. А. Злобинның «Камадагы очрашулар» әсәре турында да шул ук сүзләрне кабатларга мөмкин. «Камадагы батыр» китабында без язучының «Куен дәфтәреннән» дигән язмалары белән танышкан идек. «Камадагы очрашулар» — шуның тулыландырылган, төзекләндерелгән варианты.

Шуның белән бергә, «КамАЗ» җыентыгында моңарчы без белмәгән, без укымаган материаллар да шактый. В. Семин «Тормыш төзелә» исемле очеркында КамАЗга бәйле бик күп мәсьәләләрне күтәрә, автозавод төзелешенең бөтен якларын иңләргә омтыла. Очерк авторы вакытында Куйбышев ГЭСын төзүгә катнашкан. Ул әледән-әле үткәннәргә экскурс ясый, КамАЗ төзелешенең зурлыгын, колачын конкретрак итеп күз алдына китерү өчен, аны ГЭС төзелеше белән чагыштырып, шуның яңашәсенә куеп бара. Людмила Атрашенконың «Яшьлек калалар төзи» дип исемләнгән язмасы — КамАЗ төзелешендә эшләүче яшьләрнең мораль йөзләре, рухи ихтыяҗлары, эчке дөньялары турында.

Китаптагы дистәләгән мәкалә-очерклар арасыннан аеруча нык аерылып торганы — Г. Филяшинаның «Минем бригадам» дигән мәкаләсе. Мәкалә табигый һәм эчкерсез булуы, төзелеш мәсьәләләрен, төзүчеләр тормышын тирәнтен белеп язылуы белән игътибарны җәлеп итә. Артык зур булмаган шушы мәкаләне укыганда, Г. Филяшина җитәкләгән бригада кешеләре, алар башкарган күп эшләр белән танышасың. Мәкалә кызыклы күзәтүләре, төпле фикерләре белән үзенә тарта. «Миннән, бригадир нинди булырга тиеш, нинди бригадирлар була, дип сорыйлар — ди Г. Филяшина. — Мин дөньяда нихәтле кеше булса, бригадирлар да шул хәтле үк булырга мөмкин дип җавап бирәм. Кем бөтен нәрсәне искечә эшли, иң начары шулар... Әгәр кеше бригадир булып алгач үсми, башкалар алдында нихәтле җаваплы булуын сизми икән — бу бик начар».

Икенче бер урында бригада башкарган эшләр турында сөйләп килә-килә дә, эшнең сыйфаты турындагы мәсьәләгә җиткәч, фикерен түбәндәге сүзләр белән йомгаклап куя: «Югары сыйфатлы эш тәртипкә өйрәтә, намуслылык тәрбияли. Беренче карашка никадәр генә сәер тоелмасын, сыйфат турында кайгырткан кеше күбрәк эшли һәм азрак арый. Югары сыйфат белән башкарылган эш кешегә канәгатьлек хисе бирә, аңардагы эчке ялкынны сүндерми».

КамАЗ төзелешендә халык, ил мәнфәгатьләре югарылыгыннан торып уйлый белә торган киң карашлы яшьләр эшли икән. Г. Филяшина мәкаләсе әнә шул хакта сөйли.

Татарстан китап нәшрияты чыгарган җыентыклардан аермалы буларак, «КамАЗ» китабында поэзия әсәрләренә зур урын бирелгән. Биредә без С. Шәрипова һәм С. Хәким, Я. Смеляков һәм М. Львов, В. Костров һәм Ю. Котов, А. Гаврилов һәм Ф. Чуев шигырьләре белән танышабыз. Ул шигырьләрнең барысы да КамАЗга, гигант төзелештә эшләүче кешеләргә багышланган.

Китап нечкә зәвык белән эшләнгән рәсемнәр, төзелешнең төрле якларын чагылдырган бик күп фотолар белән бизәлгән.

Г. КОПОСОВ, Л. ШЕРСТЕННИКОВ.
Автоград. Мәскәү. «Молодая гвардия» нәшрияты. 1974 ел. Тиражы 25 000 данә. Бәясе 3 сум 23 тиен

Бу китап КамАЗ төзелешен сурәтләгән фоторәсемнәрдән тора. «Огонек» журналының танылган фоторепортерлары Геннадий Копосов һәм Лев Шерстенников күп мәртәбәләр автозавод төзүчеләре янында булганнар, төзелеш күренешләрен, анда эшләүче кешеләрне фотога төшерә барганнар. «Автоград» шул фоторәсемнәр нигезендә төзелгән.

Фоторәсемнәрдән тыш, китапта кыска-кыска очерклар, көндәлек дәфтәрләреннән өзекләр, КамАЗ шагыйрьләренең шигырьләре бирелгән.

Җыентык кыска гына кереш мәкалә белән ачыла. Икенче төрле әйткәндә, аны Ленин комсомолының хезмәт биографиясе дип атарга мөмкин. Мәкалә авторлары беренче бишьеллыклар чорыннан алып бүгенге көнгә кадәр комсомол шефлык иткән бөек төзелешләр, комсомол башкарган

данлы эшләр белән таныштыралар. КамАЗ — шуларның иң зурысы, иң яңасы.

Китап зур булмаган алты бүлектән тора. Һәр бүлек төзүчеләр тормышының нинди дә булса конкрет бер өлкәсен яктырта. Беренче бүлектәге фоторәсемнәр Чаллы якларының ерак үткәне турында сөйли, безне автогигант төзелешенең башлангыч чоры белән таныштыра.

КамАЗ ни дигән сүз? КамАЗ нинди төзелеш ул? Китап авторлары, әнә шул сорауга җавап бирүләрен үтенеп, Чаллыда эшләүче төрле буын вәкилләренә, төрле һөнәр кешеләренә («Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе начальнигының беренче урынбасары Е. Батенчукка, КПСС-ның Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре Р. Беляевкә, монтажчылар бригадиры В. Чирчикка, архитектор Л. Криницкаяга, оператор З. Шалагинага, Лихачев исемендәге Мәскәү автомобиль заводының баш конструкторы А. Кригерга, төзелешнең комсомол комитеты члены, инженер М. Ризвановка, ташчылар бригадасы бригадиры В. Мәүликовка, 10 нчы мәктәп укучысы Т. Прокошевага, төзелешнең комсомол штабы начальнигы Р. Халитовка) мөрәҗәгать иткәннәр. «Темп, темп, темп» дип исемләнгән икенче бүлеккә аларның җаваплары урнаштырылган. Анкета сорауларына җаваплар төзелеш күренешен сурәтләгән фоторәсемнәр белән бизәлеп килә.

Өченче бүлек беренче бишьеллыклар батырларының фоторәсеме белән ачыла. Бу бүлектәге фотоларда үткән белән бүгенге көн, үткәндәге төзелешләр белән КамАЗ янәшә куеп, чагыштырып барыла.

Люба Чудковская — Волгоград кызы. КамАЗ төзелешендә ташчы булып эшли. Көндәлекләр алып бара. «Көндәлек битләреннән» дип исемләнгән бүлектә шул дәфтәрдән өзекләр бирелгән. Авторлар ул язмаларны да фоторәсемнәр белән иллюстрацияләп баралар.

«Шигырь дә, җыр да» дигән бүлек «Орфей» әдәби берләшмәсенә йөрүче яшьләр иҗатына багышланган. В. Хатюшин, Е. Кувайцев, И. Лимонова, О. Яшкина, В. Быченок шигырьләрендә гигант төзелешнең күп төрле яклары чагыла.

Соңгы алтынчы бүлекне башкача «КамАЗ елъязмасы» дип тә исемләргә мөмкин. Чаллыдагы автохуҗалык эшчесе Камил Ситдиков берничә еллар буена төзелеш күренешләрен фоторәсемгә төшерә барган. Аның рәсемнәрендә гигант төзелешнең бөтен тарихы чагыла. Бу бүлектә төп урынны К. Ситдиковның шул фотолары алып тора.

«Автоград» җыентыгы илебезнең башка зур төзелешләре хакында сөйли торган фоторәсемнәр белән ябыла.

В. ИХСАНОВА. Учаклар. Очерклар. Татарстан китап нәшрияты. 1974 ел. Тиражы 5000 данә. Бәясе 12 тиен

Кем булырга? Нинди һөнәр сайларга? Мәктәпне тәмамлап, олы тормыш юлына аяк басарга әзерләнгән һәр укучы алдында әнә шундый сораулар тора. Әлеге сорауларга җавап эзләп, республикабыз укучылары Кама буйларына — автогигант төзелгән җирләргә киләләр, яңа шәһәр белән, анда эшләүче кешеләр белән танышалар.

Кама елгасының теге ягында, Алабуга шәһәре янындагы нарат урманында автозавод салучыларның балалары ял итә торган пионер лагере бар. «Алтын тау» исемле шул лагерьда кичләрен учаклар кабына. Учак янында КамАЗ геройлары пионерларга үзләре сала торган завод һәм шәһәр турында, бергә эшләгән иптәшләре турында сөйлиләр. В. Ихсанованың урта яшьтәге мәктәп балаларына адресланган «Учаклар» исемле китабында әнә шул вакыйгалар турында сөйләнә.

Мәктәп балаларына Кама ярларындагы төзелешнең бөтен колачын, үзенчәлекләрен аңлату шактый авыр эш. Шуны истә тотып, автор үзе күтәргән мәсьәләләрне билгеле бер сюжетка, әдәби формага салып язган.

Җыентык кечкенә-кечкенә аерым очерклардан тора. Һәр очерк төзелеш, анда эшләүчеләр белән бәйле берәр мәсьәләгә багышланган. «Танышу», «Көндәлектән юллар», «Монтажчылар», «Иң кирәге» кебек очеркларда төзелешнең күләме, үзенчәлеге турында гомуми мәгълүмат бирелә. «Беренче учак», «Икенче учак», «Өченче учак» дигәннәрендә автор укучыларны төзелешнең атаклы кешеләре белән таныштыра...

Кыскасы, «Учаклар»ны укыганда без төзелешнең үзе турында да, анда эшләүче кешеләр турында кызыклы һәм файдалы күп нәрсәләр белеп калабыз. Аның төп кыйммәте әнә шунда.

Х. КАМАЛОВ. Язмыш елмаюы. Татарстан китап нәшрияты. 1974 ел. Тиражы 3000 данә. Бәясе 40 тиен.

Хисам Камаловның яңа җыентыгы «Язмыш елмаюы» исемле зур шигъри әсәр белән ачыла. Ул автогигант төзүчеләр тормышыннан алып язылган. Жанры аныклы түгел. Автор үзе лирик эскизлар дип куйган. Ихтимал, ул хаклыдыр. Әсәрнең язылу рәвешендә һәм стилендә, алынган материалны бүлекләргә бүлүдә һәм ул бүлекләрнең эчтәлегендә эскизлык шактый ныклы сизелә.

Шагыйрьләребез соңгы елларда КамАЗга багышлап бик күп шигырь, берничә поэма яздылар. Моңарчы язылган әсәрләрдә төзелешнең колачы, масштаблары белән соклану өстенлек итеп килде. Алардан аермалы буларак, Х. Камаловны төзелешнең кешегә, аның характерына булган йогынтысы күбрәк кызыксындыра. Әсәрнең үзәгенә кеше язмышы белән бәйләнгән вакыйгалар салынган.

«Язмыш елмаюы»нда төзелешнең башлангыч чоры өчен хас эпизодлар сурәтләнә, шул чор өчен характерлы каршылыклар алынган. Мәгълүм булганча, яңа оешкан һәр коллектив, зур эшләрне җиңеп чыгарлык көчкә әверелгәнче, ипләнү чорын уза. Шул чакта кешеләрнең характеры, ныклыгы, иманы сынала, чын йөзләре ачыла. Бу әсәрдә дә шулай. Прораб Нур, бетончы Өлфәт һәм бүтән образлар аша автор автогигант төзелешендәге хезмәтнең киренке һәм кискен якларын сурәтли, аларның заман кешеләренә хас булган уй-фикерләрен, шатлык-борчуларын ачып сала, шул юл белән укучыларга тәэсир ясарлык образлар иҗат итә.

Әсәрдәге күпләгән образлар арасыннан аеруча хәтердә калганы — Нур Хәлкин. Ул әсәрдә сурәтләнгән барлык вакыйгаларда катнаша. Тормыш дулкыннары аны әйләндереп-тулгандырып йөртә, бер ярдан икенче ярга куа. Ул бер күтәрелә, бер төшә, ниһаять, үзенең чын урынын таба. Кайбер каршылыклы урыннары, дәлилләп җиткерелмәгән фигыльләре булуга да карамастан, Нур образын авторның уңышы дип санарга була.

«Язмыш елмаюы»ннан тыш, җыентыкка авторның соңгы елларда язылган байтак шигырьләре кергән.

Р. МИНГАЛИМОВ. Күз карасы. Поэма һәм шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1974 ел. Тиражы 2000 данә. Бәясе 32 тиен

Бу җыентыкның шактый өлешен «Күз карасы» исемле поэма алып тора. Поэмада автор Кама автомобиль комплексы төзелешенең аерым күренешләре белән таныштыра, төзелештән алган тәэсирләре белән уртаклаша.

Әсәр «Җыр башы», «Җыр дәвамы — шатланыр өчен», «Җыр дәвамы — эш көне», «Җыр дәвамы — сүзләр», «Җыр дәвамы —

ныклык», «Җыр дәвамы — туйлар» һәм «Җыр ахыры» дигән бүлекләрдән тора. Һәр бүлек я төзелешкә караган нинди дә булса берәр эпизодны, я авторның шул төзелеш күренешләре тәэсирендә туган уй-фикерләрен сурәтләүгә багышланган. Фикернең характерына, яңгырашына карап, автор әле ирекле шигырь алымнарына, әле традицион формаларга таяна. Әсәрдә лирика белән публицистика үзара үрелеп, чиратлашып бара. Поэманың үзәгеннән, КамАЗ җирнең иминлеген саклау өчен салына, Чаллы җимерелмәскә салына, дигән фәлсәфи фикер сузылып бара. Буйдан-буйга килеп, ул поэмадагы аерым кисәкләрне бергә туплый, аны бөтен итә.

«Күз карасы» поэмасы өчен Р. Мингалимовка 1974 елда КамАЗ премиясе бирелде.

КамАЗ китаплары белән Ф. МИҢНУЛЛИН таныштырды.

А. Буланов

Электр баганасы

Черегән... Тагын черергә
Мөмкин түгелдер ары,
Күптән йолкып атасы да...
Бәйләнеше югары!...

Түмгәк

— Тормыш бара алга таба,
Мин кузгалмый яшим, димәк,
Зарар юк. Аның каравы,
Абынганым юк, — ди түмгәк.

Зур бурычлар

Алда тора зур бурычлар:
...Мең сум әҗәт түлисе бар.

Матурлыкны кадерләүче

Матурлыкның кадерен,
Бәясен белә Мәгъсүм.
Базарда сата чәчәк:
Берсе-берсе өч-дүрт сум.

Җәүдәт Дәрзаманов

Өйләнеп бер ел торгач

Мәзәк

Их син, кайниш, ялганчы,
Әйткән булдың алганчы:
«Ишек бавы бер алтын,
Безнең апай мең алтын».

Мең алтындыр — сүзем юк,
Тик холкына түзем юк.

Кашкайлары җимерек,
Яши жанны кимереп.

Әйдә, кайниш, бергәләп
Төзәтик бу хатаны —
Өстәп бирәм мең алтын,
Алып китсәң апаңны!

БЕРВАКЫТ ШУЛАЙ БУЛА...

АТАКЛЫ КЕШЕЛӘР ТОРМЫШЫННАН...

Гадәти кием һәм гади җавап

Чарлз Диккенсны маскарадка чакыралар. Кунакларның һәркайсы Вальтер Скотт романнарындагы геройларның берсе булып киенергә тиешлеге әйтелә.

Диккенс маскарад кичәсенә үзенең гадәти киемен киеп, маскасыз килә. «Сез нинди герой бүген биредә?» дигән чәнечкеле сорауларга ул бер үк гади җавапны бирә:

— Вальтер Скотт үз китапларына язган һәр керештә «Хөрмәтле укучым» дигән кешегә мөрәҗәгать итә. Мин биредә шул «Хөрмәтле укучы»ларның берсе булам.

Начар хәтер

Французз мәсәлчесе Лафонтенның хәтере бик начар булган, имеш. Бервакыт ул бер дустының хәлен белергә бара да аның моннан берничә атна элек кенә вафат булуын ишетә.

— Әйе шул! Шулай бит әле! — ди язучы, кинәт шуны исенә төшереп. — Мин бит аны күмгәндә речь сөйләгән идем.

Симерүгә каршы чара

Бик зыялы бер мәҗлестә Бернард Шоуның урыны туку фабрикасы хуҗасының хатыны белән янәшә туры килә.

— Хөрмәтле мистер Шоу, симерүгә каршы нинди дә булса төпле бер чара белмисезме сез? — дип мөрәҗәгать итә аңа шул ханым.

Бернард Шоу фабрикант хатынының тау хәтле гәүдәсенә күз сала да әйтә:

— Андый чараны мин беләм, әмма ничек дип әйтелгәнен сезгә тәрҗемә итә алмамдыр шикелле, чөнки «хезмәт» дигән төшенчә сезнең өчен чит тел сүзе ул.

Үч алу

«Юкка чыккан җәннәт» исемле әсәр язган инглиз шагыйре Джон Мильтон үзе белән дошманлашкан бер тәнкыйтьчегә кызын кияүгә бирә.

— Кызыгызны шул кешегә кияүгә бирергә ничек риза була алдыгыз? — дип сорыйлар шагыйрьдән.

— Җан дошманымнан ничек тә булса үч алырга кирәк иде бит миңа! — дип җавап бирә шагыйрь.

Газетада хәбәр чыккач

Уильям Фолкнерга Нобель премиясе тапшырган вакытта бер хәбәрче аңа мондый сорау биргән:

— Сез хәзер нәрсә эшлисез?

— Утын кисәм, — дигән әдип.

Шушы җавап газетада басылып чыга һәм шуннан соң әдипкә мондый бер хат килә: «Сез утын кисәсез икән һәм күптән түгел утыз мең доллар акча көрәп алгансыз, дигән хәбәрне укыдым. Әйдәгез, утынны бергәләп кисә башлыйк! Бу эштә минем бик зур тәҗрибәм бар...»

Имза

Язучы Марк Твенга бервакыт имзасыз хат килә. Хатта нибары «Дуңгыз» дип кенә язганнар. Икенче көнне язучы үзе чыгара торган газетада мондый җавап урнаштыра: «Гадәттә мин имзасыз хатлар гына ала торган идем. Кичә миңа хатсыз гына имза килде».

Юкка елаучылар

Яңа бер симфониясен тыңлаган кичәдә, Бетховенны котларга дип, сәхнә артына берничә тамашачы керә.

— О, маэстро, сезнең көйне тыңлаганда мин эреп китә яздым, менә хәзер дә әле елаудан туктый алмыйм! — ди шулардан берсе.

— И кешеләр! Мин бит музыканы ул көрәшкә әйдәсен дип язам, ә алар елап утыра икән, — ди композитор.

Шагыйрь кичергән хисләр

Көннәрнең берендә Пушкин Царское Селода Николай патшаны очраткан.

— Я, әйт инде, нинди хисләр кичердең соң шул чакны? — дип сорыйлар аңардан.

— Бөтен кан тамырларыма үтеп кергән әшәкелекне сиздем,— ди шагыйрь.

Тыйнаклыкка өндәү сүзе

Бер мактанчык аристократ үз ата-бабаларын чиксез зур данлы итеп шапырынып сөйләгәндә, бөек инглиз сатиригы Джонатан Свифт моңа әйтә икән:

— Сезгә карап торганда, нигәдер, мин гел бәрәңге турында уйлыйм.

— Ә ни өчен бәрәңге турында?

— Чөнки аның кешегә файдалы бөтен нәрсәсе җир астында була бит, — дигән Свифт.

«Төстәш»

...Неапольдан Италиянең төньягына барышлый, Максим Горький бер шәһәрдә: «Бүген «Тормыш төбендә» пьесасын, режиссер буларак, автор үзе куя», дигән бик гаҗәп бер афиша күрә. Искиткеч кызыксынып, әдип спектакльне карарга була.

Беренче актган соң, тамашачылар чакыру буенча, сәхнә алдына... Горькийның төстәше килеп чыга: өстендә кыек якалы күлмәк һәм ул, башын түбән иеп, залга рәхмәтләр яудыра.

Гаҗәпкә калган Горький сәхнә артына юнәлә, үзенең төстәше кем икәнен беләсе килә.

Ә төстәшнең исә кинәт котлары чыга. Горькийдан ул үзен фаш итмәвен ялварып үтенә башлый, үзенең күп төрле язучылар булып киенә, буяна-бизәнә алу «һөнәре» барлыгын әйтә.

ӘДӘБИЯТ һӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

ШИГЪРИЯТ ТУРЫНДА ЗУР СӨЙЛӘШҮ

Смоленск жире — Мәскәү капкасы. Дошманнарга каршы аяусыз көрәше белән тарихта дан алган изге жир: Смоленск жире — рус поэзиясенә Александр Твардовский, Михаил Исаковский, Николай Рыленковларны биргән як. Батыр һәм матур тарихлы менә шул җиргә Россия шагыйрьләре җыелып, житмешенче еллар поэзиясе турында зур әдәби сөйләшү алып бардылар. РСФСР Язучылар союзы идарәсенең декабрь аенда уздырылган күчмә пленум утырышларында М. Горький исемендәге премия лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким катнашты һәм бүгенге поэзия турындагы фикерләре белән уртаклашты. А. Твардовский укыган Смоленск педагогия институтына мемориаль такта кую тантанасында булды, заводларда һәм культура йортларында эшчеләр белән очрашты.

МӘСКӘҮ НӘШРИЯТЫНДА

Татарстан язучылар союзы правленнесе председателе Гариф Ахунов Мәскәүнең «Современник» нәшриятында булды һәм РСФСР халыклары әдәбиятына багышланган редакция советы утырышында катнашты. Утырышта алдагы ел планнары тикшерелде, нәшриятның 1975 елгы планы расланды.

ШАГЫЙРЬНЕҢ ХЕЗМӘТ БӘЙРӘМЕ

16 январьда Казанның Актерлар йортында күренекле татар совет шагыйре Шәйхи Маннурга 70 яшь тулган көн тантаналы рәвештә билгеләп үтелде. Ярты гасырга якын иҗат гомерендә халкыбызга бик күп шигырьләр, поэмалар биргән, «Муса» романын, «Агымсуларга карап» повестен язган, балаларга күңелле әсәрләр бүләк иткән, рус әдәбияты жәүһәрләрен татарчалаштырган язучыны иҗат уңышлары белән тәбрикләү өчен бирегә язучылар, партия-совет работниклары, якташлары һәм авылдашлары, күп санлы әдәбият сөючеләр килгән иде.

Кичәне Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты шагыйрь Илдар Юзеев ачты. Шәйхи Маннурның иҗат эшчәнлеге турындагы докладны Татарстан язучылар союзы правлениесе председателе Гариф Ахунов сөйләде.

Партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре Мирзаһит Фәтхиевич Вәлиев, партиянең Мамадыш район комитеты секретаре Нәжип Ганиев, шагыйрь туган «Чулпан» колхозы председателе Галимжан Җиһаншин, егерме елдан артык сыер савучы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән Фәүзия Шәфигуллина, китапханә мөдире Вәсига Зәйнетдинова, Гайҗан бабайның оныгы, алдынгы механизатор Хуҗаҗан Газизҗанов, Муса Җәлилнең көрәштәше Фәрит Солтанбеков, күп санлы иҗат оешмалары, эшче коллективлары юбилярны иҗат уңышлары белән котладылар, истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

Кичә зур концерт белән тәмамланды. Тамашачылар Шәйхи Маннур сүзләренә язылган жырларны, аның шигырьләрен, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры һәм Г. Тукай исемендәге филармония артистлары башкаруында, яратып тыңладылар.

*
* *

Татар совет әдәбияты өлкәсендә озак еллар уңыш белән эшләгән өчен һәм 70 яшь тулу уңае белән язучы **Шәйхи Маннур** СССР Верховный Советы Президиумының 1975 ел, 22 январь Указы нигезендә **Халыклар дуслыгы** ордены белән бүләкләнде.

*
* *

Шәйхи Маннурга 70 яшь тулган көн уңае белән Татарстан Дәүләт музеенда «Агымсуларга карап» повесте буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Конференцияне филология фәннәре докторы Хәмит Ярми алып барды.

*
* *

Шагыйрьнең иҗат бәйрәме аның туган районы Мамадыш культура йортында, Тулбай авылы китапханәсендә, республикабыз мәктәпләрендә һәм клубларында дәвам итте.

ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Январь ахырында Татарстан язучылар союзының Г. Тукай исемендәге клубында әдәби ел йомгакларына багышланган жыелыш булды.

1974 елда газета-журнал битләрендә басылган, аерым китап булып чыккан проза әсәрләре турындагы докладны язучы Мөхәммәт Мәһдиев ясады. Ул прозадагы тема төрлелеген билгеләп үтте. Әсәрләргә анализ ясап, аларның уңай һәм кимчелекле якларына тукталды. Прозаның үсеш тенденцияләрен ачарга омтылды. Докладчы хикәя жанрының артталыгына тукталып, Шәриф Камал, Фатих Хөсни, Газиз Мөхәммәтшин һ. б. хикәячеләрнең традицияләре онытыла баруын, узган елда истә калырлык хикәяләр булмавын әйтте.

Поэзия буенча докладны шагыйрь Гәрәй Рәхим ясады. Ул, поэзиянең төп герое — хезмәт кешесе, дип әйтте. Узган елда язылган иң уңышлы поэмалар һәм шигырьләр КамАЗ төзүчеләргә багышланган булуын күрсәтте. Өлкән буын шагыйрьләрнең яшьләрчә дәрт белән эшләүләрен билгеләп үтте. Шул ук вакытта кайбер шагыйрьләрнең ижатындагы ясалмалыкка тукталды, аның сәбәпләрен ачарга тырышты.

Драматург Юныс Әминовның узган елгы драматургия турында ясаган доклады да зур кызыксыну белән тыңланды. Бер ел эчендә драматургларыбызның 10 пьесасы сәхнәгә куелган, диде докладчы. Ләкин республикада сигез театр эшләп килгәнен искә алганда, моның бик аз булуын, театрларның яңа әсәрләргә мохтажлыгын канәгатьләндерә алмавын әйтте. Пьесаларга анализ ясады, уңай һәм кимчелекле якларын ачты.

Тәнкыйтьче Фарваз Миңнуллин әдәби тәнкыйть турындагы докладын, партиябез Үзәк Комитетының әдәби тәнкыйтьнең торышы турындагы карары республикабызда әдәби тәнкыйтьне нык жанландырды, дип башлады һәм тәнкыйтьчеләрнең, әдәбият галимнәренең бер ел эчендә басылган китапларына, мәкаләләренә, рецензияләренә анализ ясады. Бүгенге көн әдәбиятына караган мәсьәләләрне яктырткан тәнкыйть материалларының күбрәк басылуын билгеләп үтте.

Балалар әдәбияты турындагы докладны Шәһидә Максудова ясады. Ул татар балалар әдәбиятының бүгенге көн таләпләреннән артта калуын әйтте, аның сәбәпләрен ачарга тырышты.

Тәрҗемә әдәбият турындагы докладны тәрҗемәче Тәһир Нурмөхәммәтов ясады. Ул классик әдәбиятның татар теленә күбрәк тәрҗемә ителергә тиешлеген, моның өчен бездә тәжрибәле, сәләтле тәрҗемәчеләр булуын әйтте. Тәрҗемә ителгән аерым китапларга анализ ясады.

Рус язучылары ижаты турында язучы Марсель Зарипов доклад ясады. Аларның әсәрләрендәге уңышлы һәм кимчелекле якларга тукталды, заман темпыннан сүлпәнрәк баруларын әйтте.

Жыелышның икенче көнендә докладлар буенча фикер алышулар булды. Туфан Миңнуллин, Фатих Хөсни, Шамил Рәкыйпов, Аяз Гыйләҗев, Гәрәфи Хәсәнов, Марс Шабаев, Рафаил Төхфәтуллин, Разил Вәлиев, Флүн Мусин, Әдип Маликов, Ләбибә Ихсанова, Флера Әхмәтова, Рөстәм Мингалимовлар чыгыш ясадылар.

РСФСР Язучылар союзы консультанты В. В. Синицын һәм Татарстан язучылар союзы правлениесе председателе Гариф Ахунов алда торган бурычлар турында сөйләделәр.

Соңыннан КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин чыгыш ясады.

Ел йомгакларына багышланган утырышта ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев шагыйрь һәм прозаик Шәйхи Маннурга СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән Халыклар дуслыгы ордены тапшырды.

Әдәбиятка кагылышлы бу зур сөйләшүдә СССР Язучылар союзы, РСФСР Язучылар союзы, «Литературная газета» вәкилләре, газета-журнал работниклары да катнашты.

ДРАМАТУРГНЫҢ ТУГАН КӨНЕНӘ

1974 елның декабрендә Алабуга дәүләт педагогия институтының актлар залында әдип, драматург, галим Нәкый Исәнбәтнең тууына 75 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә уздырылды.

Кичәне татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире доцент Л. Арсланов алып барды. Нәкый Исәнбәтнең бай ижат һәм тормыш юлы турында докладны филология фәннәре кандидаты Ф. Урманчиев ясады. Филология фәннәре кандидаты М. Фәйзуллина Нәкый Исәнбәт белән очрашулары турында сөйләде.

Студентлар «Зифа» комедиясеннән өзекләр күрсәттеләр, Нәкый Исәнбәт сүзләренә язылган жырларны жырладылар, ул язган шигырьләрне, ул жыйган мәкальләр, табышмакларны сөйләделәр.

УДМУРТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНДА

Декабрь аенда ут күршебез удмурт язучыларының 10 съезды булып узды. Язучы Мөхәммәт Мәһдиев съездда татар һәм удмурт әдәбияты багланышлары турында чыгыш ясады һәм каләмдәш дусларны әдәбиятта ирешкән уңышлары белән котлады.

ДРАМАТУРГЛАР СЕМИНАРЫ

РСФСР Язучылар союзы, РСФСР Культура министрлыгы һәм Бөтенсоюз театр жәмгыяте актерларның Руза ижат йортында драматурглар семинары үткәрде.

19 январьдан башланган бу семинарда Бөек Жиңүгә багышланган пьесалар турында сүз барды. Семинарда шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеев катнашты. Аның «Бер гомерлек төн» дигән трагедиясе уңай бәя алды.

МӘСКӘҮ НӘШРИЯТЛАРЫНДА БАСЫЛДЫ

«Художественная литература» нәшрияты Шәрәф Мөдәрриснең «Сквозь пепел дней» дигән шигырь китабын басып чыгарды.

Шигырьләрнең тәржемәсен, шагыйрь турында кереш сүзне һәм китапның рәсемнәрен шагыйрь һәм рәссам Виктор Гончаров эшләде.

*
* *

«Современник» нәшрияты Мөхәммәт Мәһдиевнең журнал укучыларыбыз яратып кабул иткән «Фронтовиклар» романын «Большая земля под крылом» дигән исем белән чыгарды. Китапның тәржемәсен Е. Левакovская эшләгән.

*
* *

«Наука» нәшрияты «Веселая россыпь» дигән китап чыгарды. Бу китапның эчтәлеген язучы Гомәр Бәширов тарафыннан күп еллар буе җыелган, әдәби әсәр дәрәҗәсенә житкереп эшкәртелгән татар халык мәзәкләре тәшкил итә. Мәзәкләрне Г. Ладонщиков тәржемә иткән.

*
* *

«Просвещение» нәшриятында «История педагогики» дәреслегенең 4 нче яңа басмасы чыкты. Дәреслекнең авторлары: Н. А. Константинов, Е. Н. Медынский һәм М. Ф. Шабаева.

Бу китапта татар халкының атаклы галиме, педагогы һәм язучысы Каюм Насыйриның иҗат эшчәнлеге турында да материал урнаштырылган.

*
* *

«Советская Россия» нәшрияты Габдрахман Минскийның «Первая симфония» дигән китабын чыгарды. Бу җыентыкка язучының төрле елларда язылган унтугыз хикәясе тупланган.

КОНКУРСТА ҖИҢҮЧЕ

«Хезмәт кешесе — безнең заман герое» дигән девиз белән «Литературная газета» игълан иткән иң яхшы очерклар өчен конкурс 1974 елда да дәвам итте. Газета битләрендә бер ел эчендә басылган егерме очерк арасында язучы Марсель Зариповның «Мин аңламый торган Чигвинцев» исемле очеркы өченче бүләккә лаек дип табылды.

ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры халкыбызның батыр тарихын күрсәткән әсәрләргә зур игътибар бирә. Тамашачыларыбыз узган елгы сезонда Нурихан Фәттахның «Кол Гали» драмасы белән танышканнар иде. Театр коллективы январь ахырында драматург Туфан Миңнуллинның «Канкай углы Бәхтияр» пьесасы буенча эшләнгән спектаклен күрсәтте. Бөек крестьян восстаниесенең 200 еллыгына багышлап куелган бу спектакльдә Пугачевның якын көрәштәше, крестьян полковнигы Бәхтияр Канкаев ролен РСФСРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров һәм Татарстанның атказанган артисты Наил Дунаев башкаралар. Спектакльне сәхнәгә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты Марсель Сәлимжанов куйды. Оформлениеләр ТАССРның халык художнигы Мәэмүн Сүтюшев житәкчелегендә эшләнде. Костюмнар художнигы — Тавил Хажиәхметов, музыкасын Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мирсәет Яруллин язды.

*
* *

Качалов исемендәге рус драма театры тамашачыларга «Тапшырылмаган хатлар» спектаклен күрсәтте. Пьесаның авторлары Габдрахман Минский һәм Алексей Найденов. Галия ролен Кара-Гяур, Искәндәр ролен В. Косенков, Вәли ролен ТАССРның атказанган артисты, Муса Җәлил премиясе лауреаты Ю. Федотов башкарды.

Спектакльнең оформлениесен О. Цельков эшләгән.

*
* *

Уфа тамашачыларына яңа ел премьерасы итеп М. Гафури исемендәге Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Башкорт дәүләт академия драма театры Илдар Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» исемле моңсу комедиясе буенча куелган спектаклне күрсәтте. Яңа спектакльдә төп рольләрне СССРның халык артисткасы З. Бикбулатова, БАССРның халык артисты Х. Фәхриев, БАССРның атказанган артистлары Г. Арсланов, Х. Яруллин, К. Нәзировлар башкардылар.

Спектакль тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителде.

ХОР ҖӘМГЫЯТЕНДӘ

Декабрь аенда Хор җәмгыяте Татарстан бүлеге идарәсенең отчет сайлау җыелышы булды, идарәнең яңа составы сайланды. Шагыйрьләрдән Зәки Нури, Мөхәммәт Садри, Зөлфәт Маликовлар идарә составына кертелде. Идарәнең житәкчесе итеп Казан дәүләт консерватория укытучысы В. Лукьянов сайланды.

МӘСКӘҮДӘГЕ КОНЦЕРТЛАР

Казанның Абдулла Алиш исемендәге Пионерлар сарае хор коллективы (житәкчесе В. Лукьянов, хормейстеры Ф. Газизова, концертмейстеры А. Миркина) кышкы каникул көннәрендә Мәскәүдә Бөтенсоюз композиторлар йортында һәм Үзәк телевидение буенча концертлар бирде. Алар та-

тар композиторлары, дөнья классиклары һәм рус совет композиторлары әсәрләреннән зур программа башкардылар.

ЧИРЕК ГАСЫР

Шәһәребезнең Ленин исемендәге эшчеләр сарае каршында хор коллективы оештырылуга 25 ел тулды. Шушы еллар эчендә коллектив зур иҗат юлы үтеп, халык хоры исемен алды, Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты булды. Хор коллективы Татарстан композиторлар союзы белән, бигрәк тә композитор Бату Мулюков белән, иҗади элемтәдә яши. Бу данлыклы иҗат коллективы белән бик күп еллардан бирле республикабызның атказанган культура работнигы Суфия Шагиева җитәкчелек итә.

Февраль аенда Ленин исемендәге эшчеләр сараенда хор коллективы оештырылуга 25 ел тулган көн тантаналы рәвештә билгеләп үтелде. Язучылар, композиторлар, профессиональ җырчылар, күп санлы сәнгать сөючеләр бу кичәдә юбилярның иҗат юлы турында кереш сүз тыңладылар, аңа тәбрикләү сүзләрен җиткерделәр. Кичәнең икенче бүлегендә зур концерт булды.

БАКУДА КОНЦЕРТЛАР

РСФСРның халык артисткасы В. Шәрипова, Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең яшь җырчылары Т. Якупов һәм И. Шиһапов һ. б. Бакуда зур концертлар бирделәр. Концертларда Г. Сәйфуллин һәм Ю. Шәмсетдинов җитәкчелегендәге инструменталь ансамбль дә катнашты. Концертларны нәфис сүз остасы Ф. Юсупов алып барды.

Әзербәйжан тамашачылары татар артистлары чыгышыннан эстетик ләззәт алдылар.

ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе эстрада солисты **Зиннур Нурмөхәммәтовка** совет музыка сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен **Татарстанның атказанган артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен Казан дәүләт курчак театры артистларыннан **Фуат Таһировка Татарстан АССРның халык артисты дигән, Рәшидә Үтәевага Татарстан АССРның атказанган артисткасы** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

ИҖАДИ ОЧРАШУЛАР

Төрле иҗат оешмалары эшчеләр, колхозчылар, интеллигенция вәкилләре арасында еш булалар, үзләренең эш планнары белән уртаклашалар, иҗат «серләре» белән таныштыралар. Шундый күңелле очрашуларның берсе язу машиналары җайланмалары заводында булды. Эшчеләр янына Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары килгән иде. Театрның директоры Рәшидә Җиһаншина коллективның эше белән таныштырды. Комсомол комитеты секретаре Фирдәвес Хәйруллина яшь артистларның иҗаты турында сөйләде. Кунаклар завод коллективына үзләре куйган спектакльләрдән өзекләр күрсәттеләр.

*
* *

Казан циркы коллективы компрессорлар заводы эшчеләре белән очрашты. Казан машина төзүчеләре кунакларны алкышлап каршыладылар, цирк сәнгате турындагы чыгышларны, Рига шәһәре цирк мастерларының чыгышларын яратып карадылар.

*
* *

Башкортстанның Күгәрчен районы урта мәктәбендә язучы Мәҗит Рафиков белән очрашу булды. Ул мәктәп коллективын татар әдәбиятының җитмешенче еллардагы уңышлары, республикада чыга торган әдәби журналларның эше белән таныштырды. Әсәрләреннән өзекләр укыды.

Укучылар авылдаш язучыларын кызыксынып тыңладылар.

Мәҗит Рафиков Татарстанның «Крутушка» санаториенда ял итүчеләр белән дә очрашып, әдәбият турында кызыклы әңгәмәләр алып барды. Үзенең «Биш пуля» исемле хикәясен укыды.

*
* *

Кукмара районы, Зур Сәрдек мәктәбе укучылары һәм укытучылары шагыйрьләр Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һәм драматург Туфан Миңнуллиннар белән очрашып, әдәбият яңалыклары турында сөйләштеләр. Авторлар яңа әсәрләрен укыды.

АКТЕРЛАР ЙОРТЫНДА

*
* *

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге, сәхнә ветераннары һәм Актерлар йорты советлары РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Камал III нең тууына 75 ел тулуга багышланган кичә үткәрде. Камал III нең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеге турында Татарстанның халык артисты Фатих Шәрәфиев сөйләде. Артистның замандашлары Риза Ишморат, Ширияздан Сарымсаков, Касыйм Шамиль-

скийлар үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар. Соңыннан үзешчән сәнгать артистлары зур концерт бирде.

*
* *

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры солисткасы Әлфия Заһидуллинаның иҗат кичәсе дә Актерлар йортында уздырылды. Бу кичәдә артистка рус, татар совет композиторлары, чит ил композиторлары әсәрләреннән ариялар, романслар һәм җырлар башкарды. Кичәне Рәмзия Такташ алып барды.

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Декабрь аенда драматург Юныс Әминовның «Сафура буранлары» исемле яңа комедиясе тикшерелде. Әсәр сәүдә хезмәткәрләре тормышына, мораль-әхлак темасына багышланган. Фикер алышу вакытында Сәет Кальметов, Сажидә Сөләйманова, Гамил Афзал, Әдип Маликов, Аяз Гыйләҗев һ. б. пьесага нигездә уңай бәя бирделәр, аны камилләштерү буенча кызыклы фикерләр әйттеләр.

*
* *

Декабрьның икенче яртысында Баулы районында, Әлмәт бүлеге язучылары катнашында, татар әдәбияты көннәре үткәрелде. Язучылардан Сәет Кальметов, Сажидә Сөләйманова, яшь язучы Альберт Хәсәнов, яшь шагыйрь һәм үзешчән композитор Разим Вәлиуллин беренче көнне район культура работниклары алдында чыгыш ясадылар. Алар үзләренең әсәрләрен укыдылар, тыңлаучыларны әдәбият яңалыклары белән таныштырдылар. Язучылар 9 көн эчендә Кызыл Яр, Дым-Тамак, Кәрәкәшле, Бәйрәкә, Бәйрәкә Тамак, Иске Урыссу, Исергәп авылы клубларында, Баулы, Урыссу поселоклары культура сарайларында, мәктәпләрдә, терлекчелек фермаларында — барлыгы 14 очрашу үткәрделәр, һәркайда китап сәүдәсе оештырылды.

*
* *

Әлмәт районы, Яңа Кәшер урта мәктәбендә язучылар белән очрашу кичәсе булды. Юныс Әминов, Клара Булатова, яшь шагыйрь Рәшит Бәширов укучыларга хикәя һәм шигырьләр укыдылар, аларның күпләгән сорауларына җавап бирделәр. Укучылар Юныс Әминов пьесаларыннан өзекләр күрсәттe.

*
* *

Рафаил Төхфәтуллинның «Йолдызым» повесте буенча Әлмәт шәһәренең 2 номерлы китапханәсендә, Шамил Бикчуринның рус телендә басылган «Каты токым» романы буенча Лениногорск нефть техникумында китап укучылар конференцияләре үткәрелде. Конференцияләрдә бу авторлар үзләре дә катнаштылар һәм сорауларга җавап бирделәр.

КАМАЗДАШЛАР

НӘҖИП ҖИҺАНОВ музыкасы

РЕНАТ ХАРИС сүзләре





Без җыелдык Камага,
Чаллы дигән калага.
Алып килде безне монда
Хыял яктырткан юллар,
Тотындык зур төзелешкә
Яшьләрчә җиңел кулдан.

К у ш ы м т а.

Рус, татар, башкорт дуслар,
Украиннар, чувашлар,—
Менә дигән юлдашлар,
Хәзер без камаздашлар,
Хәзер без камаздашлар.

Без эшлибез Камада,
Чаллы дигән калада.
Яшьлегебез мәйдан тота
Халык, заман каршында.
Ватаныбыз нәрсә кушса,
Без үтәрбез барысын да.

К у ш ы м т а.

Без калабыз Камада,
Чаллы дигән калада.
Үзебез салган йортларда
Яшьнәп яшисе килә.
Соклансыннар безгә карап:
Нинди тату ганлә!

К у ш ы м т а.

Бәясе 50 тиен
Цена коп.

КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210